# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1990



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**1990**

**4**

**(810)**

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

К. СИБГАТУЛЛИН. Таныш кеше. *Шигырьләр* . 3
Р. ГАТАУЛЛИН. Әдәби кичәдән соң... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Т. ӘЙДИ. Елан угы. *Роман* . . . . . . . . . 12
К. МОСТАФИН. Эзлибез... *Шигырьләр* . . . . 85
Н. ИЗМАЙЛОВА. Язын. *Шигырьләр* . . . . 88
Г. ТАВЛИН. Афәт. *Роман* . . . . . . . . . 91

ОСТАХАНӘ

С. ЗЫЯТДИНОВА. Хөкем. *Хикәя* . . . . . . . 143
Г. ШӘРӘФИ. Хисләргә тирәнлек бир, каләм! . . 148

ПУБЛИЦИСТИКА

Без бик озак көттек. *(Татар иҗтимагый үзәге рәисе М. Мөлеков белән әңгәмә)* . . . . . . 150
Ә. МӘХМҮДОВ. Үагәреш булырмы? . . . . . . 158

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Талант — милләтне күтәрә! . . . . . . . . . . . . . . . . . 163

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тукайлар рухы. *(Шагыйрь М. Әгъләмов белән әңгәмә)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Т. ГАЛИУЛЛИН. «Йолдызлар җитә һәркемгә...» 173

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Р. НӘФЫЙКОВ. Тукай һәм хатын-кызлар . . 179

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . 182

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . . 187

Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . 189
Безнең календарь . . . . . . . . . . 189
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Т. АЙДИ «Жало змеи»; окончание романа Г. ТАВЛИНА «Рок». Стихи К. СИБГАТУЛЛИНА, Р. ГАТАУЛЛИНА, К. МУСТАФИНА, Н. ИЗМАЙЛОВОЙ.
«Литературная мастерская»: рассказ С. ЗИЯТДИНОВОЙ «Суд» анализирует писатель Г. Шарафи.
«Публицистика». «Мы очень долго ждали». Беседа с председателем Татарского общественного центра М. Мулюковым.
Статья А. МАХМУДОВА «Будут ли изменения?».
«Острая проблема»: статья Ш. АХМАДУЛЛИНА «Талант — гордость нации».
«Литературная критика». Беседа с поэтом М. АГЛЯМОВЫМ. Статья Т. ГАЛИУЛЛИНА «Звезды достаются каждому».
«К истории культуры»: статья Р. НАФИКОВА «Тукай и женщины». Слово читателя. Отрывки из писем.
Навыки чтения на основе арабской графики.
В номере отмечаются 60-летие И. Ахунзянова и Т. Нурмухаметова. Дневник культурной жизни.
На наших обложках — эпиграфические памятники периода Казанского ханства (1530 г.); лауреат государственной премии Татарии им. Г. Тукая, писатель Г. Ахунов.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 6.02.1990 ел. Басарга кул куелды 27.03.1990 ел. ПФ 05194. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учети.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83944. Заказ Д-61. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

## ШИГЪРИЯТ

# Кадыйр Сибгатуллин

## Таныш кеше

Йөри кеше.
Башын күккә чөйгән.
Бакый Кояш кебек балкыган.
Әйтерсең лә,
кырык фил өстендә
кырык сандык килә артыннан.
Каян килсен?!
Бик күп булса, бәлки,
өч бүлмәле фатир алгандыр.
Йә,
йөрәге җитеп,
беренче кат
чит хатында куныл калгандыр...

Йөри кеше.
Борын җиргә тигән.
Хәсрәтеннән тәмам исергән.
Әйтерсең лә,
менә яңа гына
атарга дип хөкем ителгән.
Ник атсыннар?!
Үтерүче түгел.
Үз гомерен бирер хаҗәттә.
Килмәгәндер сагынып көткән кеше...
Бирмәгәндер дусты әҗәткә...

Шатлыгының,
кайгысының сере
билгеледер аның үзенә.
Йөри кеше.
Яши кеше шулай.
Бөтенесе — аның йөзендә.

*

Мин йокыдан әллә уяндыммы?
Ни кузгатты әле уйларымны?
Кемнәр йоклый? Кемнәр уйга талган?
Нигә дөнья болай тынып калган?

Үзәннәрне баскан тын моңсулык,
Йөрәкләрне кыса ямансулык.
Мескенлек бар урман шаулавында,
ник күренми бөркет тауларында?

Баскан идем менеп кыясына,
җылыныр дип җаным кояшында.
Кояшларын каплап тора болыт.
Явар кебек өскә кар-боз булып.

Бетми торган нинди сабырлык бу?
Җилкәләрдә нинди авырлык бу?

---

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН (1942) — *шагыйрь, «Әманәт», «Гамь», «Авазлар» һ. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән шигырь китаплары авторы. Чаллыда яши.*

Кайчан да бер төшеп калыр микән?
Я гомергә шулай барыр микән?

Әйтерсең лә, тоташ тере яра —
күккә ашып анда нәрсә яна?
Күтәрелеп офыкларга кара.
Офыкларда кояш баеп бара...

Офыкларда кояш баеп бара...

❁

Христиан чиркәү яңарта.
Ялтырый калайлары.
Көнләшеп карап торалар
мөселман балалары.

Чукынырга дип яңартмый.
Хикмәте диндә түгел.
Тарихны тарихка саклый.
Эш — синдә, миндә түгел.

Киләчәкне дә уйлаган —
христиан аңлаган шул...
Мөселманның яңартырга
мәчете калмаган шул.

❁

Мин генәме әллә фани җирдә?
Әллә син дә бармы?
Булсаң әгәр, бу фәкыйрең сине
эзләп бер табармы?

Яши миндә сиңа дигән бер сүз.
Инде күптән яши.
Таныр иде йөрәк, таныр иде...
Йөрәк һаман дәшми.

Сүзем сиңа кайчан булса да бер
барып җитәр микән?
Әйтелмичә шулай үзем белән
бергә китәр микән?

Ялгызмы әллә мин бу фани җирдә?
Бармы әллә син дә?..
Әгәр булсаң, сиңа гына дигән
бер сүз яши миндә.

## Есенинны уйлап

Килми кеше үзе теләп җиргә.
Үзе теләп җирдән китми ул.
...Я кайта алмый, артык ерак китеп,
я каядыр барып җитми ул.
Беркайчан да әле булганы юк,
беркемнең юк әле күргәне
кешеләрнең теләгәнчә яшәп,
теләгәнчә генә үлгәнен.
Дөнья белән килешүе кыен:
сатылырга кирәк,
сатарга...
...Утыз яшьтә телимени кеше
табутларга кереп ятарга?!
Синең кулга кайчак мылтык бирә:

үзеңә-үзең тәрә көпшәсен!
Мылтык тавышы инде шартлагач та
яшәүләрне әле көтәсең.
Тоттыралар кайчак кулга әлмәк.
Тик муенга гына такмыйлар.
Дөньялардан киткәч,
үзен-үзе
үтерүче диеп атыйлар.
Горур гына тумаган ул кеше,
үтерергә туган,
үләргә;
яшәү бәхетеннән «котылу» өчен
үлемнәре белән түләргә.

Яшәү, үлү яңа түгел, диеп,
әйтеп киткән идең син кичә...
Ул бүген дә шулай —
яшәү, үлү...
Үтерүләр дә шулай —
искечә!

*

Агым сулар ага.
Карап торам ярдан.
Су буйларын — камыш,
мине сагыш сарган.

Елга борылмалы.
Бәрелеп-сугылып ага.
Язмышлары шулай —
ярдан-ярга кага.

Китә алмый ярлар.
Туктый алмый су да.
Агымсулар моңлы
әллә инде шуңа?

Агар яңа сулар...
Үтәр көннәр, айлар...
Басып торыр һаман,
һаман шушы ярлар.

## Орган залында

Уе-гаме әле бар вакытта,
исән чакта хәсрәт-кайгысы,
тумышыннан килгән моңнарына
була алмас кеше ваемсыз.

Тальяннарда безнең үз моңыбыз.
Таныш моңнар яши курайда.
Кубызлары,
думбралары якын,
бертуганнар уйный сорнайда.

Бу кемнеке?
Орган залларына
тыннарымны кысып керәм мин.
Бу кемнәрнең сулышлары икән,
җан авазы икән кемнәрнең?

Гасырларның бәгырь төпләреннән
ишетелә икән бу аваз.
...Күңелләргә көзләр кереп тула,
күңелләргә кереп тула яз.

Авыруга сихәт булып керер,
үләр җирдән кабат яшәтер.
Җирнең генә моңы түгелдер бу,
безгә шулай күкләр дәшәдер.

Бар халыкның җанын
ничек итеп
тетрәндерә икән бу кадәр?!
Үткәннәрдән...
Киләчәктәндер бу...
Мәңгелектәндер бу моң-хәбәр!

Яратуның күзе сукыр, диләр.
Хаклык була халык сүзендә.
Кемнәр белсен аны?
Аңлап булмый
мәхәббәтнең әле үзен дә.
Күреп киләме ул, күрмиме ул?
Күрәбезме әллә аны без?
Шуны гына беләм:
ул кагылса,
өр-яңадан туа җаныбыз.
Йөрәкләргә юллар бик әйләнгеч.
Ә ярату — туры юл таба.
Мәхәббәтем икән — килсен әйдә!
Ярар миңа — сукыр булса да...

Минем шатлык белән шатланма син,
кайгырма син минем кайгыдан.
Йөрәгемә минем керерсең дә,
калырсың, дип, шунда... кайгырам.
Андый хәлләр була алмый, димә.
Була гына түгел, бар алар.
Мәхәббәтең булып керәләр дә,
яраларың булып калалар.

# Рәдиф Гатауллин

## Әдәби кичәдән соң бер ханымның хаты

Менә ни җитмәгән икән!

Сыендырган яшьлегемне
Илнең бер ерак төбәге:
Торыр җир, эчәр суым бар...
Сусаган ласа йөрәгем! —

Туган тел җитмәгән икән!

Сез, әдипләр, кереп, гүя
Гомерем чапкан вагонга,
Адашкан болан-җанымны
Алып чыктыгыз хак юлга! —

Миңа моң җитмәгән икән!

Сез төштегез станцада,
Сүнде күк вагон утлары...

Әмма күңелне мәңгегә
Балкытыр ялкын-уй алды! —

Гамь нуры җитмәгән икән!

Кайттым балачакларымда
Әнкәм көйләгән моңнарга.
Инде әзермен, тукталмый,
«Әллүки»ләрне җырларга! —

Газиз көй җитмәгән икән!

Гүя йоклап узган гомер
Үги язмыш поездында...
Туганнарым, сезне таптым,
Инде адашмам юлымда! —

Кәгъбәбез — Туган тел икән!

## Синең газәл

— Болытлар, юлыгыз кая, Казангамы, әйтегез?
Туган якларыма җиткәч, сагынганым әйтегез!

Болытлар, кадерлем нишли, күрерсез, бәлки, аны?
Һәр хәбәрен көтеп алам, — табынганым әйтегез!

Ул рухымны күтәрәчәк — сөюнең чын сакчысы!
Мин генәме, дуслары күп монда аның, әйтегез!

Тик һаман да шундый калсын, заман дип үзгәрмәсен:
Ак хыялларда балкытсын ихлас җанын, әйтегез!

Шау-шулы металл музыка, роклардан Моңны яклап,
«Биек тауга менәмсең» дип, еш җырласын, әйтегез!

Дөньясы шундый: күп бүген хиссезләр, эшкуарлар...
Биектә калсын — юлыннан тайпылмасын, әйтегез!

Болытлар, аны-дусымны тиз көндә күрерсезме?
Уралда калды ядкаре — сакланасын әйтегез!

---

Рәдиф ГАТАУЛЛИН (1941) — *шагыйрь, «Ирләр булыйк», «Чакыру», «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» һ. б. татар, рус телләрендә басылган уннан артык китап авторы. Казанда яши.*

## Уйланганда

*А. Г. кә*

Кырыс әкә! Нәкъ егерме ел элек
Бер хатында мине «искә алгансың»:
— Кара, нинди ялгыз ул, дусларсыз ул! —
Сиңа, миңа шундый язмыш язмасын!

Дус кадерен белмәс яшьтә булганга
Бу сүзләрең сәерсендерде мине...
«Нинди ялгыз... дусларсыз!» дип сыйфатлау —
Горур, мәгърур ул, дип раслау күк иде.

Аннан әйттем: шулай авыр язмышны
Укып белгән, бәлки, җиңел холкымнан?
«Ялгыз, дусларсыз...» Ялгыш та, язгым
Алып китмәсен берүк ил-йортымнан!..

Гомер бара... Уйланам да, шул сүздән
Егерме ел җыя алмыйм исемне:
Егерме ел башым тотам —
Кешеләр
Таш атып куган
пәйгамбәр шикелле!

## Аз яндык...

— Яздыгыз... Уч төбе кадәр дә
Ак килеш калмады ич сезнең... —
Түктекме шулай без, кәгазь, әйт,
Чамасын белмичә хис, сүзнең?!

Тумыштан ят җаннар аңламас...
Гомернең таңында ук мандык
Хыялны алсуга... Ә дөнья —
Утларда... Янганга без яздык!

Ялкын һәм афәтләр чорыннан
Ак килеш кем чыгар? Каралдык...
Гасырның нәкъ үзе — ысландык,
Тик кабат җыр белән агардык...

Мәдхия өченме бу гасыр?
Син, дөнья? Күп вакыт каргандык.
Аннары, тәүбә! дип, җыр яздык:
Гыйшкыбыз яңарттык — сафландык...

Гомер — ни? Ул — очкын, ил — учак;
Яндык шул, ничә көз... яз яндык,
Яратып бу кырыс дөньяны...
Яхшырак иттекме без аны? —
Юк икән, димәк, без аз яндык, —
Аз яздык!

❁

Исерткеч мушмула,
Лаванда исләре...
Ә диңгез һавасы?
Ә дулкын төсләре?

Цикада җырлары
Тынуга — төн узып, —
Әй сайрый кошлары
Шатланып, көнозын...

Розалар — куакта,
Зәйтүннәр яшь һаман.
Кар болыты кайчак
Күренсә дә таудан,
Яз һаман Кырымда —
Ноябрь аенда!

...Саулык эзли кеше
Ел буена монда.

Мин дә шат бу язга —
Бу җылы дөньяга...
Ә соң нинди бер кыл
Тетри әле җанда?

Йоклаган хәтерме
Уянып, чакыра
Уйланырга монда:
— Онытма ватаннан —
Бу гүзәл җирләрдән
Куылганнарны да, —
Беркатлы җан булма!

...Югыйсә, гамь эзләп
Йөргәннәр аз монда —
Гөл иле Кырымда!

❁

Нәркисләрең нигә төбәп карый?
— Югалтканнар булыр сезне, абый?!

...Югалдым ла үзем синең янда —
Хыялларда эреп, ал томанда...

Зәңгәр кичнең салкын, саф сулышы...
Кай арада хистән җан тулышты...

Исе, исе язгы бөреләрнең! —
Бөре кебек ачыла иреннәрең,

Пышылдыйлар, үртәгәндәй мине:
— Сезне, чынлап, көтәләрдер инде?..

Ә мин әле болытларда, күктә...
(Төшәргәме? — вакыт ник тиз үтә?!)

Ә ник кала алмыйм синең янда,
Яшьлегеңдә — биеклектә, язда?!

— Ястык кадәр булсын, язгы бозга —
Мавыгуга! — куркам таянырга!...

Хыяллардан чынлык күпкә үзгә! —
Шундый сүзләр укыйм синең күздә.

Каян бөек Гакыл япь-яшь кызда?

Ахры, мине Тормыш читләп уза...

Нәркисләрең кызгангандай карый:
— Сезне... Җирдә эзлиләрдер, абый?!

## Ләйләләр язса...

— Менә нindигә әйләнде дөньялар!
... Күптән үзгәрде син күргән гөлъялан, —
Аңа ул чак кем сокланып узмаган? —
Синең хакта сөйли ник гөлләр һаман?
Менә нindигә әйләнде дөньялар!

Син, озын чәчле, хыялый бер гашыйк,
Килдең дә бер ул яланга, сак басып,
Киттең үзең — гүя чынлыктан качып...
Хәзер аңлыйм: киткән алып хыяллар.
Менә нindигә әйләнде дөньялар!

Мин — ул чактагы «очынтык» кыз түгел,
«Биек янган салкын бер йолдыз» түгел.
Син хурлаганча, минме бер «таш күңел»? —
Тәкәббер яшьлегемнән оялам...
Менә нindигә әйләнде дөньялар!

Җирдә бар да Мәҗнүндәй гашыйклармы?
Ә сөйгәнен аңламаганнар азмы?
Их, дим, нигә Ләйләләр каләм алмый? —
Алар чын булганны язып чыксалар!
Менә нindигә әйләнде дөньялар...

Соңлап бәлки бу хисләрем уянган?..
Әйе, үзгәрде син сөйгән гөлъялан;
Анда, белдем: синдәй гашыйк булмаган.
Исән гөлләрем исеменнән мин язам:
Менә нindигә әйләнде дөньялар!

*

Иң матуры безнең авылда ла!
Ни җитми соң малай кешегә?!
Кызлар түгел әле кызыктырган:
Алма өлгергән, ул — күршедә.
(Иң тәмлесе, никтер, кешедә!)

Матур кызлар? Бездә алар да бар...
Белдек үскәч: балкый урамнар;
Кара: күрше авыл малайлары...
Имеш, инде егет булганнар! —
Алма түгел, хәзер кызлар күзли:
Алар әнә безнең урамда...

Ә кызлар ник авылдашларына —
Бергә үскәннәргә карамый?!
Шул килмешәк малайларны сайлый,
Ә без?
Кай җиребез ярамый?!
Барыйк без дә күрше авылга соң —
Анда да бит кызлар бар әле...

Алмаларын ашап үстек, инде
Кызларга сүз кушып өйрәник...
Үзебездә иң-иң матур кызлар! —
Әллә яшьлек, әллә юләрлек,
Без — читләргә, читләр — безгә йөрде...
Тагы да читтән сөеп, өйләндек!

Калада мин.
Яшим тугыз катлы,
Авыл сыяр йортта...
Күршедә —
Ундүрт катлы... Уллар, кызлар үсә —
Безгә охшамаган берсе дә:
Әллә күрә белмим... Мәхәббәт тә,
Яр сайлау да хәзер башкача...
Әйтер бераү:
Атом гасырында
Хыял, Хискә — Акыл баш laca!

Әмма
Яши безнең йортта яшь бер малай,
Хыялында ул бер шаһзадә!
Бәхетен эзли һаман күршедән ул:
Алтын чәчле яры дәшә аны
Алтын алма үскән бакчадан.

Шул «башсыз»га көч бир, әй, табигать!
Бәлки соңгы Хыял Гөлен — анда?!
Сакла аның бәхетен, таш кала!

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Тәүфикъ Әйди

# ЕЛАН УГЫ

РОМАН

1



Ишек кинәттән төбенә кадәр каерылып ачылды. Бусагада баштанаяк күн кием — тужурка, галифе, фуражка һәм итекләр кигән баһадир гәүдәле бер ир-егет пәйда булды. Бил каешына уңда — инглиз маузеры, сулда төрле асылташлар белән бизәкле кәкре Бохара кылычы аскан үтә сугышчан кыяфәтле кешене күргәч, бүлмәдә утырган киң маңгайлы чекист урыныннан сикереп торды. Якыннан таныш булмаса да, калку күкрәкле, юан муенлы, тыгыз мускуллы бу пәһлеванның Республика хәрби комиссары икәнлеген ул бик яхшы хәтерләп калган иде. Төнге кунак исә, уң кулын ишек тоткасыннан ычкындырмастан һәм сулы белән икегә бөкләп тоткан камчысын күнитек кунычына суккалап, бер мәл бүлмәгә күз йөгертеп алды, аннары гына исәнләшеп:

— Мин — Шиһабетдинов,— диде.— Ә сез кем буласыз?

— Фарукҗан Байкучатов.

— Бүген Чекада сез дежурмы?

— Әйе.

— Постта торучыларыгызны мин хәзер үз сугышчыларым белән алыштырам.

— Ихтыярыгыз. Гарнизон башлыгы сез ич, ничек кирәген үзегез яхшырак беләсездер.

— Нинди дә булса аңлашылмаучылык килеп чыкса, туп-туры үземә шалтыратыгыз.

— Тыңлыйм, иптәш комиссар!

Шиһабетдинов аның озын төз гәүдәсенә кара калын кашлары астыннан сынап бер генә күз салды да чыгып китәргә җыенды, әмма шулчак ниятен үзгәртеп, өстәл янына килеп басты һәм Фарукҗанга янә бер җитди караш ташлады. Аннары Байкучатовның тыгыз иңнәренә, беләкләренә кагылды, яшь егетнең устав таләп иткәнчә үрә катып торуына игътибар итепме, елмайды һәм:

— Кайда хезмәт иттегез? — дип сорады.

---

Тәүфикъ ӘЙДИ (1941) — *әдип, «Божра», «Кайда да кадерле», «Тылсымлы көч» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

Кыскартып басыла.

— Австрия фронтында.
— Революцион хәрәкәттә күптәнме?
— Унҗиденченең февралендә солдат депутатларының полк комитетына, аннары дивизия ревкомына сайландым.
— Партиядә кайчаннан?
— Былтыр кердем.
— Монда ничек килеп урнаштыгыз?
— Үзәк Комитет күрсәтмәсе буенча. Татарстанның Тәтеш кантокомы Төркестан фронты карамагына җибәргән иде. Бохара компартиясе ярдәм сорый дигәч...
— Әйбәт, туганкай, әйбәт. Тик болай ук үрә катып интекмәгез әле. Өйләнгәнме?
Байкучатов, утырырга базмыйча, аягүрә торуын дәвам итте. Ләкин хәзер инде ул Шиһабетдиновның тавышы дусларча яңгырый башлавын, кырыс карашы җылынуын, иптәшләрчә кызыксыну төсмере алуын тоеп, киеренке хәлдән чыкты, хәтта бераз кыюланып ук җавап бирде:
— Юк, иптәш комиссар. Вәгъдәләшкән кызым менә шушы якларда яшәргә тиеш, тик хәзергәчә күзгә чалынганы юк.
— Исән булса, табарбыз, туганкай. Монда кайсы бүлекне алып барасыз?
— Теркәү эшләрен. Әлегә нибары ике-өч шымчы гына хәбәр бирә, колач җәю кыен. Аннары... мине милли гаскәр берләшмәләрендә файдалануны күздә тотканнар иде. Монда исә...
Байкучатов үзен чын командирларча таләпчән, ләкин иптәшләрчә гади тоткан Шиһабетдиновка карата күңелендә ниндидер үз итү тойгысы яралуын тоеп, аңа четерекле вазифасының кыенлыкларын сөйләп бирергә, белмәгән нәрсәләрен киңәшергә талпына башлаган иде, тик хәрби комиссар үзе телгә килеп:
— Хикмәт кешеләрегез әзлегендә генә түгел, бар кадәресенең ышанычлы булуында,— диде.— Югыйсә монда хәлләр катлаулы, күрәшнең кызган чагы. Сез иртәгә, бераз ял иткәннән соң, минем янга кереп чыгыгыз әле. Иркенләбрәк сөйләшәсе нәрсәләр бар. Әмма минем белән күрешәчәгегезне берәүгә дә ычкындырмагыз. Шул исәптән, Чекадагы иптәшләрегезгә дә. Аңладыгызмы?
— Әйе, иптәш комиссар.
Шиһабетдинов саубуллашыр өчен көрәктәй кулын биреп:
— Бохара хезмәт ияләренең үтенече буенча монда ярдәмгә байтак татар егетләре килде,— диде.— Без, Фарукҗан якташ, игенче-диһканнар, һөнәрчеләр — бөтен юксыллар өметен акларга тиеш. Төрле коткыларга бирелмәстән, бары тик юксыллар хакын гына яклыйк. Сынатмыйк!
Хәрби комиссар давыл шикелле ничек ургылып килеп кергән булса, хәерле төн теләп, шундый ук тәвәккәл, кызу адымнар белән чыгып та китте. Фарукҗан, ишек ябылуга, тәрәзә янына барып басты. Баганадагы керосин фонаре якын-тирәгә кавын кабыгыдай сыек саргылт яктылыгын сибә, аның саран нурлары төшкән кәрвансарай ишегалдында иярле ике атны йөгәненнән тоткан бер гаскәри күренә иде. Йөзен танырлык булмаса да, буе-сыны һәм хәрәкәтләре буенча, Фарукҗан аны хәрби комиссар йомышчысы Рахманколга охшатты. Шул мизгелдә Шиһабетдинов капка артыннан берәүне ишегалдына чакырып кертте дә кәрвансарай сагына куйды, аннары элек каравылда торган солдатны һәм йомышчысын ияртеп чыгып китте дә, урам караңгылыгына сеңеп, шундук күздән югалды. Әле төн уртасы җитмәгән, сәгать унбер генә тулып килә иде.
Постларга кертелгән үзгәреш гадәттән тыш һәм сәеррәк тоелса да, Фарукҗан хәрби комиссардан моның сәбәбен сорарга базмады. Бәлки ул аңа ияреп ишегалдына чыгарга һәм Бохара республикасы хәрби

министрын озатып йөрүчеләрне үз күзе белән күреп, аларның барысын капка төбендә озатып калырга тиеш булгандыр. Әмма Чекада дежур торырга беренче мәртәбә билгеләнгән Фарукҗан, әллә яшьлеге һәм тәҗрибәсезлеге, әллә шәһәр иминлеге сагына баскан хәрби комиссар карамагындагы махсус отряд егетләренә артык ышануы аркасында, бу төндә җитди хәвеф-хәтәр булу ихтималын уйлап та карамады, яңадан өстәле артына килеп утырды да тыныч кына стенадагы картага төбәлде. Шиһабетдиновның: «Исән булса, табарбыз, туганкай»,— дигән сүзләрен кабат күңеленнән кичергәч, аңа бик рәхәт булып китте.

Төннең кара шәлен ябынгач, Бохара гадәттә иркән сулыш ала торган иде. Ишәк җигелгән бер күчәрле арбалар, зур-зур йөк чүмәләләрен аскан дөяләр кәрваны узган саен бөркелеп күтәрелгән көндезге тузан болыты тәмам басыла. Мич төбедәй кызган саргылт-соры биек дуваллар — балчык коймалар арасыннан сузылган тар урамнарга да хәл керә. Ыгы-зыгы басыла, арыклардан йөгергән су тавышы ишетелерлек талгын тынлык канатын җәя. Өлгерүе тәмам җиткән җимешләрнең хуш исләре бакчалардан урамга ташып чыга. Кояшны йөзем куаклары «дивары» каплаган әйваннарда — саф һавалы ачык верандаларда карт-коры рәхәтләнә. Салкынча төн бөтен гәүдәңне изрәтерлек, күңелләрне тынычландырырлык тансык ял бирә, көндезен маңгайлардан, беләкләрдән бәреп чыккан көмеш бөртекләр, ниһаять, очып бетә, йөрәкләр тигезрәк тибәргә тотына. Күкрәкләрне киңәйтә, сулышларны җиңеләйтә торган мондый хозур кичләрдә ут алып янә бер чәй табынына җыелучылар да булгалый. Шунда ипле генә гәпләр дә куерып киткәли иде.

Әмма быелгы көз Бохараның ата-баба заманыннан күнегелгән бертөрле сүлпән тормышына көтелмәгән кискен үзгәрешләр кертте. Моңа кадәр йөзләгән мәчет манарасыннан көйләп-көйләп моңлы мәкам белән әйтелгән кичке азан хәзер, йоладан баш тартырга яхшысынмаган төстә, генә, ягъни илһам-фәләнсез, тыйнаграк һәм кыскарак итеп үтәлә иде. Әллә инде хәвеф-хәтәрдән саклангандай, капкаларны эңгер-меңгердә үк шартлатып бикләү гадәткә керде, ут алуны инде әйткән дә юк, кичләрен бакчаларда яки әйваннарда гаилә белән чүкердәшеп хозурланулар да өреп очыргандай юкка чыкты. Давыл алдыннан кош-корт, киек-җәнлек ышанычлырак урынга сыенырга ашыккан шикелле, кала халкы да дүрт дивары эченә кереп посуны кулайрак күрә башлады. Хәтта терлек-туар авазлары да юашланды сыман, күктәге көмеш ай-йолдызлар да күренер-күренмәс кенә җемелдәп, тора-бара бөтенләй караңгылык эчендә эреп бетте.

Шәһәрдә шомлы, киеренке тынлык. Урамнарда төнге каравылчыларның һәм аларга баш миршабларның да эзе суынды, хәтта әмир сарае тирәсендә дә җан әсәре барлыгы абайланмады. Өч өлкән хатынын, йөз илле кыз белән җиде яһүд малаеннан гыйбарәт хәрәмен язмыш ирkenә ташлап һәм бары тик яшь марҗа бикәчен генә ияртеп, әмирнең башкаласыннан чыгып китүенә дә ай ярымлап вакыт узды. Бу юлы Ситтәрәи Маһи-һусага — үзенең җәйге утарына гына юнәлмәде ул, билгесез тарафка — очы-кырые күренмәгән Караком сахралары эченә кереп югалды. Моннан ике атналар элек халык вәкилләре Корылтае бер дә какшамас төсле тоелган Әмирлек урынына Бохара Халык Совет Республикасы корылуын игълан итте.

Әмир үзенең тәхетен ташлап качарга мәҗбүр булды. Әмма ул җылы оясыннан аерылганчы тугрылыклы түрәләренә, якыннарына корал өләшеп, революция ясаган халыкка каршы көрәшер өчен агулы коткы салырга өлгергән иде. Ныгытмасын штурмлаганда тукмалып бетмәгән гаскәрләрен, тиздән яңадан бер учка җыйнап юксылларның канын кояр өчен, аулаграк кышлакларга таратты. Төрмәләрдәге барлык җиңаятьчеләрне, кулларына корал тоттырып, шулай ук иреккә

чыгарды һәм тыныч илгә өстерде. Шымчыларын, куштаннарын, үзе кебек кеше җилкәсендә рәхәт күрүче бәк-морзаларын астыртын рәвештә һәм ачыктан-ачык җәдитләр, «карасөякләр» белән көрәш алып барырга рухландырды. Менә шунлыктан тирән тынлыкны әледән-әле ату тавышлары сискәндерә, дөм караңгылыкны кай арада янгын телләре ялый башлый иде.

Мондый чакларда шәһәрдә беренче булып ябык базар янындагы кәрвансарай хәрәкәткә килә иде. Аның бер канатында контрреволюциягә, спекуляция һәм саботажга каршы көрәшүче гадәттән тыш комиссия — Чека урнашкан. Яңа тернәкләнеп килә иде әле ул. Кайбер бүлекләре кәгазьдә генә яши — хезмәткәрләр җитешми. Булганнары да бу эшкә махсус әзерлексез, тәҗрибәсез яшьләр. Бүген төнлә кизү торучы Фарукҗан да нәкъ менә шундыйларның берсе иде.

Байкучатов бүген — егерменче октябрь төнендә булуы ихтимал барлык гадәттән тыш вакыйгалар турында беренче хәбәр алырга, хәвефле хәлләрдә кирәкле чаралар күрергә — кыю һәм җитез хәрәкәт итеп, контрреволюция казынуларына чик куярга тиеш иде. Менә ни өчен аның зәңгәр күзләре тонык керосин лампасы яктысында стенага эленгән шәһәр картасына әледән-әле төбәлә, куллары билендәге револьверына кагылгалый, сагайган колаклары тыштагы һәр тавышны аулый иде. Аның Чекада эшкә керешүенә генә түгел, Бохарага килүенә дә әле нибары өченче генә атна бара иде. Көтелмәгән яңа вазифасы да, шәһәр үзе дә Идел буендагы авылларның берсендә туып үскән Фарукҗанга үтә сәер, таң калырлык ят һәм серле күренде. Монда әмир сарайлары гына түгел, һәрбер бәк, морза, һәрбер һөнәрче һәм хәтта ялчы йорты да калын, биек дуваллар белән коймаланып алынганлыктан, шәһәр тоташ ныгытмалардан гына торган сыман тоелды. Монда тормыш, Идел буендагы калалардагы шикелле, завод-фабрикаларда, урамнарда һәм мәйданнарда — кеше күз алдында түгел, әнә шул ябык дуваллар эчендә ага иде. Дөрес, көндез җанланып ала торган базарлары, азан яңгыратып мөселманнарны үзенә җыйнаучы мәчетләре бар. Әмма Фарукҗан ничәмә ел мәдрәсәләрдә дини вәгазьләр тыңлыйтыңлый Коръән сүрәләре ятласа да, балачактан намаз укырга өйрәнсә дә, соңгы дәвердә галиҗәнап ак патша хакын яклап сугышка керүе, Австрия гаскәрләре яудырган ук-ядрә яңгыры астында еллар буе окопларда аунавы, аннары исә сыйнфый көрәш давылларына катнашып китүе аркасында, инде байтактан бирле мәчет сукмагының ни икәнен дә оныткан иде. Базар ягына килсәк, монда борын-борыннан хатын-кыз халкы аяк басмаган. Иптәшләренең сөйләвенә караганда, бу көннәрдә анда гомумән алыш-бирешнең коты киткән, сәүдәгәрләр сафы сирәкләнгән, шау-шу кими төшкән — данлы Бохара базарлары, укасы коелган калфак төсле, бәйрәмчә купшылыгын, төсләр һәм бизәкләр байлыгын җуебрак җибәргән иде.

Әмма стенадагы картадан шәһәр мәхәлләләрен күздән кичергәндә Фарукҗан бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлады. Аның исәбенчә, әнә шул мәхәлләләрнең берсендә әле һаман күңеленнән китмәгән Зөһрәгөл яшәргә тиеш иде. Моннан җиде ел элек Казанда танышкан кыз.

Ул чакта Фарукҗан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә кереп, бер кышта бишенче-җиденче сыйныфларны тәмамларга өлгергән, борын астыннан мыек тәртеп килгән шәкерт иде инде. Авылдан киеп килгән бишмәтен, җиңсез камзулын, мөселман ыштанын, читеген, мескен бүреген салып атып, ярыйсы гына ыспай пальто, укучылар кителе, озын балаклы чалбар, штиблет кигән, хәйран гына чәч тә үстергән, шунлыктан үзен инде тәмам «аурупалашкан» егет саный башлаган иде. Яңалыкларга омтылган үсмер Шәрык клубына йөрергә дә ияләшкән иде. Менә шундагы кичәләрнең берсендә Фарукҗан туткылрак йөзле бер туташка күз салды. Нәфис соры постаудан кофта-итәк киеп, ак якасына

килешеп торган тасма күбәләк тагып килсә дә, кызыкай бүтән гимназистка, курсисткаларга охшап бетмәгән иде. Калфак өстеннән бөркәнгән ак ефәк шәлен бөтенләй үк салырга җөрьәт итмәве, тирә-якка кызыксынып, әмма керфек астыннан тартынып кына каравы аның әле клубка беренче аяк басуы турында сөйли иде. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: Фарукҗан ике дә уйламый иптәшен ияртеп керде дә нәкъ шулар артындагы урынга утырды. Сүзләренә колак сала торгач, бу кызыкайның Аитова ханым мәктәбендә укуын һәм, хәтта, Ташкенттан килеп урнашуын да белеп алды. Аннары күзе төшкән кешесенең игътибарын җәлеп итәр өчен, иптәше белән пыш-пыш сөйләшә башлады. Билгеле, аларны бик тиз туктаттылар, тик шулай да кызыкайның артына борылып үзенә бер караш ташлавына иреште ул. Тәнәфестә Фарукҗан тагын да кыюлана төште, сылтавын табып сүз кушты һәм тыенкы гына утырган сөйкемле кызыкай белән аның иптәшен спектакльдән соң Акком урамына — өйләренә кадәр озата да барды. Әллә ни сүз булмады булуын, тик икенче кичәдә алар инде иске танышлар кебек исәнләштеләр.

Казан татарларын йокымсырап яшәүдән уяткан төрле лекцияләр оештырып, аларны әдәбият, сәнгать, дөньяви белемнәр белән сугара башлаган, танс, лото, тагын әллә нәрсәләре белән дан казанган Шәрык клубы моннан соң Фарукҗанга бигрәк тә ямьле, бигрәк тә кадерле урынга әйләнде. Әмма көннәрнең берендә малаеның чамадан тыш азып-тузып, «шиблит киеп, поп шикелле бер көлтә чәч үстереп чукынырга йөрүе», хакында каладан хәбәр алган ата кеше җир кипмәс борын мәдрәсәгә килеп кермәсенме! Әмере кыска булды аның: өйгә! Ярый әле шәһәрдә кирәк-ярак сатып алырга дип беразга тукталды, юкса Фарукҗан Зөһрәгөлне күрми-нитми генә китеп барасы икән. Атасы кибетләргә юл тотуга, егет аягы җиргә тими Аитова ханым мәктәбенә элдертте һәм күңелен кузгаткан кызыкайны дәрестән чакыртып чыгарды. Аның түгәрәк йөзенә, гаҗәпсенеп ачылган зур коңгырт күзләренә төбәлеп, исәнләшми-нитми тота-каба әйтә салды:

— Зөһрәгөл, вәгъдәләшергә килдем мин.

— Ни хакында?

— Ни... болай гына...— диде ул, үзе кинәт кызарынды, каушады.

Зөһрәгөл көлемсерәп һәм кызыксынып:

— Болай гынамыни? — дип кайтарып сорады.— Алайса нигә әле кинәт ду куптыгыз соң?

— Ашыкмый хәлем юк.

— Болай гына нинди вәгъдә соң ул?

— Мин сезгә йөзек алып килдем.

Зөһрәгөл аның сузган бүләгенә ни әйтергә белми аптырап карап торды, аннары:

— Миңамы? — дип гаҗәпләнде.

— Сезгә шул.

— Ничек инде...

— Онытмас өчен. Төсем итеп киеп йөрерсез дип!

— Берни дә аңламыйм, нәрсә булды соң сезгә?

Фарукҗан бер дә уйламаганда тирли башлады, шулай да сер бирәсе килмәде.

— Хәзер илгә кайтып барышым,— диде ул.— Безнең бик озакка аерылышуыбыз мөмкин. Тик мин көзен барыбер яңадан Казанга әйләнеп килергә тырышачакмын.

Кызыкай йөзекне алып, бүләкне әйләндергәләп карады да:

— Бик матур икән, рәхмәт! — диде. Аннары ягымлы елмаеп өстәде: — Тик үзем хәзер сезгә берни дә бүләк итә алмыйм шул.

— Аптырамагыз.— Фарукҗан аңа күзләрен тутырып карады һәм кыюлана төшеп әйтте: — Сез мине бары онытмагыз гына!

— Үзегез онытмассызмы соң?

— Минме? Мин Казанга килеп җиткәч үк сезне эзләп табармын. Көтегез генә!

Зөһрәгөл күзләрен яшерсә дә, җавапсыз калмады. Ихлас рәвештә:

— Тик көздән дә кичекмәгез,— диде.— Без иптәш кызым белән сезгә ияләшеп өлгердек инде.

Эченә җылы йөгергән Фарукҗан шундук балкып китте.

— Таш яуса да, әйләнеп киләм — вәгъдә. Әмма миңа иптәш кызыгыз бөтенләй кирәкми!

— Кызык.

Кыз кеше белән көпә-көндез ил-күз алдында озак серләшеп торырга ярамый иде. Теле белән дөнья гизәргә вакыты да тар, моңа осталыгы да чамалы. Атасының йомышларын йомышлап бетерү ихтималын гел истә тотканлыктан, Фарукҗан саубуллашу ягын карады.

Соңыннан ул җан аткан кешесен ут капкандай ашыгып ташлап китүе өчен торып-торып үкенде. Чөнки алдагы тормышы бер заман үзе бөтенләй ниятләмәгәнчә ага башлады. Башта «аурупа» киемнәрен салып ташлап, игенче камытына җигелергә туры килде. Көзен исә кәрәк-сәнәкләрне калдырып, бер тегүчегә өйрәнчеклеккә тагылды һәм авылдан-авылга гизеп көн күрергә кереште. Язга таба Себергә китеп, тимер юл салырга тотынды һәм шуннан солдатка алынды. Ул Казанга кабат әйләнеп килгәндә Аитова ханым мәктәбе Татар кызлар гимназиясенә әйләнгән, әмма анда Зөһрәгөл күренмәде шул инде.

Турысын әйткәндә, Зөһрәгөлнең укуын тәмамлагач, ата-анасы янына Ташкентка кайтуын фараз иткәнлектән, бик теләп риза булды ул партиянең кантон комитеты тәкъдименә. Шуңа күрә Төркестанга ашкынып, түземсезләнеп килде, шуңа күрә эшкә Ташкентта калырга тырышты. Мондагы шартларда кыз-кыркынны сорашып йөрүнең шик-шөбһә генә уятачагын һәм үзен дә, сөйгәнен дә уңайсыз хәлгә генә куячагын чамалап, уңае чыгу белән, ул аның атасын эзләп карады. Бер рус текстиль промышленнигының агенты булган ата кешенең Ташкенттан Бохара ягына күчеп китүен ачыклагач та өметен өзмәде. Хәзер инде Фарукҗан авыз ачып калмаска, ничек тә теләгенә ирешергә карар биргән иде. Менә ни өчен партия Үзәк Комитеты башка коммунистлар белән бергә үзен дә Бохарага җибәрергә ниятләвен белгәч, бары сөенде генә ул. Килү белән монда да Зөһрәгөлләр гаиләсенең эзенә төшәргә омтылды, әмма беренче талпынулар әлегә нәтиҗә бирмәде. Шәһәрне иркенләп айкап чыгарга кулы тимәде. Укымышлы, хәрби әзерлекле, Бохара халык революциясенә чын күңелдән бирелгән кешеләр җитешмәгәнлектән, аңа да берьюлы әллә ничә төрле эш йөкләделәр, дөнья шундый кайнаган чакта иптәшләреннән бер сәгатькә аерылып китеп торуы да кыен иде. Мондый хәлдә хәрби комиссарның аңа шәхсән булышырга җыенуына Байкучатовның җаны эрү гаҗәпмени?!

Ләкин Шиһабетдинов аны иртәгә кәләш эзләшер өчен генә чакырмагандыр ич? Очрашуны сер итеп калдырырга кирәклегенә аерым басым ясады. Димәк, җитди һәм эшлекле сөйләшү көтә аны. Бохара республикасын дошманнардан саклауны кайгыртучы кеше Чеканың сугышчан көчен, сәләтен һәм өлгерлеген күз уңында тотарга, аны сынап карарга, үстерергә, ныгытырга телидер. Яңа бүлекнең ниләр майтаруын, җыйнаган мәгълүматларын сорашыр. Менә шул чакта авызга су кабып тору да, артык лаф ору да Фарукҗанны хур итәргә мөмкин. Юк, юк, андый хәлгә калмас ул.

Байкучатов түрдәге сейфтан шымчыларның яңа хатлары тупланган папканы алып, һәр кәгазьне аерым-аерым күздән кичерергә кереште. Күзләрен йокы баса башлагач, урыныннан торып, оеган тәнен бөгеләсыгыла язып алды, аннары тагын укуын дәвам итте. Әнә шулай йокылы-уяулы килеш бүлек эшен бизмәнләп утырганда кинәт стенага эленгән телефон шалтырады. Трубканы алуга, кемдер үзенең исемен дә әйтеп тормастан:

— Шиһабетдинов үзен-үзе атып үтерде! — дип кычкырды.

— Кайда? Кайчан? Алло, алло...

Әмма бүтән һичбер җавап ишетелмәде, элемтә, балта белән чапкандай, кырт өзелде. Байкучатов трубканы куеп, каушаудан нишләргә белми, кобурасыннан револьверын тартып чыгарды. Йөгереп барып тәрәзә пәрдәсен ачты — кәрвансарай каравылына куелган кызыл гаскәри берни булмагандай үз урынында басып тора иде. Фарукҗан көнчыгышта, өлгереп җитмәгән карбыздай, сыек шәфәкъ шәүләсе җәелә башлаган офыкка карап: «Тагын кан!» дип пышылдады. Австрия фронты гарасатында ук хәтереннән бер дә китмәгән Әбүгалисина шигыре янә гөлт итеп аңында кабынды: «Тәнебез утыдыр, җаныбыздыр кан, нигә аның җае гүя бер зиндан? Нигә түгеләдер ул болай яман, нигә арзанайды әле газиз җан?».. Истән чыкмый торган юллар. Тик Байкучатов бу юлы мең ел элек язылган шигырь тылсымына бирелеп, уйга талып тормады, елдам гына ишеккә ургылды һәм револьверын һавага төбәп, чакмасына басты:

— Коралланыгы-ы-ыз!

## 2

Таң беленгәндә кәрвансарайдан, сабантуй чабышкыларыдай, ургылып чыккан алты җайдак Ширбәдәнгә — ныгытма тышындагы әмир утарына алып бара торган юлга төште. Аларның иң арттагысы — томырылган тимер-күккә атланганы Фарукҗан Байкучатов иде. Ачык изүдән бәреп кергән һава агымы тәнне өтәрлек дәрәҗәдә дымлы һәм салкынча тоелды. Ул, кителен төймәләргә теләп, тезгенен тартыбрак тотты. Хәер, аның йөрешен әкренәйтүе моның өчен генә түгел, оператив төркемне кая ияртеп барырга кирәклеген дә белми иде Фарукҗан. Күңелендә һаман көчәя барган хәвеф тә бәлки нәкъ менә шул билгесезлектән тугандыр. Чөнки, аның фикеренчә, гадәттән тыш вакыйга турында иң тулы хәбәрне башлап нәкъ менә ул ишетергә, бүтәннәргә ул белдерергә, чаңны беренче ул кагарга тиеш иде.

Дөрес, шау-шуны чыннан да Байкучатов алдан күтәрде. Ләкин шуннан арысы...

Чека хезмәткәрләре нигездә кәрвансарайда гына яшәгәнлектән, тревога аларны бик тиз аякка бастырды. Дежур бүлмәсенә барысыннан элек яшерен-оператив бүлек мөдире Юлтай Симиниев йөгереп керде. Ашыгыч килеп җитсә дә, хәрби киеме пөхтә һәм актык төймәсенә кадәр каптырылган, үзе яхшы ял иткән кеше тәэсирен калдырды. Аның татарчадан тыш казакъ, үзбәк телләрендә дә чатнатып сөйләшүен, таҗиклар белән дә рәхәтләнеп фарсыча гәп куертуын, Казалыдагы җәдит мәдрәсәләренең берсендә укытканлыктан, ярыйсы ук мәгълүматлы, шома егет икәнлеген Фарукҗан беренче очрашканда ук чамалап алган иде инде. Бу юлы да Юлтай ышанычлы атлап түргә узды да:

— Нәкәс җаннар тынгы бирмиме? — дип эндәште.

Әмма Байкучатов аңа җавап биреп өлгергәнче ишегалдында тагын аяк тавышлары, атлар пошкыруы ишетелде, аннары бүлмәгә баштанаяк коралланган ирләр — Бохара Чекасы председателе Эминев, агентура бүлеге башлыгы Нурморатов һәм тагын берничә хезмәткәр килеп керде. Йөрәге кымырҗыган Фарукҗан шундук үрә катып:

— Иптәш Эминев, әле генә телефоннан хәбәр иттеләр. Хәрби назыйр Шиһабетдинов үзен-үзе атып үтергән, имеш...— дип белдерде.

Йөзеннән кан качкан Чека председателе, Фарукҗанга колак салып торгандай күренсә дә, уе белән әллә кайда еракта иде, ахры. Ул, гомумән, каушап калган кешене хәтерләтте. Нурморатов исә итәкҗиңен җыйган, бәхетсезлекне тикшерергә күптән әзер кыяфәттә бүлмәдәгеләргә күз йөгерткәләп алды да:

— Иптәш Әминев, безгә кирәкле кешеләр барысы да килеп җитте шикелле,— дип искәртте.

— Бәхетсезлекнең гадәттән тыш зур вә җитди икәнлеген аңлатып торасы юктыр, иптәшләр,— диде Чека председателе.— Мин үзем монда калам, ә сез кичекмәстән вакыйга урынына юнәлегез. Оператив төркем җитәкчесе итеп Симиниевне билгелим. Нурморатов, Байкучатов, сез аңа булышырсыз, ярдәмчеләр алыгыз да юлга чыгыгыз.

Һәм менә алар юлда. Әмма Фарукҗан әле һаман исенә килә алмый бара. Беренчедән, бәхетсезлек булган җирне кемнең дә аңардан сорашмавы гаҗәп тоелды. Икенчедән, шактый еракта гы үз йортында яшәгән Нурморатовның ун минут эчендә кәрвансарайга килеп җитүе дә сәер иде. Револьвер тавышының аларга ук ишетелүе һич тә мөмкин түгелдер. Калын дивар, әллә ничә ишек артындагы кешегә ай-һай... Симиниевнең оператив төркемне иртәп алып баруы да шикле. Вакыйганы да, аның булган урынын да алар ничек Байкучатовтан яхшырак белергә тиеш соң әле? Телефоннан шулай ук хәбәр алганнармы икән? Алай дисәң, Нурморатовларда телефон юклыгы билгеле ич Фарукҗанга... Аннары... аның белән иртәгә көрешергә ниятләвен истән чыгармасаң, берничә сәгать кенә элек саубуллашып күздән югалган хәрби комиссар үзен-үзе һич тә болай атып үтерергә җыенган кешегә охшамаган иде. Сәер! Бәлки вакыйга нәкъ менә шулай серле булганга, фаҗигане шаһиты үзенең кем икәнлеген дә, кайчан шалтыратуны да белгертергә базмагандыр, хәвефле җирне атап күрсәтергә дә теләмәгәндер? Алайса ни дип шалтыратырга алынган? Танык кына булды микән ул? Күзгә төртсәң күренмәслек мондый караңгыда нинди очраклы шаһит ди ул? Очраклы кеше Шиһабетдиновны ничек танысын инде? Дошман дисәң, анысы хәбәр дә биреп маташмас иде, комиссарның дус-ише, танышы яки мәсләктәш сугышчысы исә үзенең кемлеген белдерергә тиеш. Ә бу телефон шалтыраткан ят кешенең үз-үзен тотышы акылга сыймый. Әгәр төп максаты бутау гына булмаса, әйе, әйе...

Фарукҗан әнә шулай баш ватып барган арада, алдагылар олы юлдан сулга каерылды һәм бераздан таң йокысына оеган кышлакка килеп керделәр. Тезгеннәр тартылды, тезелешеп чабып барган җайдаклар, буага очраган ташкын төсле, бергә укмашты, аннары биек дуваллар арасына кысылган тар тыкрык буйлап яңадан кузгалды һәм тиздән ачык капка янына җитеп туктады. Атлардан төшеп, ыгы-зыгы килгән кышлак халкын як-якка кысрыклап, берәм-берәм ишегалдына керделәр.

Әле көн туып җитмәгән, тирә-як куе томан эченә чумгандай тоела иде. Шулай да Фарукҗан ишегалдына аяк басуга, бер кырыйдагы ярым европача корылган озын йортны ачык шәйләде. Аның буеннан-буена иркен әйван сузылган, шул әйваннан йорт эченә керә торган ишекләр тезелешеп киткән иде. Монда аларны өч хәрби, шул исәптән, Шиһабетдиновның йомышчысы Рахманкол каршы алды һәм чекистларны уң яктагы кырый бүлмә янына алып килде дә:

— Мәет менә шушында,— дип юл бирде.

Оператив төркем килеп кергәндә бүлмәдә берәү дә юк, уңъяк стена буендагы квадрат өстәл өстендә керосин лампасы гына төтәп тора иде. Эскәтер-фәлән ябылмаган өстәл тирәсендә артсыз өч урындык. Бүлмәнең сул ягында алгы почмакта түгәрәк мич, арткы почмакта бер кешелек гади тимер караватъ. Монда игътибарны җәлеп итәрлек бүтән һичбер нәрсә күренми, тәрәзәсе юк, буялмаган такта идәненә келәм-фәлән җәелмәгән иде. Әгәр караватка ак җәймә җәелеп, ак тышлы мендәр куелмаган булса, бу бүлмәдә соңгы вакытта тере җан иясе яшәгәнлеген, гомумән, берәү дә исбатлый алмас иде.

Ак җәймә өстендә чалкан яткан хәрби комиссар күн итек кигән аякларын чалыштырып йокыга гына киткән кешене хәтерләтә иде.

Йөзендә җәфалану, күзән җыеру билгеләре дә күренми. Бары тик сул чигәсеннән мендәргә, аннан җәймәгә саркыган һәм идәнгә — бүлмә уртасына таба агып төшкән, шунда җәелеп каткан кан эзе генә... Кан түшәктә, суалчан шикелле, нәзек бер эз генә калдырган, ни стенада, ни җәймәдә тап-фәлән, чәчрәү-мазар күренми иде. Мәетнең уң кулы стенага орынып гәүдәсе буйлап сузылган, сулы караваттан асылынып төшкән, әмма идәнгә тимәгән иде. Сул кул бармаклары нидер тоткан, аны бары соңыннан гына ычкындырган төсле, бераз бөгелеп тора. Идәннең кан эзеннән кырык сантиметрлап арырак җирендә унатар-маузер аунап ята иде. Фарукҗан комиссарның үзенә кичтән таныш киемендә булуына, бары тик фуражкасы, инглиз маузеры, портупеясы, кылычы һәм камчысы гына юкка чыгуына игътибар итте.

Бүлмәгә кергә, Симиниев өстәлдәге лампаны кулына алып филтәсен рәтләде, аннары шуның белән һәр почмакны яктыртып карады да караватка тирәли әйләнеп чыкты.

— Кем уйлаган инде моны, кем уйлаган... Пуля, мөгаен, уң чигәсеннән кергән дә башын үтәли тишеп, сулыннан чыккан. Вакытсыз әрәм иткән үзен, сыйнфый җаваплылык тоясы урында...

Нурморатов идәндә аунап яткан әлеге маузерны иелеп алды да, ут яктысына якынрак килеп, патрон тартмасын тикшерде.

— Берсе җитми, бары берсе генә,— диде ул иптәшләренә карап.

Әмма Фарукҗан авыз ачарга ашыкмады. Яшерен-оператив бүлек мөдире Юлтай Симиниев бер үк вакытта Чеканың эш йөртүче секретаре да, бу вакыйганы инәсеннән җебенә кадәр ачыкларга җибәрелгән сугышчан төркемнең башлыгы да иде. Агентура бүлеге җитәкчесе Латыйфхан Нурморатов белән алар икесе дә оешкан көненнән үк Чекада бергә эшли башлаганнар, Шиһабетдиновны да, Бохара хәлләрен дә Фарукҗаннан күпкә яхшырак белергә тиешләр. Бәлки нәкъ менә шуңа күрә Юлтай һич тә аптырап калганга охшамыйдыр? Тәбәнәк буйлы йомры гәүдәсенә кайдан шул кадәр дәрт-дәрман туплагандыр, күяз кара мыекларын бөтергәли-бөтергәли бер иелә, бер тора, лампасын әле үзләренә ияреп кергән Рахманколга һәм аның иптәшләренә, әле комиссар яткан караваткa таба суза, таныкларга берөзлексез сораулар яудыра һәм нәтиҗәләр ясый иде.

— Мин бүлмәгә килеп кергәндә иптәш Шиһабетдинов гадәттән тыш дулкынланган, тынычсызланган хәлдә караватында кырын ята иде,— диде Рахманкол аның соравына.— Өстәл янындагы урындыкта бер хатын-кыз ишеккә аркасы белән борылып, нидер сөйләп утыра иде. Ишек ачылгач ук ул сүзен туктатты, Шиһабетдинов исә сикереп торды да миңа чыгып китәргә ишарә ясады. Артымнан: «Бераздан үзем чакырып алырмын, ял ит хәзергә», дип кычкырып калды.

— Шуннан соң кая киттегез? — диде Симиниев.

— Күнозын аяк өсте йөреп йончыган идем, күрше бүлмәдәге үз урыныма чыктым да аудым. Командирым эндәшүен яхшырак ишетер өчен, бүлмәм ишеген ачык калдырдым. Шулай ят тавышлар да тизрәк колакка керер, дидем. Хәтәр заман бит, тирә-якта безгә теш кайраучы дошманнар җитәрлек, комиссар иминлеге өчен беренче үзем җавап бирәм.

— Шиһабетдинов сезне кайчан үзенә йомышчы итеп алды?

— Август ахырында. Тик без аның белән күптәннән бирле якын тыныш идек инде.

— Ничек?

— Бөртекләп сөйләсәң, озынга китәр. Иптәш Шиһабетдинов Верныйга Беренче мөселман батальонын оештырып килгәч, мин дә кызылларга кушылдым. Иске таныш дипме, тапшырган берничә йомышын әйбәт үтәгәнгәме, ул мине гел үз тирәсендә тотты. Төркестан съездына депутат итеп сайлангач та, Җидесуда калдырырга теләмәде, Ташкентка ияртеп килде.

— Шундый якын кешегезне ничек саклап кала алмадыгыз соң?

Юлтай лампаны өстәлгә китереп куйды да һаман ишек төбендә таптанган Рахманколны якынрак килергә чакырды.

— Иптәш Симиниев, мин аң булыр өчен ишекне махсус ачык калдырдым лабаса инде,— дип дәвам итте йомышчы.— Бераздан әлеге хатын-кыз да әйванга чыкты. Күп тә үтмәде, комиссар бүлмәсендә ату тавышы яңгырады.

— Сезнеңчә, читтән һөҗүм ясалмады инде? — дип эндәште Нурморатов.

— Юк, юк. Маузерның күрше бүлмәдә шартлавын аерым-ачык ишеттем. Мин йөгереп кергәндә командирым тирәсендә дары исе дә аңкып тора иде әле. Артымнан ук кире атылып кергән әлеге хатын-кыз да аны яхшы тойгандыр.

Шунда Фарукҗан да:

— Сез килеп кергәндә комиссар япа-ялгыз шушы хәлдә ята идеме? — диде.

— Әйе.

— Караваты да шушы урында идеме?

— Әйе.

— Әлеге хатын-кыз кайда соң хәзер? — дип дәвам итте Фарукҗан.

— Белмим,— диде Рахманкол күңелсез төстә.— Иптәш Шаһабетдиновның җан биргән ачыкларга, тизгрәк бу хакта иптәшләргә хәбәр итәргә йөгердем. Без әйләнеп кайтканда әлеге хатын-кыз күренми иде инде.

— Кемнәр ул «без»?

Рахманкол бер мәл аптырап, өстәл тирәсендәгеләргә күз йөгертте, аннары гаепле кеше сыман:

— Үземне әйтүем инде,— диде.

— Монда кузна уены түгел, төгәл итеп җавап бирергә кирәк, диде Фарукҗан.— Әлеге хатын-кызны танып калдыгызмы соң?

— Юк. Мин беренче килеп кергәндә лампа филтәсе басып куелган, бүлмә шактый ук караңгы иде. Җитмәсә, аркасы белән утырган, йөзен бөтенләй күрмәдем. Икенче күрүемдә, мондый фаҗигагә юлыккач, башым-күзем тәмам әйләнде, тиешенчә игътибар итмәгәнмен.

— Ярар, ул хатын-кызны ачыклап, комиссарга кулләгә төшермик,— диде Симиниев.— Иптәш Шиһабетдинов үзен-үзе атканда чибәркәй әллә кайчан әйванда булган инде. Фельдшер, сез мәетне җентекләбрәк карагыз да, акт төзеп, беркетмә язырбыз.

— Кызу канлы, диләр иде аны.— Нурморатов башын селкеп куйды.— Тик мин болай уктыр дип уйламаган идем. Ниндидер бер хатын-кыз аркасында үзеңне корбан ит имеш, һич аңлашылмый.

Фельдшер лампаны кулына алып шулай ук караватт тирәли әйләнеп чыкты, аннары Симиниев сүзләрен раслап:

— Әйе, пуля уң чигәсеннән кереп сулыннан чыккан,— диде.— Бик тиз үлгән, канын күп югалткан.

— Арыслан кебек гайрәтле ир иде бит, нинди кызганыч,— дип уфтанды кызыл гаскәриләрнең берсе.

— Бу менә сезгә бик әйбәт сабак инде,— диде Симиниев акыл өйрәткән төстә.— Озын чәчләрдән һәрвакыт ераграк йөрегез!

Сәер дә, көлке дә тоелды бу сөйләшү Байкучатовка. Фаҗига аңлатылдымы, вакыйга урыны каралдымы инде шулай? Симиниевнең өстәлгә кәгазьләр таратып, язарга җыенып утыруын башкача ничек төшенергә соң? Гаҗәп тиз, искитмәле җиңел табылды түгелме соң йомгак очы? Әйтерсең, кәҗә бәтие генә аяк сузган! Югыйсә, кеше, аның да әле нинди — Республиканың хәрби министры һәлак лабаса. Фаҗигане болай өстен-өстен генә тикшереп нәрсә ачыклыйсың инде? Бәхетсезлекнең сәбәбен, һәлакәт шартларын өйрәнергә, төн караңгысына уралган афәтне зирәк эзләнүләр нәтиҗәсендә серле билгесезлек-

тән яктыга чыгарырга кирәкми микәнни?

Фарукҗан чекист иптәшләре Юлтай белән Латыйфханның, бигрәк тә аларга ияргән фельдшерның да ялгыш фикергә килүләреннән куркып, үз икеләнүләрен белдерергә кереште:

— Аның хатын-кыз аркасында харап булуын беребез дә өздереп раслый алмый ич әле.

— Синеңчә, ник үз-үзенә кул күтәргән соң ул алайса? — диде гаҗәпсенгән Симиниев.

— Үзен-үзе атуы да шикле әле аның.

— Шулаймыни? Арабызда менә кем иң зирәк икән ул!

Бүлмәдәгеләр барысы да Фарукҗанга төбәлде, Симиниев исә мыскыллы көлемсерәп, кәгазьләрен арткарак этеп куйды.

— Әйдә, әйдә, дәвам ит инде ачышыңны,— диде ул урыныннан кубып.— Алайса кайсы кабахәт аткан соң комиссарга?

Фарукҗан сорауга сорау белән җавап бирде:

— Ул үзен-үзе аткан икән, маузерын уң кулына тотарга тиеш булгандыр ич инде? Пуля уң чигәсеннән кергән, дип раслыйсыз түгелме соң?

— Әйе, әйе,— дип җөпләде фельдшер.

— Шулай икән, канның пуля кергән зуррак тишектән ага башлавы, караватның нәкъ менә уң ягында зуррак күлдәвек хасил итүе табигыйрәк булыр иде. Тик ул тарафта урын-җир дә, идән дә нигәдер бөтенләй буялмаган дип әйтерлек.

Симиниев көлемсерәвен сүндереп:

— Аның син әйткәнчә булуы һич тә мәҗбүри түгел,— диде.

Әмма Фарукҗан шик-шөбһәләрен әйтеп бетермәгән иде әле.

— Аннары,— диде ул,— уң кулы белән аткач, маузер нигә караватының сул ягына шуып төшсен икән?

— Дөрестән дә...

Кызыл гаскәриләрнең берсе Фарукҗан фикеренә кушылуын күреп, Симиниев тагын үртәлә башлады.

— Монысы инде хыял, юкка бәйләнү. Җан биргәндә кулын ничек селтәмәс адәм баласы?!

— Ә шулай да маузер комиссар гәүдәсенең йә уң ягына шуып төшсә, я күкрәгендә калса, дөресрәк, аңлаешлырак булыр иде,— дип сүзен бирмәде Фарукҗан.— Янә шуңа да игътибар итегез: стенага орынып яткан хәлдә уң кулы белән чигәгә ату җиңел эшме?

— Нигә мөмкин түгел ди ул? — Нурморатов белдекле кыяфәттә аңлата башлады: — Газапланмыйча, озак тинтерәмичә үләсең килсә, коралыңа иң яхшы мәрә — чигә.

— Ә сез дивар буена Шиһабетдинов шикелле ятып карагыз,— диде Фарукҗан кырыс кына.—Терсәк сузарлык чама да калмый лабаса. Маузер чигәгә түгел, үзеннән-үзе иякә яки бугазга төбәләчәк. Пуля да я җилкәдән, я баш түбәсеннән килеп чыгачак.

Бүлмәдәгеләр яңадан караватъ янына килеп, мәеткә күз салды. Хәзер инде барысы да Фарукҗан дәлилләренең нигезсез түгеллегенә ышана башладылар. Тик Нурморатов үз карашыннан ваз кичәргә теләмәде, ахры, Рахманколга:

— Командирың сулагай түгел идеме? — дип мөрәҗәгать итте.

— Юк.

Байкучатов йомышчының аптырашта калуын салкын кан белән күзәтте. Ул арада Симиниев караватка барып тотынды да:

— Егетләр, әйдәгез мәрхүмне бүлмә уртасынарак күчерик әле, карарга уңайлырак булсын,— диде.— Пуляның кайсы яктан керүен җентеклəбрәк ачыклыйк!

Оператив төркем җәрәхәт эзен кабат күздән кичергәч, пуляның уң чигәдән керүен яңадан расларга мәҗбүр булды. Шуннан соң Симиниев өстәлгә утырып беркетмә язарга, фаҗига урынын кәгазьгә

төшерергә кереште. Аның сызымында карават бүлмә уртасында сурәтләнүен чамалап алгач, Фарукҗан таң калып:

— Юлтай абый, ялгыш ясыйсыз түгелме? — диде.— Карават стена буенда тора иде ич!

— Ә хәзер бүлмә уртасында, күрмисезмени?

— Кире күчерик соң, ул үз урынына куелырга тиеш.

Симиниев бер дә көтмәгәндә чыгырыннан чыгып сикереп торды да:

— Кеше артыннан күзәтү нинди гадәт ул? — дип каләмен атып бәрде.— Син нәрсә, үз ихтыярыңны барыбызга да көчләп тагарга тырышасың? Мондый четерекле җинаятьләрне фаш итүдә ни тәҗрибәң, ни махсус әзерлегең булмый торып, ниткән акыл сату бу? Бәлки мин төрле вариантларны фараз итеп карыймдыр, ә син суларга да ирек бирми баш катырасың. Байкучатов, син миңа хәзер чынлап торып әйт әле: бу фаҗигане тикшерүгә кем җитәкчелек итәргә тиеш соң? Кем җаваплы? Бәлки сиңа күптән кәрвансарайга кайтып китү хәерлерәктер? Чека председателе үз кул астындагы гади бер хезмәткәре өчен күпме кизү торырга тиеш?

— Чыннан да, сез анда кирәгрәктер шул,— дип Латыйфхан да Юлтай сүзләрен куәтләде.— Монда инде бар да ачык, хәзер берәүгә дә куркыныч янамый. Шәһәрдә бу вакытта тагын нindидер көтелмәгән хәвеф-хәтәр килеп чыкса, үзегез уйлап карагыз, ике кулсыз калдырдык ласа рәисне.

— Ярар, киттем алайса. Дөрес сурәтләнсен дип кенә искәртүем иде, ачуланмагыз инде мин пешмәгәнне.

Нурморатов тынычландырган һәм үсендергән кыяфәттә Фарукҗанның иңенә кагылды да:

— Уяулыгыгыз бәлки башка җирдә урынлырак та, кирәклерәк тә булыр,— диде.— Беренче тапкыр һәлакәт урынын карарга чыгучы өчен сезнең уйлар, Фарукҗан энем, шактый кызыклы. Шулай ич, Юлтай әкә?

— Әһе... без аларны искә алырбыз, билгеле, әмма берәү дә, мавыгып китеп, үз туксанын гына туксан санамасын. Менә шул!

Симиниев көйгә килеп кире урынына утырды да:

— Кая, Рахманкол, бирерәк килеп, аңлатма языгыз әле,— дип боерды.

Фарукҗан монда үзенең тәмам артык икәнен тоеп, теләсә дә, теләмәсә дә, чыгып китәргә мәҗбүр булды. Бераз тынычлангач, янәшәдәге ишекне ачып, Рахманкол йоклаган бүлмәгә башын тыкты. Тышта сизелерлек яктыра төшсә дә, ишектән кергән зәгыйфь шәүлә генә мондагы күренешне яхшылап күздән кичерергә мөмкинлек бирми иде. Шулай да Фарукҗан чамалаган кадәресенә гаҗәпләнми булдыра алмады, чөнки бу бүлмә дә нәкъ хәрби комиссарныкына охшаган, миче дә ишек катында, караваты, өстәле, урындыклары да күршедәгечә тезеп куелган, тик түшәгенә генә ак җәймә ябылмаган иде. Бүтән бүлмәләрнең бикле икәнлеген ачыклагач, ишегалдын да тикшереп чыкты, аннары нindидер бүкән табып алып, шуны дивал буена тәгәрәтеп китерде. Бүкәнгә басып, аргы якка үрелеп караса, ни күрсен: кибетләр, чәйханәләр, ашханә-харчәүнәләр, һөнәрче остаханәләре тезелеп киткән олы гына базар мәйданы икән анда. Димәк, бу йорт — сәүдәгәрләр туктала торган кунакханәдер, дип уйлады Фарукҗан. Әйтәм аны Республика комиссары фатирына бер дә охшамаган шикелле тоелды. Хәрби комиссариат та, аның кечерәк гарнизоны да Ситтәрәй Маһи-һуса сарае янындагы шәһәрчектә урнашкан иде ич. Шиһабетдинов нәкъ менә шунда яшәргә тиеш иде ләбаса. Нindидер кышлактагы тәрәзәсез-нисез бүлмәдә түгел. Тәрәзәсез?.. Тукта!

Фарукҗан җәһәт кенә бүкәненнән сикереп төште дә йөгерәйөгерә әле яңа гына тәмсезләнеп ташлап чыккан бүлмәсенә — хәрби

комиссар фаҗигасен тикшерүче иптәшләре янына әйләнеп керде. Аның дөбер-шатыр кабат пәйда булуы өстәл башында каләм кыштырдатып утырган Рахманколны да, Симиниев белән Нурморатовны да сөендермәде шикелле. Ләкин алар барыбер кәгазьдән башларын калкытырга, мич буенда гәп куертучылар исә тынып калырга мәҗбүр булдылар.

— Җәмәгать, без Шиһабетдинов башына җиткән пуляны эзләмәдек ич әле. Ул үзен-үзе монда үтергән икән, пуля да шушы бүлмәдә табылырга тиеш...

Латыйфхан белән бер мизгел үзара карашып алганнан соң, чырае сытылган Юлтай тәмәке кабызды.

— Ә мин Мәккә, Мәдинәләргә иблисләр Каф тавын ишеп төшергән, дип торам. Дөнья куптарып йөрүче гыйфрит үзебезнең Байкучатов икән ләбаса.

Симиниевнең шаяртуына берәү дә көлмәде, елмаймады. Чекистларның берсе исә Фарукҗан фикеренә куәт бирде.

— Чыннан да, бик кирәкле дәлилдер ул, эзләп карыйк әле..

Җанланган кызыл гаскәрине Нурморатов төксе генә туктатты:

— Яктырсын әле, өлгерербез. Ә сез, Фарукҗан, баядан бирле әле һаман монда тулганасызмыни? Карагыз аны, соңыннан өстегезгә сүз килмәсен.

— Пуляны тапмый торып, акт язу ярамый, Латыйфхан абый.

— Ә бәлки без инде аны караштырганбыздыр? — диде Симиниев.— Баш бит бер синдә генә түгел. Үзеңне генә булдыклы күрсәтергә тырышуың миңа бөтенләй ошамый бит әле.

— Эзләргә онытмасагыз иде, дип кенә хафалануым инде бу.

Симиниевнең дә, Нурморатовның да үзен болай коры каршылавы Байкучатовта янә әллә нинди ризасызлык уятты. Атылган пуляны эзләмәүләре, ул турыда хәтта уйлап та карамаулары көн кебек ачык иде. Әмма барыбер тыныч кына акт язалар, кимчелекләрен искәрткән өчен җенләнәләр. Хәзер инде ул Рахманколга бирергә җыенган яңа сорауларын да авыз ачып әйтә алмады, кырт борылды да ишегалдына чыгып китте.

Капка төбендә атлар караштырып калган кызыл гаскәри Байкучатовка тезгенне тоттырганда:

— Җулдас командир, Бәкәне кем үтергән соң инде, белдегезме? — дип мөрәҗәгать итте.

— Нинди Бәкәне?

— Җулдас Шиһабетдиновны. Без, казакълар, аны үз итеп шулай олылый идек.

— Ә-ә-ә... Белмим шул әлегә. Ә сезнеңчә кем кул ягарга тиеш?

— Эт токымнары! Бәкә үтә гадел, үтә яхшы адәм иде. Ил батыры. Аның өчен дошманнан рәхимсез үч алырга тиеш без, гаепле кара еланның тамырын корытырга. Бәкә алтын адәм иде гуй!

— Кайдан беләсез?

— Минме? Ул миңа туганымнан, агай-энемнән дә якынрак кеше иде. Хәзер аннан башка нишләрбез инде без тагын?

Тавышы калтырана башлаган кызыл гаскәри, җилкәсенә борынын төрткән бахбайны куган булып, читкә борылды. Тик Фарукҗан аның бугазына тыгылган кайнар төерне үткәреп җибәрер һәм дымланган күз төбен яшерер өчен генә шулай итүен аңлап алды. Бу шулкадәр көтелмәгәнчә гади һәм эчкерсез килеп чыкты, Фарукҗан аның ихлас кайгыруын аңлады. Ә бит тегендә фаҗигане тикшерүчеләрнең берсе дә вакыйганы күңеленә болай якын алмады сыман? Ниһаять, җинаятьнең ачылуына омтылучы, шуңа ярдәм итәргә әзер кадерле зат аның алдында.

— Сез кем соң? — дип эндәште сөенеп киткән Фарукҗан.

— Амантай Туктаров.

— Кайда хезмәт итәсез?

— Бәкәнең махсус отрядында идем. Хәзер инде белмәймен ни буласын, безне таратулары да ихтимал.

Шиһабетдинов бүлмәсеннән тагын кемнеңдер тышка чыгуын абайлаган Фарукҗан калган гәпне бик кыска тотарга мәҗбүр булды.

— Курыкма, Амантай! — диде ул «син»гә күчеп.— Хәтерләп кал һәм онытма: Чекадан Байкучатов булам мин. Соңыннан үзем сине эзләп табармын. Комиссар фаҗигасенең серен, һичшиксез, ачарбыз. Бергәләп!

Ул яңа танышының кытыршы кулын дусларча каты итеп кысты да сикереп юртагына атланды һәм шәһәргә таба томырылды. Хәзер инде алсу шәфәкъ нурлары бөтен офыкка таралып өлгергән, тузанлы тар юл да, Бохараның саргылт-соры ныгытма диварлары да җайдакка бик яхшы күренә иде.



3

Фарукҗан биш-алты чакрым араны, тимер-күген ак күбеккә батырып, коштай очып кайтты. Билгеле, моннан соң аңа болай ук ашыкмаска да мөмкин, таң атканнан соң һушны алырлык тагын берәр нәрсә килеп чыгу ихтималы әзрәк иде. Хәер, аны алдагысы һәм билгесезе түгел, инде артта калганы, булганы, әмма әле һаман акылга сыймас яклары белән эчне тырнап торганы җилкетте шикелле. Әлбәттә, ул вакыйганы тикшерүгә җаваплы Симиниев Байкучатов ярдәменә бик мохтаҗ түгел. Хәтта аны бу эшкә катнаштырырга теләми бугай, бик әйбәтләп озатты ич әле менә кышлактан. Бәлки ул хаклыдыр да, мәхәббәт аркасында көндәше белән атышкан яки сугышкан, үзен-үзе харап иткән дуамаллар әзмени? Һәм, гомумән, дуамаллык микән мондый адым? Ничек аталса да, андый сәләткә Фарукҗан, мөгаен, ия түгел бугай. Әгәр Зөһрәгөл аны еллар буе көтеп алган булса, инде әнә-менә кавышып бәхеткә ирешәбез, дигән мизгелләре җитсә һәм нәкъ шул чак араларында көтелмәгән киртә калыкса, шик юк, Байкучатов та җебеп тормас, хәлиткеч адым ясарга омтылыр иде. Ләкин мәхәббәт колына әйләнеп, революциягә хезмәт итәргә тиеш газиз башкаеңны югалту чамадан тышрак мавыгу түгелме икән? Бигрәк тә Бохара мәмләкәте хезмәт ияләре сине шундый җаваплы урынга куйган һәм кирәксенгән чакта... Юк, Республика хәрби комиссары Шиһабетдинов, гыйшык каһарманыннан бигрәк, революция каһарманына охшаган иде. Андый кеше исә, үзен-үзе атып үтереп, идеалына хыянәт кенә ясаячагын яхшы төшенә. Әйе, әйе...

Тик Фарукҗан үз фаразларына нидер җитмәвен дә тойды. Чекада инде ике атна эшләсә дә, хәзергә кадәр ул әле турыдан-туры чын йөзен яшермәгән дошманнар белән генә көрәшкән — бирегә Рәсәйдән килеп оялаган контрлар белән атышкан, кышлакларга чыгып әмир гаскәрләре калдыкларын коралсызландырып йөргән иде. Бүгенге төн вакыйгасы исә бөтенләй башка. Монда кем дус, кем дошман икәнне белү үзе төп бурыч, иң кыен эштер, ахры.

Шиһабетдинов дусмы, дошманмы? Аны һәлакәткә кайсысы этәргән? Бәхетсезлеккә сәбәпче бәндәләр хәзер кайда? Симиниев вакыйганы тикшерүдә үзен ник болай сәер тота икән?

Фарукҗан хәзергә бу сорауларның беренчесенә генә ышанычлы җавап бирә ала. Калганнарына җавап эзләүдән аны азат иттеләр!

Байкучатов кабинетына кайтып кергәндә дә ачуыннан арынып бетмәгән иде әле. Шкафындагы барлы-юккы китапларын тәртипкә китерде, өстәлендәге кара савытын, корыч каләмле ручкасын ары-бире күчерде, бүлмәсендәге өч урындыкның һәммәсен бер сафка тезеп, шуларга сузылып кырын ятып карады, аннары кире сикереп торып сей-

фын, өстәл тартмаларын күздән кичерде. Нәкъ менә бүген бик мөһим эшләр хакында киңәшергә, күп мәсьәләләрне ачыкларга теләгән, соңыннан Зөһрәгөлне табуда ярдәм итәргә җыенган, бер дә көтмәгәндә Фарукҗанның тынгысыз йөрәген җылыта торган сүзләр әйтеп, күзгә күренмәс нык җепләр сузган кеше нигә әле, аны нәүмиз итеп, капыл гына үзен-үзе ата? Симиниев белән Нурморатов нигә санга сугарга теләми соң әле үзләре кебек үк чекистны?

Байкучатов урыныннан торып, өс-башын тәртипкә китерде дә тәвәккәл генә Әминев кабинетына атлады. Ул гына баш ватарга, ялгызы гына караңгыда кармаланырга тиеш түгел ләбаса. Хезмәте буенча да Фарукҗан үзенең күргән-белгәннәрен беренче чиратта югарыга җиткерергә тиеш!

Чека председателе, сул кулын маңгаена терәп, нидер язып утыра.

— Кайтып җиттегезме? — диде ул Байкучатовны күреп алгач.

— Хәзергә мин үзем генә әле. Кизү торасым булганга, тизрәк уралырга тырыштым. Аннары... мин анда артык та идем, ахры, иптәш Симиниев шулайрак сиздерде.

— Тукта, Шиһабетдинов ничек анда, хәбәр чынмы?

— Әйе.

— Нәрсә ачыкладыгыз?

— Әллә тагын. Анда һәркем үзенчә сукалый. Симиниев белән Нурморатов, комиссар үзен-үзе аткан, дип акт төзи калды.

— Таныклар бармы?

— Ба-а-ар.

Фарукҗан бу сүзне шундый итеп әйтте ки, аны тыңлаучы һәркем җавапны тик кире мәгънәдә генә аңларга мөмкин иде. Чека председателе Байкучатовка төбәлеп беравык карап торды да:

— Нәрсә, шик уяталармыни? — диде.

— Белмим. Миңа анда байтак нәрсә шикле тоелды. Иптәш Шиһабетдинов Ситтәрәи Маһи-һуса янындагы хәрби шәһәрчектә яши иде түгелме соң?

— Шуннан?

— Бүген ниндидер кышлакта кунганнар, имеш. Йомышчысы Рахманкол хәзер шундагы мәрхүм яткан бүлмәне комиссарныкы итеп танытып маташа.

— Алай...

— Иптәш Әминев, хәрби комиссар өйләнгән кеше идеме?

— Әйе. Тик аның хатыны Верныйда калган бугай, хәбәр җибәрү файдасыз. Ә менә РСФСР вәкиллегенә белдерергә кирәк булыр.

Чека председателе урыныннан торып өстәл арасыннан чыкты һәм ишекле түрле йөренә башлады. Уң кулы белән чигә чәчләрен шәрәләнә башлаган баш түбәсенә таба сыпыргалады, әмма пеләшен каплыйсы урында, үзе дә сизмәстән, аларны җыерчыкланган киң маңгаена гына төшереп калдырды. Бүтән чакта терекөмештәй йөгергән йөзем төсле яшькелт күзләре хәрәкәттән туктады, калку яңак мускуллары тартылды, болай да юка иреннәре тәмам кысылганлыктан, ияк чокыры, гомумән, язылып бетте. Ул, гүя, кабинетында басып торган теркәү бүлеге башлыгы Байкучатовны бөтенләй онытты, бүгенге фаҗигале төннең вакыйгасын исеннән чыгарды, үзенә генә мәгълүм һәм үтә катлаулы дөнья ваемнарына кереп чумды. Аның үз-үзен болай тотышы, кинәт уйга талып ишекле-түрле идән такталарын саный башлавы Фарукҗанны борчыды, хәтта ачуын китерде. Чека председателе, аның уенча, кыю, каты куллы, чая һәм өлгер булырга тиеш иде. Хәзер мондый таркау кешегә үзенең шөбһәләрен ничек сөйләп бирсен, дәлилләрен ничек китерсен инде ул? Җитмәсә, Симиниев сыман фикер йөртсә, аның әзер нәтиҗәләрен ышанып кабул итсә һәм үз иманына әйләндерсә? Бәлки Шиһабетдинов нәкъ менә шундыйларны истә тотып, бүгенгә килешенгән очрашуны сер кылып сакларга кушкандыр?

Озакка сузылган тынлыкны телефон чылтыравы бүлде. Кабинет хуҗасы ашыкмый гына трубканы күтәрде.

— Чека, Әминев тыңлый.

Гаҗәп, председатель әлеге сүлпәнлегеннән, уйчанлыгыннан күз алдында берьюлы арынып, кемнеңдер үзбәкчә итагатьле, йомшак һәм дәвамлы исәнләшүенә, хәл-әхвәл сорашуына колак салып, үзе дә шулай ягымлы җаваплар бирә башлады.

— Вәгаләйкем әссәлам. Рәхмәт, тәшәккер кыламын... Сезгә дә! Яхшы, үзегез исән-аманмы? Гаиләгездә иминлекме? Кардәш-ыру саумы? Каефегез яхшымы?.. Хуп, иптәш Хуҗаев, хуп. Әйе, кәттә бәхетсезлек, авыр югалту. Әлегә һәлакәт хәлләрен тәфсилле белмимен. Хуп, мәйле, ярар. Симиниев белән Нурморатовлар тикшерә... Оператив төркемдә фельдшер да бар... Әйе, әйе, хуп, хәбәр итәрбез... Сипулян? Беләмен... тыңлыймын, әйе, хуп, җибәрербез... Кайдан алырга? Хуп, ярар.

Байкучатов чылтыратучының кем икәнлеген бик тиз чамалап алды. Чека башлыгына болай сүзе үтә, аңа эш куша ала торган кешеләр Бохарада санаулы гына. Бу, һичшиксез, Халык Комиссарлары Советы рәисе Фәйзулла Хуҗаев иде.

Сөйләшү тәмамлангач, Әминев Фарукҗанга җитди генә карап:

— Менә нәрсә, иптәш Байкучатов,— диде.— Сипулян кышлагында ниндидер коралны ят кешеләр тупланган, имеш. Басмачылар булмагае, дигән шик бар. Халык Комиссарлары Советы һәм хәрби комиссар карамагындагы махсус отрядлардан берәр взвод алыгыз да хәзер үк шунда элдертегез. Җитез, сак хәрәкәт итегез. Барлык ят кешеләрне ачыклагыз, коралсызландырыгыз. Ул кышлакның кайда икәнлеген беләсезме?

— Каршы капкасы алдында бугай.

— Дөрес. Бер минутыгызны әрәм итми шунда кузгалыгыз. Республика хөкүмәте башлыгы үзе тапшырган йомыш, сынатмагыз. Эшнең очына чыгуга, миңа хәбәр итәрсез. Аңлашылдымы?

— Әйе.

— Хәерле юл!

Чека председателе, хезмәткәре белән сүзен беткәнгә санап, телефонына үрелде һәм РСФСР вәкиллегенә шалтырата башлады. Үзенә кирәк кешене тизрәк тапсыннар өчен, кем икәнлеген дә искәртеп куйды. Моның файдасы тиде, күрәсең, аппаратка озакламый җан керде. Әминев кемгәдер кыска гына итеп хәрби комиссар фаҗигасен хәбәр итте.

— Иптәш Фрунзега? Телеграмма? Юк, бирмәдек. Кирәкме икән соң ул?.. Төшенәм, алайса, әлбәттә. Яхшы, хәбәр итәрбез. Ул хәзер Ташкентның үзендәме икән? Яхшы, һичшиксез. Әле оператив төркем кайтмады. Соңыннан күрешербез, әйе, хәзергә хушыгыз!

Чека председателе бу сөйләшүне тәгалләгәч тә трубканы куймады, почта белән элемтәгә керде.

— Алло, ашыгыч телеграмма сугыгыз әле. Текстны язып алыгыз: «Ташкент, Төркестан фронты фәрманчысы Фрунзега. Бүген, егерме беренче октябрь таңында БХСР хәрби комиссары Баһаветдин Шиһабетдинов фаҗигале рәвештә һәлак булды. Оператив төркем вакыйганы тикшерә. Күрсәтмәләрегезне көтәбез. Бохара Чекасы председателе Әминев».

Трубканы куйгач, ул ишек төбендә басып торган Байкучатовка: чатовка:

— Сез әле китмәдегезмени? — диде.

Фарукҗан аның шушы санаулы минутларда әллә ничә төрле рәвешкә керүен, шартына карап шактый елдам хәрәкәтләнүен бераз күзәтеп торгач, башлыгы турындагы баягы фикерен үзгәртә төшкән иде. Шуңа күрә ул хәзер үзе бик әһәмиятле дип санаган уйларын уртаклашырга теләде.

— Иптәш Әминев, Шиһабетдинов һәлакәтен җентекләбрәк тикшерергә кирәк.

— Оператив төркем шуның өчен китте ич инде.

— Шуның өчен. Әмма иптәш Симиниев белән Нурморатовның бу вакыйгага мөнәсәбәте мине киресен уйларга мәҗбүр итте...

Фарукҗан фаҗига урынын карау нәтиҗәләренең ни өчен шик уятуын үзенчә кабатларга тотынды. Йөзе караңгыланган Әминев:

— Сез бу фикерләрегезне иптәшләрегезгә инде белдердегезме? — дип сорады.

— Әйе.

— Менә нәрсә, энем. Бу сезгә Татарстан түгел, Бохара мәмләкәте. Монда хәлләр бөтенләй башка. Бигрәк тә хәзер, иске үчеп бетмәгән, яңа тамыр җибәрергә өлгермәгән, сыйнфый дошманнар безгә — Рәсәйдән килүчеләргә карата ышанмаучылык уятырга тырышкан көннәрдә. Үзбәк, таҗик, төрекмән ярлылары җитәрлек оешмаган, күпләр тугантумачалык тозагына, мулла-мунтагай йогынтысына бирелгән. Мондый шартларда Шиһабетдинов һәлакәтен үзегезчә һәм үзбаш ачыкларга тырышсагыз, фикерләрегезне дә, дәлилләрегезне дә теләсә кем белән уртаклашырга ашыкмагыз. Хәтәр бу, аңлыйсызмы? Хә-тәр!

— Чекадагы иптәшләремә дә берни әйтмәскәме? — диде Фарукҗан хәйран калып.

— Кайчакта-әйе. Республикадагы сәяси хәл әлегә шундыйрак. Барыгыз, кушылганны үтәгез. Ә бу хакта ачыграк, иркенрәк итеп соңыннан сөйләшербез. Чү, туктагыз әле, минем монда сезнең аша узмаган ике Фирганә хаты бар лабаса. Хәзер үк теркәгез, үзегез дә тиз генә танышкач, юлга чыкканчы ук кире кертеп бирерсез.

Чека председателе киңәше Фарукҗанга ошамады гына түгел, ул аның акылына да сыеп бетмәде. Әгәр монда да үзара турысын сөйләшергә ярамаса, башка җирдәгеләр нишләргә тиеш икән?

Фарукҗан Әминев кабинетыннан яхшы ук аптыраган хәлдә чыкты. Аннары хәрби комиссар карамагындагы махсус отрядтан да сугышчылар аласын исенә төшереп, адымын тизләтте. Менә кайда һич югы бер ышанычлы кешегә юлыгуы ихтимал Байкучатовның. Шиһабетдинов үлеме белән килешә алмаган Амантай Туктаровның, һичшиксез, ярдәм итәчәгенә, бәлки әле нинди дә булса яңалык та ача алачагына өмете зур иде аның.

Шундый уйлар биләгәнгәме, Әминев, тоттырган кәгазьләргә бик үк аһ итмәде ул. Хатларда югары сәясәт кенә икән, чара күрер өчен үзенә тапшырылмаган, аның өлешенә бер серне чишү дә җитәр, димәк, Байкучатов дигән егеткә бу хатларның кагылышы чамалы, дип аларны тиз генә зур кенәгәгә теркәп, сул яктагы өске почмакларына тәртип санын һәм көнен язып куйды. Шуннан соң хәтер өчен генә әлеге хатларга янә бер күз йөгерткәч, хуҗасына кертеп бирде.

## 4

«БХСР Чекасына.

Моннан бер-ике атна элек басмачыларның яшерен очрашу өненә кинәт бәреп кереп, байтак корал, коткы сала торган өндәмәләр, җөмләдән, шушы хатыбызга теркәп күчермәсе сезгә салына торган инглиз телендәге бер язуны да кулга төшергән идек. Без аны Ташкентка җибәреп тәрҗемә иттердек һәм язуның шактый өлеше Бохара эшләренә кагылуын ачыкладык. Бу күчермә белән танышу сезгә дә зыян итмәс, дип уйлыйм.

Бәрелеш вакытында, төн караңгылыгыннан файдаланып, кайбер дошманнар качып котылды. Әсирләрнең икърар итүенчә, алар арасында бер ят европалы да булган икән. Үтә тәҗрибәле һәм мәкерле ул бәдбәхет киләчәктә тотылса, безгә дә хәбәр бирүегезне үтенәбез.

Коммунистик сәламнәр соңында Фирганә Чекасы рәисе...
(имза) Кукан. Сигезенче октябрь».

«Капитан Блеккерга».

Кешеләребез кара халык фетнә күтәргән Бохарадан әмир белән бергә чыгып китәргә мәҗбүр булганлыктан, шушы боерыкны алгач ук, БХСРга килеп, резидент вазифасын үти башлагыз. Бохара ханлыгы соңгы вакытта де-юре Русия составыннан чыгу аркасында, аннан Лондонга Кари Мирза бәк җитәкчелегендә вәкилләр җибәрелгән һәм әмир сараенда Бөекбритания вәкиле булдырылган, шуның нәтиҗәсендә бу төбәктә йогынтыбыз шактый үскән иде. Хәзер әмир ерактагы ышанычлы дуслары ярдәмендә, тәхетен кайтарып алыр өчен, биләмәләренең көнчыгыш өлешендә көрәшен дәвам итә, безгә исә эшебезне шулай ук яңабаштан юлга салырга туры киләчәк. Яшь бохаралылар арасында Лондонга дустанә караучылар булу, РСФСР тарафыннан БХСРның ирекле рәвештә үзбилгеләнү хокукы танылу ул бурычны уңышлы үтәргә мөмкинлек бирер, дип уйлыйбыз.

Капитан әфәнде, Азиядәге биләмәләребезгә Русиянең даими янап торуы, монда йогынтыбыз үсүенә бөтен куәтен җигеп аяк чалуы яхшы билгеле. Революция барышында ул эчке көрәшләр упкынына тәгәрәп, безнең кулларны шактый чишкән иде. Әмма соңгы вакытта Русия, тирә-якка коммунизм чире йоктырып, демократ булып кыланып, Бөекбританиягә җитди зыян сала башлады. Корольлегебездә компартия төзелү, Ирландия, Канада, Һиндстанда аерылып үзбаш яшәү омтылышлары көчәю, Иранда һәм Әфганстанда безгә каршы дошманлык арту — болар барысы да Совет котыртуы нәтиҗәсе. Шуңа күрә без БХСРда РСФСРга һәм коммунистларга каршы рәхимсез көрәшергә, бу көрәштә бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга тиеш.

Бохарага килү белән, Бөекбритания тарафдарларын барларга керешегез һәм алар аша яңа җитәкчеләрне капшагыз. Укымышлыларга, сәүдәгәрләргә, руханиларга РСФСР игълан иткән ирекле үзбилгеләнү хокукының вакытлы тактик чара, аякка ныклап басканчы бер хәйлә — сәяси уен гына икәнлеген, үз биләмәләре уртасында утрау шикелле яшәячәк мөстәкыйль Бохара дәүләтен ул якын киләчәктә үк яңадан йотарга тырышачагын, шуңа күрә БХСР хөкүмәте Совет Русиясе белән ашыгыч рәвештә, Литва шикелле, рәсми килешү төзеп, суверенитетын дипломатик чаралар белән ныгытырга тиешлеген аңлатыгыз. Советларның шәхси милеккә, дингә кул күтәрүен, Бохараның арзанлы мамыгына күз кыздыруын, РСФСР дәгъваларын һәм басымын кире кагуда БХСРга ышанычлы терәк кирәклеген, ә Бөекбританиянең, үз чиратында, яшь республиканы якларга әзер торуын белгертергә кирәк.

Шул ук вакытта көнчыгыш биләмәләрендә көч тупларга тотынган әмиргә ярдәм кулы сузу, аның пайтәхетендә калган һәм башка җирләрдә сибелеп яшәгән тарафдарларына оешырга, галиҗәнапләре белән бәйләнеш урнаштырырга булышу да сезгә йөкләнә.

РСФСР яклы яки Бохараның чын бәйсезлеге турында хыялланучы йогынтылы яңа эшлеклеләрне барлау, алар арасында бер-берсенә ышанмау хисләре уяту бәхәсләр һәм низаглар чыгару да әһәмиятле. БХСР хөкүмәтенең, безнең сәясәтебезгә каршы баш күтәргән. Шәрык милләтчелегенә бирелгән Әфганстан белән аралашуына комачаулау аеруча мөһим икәнен бер генә минутка да онытмагыз. Шул максатта берәр шау-шулы нәрсә оештыруны, тел тегермәненә мул азык бирүне үз ихтыярыгызда калдырам.

Дусларыбыз өчен шактый күләмдә корал әзерләп куелды, аның бер өлеше каракулгә алмашыначак, калганы бушлай бүләк ителәчәк. Яңа җирдәге эшегез хакында өч көн саен хәбәр җибәреп торыгыз.

Бохарада сезне Мөхәммәт Пәррана гөмбәзе астында көтәчәкләр. Күрешү вакыты, элемтәченең кыяфәте, пароле шул ук.

Полковник Штеннел. Мәшһәд. Өченче октябрь».

5

Караңгы бүлмә почмагында янган ялгыз шәмнең зәгыйфь яктысы каршыдагы диварга Зөһрәгөлнең күләгәсен сәер рәвештә төшергән иде: терсәкләре озын, толымнары беләк юанлыгы, хәрәкәтләре, йокысыннан айнымаган кешенекедәй, сүлпән һәм тотрыксыз.

Ул көзге алдында чәчләрен үреп утыра иде. Дөресрәге, әле үрә, әле сүтә. Бүлмәнең бердәнбер нәни тәрәзәсе калын пәрдә белән капланганлыктан, ишеге ябып куелганлыктан, аңа төн һаман дәвам итәдер төсле тоела иде. Сыйпый-сыйпый шушы толымнарны иркәләрлек яки, берәр эш кушып, урыныннан кузгатырлык кешесе кайдадыр югалып йөргәнлектән, Зөһрәгөл бу иртәдә ялгызы гына уйлары дөньясында йөзеп онытыла. Ул әле йокысы кочагыннан, бүген күргән төшләре эсирлегеннән чыннан да айнып бетмәгән, турысын гына әйткәндә, хәзерге мохиттән күп тапкыр күңеллерәк, күп тапкыр хушрак күренешләрдән аерылырга теләми дә иде кебек. Бохара

хәзер җанланса, элекке дәвере белән чагыштырганда, тәмам кайнап торса да, Зөһрәгөл каладагы тормышны хыялый дөньясы белән тиңләргә, аңардан кызыклырак, баерак һәм матуррак санарга һич тә җыенмый, җыенса да, моны булдыра алмый иде. Нигә шулай икән бу? Әмирлектәге үзгәрешләрнең аңа кагылмыйча узуы, аның тормышына нинди дә булса яңалык өстәмәве аркасында микән әллә? Күпләрне дер селкеткән вакыйгалар аңа бөтенләй канатын тидермәде дию мөмкин түгел лә баса, якын саналган кешесенең соңгы вакытта күңеле алгысыну, Зөһрәгөлгә игътибары кимү, әллә Булатхуҗаев, әллә Атахуҗаев, кайсыдыр Хуҗаевлар өенә баруны хәйран ешлатып җибәрүе, анда бер чибәркәйнең һәм аның туганнарының җылы карашын аулавы начар фал гына түгел, гади кешене аяктан егарлык нәрсә иде. Тик Зөһрәгөлнең моңа бик үк сыны катмады. Чөнки аны дулкынландырырлык, һушын алырлык хәлләр инде бер булганлыктан, хәзер ул кайбер нәрсәләрне салкынрак, сабыррак кабул итәрлек халәткә килгән иде. Мондый үзгәрешләргә кайчан да булса баш күтәрәчәген сизенә, әмма хәзергә әле үзен һаман тыеп тора, авырлыкларга бирешмәс өчен, үткән тормышыннан көч ала, кайчандыр күңелен дәртләндергән вакыйгаларны һәм кешеләрне исенә төшереп юана иде. Ташкентта торганда һәм бигрәк тә Казанда укыганда күңелле көннәрне дә кичермәдемени ул? Әле күптән түгел яңадан кия башлаган ахак кашлы йөзеге дә шуның бер истәлеге һәм дәлиле түгелмени? Тик, кызганыч, аны бүләк итүче егет кенә кинәт әллә кая китеп барды. Әрсезлеге бар иде, үзен белдекле, чая күрсәтергә тырышуы хәтердә, шул ук вакытта ихлас тойгылы кеше булып та күңеленә керергә өлгергән иде — югалды. Ә йөзеге менә исән. Башка сүз салучылар да, бүләк биреп маташучылар да очрады, тик Зөһрәгөл «Мөхәммәдия» шәкертенә биргән вәгъдәсен бозарга теләмәде. Бер ел, ике... Хәзер менә шул егетнең — Фарукҗанның төшкә килеп керүен күр инде. Ни гомерләр узгач! Дөяләр кәрваны белән эссе чүлләрне кичкән дә, бәйләм-бәйләм аскан йөкләрен күрсәтеп: «Болар барысы да сиңа мәһәр, Зөһрәгөл багалмам»,— дип сөйләнә. Зәңгәр күзләре елтыр-елтыр яна, мыегы хәтәр бөтерелгән, ә башында — яулык. «Ятлар мине танымасын әле, юри шулай бөркәндем мин аны», ди. Зөһрәгөл исә егеткә авыз ачып ләм-мим дәшә алмады, инде әллә кайчан, Йосыфны сөйгән Зөләйхадай, бөкре карчыкка әйләнгән, таякка таянып янында тик кенә басып тора, имеш. Фарукҗан эчәргә су сорагач, теркелдәп кенә өенә кереп китте, әмма аның тустаган белән алып чыкканы пылау, имеш, егет Зөһрәгөлгә: «Бик сусадым ич, нигә болай шаяртасың инде», дип үпкәләде. Зөһрәгөл исә: «Мин хәзер чәй белән дә сыйлармын үзеңне, балакай»,— дип акланды, ләкин ул кире капка төбенә уралганда, кәрван да, Фарукҗан да күздән югалган иде. Шуннан соң ул, җаны көя башлавын тоеп, алып чыккан суын үзе голт-голт эчәргә кереште, әмма тустаганын бушатып бетерсә дә, сусыны канмады. Зөһрәгөл менә шулай, судан чыгарып ташланган балыктай, авызы кибүдән уянып китте. Яңадан йокыга оерга, төшен күрүне дәвам итәргә бик теләсә дә, йә вакытында тора алмам, дип курыкты һәм, ут кабызып, көзге каршысына килеп утырды. Билгеле, ул инде хәзер Казанда чактагы үсмер кызыкай түгел. Битләре кабартма шикелле күпергән, түшләре дә... Әмма куе кара чәчләре һаман шул, ул тагын да озынрак, тагын да куерак үскән булса гына инде. Аһ, бу толымнар заманында егетләргә шул кадәрле ошый иде бит! Шулкадәр ошый иде...

## 6

Ак чәчәкләргә күмелгән болынны хәтерләтүче мамык кырлары арасыннан җайдаклар отряды атлый. Кояш инде хәтсез күтәрелгән,

һава торган саен бөркүләнә бара. Тик изүләрен чишкән сугышчылар моңа сукранмый, хәвефләнгән бәрелешнең булмый һәм кан коелмый калуына сөенеп, әле яңа гына Сипулян кышлагын ничек камап алуларын, кемнәрнең хәйран егетләнеп алга ыргылуын, кемнәрнең мыштырдап артта таптануын искә төшерә, үртәшә һәм көлешәләр иде.

Тынычлана төшкән Байкучатов хәзер инде колонна артыннан атлый иде. Әлбәттә, ул башкалар шикелле бөтенләй үк язылып, иркенәеп китә алмады, бүген таң атканда танышкан әлеге кызыл гаскәрине чакырып алып, үзе белән янәшә барырга боерды.

Уяу уздырылган төн, көчәя төшкән эсселек, атларның бер көе генә салмак тирбәтүе, һөҗүм алдыннан пәйда булган баягы киеренкелекнең юкка чыгуы гәүдәне изрәтә, башны авырайта һәм авызны әледәнәле ачылырга мәҗбүр итә иде. Фарукҗан, ихтыярын бик нык җигеп кенә, үзен йокыга оеп китүдән тыя алды. Ул тезгенен тартып, отрядтан тагын бераз арткарак калды да:

— Йә, Амантай туган, менә хәзер иркенләп сөйләшер вакыт җитте безгә,— диде.— Кайдан беләсез иптәш Шиһабетдиновны? Ни өчен якын күрә башладыгыз? Нигә аны берәрсе үтергәндер дип саныйсыз?

— Җулдас командир, мин сезгә бер-ике сүз белән генә җавап бирә алмаймын, әңгәмә озын булады.

— Зыян юк, сөйли бирегез.

— Алайса тыңлагыз.

## 7

Амантай менә ничәнче ел инде Кызылком чүлендә бай көтүен көтә иде. Табигать бу якларда үтә кырыс: җәе чамасыз эссе, кышы суык, җилләре, аеруча Әфганстан ягыннан исә торганы һәм «әфгани» дип телгә кергәне, җелеккә үтәрлек әче. Чүл март-апрель айларында гына бераз ямьләнеп ала — әрем, бозаубаш, балыккүз, янтаклар кыюсыз гына сыек яшел төскә керә, кайбер урыннарда кыска гомерле мәкләр һәм лаләләр ялкын телләрен чыгарып чәчәк ата иде. Нәкъ менә шушы чорда ташбакалар да хәрәкәткә килеп, чүлдә тереклек барлыгын искә төшерә. Әмма май аенда инде болай да сирәк үсемлекләрнең күбесе корып бетә, талымсыз саксавыл белән әрсез янтак кына андасанда күзгә чалына. Мондый чакларда Амантайга инде шактый арыкланган сарык көтүе белән көн саен байтак җир узарга туры килә, маллар тамырда утырып корыган чүл үләне белән тамак туйдырганчы һәм кире кое янына уралып килгәнче кич була иде.

Аулак җир иде бу. Зәрәфшән үзәненең кырыена урнашкан иң якын кышлакка кадәр дә ким дигәндә илле-алтмыш чакрымнар бардыр. Шуңа күрә аннан чабаннарга ашамлык һәм төче су алып килә торган ялчы атнага бер яки тагын да сирәгрәк юлга чыга иде. Менә ни өчен хайваннар гына түгел, Амантай белән бергә мал багучы Чалабай картка да еш кына чүлдәге коеның шактый ук тозлы суын эчәргә туры килә иде.

Гомере буе кеше малын көткән, кышы-җәен көнне — ачык сахрада, төнне тишек-тошык иске тирмәдә уздырган карт чыдамлыгы, күндәмлеге белән баштагы вакытларда Амантайны таң калдыра иде. Әмма тора-бара малай үзе дә нәкъ шундый ук әз сүзле, тыныч, кояшка-җилгә бирешми, һәр мәхлукка — сарыкларга һәм этләргә дусларча эндәшә торган сабыр адәмгә әйләнде. Өч-дүрт ел һәнүз бергә яшәгән, суыкны һәм кызуны, ком бураннарын һәм ач бүреләр һөҗүмен бергә кичергән, малларны бергә көткән һәм саклаган арада ул өлкән иптәшенә иләште генә түгел, аның байтак сыйфатларын һәм гадәтләрен дә үзләштерде. Чалабай агасы елына ике-өч мәртәбә кышлакка, гаиләсе янына кайтып киткән көннәрдә, иптәшенә алмашка ке-

ше килсә дә, Амантай һәрвакыт ялгызлык хисе кичерә иде. Дүрт-биш көннән өлкән чабан кире әйләнеп кайткач, аның күңеле ничектер тагын урынына утыра, чүл тагын туган йорты кебек үз булып күренә башлый иде.

Амантай Чалабай картны хәзер үз атасыннан да яхшырак белә иде сыман. Аның үзен генә түгел, бөтен гаиләсен дә! Чөнки маллар утлаган арада, аннары кичке учак янында дүрт ел буе нiләр генә сөйләмәде икән аңа чабан агасы.

— Таулар, үрләр — табигатьнең өлкән балалары,— дип башлый иде ул сүзен.— Картаеп беткәннәре. Алар мең еллар буе барлыкка китерелә. Ком барханнары менә — бер төн җимеше. Ваемсыз ком бураны җир куенындагы балаларын, акылдан шашкандай, минут эчендә юкка чыгара ала. Аларны бүтән җиргә күчереп куярга да күп сорамый.

Чүл һәм үсемлекләр, йолдызлар һәм бүреләр, арыклар һәм коелар, кышлак тормышы һәм үзенең егет чагы, яңа туган бәрәннәрне саклау һәм учак тергезү, чаяннар һәм ташбакалар турында — дөньяның үзе белгән барлык серләрен әңгәмә итә иде ул. Андый чакта Амантай сүзне яңадан-яңа нәрсәләргә борып җибәрергә генә тора.

— Чаләкә, сез әмирнең җәйге сараен беләсезме? Күргәнегез бармы?

— Ситтәрәи Маһи-һусаны әйтәсеңме?

— Әйе.

— Аңа һич эшем төшкәне юк шул,— ди көтүче карт.— Бер дәрвиш сөйләгән иде: көндезләрен ул таң калырлык матур, төннәрен котны алырлык шомлы имеш. Бакчасындагы йөзьяшәр агачларның ябалдашлары арасыннан тоныкь эре йолдызлар җемелди, төнге кошларның кабердәге шикелле ухылдап куюлары ишетелә, хәрәмнең кысан хөҗрәләрендә җәфаланган чибәркәйләрнең шәрә өрәкләре саташып, сарай ишегалдына килеп чыга имеш.

— Чаләкә,— дип эндәшә тагын Амантай,— дәрвишләр теләсә кая барып керә аламыни?

— Аларга хөррият,— дип раслый карт.— Әллә дивана, әллә изге — белмәссең үзләрен. Гомерләре гел каңгырап уза: бүген фәкыйрь диһкан куышына сыенсалар, иртәгә аксөякләр мәҗлесенә килеп керәләр. Үзләренең бер малы юк, әмма ишаннарга да, бәкләргә дә буйсынмыйлар. Дәрвиш иген икми, терлек асрамый, өй кормый, өйләнми...

— Алай да яшәргә мөмкинмени соң ул?

Чалабай карт ризасызлык сизелгән тавыш белән:

— Ил җилкәсе күтәрә инде,— диде.

Сарай, дәрвишләр тормышы әллә нинди серле, ят иде Амантайга. Шуңа күрә ул өлкән хезмәттәшенең егет чагын, кышлактагы бәйрәмнәрне, туйларны, андагы яшьләр уеннарын искә төшереп утыруын бигрәк тә яратып тыңлый, аннары байтак вакыт йокыга китә алмый хыялланып ята иде.

Әмма чүлдә мал бага башлавының өченче язында җәйләүләренә Чалабай агасының хатыны килү, җитмәсә, кызы Балҗанны да ияртеп килүе аның хәтеренә аеруча тирән эз салды. Ул көнне Амантай кое янында улакларга су тутырырга калган иде. Вакыт инде кичкә авышканлыктан, саксаул ботаклары ягып казан да асты һәм иртән сауган сарык сөте белән дөге боткасы пешерергә куйды. Менә шулчак егет офыкта кышлак тарафыннан нәни кәрван пәйда булуын күреп алды. Билгеле, ул тирмә янына килеп җиткәнче әле тагын хәтсез вакыт узачак иде, тик шулай да хәвефләнгән Амантай учагына тынгысызланып күз салды. Бүген үк көтмиләр иде әле бай илчесен. Хуҗа яшь мал итеннән пылау пешерергә комарлангандыр, күрәсең. Нишләтергә инде хәзер ботканы, дип пошынды егет, казанны алып яшерергәме, әллә утны

куәтләрәк дөрләтергәме? Ят күз килеп җиткәнче пешеп өлгерерме икән? Әгәр бай ялчысы аларның сөтле азык белән сыйланып ятуын хуҗага кайтып сайраса, гауга чыгасын көт тә тор. Ул әле болай да чабаннарына һәрвакыт: «Кортны әз ясыйсыз!» дип бәйләнә. Амантай учакка яңа ботаклар өстәп, күзеннән яшь сытылганчы сүрелгән күмерләргә өрә башлады. Ялкын телләре үрләп казанны бар яктан да яларга тотынгач кына, ул яңадан кое янына килде.

Йөк асылган, шуның өстенә ике сәяхәтче дә менеп атланган дөяләр тирмә янына килеп җиткәндә, аның улаклары мөлдерәмә тулы, чәе кайнаган, боткасы пешкән һәм казаны белән аулакка яшереп куелган иде инде. Әмма аның саклыгы бөтенләй артык булып чыкты, чөнки гадәттәгечә ялчы урынына бу юлы дөяләргә Чалабай картның хатыны белән кызы менеп кунаклаган иде. Хуҗа аларны язгы муллыкта сарыкларны савар, корт кайнатыр өчен махсус җибәргән иде.

Бер кышлакта яшәмәсәләр дә, юлаучыларның кем икәнлеген Амантай шунда ук чамалап алды, йөгереп килеп аларга дөядән төшәргә, йөкләрен бушатырга булышты. Хәер, ундүрт-унбиш яшьләрендәге буй тарткан елгыр кыз егетнең ярдәмен көтеп тормады, өркәчле бахбаен җиргә яткырды да үзе аска шуды.

Таң атканчы ук сәфәр чыккан һәм чүл буйлап михнәтле озын юл узган сәяхәтчеләргә Амантай кайнаткан чәй иң тансык сый иде. Карчык, гомумән, йөк бушатуны яшьләргә калдырып, тизрәк тирмәгә кереп утыруны, шунда сусын кандыруны хубрак күрде. Йөкләрне чишеп, урын-җир, савыт-саба һәм ризыкларны тирмәгә ташыганда, Амантай яшь кунакка:

— Ә мин сезне беләм!— диде.— Сез — Чаләкәнең олы кызы Балҗан.

Юлаучы аның зур бөктәрләрне җиңел генә күтәреп алып китүен кызыксынып һәм елмаеп карап калды. Амантай икенче мәртәбә әйләнеп килгәндә аңа:

— Кунаклар көтми идек, менә Чаләкә куаначак инде,— дип эндәште.

Кыз бу юлы:

— Без дә егет кешенең тирмә ышыгында, күләгәдә хәл җыеп кына ятуын, малларны картның ялгыз башы гына багуын белми идек,— диде.

— Суны чиратлап әзерлибез,— диде Амантай акланып.— Иртәгә кое янында атагыз калачак.

Балҗан шаяртырга гына теләгән иде, ахры, егетнең чынлап торып акланырга керешүен күргәч, ышанмаган төсле башын чайкады, тик тагын үртәүдән тыелырга тырышты.

— Ә мин сезне башкачарак күзаллаган идем,— диде ул.

— Ничек итеп?

— Болай ук...— Кызның алсу битләре тагын да кызарып китте шикелле.— Болай ук көчледер дип уйламаган идем.

Амантайга моны ишетү күңелле иде, шуңа күрә ул калган әйберләрнең барысын да берьюлы әләктереп алырга омтылды. Аннары дөяләрне утларга җибәрде, яшереп куйган боткадан кунакларга өлеш чыгарып:

— Сез хәл җыя, тамак ялгый торыгыз, ә мин Чаләкәдән сөенче алыйм әле!— диде дә ашыга-ашыга көтүне каршы алырга йөгерде.

Башка чакларда тирән коедан су чыгарып улакларны тутырганчы яхшы ук арыса, бүген ул беләкләре талуын бөтенләй сизмәде, адымнары җиңел, күңеле шат иде. Үзенең авыр бөктәрләрне очыртып кына күтәреп алуын, Балҗанның исә моны сокланып күзәтеп торуын искә төшергәч, кәефе тагын да ачылып китте...

Чабаннар тирмәсендә ике кеше арту Амантай өчен чүл тормышын бигрәк тә күркәмләндереп җибәрде. Дөрес, болай да кысан киез өйне

чаршау белән урталай бүлгәч, түшәктә борылырга да чама калмады. Әмма көтүне бүреләрдән саклар өчен тышка еш чыгып йөрергә туры килгәнлектән, башы мендәргә тиюгә каты йокыга тала торган егет ул үзгәрешне сизмәде дә. Аның каравы иртән үзе уянганда, аннары күләмдә вакытта һәм кичләрен хатын-кызларның күңелле итеп сарык савуы, катык оетып, сөзмә, эремчек ясап, корт кайнатып, аны киптереп йөрүләре, аш-су әзерләүне дә үз кулларына алулары аңа үзе бер бәйрәм шикелле тоелды. Күчтәнәч май, борыч белән бергә сөт һәм тоз да салып әзерләнгән чәй (ширчәй), мамык мае тәме килгән маш боткасы һәм бодай, кукуруз ярмаларыннан пешерелгән өйрә чабаннарның туклануын шактый төрлеләндереп җибәрде. Ара-тирә Балҗан белән бер-ике авыз сүз алышу, бархannar арасыннан ташбака йомыркалары һәм лалә чәчәкләре җыеп кайту күнегелгән һәм өзлексез дәвам итүе белән туйдырып бетергән тормышка яңа бизәкләр өстәде, чүлнең элек һич тә абайланмаган саран матурлыгының кадерен белергә өйрәтте. Этләр, сарыклар арасында кырыс шартларда Чалабай карт белән узган соңгы өч ел үсмердән житкән егеткә әйләнә баручы Амантайга кешечә тойгыларның һәм омтылышларның әле байтагын йөрәгеннән кичерергә, татырга, хәтта аларның барлыгын башына китерергә дә мөмкинлек бирмәсә, Балҗанның җәйләүгә аяк басуы буаның кинәт ерылуына сәбәп булды. Бөдрә йонлы бәрәннәрне иркәлиме, корт кайнатырга асылган казан янына чүгәләп, чүмеч белән күбек җыямы, тирмә алдына чыгып биленә житкән чәчләрен тарыймы — егет шыпырт кына кызга күз салып ала иде. Балҗанга караган саен карыйсы килүен абайлагач, Амантай бу тамашага үзе дә таң калды. Хәер, кыз да астыртын гына егетне күзли иде бугай. Кайвакыт алар бер-берсенә ярдәм иткәли, язын үрчегән ишле көтүне караштыру ирләргә генә шактый кыен иде. Савым вакыты житкәч исә малларны ачык сахрада туплап торыр өчен, күмәк тырышлык да таманга килә иде.

Бер көнне алар янтак[1] җыя-җыя тирмә яныннан шактый ераклаштылар. Сарыклар савылган, кичке чәйне инде эчкәннәр — ашыгырга сәбәп юк иде. Ераграк киткән саен янтак та күбрәк очрый, кое тирәсендәгеләрне дөяләр инде әллә кайчан ашап бетергән. Амантайлар аны учак ягарга да җыйнаштыргалаган булган, күрәсең.

— Чүлдә иң әйбәт азык — сөзмә,— диде егет.

— Нигә?

— Тамак ялгарга утырган җирдә аны җылы су өстәп сыеклыйсың да пәтереңне шуңа манып ашый бирәсең. Әгәр аңа шикәр дә төеп салсаң, бөтенләй кунак сыена әйләнә.

Балҗан елмаеп куйды.

— Нигә авыз ерасың?

— Әти дә гел шулай сөйләнә иде.— Аннары кызыкай көйләп дәвам итте:— «Бу яшьлек баштан бер көн үтәр димен, бал белән тәмле нәрсә шикәр димен»...

Амантай үртәүне аңласа да, шулай ук сүз уйнатып җавап кайтара алмады. Кышлактагы уен-җыеннарда чичәннәрдән тегесен-бусын ишетеп остара торган яшьтә ул кырыс Кызылком чүлен аркылыга-буйга гизә башлады. Монда аның даими остазлары — кояш, ай һәм йолдызлар, җил, берән-сәрән киек җәнлекләр дә үсемлекләр генә иде. Әмма шулай да ул үзен аңгыра, бөтен кешедән артта калган тинтәккә санамый иде.

— Дөньяда иң зур өч кайгының ниләр икәнен беләсеңме син?— диде ул кызның җырын бүлеп.

— Кем нәрсәләрне исәпли инде ул.

— Юк, мин бөтен кешегә уртак бәхетсезлекләрне күздә тотам.

— Яле, әйтеп кара.

---

[1] Янтак — чүл үләне.

— Яңгыр койганда өйдән чыгып китү, яшь чактагы фәкыйрьлек, беренче мәхәббәттән коры калу.

Бу юлы инде Балҗан кычкырып көлеп җибәрде. Амантай аңа сәерсенеп күз салса да, дәшмәде. Бу кызларның бар белгәне серле елмаю да хихылдау икән. Пәри кытыклыймыни! Тик шулчак ул әле генә әйткән өч бәхетсезлекне былтыр Чалабай карттан ишетүен хәтерләде һәм Балҗанның нилектән пырхылдавын аңлап алып, кулындагы янтак тутырган капчыгы белән әле һаман авызын җыя алмаган кызыкайга селтәнде. Балҗан бархан өстенә килеп төште дә егеткә астан очкыннар чәчрәтеп:

— Ә иң зур бәхет нәрсә?— дип сорады.

Амантай җавап бирмәде. Ул кызның балкып янган түгәрәк йөзенә сокланып карап торды да бархан сыртына утырып:

— Син әкияттәге пәри кызларына охшагансың,— диде.— Алар бик чибәр була, адәми затны үзләренә гашыйк итә дә өйләндерә икән.

— Син бөти тагып йөре!— диде Балҗан җитдиләнеп.— Югыйсә пәри тозакларына эләгеп харап булырсың. Бары бөтидән генә курка алар.

— Кайдан алыйм соң мин аны?

Балҗан муенса кебек тагып йөргән кара ефәк тасмасын чыгарды. Аның очына кара чүпрәккә төрелгән өчпочмак — бөти тегелгән иде.

— Иел әле, бисмиллаһир-рәхманир-рәхим!

Балҗан бөтиле муенсасын Амантайга кигезде дә бик белдекле төстә:

— Йокларга ятканда баш астыңа пычак куярга онытма!— диде.— Җен-пәриләр тимердән дә курка, якын килергә базмаслар.

Егетнең мондый киңәшне әлек тә ишеткәне бар иде. Шунлыктан карышып бер сүз дә әйтмәде, Балҗанны иңеннән тотып күкрәгенә кысты да, иренен маңгаена тидереп:

— Ә үзеңә?— дип пышылдады.

Кыз аның кочагыннан җитез генә шуып чыгып:

— Пәри кызына нәрсәгә ул?— дип көлде.— Шулай да сак булыйк, минем әти-әни җен-париләрдән дә катырак ачуланмасын!

Амантай янтак тутырылган капчыкларның икесен дә тирмә янына берүзе күтәреп кайтты.

Әмма аның шатлыгы, чүл язы шикелле, кыска гомерле булып чыкты. Кызылком күгендәге кояш, яна торган учак күмередәй дөрләп, яшеллекне май аенда ук саргайтып, көйдереп бетерде. Азык эзләп, малларны яңадан-яңа ераграк көтүлекләргә куа башлагач, сөт шактый азайгач, хатын-кызлар да кире кышлакларына юл тоттылар. Чалабай картның анда кечерәк балалары да бар, Балҗаннарга исә бай йортында да эш бетәсе түгел иде.

Моннан соң инде сарыклары артыннан атлаганда егет еш кына тансык кунакларны искә төшерә торган булды. Ошатты ул Балҗанны: җәенке алсу битләрен дә, озын кара толымын да, нечкә билен, йөгерек кулларын да, һәрвакыт булышырга әзер йомшак мөгамәләсен дә һәм, хәтта, бераз иркәләнеп йомыш кушуларын да! Карт чабанның аталарча мөнәсәбәтен, авырлыкны башта мөмкин кадәр үз өстенә алырга тырышуын, ярдәмчесен хуҗа алдында да һәрвакыт яклавын күптән сизә иде Амантай. Бары тик Чалабай карт аркасында гына, тамагын туйдыру һәм киендерүдән тыш, бай абзый аңа икенче елдан ук хезмәт хакына һәр көзне ике баш сарык та бирә башлады. Билгеле, ул бик начар ашата, ямаусыз кием кидерми, әгәр көтүне бәла-казадан исән-имин коткара алмасалар, кеше төсле генә каһәрләмәячәк иде. Ләкин әлегә кадәр аларны ходай саклады, үрчемне дә исән-имин алдылар, хәвеф-хәтәргә дә юлыкмадылар. Әгәр фәкыйрьлектән интеккән ата-анасы улларына тигән сарыкларның берәрсен һәм яңа туган тәкәләрне ел саен алып суя бармаса, Амантай быел инде унлап баш үз малын да көткән булыр

иде. Бәлки ул чакта өйләнү турында уйлау мөмкинлеге дә туар иде. Хәзер исә ни калым түләрлек чамасы, ни үз куышы юк, җәе-кышы чүлдә, җилдә нужа чиккән егет кемгә хаҗәт? Бәктән никахка рөхсәт алыр өчен генә дә бер сарык кирәк заманда кайда инде ул туй турында хыяллану!

Әмма Амантай хыялланмый да яши алмады. Сарыкларны төнге кутанга — текә ярлары, янтак тамырлары, ташлар белән нығытылган чокырга куып кертеп, кичке табын янына килеп утыргач, өлкән чабанга:

— Чаләкә, сез өйләнгәндә күпме мәһәр түләгән идегез?— дип сорау бирде.

Карт ашыкмыйча гына кисәүләрне казан астынарак этеп, мылтыгын исә арткарак шудырып куйды, дөрли башлаган учакка тагын берничә ботак өстәде. Аннары егетне кызартырлык итеп:

— Әллә берәрсенә яучы җибәрергә җыенасыңмы?— диде.

— Ю-ук, кызык ич, беләсем генә килә,— диде Амантай каушап калып.

— Кызыксынып кына сорасаң ярый, югыйсә, куркыттың,— диде карт көлемсерәп.— Әгәр өйләнсәң, яшь кәләшең сине чабанлыкка бүтән җибәрергә теләмәсә, ялгыз башым нишлим инде мин монда?

— Чаләкә, шаяртмагыз әле! Шулай да күп түләргә кирәктер ул, ә?

— Күп, олан, бик күп. Әмма һәркем кәләшне чамасына күрә генә сайлый. Байлар — байга, безнең кебекләр үз ишенә күз ата. Берәүләр мәһәргә олау-олау мал түгә, икенчеләр, үзара килешеп, тыйнаграк шартларда алыш-биреш ясый. Әмма мәһәрнең тыйнагы да кесәне ерта.

— Фәкыйрь егеткә өйләнү тәтеми, дисәгезче!

— Әйе, кыен,— диде Чалабай карт. Йөзе караңгыланган Амантайга каш астыннан бер караш ташлагач, өметлерәк итеп ялгады: — Тик ярлы кызларына бай егетләр генә кайдан тәтесен? Шуңа күрә ата кеше дә уйлый: тозларгамы аңа баласын, әллә егет эшчән, тырыш, намуслы, ата-анасы да ипле күренсә, күктән җиргә төшәргәме? Әйтик, синең шикелле буй-сынга да, төс-биткә дә килгән берәрсе яучы җибәрсә, нигә тәвәккәлләмәскә? Тик, балакай, малны да табарга, олы эшкә олы әзерлек күрү дә кирәк йола буенча.

Амантай бу сүзләрне тыңлаганда сулыш алырга да курыкты бугай. Бүтән бер сорау да бирмәде, ишеткән кадәресе дә бик күп тоелды аңа. Картка карата күңелендә уянган рәхмәт хисләре саксыз түгелмәсен, дулкынлануы бик сизелмәсен өчен, ул касәләр алырга дип тирмәгә кереп китте. Таң кебек саф һәм сөйкемле Балҗанның әле кайчан гына барханнар арасында йөгерә-йөгерә ташбака йомыркасы җыеп йөрүләрен, үзенең аңа ничек булышуларын күз алдына китереп, ул монда шактый вакыт караңгыда басып торды, аннары куанычлы елмаюын яшереп, кире учак янына чыкты. Кайнар суга бераз сөт салып, шуңа җүгәре[1] оныннан пешерелгән төче ипине турады һәм көтү сагында торган этләренә илтеп бирде. Соңыннан күктә йолдызлар җемелдәшә башлаганчы, әче корт белән чәй эчтеләр, калган ботка белән тукландылар. Бу минутларда сарыклар кутанда тыныч кына күши, этләр башларын тәпиләренә куеп хуҗаларын күзәтә, учактагы күмерләр сүрән генә көйри, Кызылком чүле талгын гына тымызык төн кочагына кереп бара иде. Амантайга көн дә кабатлана торган шушы тотрыклы күренештә бөек мәгънә бар сыман тоелды. Бүгенге кич кебек, аның үткән гомере дә, киләчәге дә киң сахрага кендеге белән бәйләнгән, саксаул, янтак, бозаубаш, балыккүз һәм әремнәр каплаган чүл буйлап, Чалабай карт шикелле, һәрвакыт көтү көтеп йөрсә, бу дөнья аны беркайчан да үги итмәс, борчулары, мәшәкатьләре, кыенлыклары белән бергә шатлыкларын да татытыр, дип уйлады Амантай.

[1] Җүгәре — тары сыман иген.

Менә шуңа күрә каядыр ашыкмый, йолкынмый, әллә ниләргә баш ватмый-нитми генә Кызылком сахраларын гизә бирде ул. Көтүдәге үз малы да әкренләп артасына, әнә шулай бер заман мәһәргә дә, туй ясарга да җитәрлек мал тупланасына өметләнде.

Әлеге сөйләшүдән соң өлкән чабан белән ул аерата якынаеп китте, талчыктыра торган эшләрне үзе башкарырга омтылды, аның һәр теләген ярты сүздән үк чамаларга тырышты. Картның мөгамәләсе дә торган саен йомшара төште. Алар менә шулай тату гына мал баккан арада янә бер ел узып китте.

Февраль урталары иде. Чалабай карт әле бер дә өметләнмәгәндә, азык-төлек китергән ялчы үзенә берничә көн көтү көтәргә дә кушылуын, теләсә, өлкән чабанның өенә кайтып килә алуын белдерде. Карт, әлбәттә, ике әйттермәде, иртәгесен таңнан торып, җәһәт кенә кышлакка юнәлде. Үзе юлның юл буе: бай ничек болай юмартланасы итте икән? Нинди гадәттән тышрак мәрхәмәт күрсәтүе икән бу?— дип баш ватты һәм «хәерлегә генә булсын!» дип белгән догаларын укыды.

Чалабай карт чүлгә бер атнадан соң гына әйләнеп кайтты. Әмма үзенең өендә бу юлы чагыштырмача озаграк тору сәбәбен Амантайга ялгыш та ычкындырмады. Башка вакытта ул ялдан шактый җанланып килә, учак янында тәмләп һәм тәфсилләп кышлак хәбәрләрен, зур дөнья яңалыкларын уртаклаша иде. Ә бу юлы исәнлек-саулыкны әйтте дә тынды, авызына су каптымыни. Мондый төкселекнең серен белергә бик кытыкланса да, егет аңа сорау бирергә базмады, агасының кәефе күтәрелеп, теле ачылуын гадәттәгечә сабыр гына көтә бирде. Әмма чүлнең яшәрә, былтыр кунаклар килгән айның якынлаша баруын ачыграк тойган саен, аңа кызыксынуын басу көннән-көн авырайды. Яңа туган бәрәннәр белән маташып аеруча йончыган бер кичне ул, ниһаять:

— Чаләкә, әллә безгә быел ярдәмчеләр килмәячәкме?— диде.

Карт чабан, Амантайның кемне зарыгып көтүен яхшы чамаласа да, егетне өметләндерергә ашыкмады. Сүрән генә:

— Бай үз файдасын кайгыртмый каламы соң? — дип куйды.— Быел ул минем хатын белән уртанчы кызымны эшкә җигәргә җыена.

— Ә Балҗан?

Юк, телгә алмаска кирәк иде Амантайга бу исемне. Әмма ул аны ничек әйтеп салуын сизми дә калды. Инде соравы бер авыздан ычкынгач, уңайсызланып җавапны көтми хәле юк иде.

— Балҗанмы? Балҗан хәзер инде, улым, туган кышлагыннан еракта-еракта. Ходай мәрхәмәтеннән ташламасын балакайны!

Алар беразга икесе дә тынып калдылар. Кичке эңгер куерса да, учак кабызырга нигәдер куллары бармады, ашыйсылары килгән этләрнең шыңшуына да игътибар итмәделәр.

— Тәкъдире шундыйдыр инде,— дип өстәде аннары карт чабан.— Кышлакка бәкнең бер танышы килгән булган икән. Менә шул безнең байда кунакта утырганда, Балҗанга күз салган. Кызыбызны икенче хатынлыкка алырга теләк белдергән. Миңа ашыгыч ял бирүләренең дә сәбәбе шул булган икән...

Амантай мондый ук рәхимсез хәбәрне көтмәгән иде. Тирә-якта яңгыраган авазлар шунда ук бер-бер артлы тоныкланды, якындагы кое бурасы һәм улаклар да, киез өй һәм аның алдына утырган иптәше дә, этләр һәм сарыклар да куе томан эченда калгандай юкка чыкты, әле яңа гына җемелди башлаган биек күк гөмбәзе дә хәзер аның өчен төнлеге ябылган караңгы һәм тәбәнәк тирмәгә охшап калды. Йөрәге исә, капкынга эләккән җәнлектәй, бәргәләнеп сикерергә тотынды.

Нәрсә дип айлар-еллар буе кеше малын көтә инде ул? Ни дип күрәсен күргән, яшисен яшәгән Чалабайга ияреп, шуңа иш булуына юанып, егет башы белән мәхлук сарыклар артыннан теркелди, катып беткән бер сынык ипи, бер уч корт һәм сүсәреп беткән иске чапан ха-

кына ястык кадәр болыт та мәкан[1] итәргә теләмәгән, алла каргаган шушы Кызылком чүлендә сөйрәлә? Иркен иген кырлары, хозур күләгәле бакчалары, матур-матур утарлары белән күз явын ала торган үзәннәре дә бар лабаса бу җир йөзенең. Нигә соң әле сахрадагы ком буранының нәрсә икәнен дә белмичә, бар хатыны өстенә тагын берне — яшьрәк һәм чибәррәк кәләшне алып рәхәт чигүче бәндәләр генә яши анда?

Амантай дәшми-тынмый аягына торып басты да, учак тергезеп маташкан Чалабай картка сыңар күзен дә салмастан, караңгы чүл буйлап атлап китте. Юк, яшәргә әйбәт җир сайламаган икән аның ата-бабалары. Егәрле чакларында шушы тозлы туфраклы, куна тактасыдай тигез, такыр җирдә яки җыерчыклары эчне пошыра, комы, кызган мич төбедәй, аякны пешерә торган боек сахрада гомер буе кеше малын көткәннәр, сакаллары чалара башлаганда көчкә гаилә корганнар һәм ялчыларның яңа буыннарын үстергәннәр...

Бәлки әле тынычланган, шушы язмышына күнгән һәм моннан соң да бик озак Кызылком чүлен аркылыга-буйга таптауны дәвам иткән булыр иде Амантай. Әмма озакламый бер төнне көтүгә бүреләр һөҗүм итү һәм чабаннар уянып, мылтыкларын эләктереп килеп җиткәнче унлап сарыкны буып ташлау егетне тәмам чыгырыннан чыгарды. Чөнки бу бәхетсезлекне ишеткәч, малларын карарга килгән хуҗа барлык гаепне ваемсыз хезмәтчеләренә сылтады — ботарланган сарыкларның өчәр башын көтүчеләр исәбенә язып куйды. Нәфрәте кузгалган Амантайны моннан соң инде барханнар арасында богаулап куеп та тоту мөмкин түгел иде. Ул бүреләрнең һәм хуҗаның чираттагы «гадел» хөкемен татыганчы, шактый киселгән дүрт еллык хезмәт хакын — исән калган биш баш бәрәнен алып, тизрәк ата-анасы янына кайтуны карады. Моннан инде язмыш аны туп-туры Каганга, мамык тазарту заводына алып килде һәм 1920 елның даулы августында әмиргә каршы күтәрелгән халык сафына бастырды.

## 8

Эксперт белән таныклар, беркетмәгә кул куеп, бүлмәдән чыгып киткәннән соң, Юлтай Симиниев иптәшенә:

— Барысын да тиешенчә эшләдек кебек инде,— диде.— Тик Байкучатовның каршы тырнавы гына эчне пошырды. Ат дагалаганда бака ботын кыстыра, ди. Бу да йөри шунда тырнак астыннан кер эзләп.

— Әйе шул,— дип җөпләде аны Латыйфхан.— Уртак Әминев аны безгә ни дип кушып җибәрде икән?

— Белмим, кардәш. Мин әле монда ул үзе килер дип көткән идем. Ни әйтсәң дә, хәрби комиссар һәлакәте олырак дәрәҗәле түрә катнашуын сорый ич. Ә ул Чекада калуны хубрак күрде. Серле...

— Үзе килмәве яхшырак та булды анысы, әмма безгә сылап җибәргән әтәче дә дөнья болгатырга бик җитәр кебек.

— Әйе, аның әле соңрак та үз сүзен куып йөрүе бик мөмкин.

— Әгәр мин Әбдиев аркылы кайберәүләрне кисәтеп куйсам, ничек булыр?

— Һәрхәлдә, зыян итмәс. Хәер, Гарипов белән үзем дә сөйләшермен әле,— диде Юлтай.— Егетнең итәгеннән тартсыннар бераз, җинаятьне тикшерүгә тулаем үзем җавап бирә торып, баш өстемнән кеше йөртергә теге...

— Әллә Шиһабетдинов белән элемтәләре булды микән?

— Хәзер инде моны ачыклаудан файда әз. Буш вакыты артык күплектән акыл сатадыр, эшне өебрәк бирербез аңа киләчәктә.

[1] Мәкан — тору урыны.

— Әминев уртак[1] юл куймаса?

— Чека эшен без генә тартырга тиешмени?— дип көлемсерәде Юлтай.— Байкучатов яшь, дәртле — көчен кая куярга белми йөри. Бәхетенә, дошманнары да мулдан, менә көрәштә күрсәтсен әле үзен!

Нурморатов бөтен йөзенә елмаеп:

— Җөдә[2] тугры,— дип баш какты.— Бу егет йә кайберәүләрне яндырачак, йә үзе муенын сындырачак.

— Артык дуамал кизәнә, соңгысына тизрәк ирешер ул,— диде Юлтай кырысланып.— Фронттан исән кайтуын гына кара син аның. Әйе, кайчак газраил лаеклы корбанын таба алмыйча интегә шул, Латыйфхан кардәш!

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә бүлмәдән чыктылар һәм ишек төбенә үзләре ияртеп килгән ике солдатны сакка куеп, мәет янына ят кешеләрдән берәүне дә кертмәскә кирәклеген аңлаттылар. Аннары капка төбендә сүзләре башкага күчте.

— Рахманкол турында да кайгыртырга кирәк безгә,— диде Юлтай тавышын әкренәйтә төшеп.— Байкучатов ишеләр каныга башласа, нәрсә килеп чыгасын берәү дә төгәл генә әйтеп бирә алмас. Ходай, саклаганны саклармын, дигәнме әле?

— Бөтенләй гөнаһсыз егет инде ул, кызганыч,— диде Латыйфхан.— Бәлки аңа Бохарадан хәзер үк китеп бару хәерледер?

— Бу кайберәүләрдә шик кенә уятачак.

— Алайса нишләсен икән соң ул?

Симиниев, иярен тикшереп караганнан соң, беравык урамга колак салып торды — әле кышлак уянмаган, тирә-як, чүлдәге кебек, тын иде. Ишегалдында постта калган гаскәриләрнең мыдыр-мыдыр гәпләшүләре исә монда ишетелеп җитми, алар да мәетле җирдә саграк булу кирәклекне истә тоталар иде, ахры. Нурморатов атын сыйпаштыргалап, иптәшенең телгә килүен сабыр гына көтте.

— Рахманколны, әлегә берәр йомыш кушып, кая да булса җибәреп торырга мөмкин, әлбәттә, анысы кыен эш түгел,— диде ниһаять, Юлтай.— Бәлане Байкучатов чыгаруы ихтимал, аңардан менә күз язмау әһәмиятлерәк. Мин аны беркөнне «Кызыл шәрык» агитпоездында да күргән идем инде.

— Андагылар җыенысы «бөтендөнья революциясе» дип кенә авыз чайкый икән, шаукымга җөдә каты бирелгәннәр.

— Әйе, Гарипов сөйләде инде, суллар күп кереп тулган анда,— дип раслады Юлтай.— Байкучатовның агитпоездга ешлатып җибәрүе тикмәгә генә булмагандыр. Ташкент партия мәктәбеннән килүчеләр белән дә әшнәлеге сизелә. Кызу егет, кыскасы, ярты юлда тукталып кала торганнардан түгел шикелле.

— Чекада кызулык имәс[3], баш белән уйлап эшләү кирәгрәк,— диде Латыйфхан.— Сезнең шикелле сабыр, әмма төпле уйлап хәрәкәт итүчеләр генә максатка ирешә.

Симиниев, иптәшенең салам кыстыруын сизсә дә, мактауны кире какмады, нәкъ шулай тиеш төсле кабул итте. Хәзер инде ул бигрәк тә сүзне үзен борчыган нәрсәгә боруны хуп күрде.

— Әминевнең монда килмәве хәерле булса да, Чекада калуы сәерсендерде әле,— диде ул шөбһәсен уртаклашып.— Ул болай безнең вазифаны, бер яктан, шактый җиңеләйтте җиңеләйтүен, әмма абзыкаебыз моны аңлы рәвештә эшләмәдеме икән?

— Башка хәтәррәк нәрсәләрне сизенгәндер, дип уйлыйсызмы?

— Бары шунлыктан гына калырга тиеш ул кәрвансарайда. Без юлга чыгу белән каршы чаралар да күрә башлагандыр.

[1] Уртак — иптәш.
[2] Җөдә — бик.
[3] Имәс — түгел.

— Ә үзе шундый юаш, беркатлы кеше кебек тоела,— диде Латыйфхан гаҗәпләнеп.

— Итәрсең аны юаш! Шулай йомшак җаеп, мине катыга утырткалады инде ул. Бу юлы да үзен бик тиз кулга алды кебек.

— Тик барыбер авыз ачып калды шул. Революция Бохара егетләренә дә җан кертте, алар хәзер ил гамен үзләре кайгыртырга тели.

— Шулай булса, бик әйбәт,— диде Юлтай,— без аларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Ашыгыйк!

Алар атларына атланып, эшлекле төстә дәррәү кузгалдылар һәм, кышлакны чыкканчы ук камчыларын болгый-болгый юртакларын чаптыра башлап, тиздән тузан болыты эчендә күздән югалдылар.

## 9

Инде Бохарага килеп җитәргә дә күп калмаган, Байкучатов исә әле һаман Амантайны тыңлап бара иде. Каршы капкасы алдында отрядның икегә аерыласын, Туктаров взводы шәһәргә кермәстән Ситтәрәи-Маһи-һуса ягына китәчәген исендә тотып, озаккарак сузылган кыйссага эче пошкан Фарукҗан:

— Амантай иптәш, моның Шиһабетдинов һәлакәтенә ни катнашы бар соң?— дип эндәште.

— Хәзер, хәзер әйтәмен, җулдас командир,— диде сүзе бүленүдән курыккан Туктаров.— Әңгәмәмнең нәкъ шул җиренә килеп җиттек менә.

— Сузма, Амантай, вакыт тар.

— Яхшы, җулдас командир...

* * *

Моннан бер ай чамасы элегрәк бер кичне Туктаровлар взводын шәһәрдә тәртип сакларга җибәрделәр. Амантай иптәше Иргәш Мирәхмәтев белән Мирдустым мәхәлләсе буйлап атлаганда, каршыларына бер хатын-кыз килеп чыкты. Башта кызыл гаскәриләр аңа игътибар да итмәде, әле караңгы төшеп җитмәгән урамда кем йөрмәс. Кыяфәте дә гап-гади: пәрәнҗә бөркәнгәнлектән, йөзе күренми, әмма киемнәрә әллә кайдан: «мин — фәкыйрь!» дип кычкырып тора иде. Аягында арзанлы кәвеш, пәрәнҗә астыннан чыккан күлмәк итәге, ыштан балагы да затлыдан түгел. Менә шуңа күрә хатын-кыз турысыннан патруль тыныч кына узып китте. Тик берзаман артына борылып карагач кына, Амантай хәвефләнә калды һәм терсәге белән иптәшенә төртеп, узгынчыга баш изәп куйды. Хәзер инде ипле генә болар әзеннән атлаучының баягы хатын-кыз икәнен таныгач, Иргәш тә шомлана башлады. Мондый хәтәр кичләрдә пәрәнҗәдән дә хыянәтчел кием юк. Ир-ат бөркәнгәнме аны, хатын-кызмы, астына хәнҗәр яшерелгәнме, наган яки бомбамы — шайтан белсен! Шулай да алар сер бирмәде, алга таба баруларын дәвам иттеләр. Баруын бардылар, тик «пәрәнҗәне» дә онытып бетермәделәр. Күләгә кебек, һаман артларыннан килүен күзәткәч, Амантай түзмәде, капылт кына борылды да туп-туры тегенең каршысына килеп басты.

— Сез кем? Нишләп безгә иярдегез?

Башта үксегән тавыш ишетелде, аннары сак кына пәрәнҗәнең чәчваны ачылды. Туктаров баскан урынында исе китеп катты да калды: аның алдында, күз яшьләрен агызып, Балҗан басып тора иде.

— Син?.. Ничек соң әле болай монда? Ничек?

Амантай, үзенә-үзе хисап бирмәстән, күкрәгенә килеп капланган якын кешесен иңнәреннән кочып алды да һаман бер үк сүзләрен кабатлады. Аерылышуларыннан соң инде ел ярымлап вакыт үткән,

бер дә исеннән чыгармаса да, ул аны бүген һич тә шушында — Бохара урамында очратырмын дип көтми иде. Җитмәсә, әле кайчан гына чүлдә, беләген сызганып, йөзен капламыйча йөргән кешесен хәзер баштанаяк чүпрәккә төренгән халдә, әле кайчан гына елгырлыгы, сылулыгы белән бөтен тирә-якка ямь, шатлык тараткан кызны болай боек, болай суырылган, кызганыч калтыранган һәм үксегән хәлдә күрүне!

— Я, тынычлан, зинһар, тынычлан! Югыйсә кеше әллә нәрсә уйлар. Ни булды соң, аңлатсана ичмасам?

— Ми-ми-не ирем ку-ы-ып чыгарды!

— Сез Гыйждуванда яши идегез имәсме соң?

Балҗан бераз тынычлана төште һәм, күз яшьләрен сөртеп, башын күтәрде, аннары Иргәшнең якынлашуын чамалап, чәчванын каплады. Амантай иптәшенә бер читтә көтеп торырга ымлады да әле һаман җавап бирмәгән хатынга төбәлде.

— Аның төп йорты Бохарада, Гыйждуванга ул килеп-китеп кенә яши иде,— диде Балҗан.— Түнкәреш булгач, мине дә төп йортына алып китте, Гыйждувандагы мин яшәгән өен сатты.

— Кайчан куып чыгарды соң әле ул сине?

— Атна-ун көн чамасы элегрәк.

— Хәзер кайда торасың?

— Күршеләрдә иде. Тик алар, ирем белән тәмсезләнәсе килмәгәнлектән, мине баштан ук теләмичә генә керттеләр, бичарадан-ничара гына. Үзем дә шулай гына торам. Бүтән барыр урыным юк...

Балҗанның яңадан сулкылдарга тотынуын сизеп алып, Амантай башка сорау бирмәде. Ата-анасыннан еракта, ят шәһәрдә сыенып кешесе калмаган, аңардан тагын нәрсә төпченергә мөмкин иде инде? Шуңа күрә иңенә кагылды да:

— Әлегә без сине туктаган шул өеңә озатып куйыйк,— диде.— Кайгырма, хәзер революция булды, моннан соң берәүгә дә кеше җәберләргә ирек бирмәбез. Бүген шунда кунып тор инде. Тик артык ут йотма, иртәгә үзем хәстәрен күрермен дә килеп алырмын. Хәзер эштә әле мин.

— Кайда? Мин сине очраткач шул кадәр сөендем, Амантай!

Балҗанның йөзе яктыра төште, иске-москы киемнән бүтәнне күрмәгән егетнең хәзерге пөхтә өс-башына, үз-үзен тотышына ул гаҗәпләнеп һәм сокланып күз салгалый иде. Моңа кәефе килгән Амантай елмаеп:

— Көт, кара аны!— дип сүзен бетерде.

Икәү генә калгач, Амантай Иргәшкә бу хатын-кызның кем булуын, нинди бәлагә таруын һәм үзенең ни өчен булышырга тиешлеген аңлатып бирде. Мамык тазарту заводында ук бергә эшләгәнлектән, Иргәш иптәшен яхшы белә иде, аның бу «пәрәнҗәгә» чын мөнәсәбәтен дә бик тиз чамалап алды. Төнге патрульдән кайтуга, кардәшләре белән киңәшкәч, Балҗанны үзләрендә урнаштырып торырга тәкъдим итте. Амантай моңа, әлбәттә, шатланып риза булды һәм кичкә таба Чаләкәсенең кызын Каганга алып кайтты.

Шуннан соң нишләргә тиеш иде инде ул? Җәйләүгә килеп бер-ике ай торган кызга гашыйк булуын, ләкин озакламый аны мәңгегә югалтуын әллә кайчан төшенгән иде Амантай. Кайгысы таралып, күңел ярасы төзәлеп килгәндә генә яңадан күрешкәч, Балҗанның бу очрашуга биниһая куануын, үзенә иналеп каравын, тагын нәрсәләрдер өметләнүен бик ачык тойды ул. Каганга килгәндә юл буе үзен кияүгә ничек көчләп бирүләрен, яңа тормышының бик үк рәхәттән булмавын тикмәгә генә сөйләмәгәндер. Хәзер аны ире талаклау гына түгел, өеннән дә сөргән, ә Амантай әле һаман буйдак, Балҗаннан әле дә суынмаган иде. Каганда үзе урнаштырса да, киләчәктә аның янына барып йөрү болай гына шәригатькә сыймаячак иде. Бу юлы да агач атка ат-

ланып калмас өчен, араны мөмкин кадәр тизрәк һәм ныграк бәйләргә кирәклеген Амантай алдына язмыш әнә шулай кабыргасы белән куйды. Моны Иргәш тә яхшы аңлаган иде, ахры, аларның тарихын отряд командирына, ә анысы исә үзенең турыдан-туры буйсынган кешесенә — Шиһабетдиновка ачты. Шуннан соң хәрби комиссар Туктаровны чакырып алды да:

— Дөрес эшләгәнсез, энем, ниятегез дә әйбәт,— диде.— Ирегебезне буучы, безгә кешечә яшәргә комачаулаучы хәшәрәтләр өерен генә туздырып бетерик, дөньядагы барлык Амантайлар, Балҗаннар үз язмышын үзләре хәл кылачак. Хәзергә кыенрак, билгеле, әмма бирешмәгез. Көч бездә, яклардбыз. Өйләнегез дә хатыныгызны эшкә урнаштырыгыз.

Шиһабетдинов бераз акча да биргәч, Амантай бөтенләй канатланып китте, шул көнне үк кечкенә мәҗлес җыеп, никах укытты. Балҗан Иргәшнең кардәшләре өендә, үзе әлегә казармада яшәсә дә, алар хәзер бәхетле иде.

Иртәгәсен Туктаров хатыны белән Бохарага китте. Теге акчага берәр кием сатып алып, Балҗанга бүләк итәргә тели иде ул. Әмма яшь өйләнүчеләр Сүзәнгәрән мәдрәсәсен һәм аның янындагы кәрвансарайны узып, шау-шулы базарга килеп җиткәндә генә, каршыларына кораллы өч кеше килеп басты. Аларның яхшырак киенгән түрә кыяфәтлесе, бүксәсен киереп, бәйдән ычкынган эт төсле, Балҗанга ташланды:

— Син нәрсә монда әллә нинди ят ирләр белән себереләсең? Танымыйсыңмы әллә мине?

Амантай, үзен хуҗа сыман тупас тоткан кешегә таң калып, алгарак чыкты да:

— Сез нәрсә болай бәйләнәсез? Мин — хәрби назыйр карамагындагы махсус отряд сугышчысы,— диде.

Тик аның хатынына очып кунган әлеге гайрәтле зат, Туктаровны читкә кагып җибәрде дә, Балҗаннан:

— Кемең бу?— дип сорады.

— Ирем.

— Ә мин кемең? Кара син чая бер тиенне... Журалар! — дип эндәште һаман әтәчләнә биргән ир үзенең иптәшләренә,— революция хатыннарга берьюлы ике ир белән никахка керергә кушамыни? Менә бу оятсыз — минем хәләл җефетем Балҗан. Аның хәзер ни лыгырдаганын ишеттегезме?

— Алладан җаяү качкан бәндә шул икән ич, уртак Әбдиев,— диде аңа ярарга атлыгып торган бер иярчене.— Пәрәнҗәсен дә салып аткан кү!

Хәзер инде Амантай кемгә юлыгуларын төшенгән иде. Шуңа күрә, Балҗанны кулыннан җитәкләп, тизрәк шикле төркем уртасыннан чыгып котылырга омтылды.

— Бәйләнмәгез, ул минем хатыным!

— Хатыным? — диде мыскыллы тавыш белән Әбдиев.— Күптәнме? Аны кайчан калым түләп алдың соң әле? Йола буенча башта мине бәхилләтергә кирәк иде. Сиңа шәригатьне бозарга кем рөхсәт бирде? Кызыл гаскәри имеш, өркетте. Ә минем кем икәнемне беләсеңме соң син? Ревком тәрәге! Синдәй солдатлар безнең карамакта йөзләгән-меңләгән, аңладыңмы? Бар, юлыңда бул, югыйсә бик тиз акылга утыртырмын!

Балҗан ул арада кычкырып елый ук башлады. Әбдиевнең иптәшләре исә сүгенә-сүгенә Туктаровны читкә кысрыклады. Шул вакыт, гаугага җыелган халык төркемен ерып, мәйдан уртасына ниндидер фаэтон якынлашты һәм яшь хатынны утыртып, күз ачып йомганчы базар ягына чаптырып алып китте.

Монда сырт кабартып ялгызы гына бер эш тә чыгара алмаячагын

төшенгән Амантай, кыйналган мал шикелле, авыр сулап, кайту юлына борылырга мәҗбүр булды.

Каганга уралгач, каныша тоз салган бәрелешне сөйләп биргән иде, отряд командиры ни өчендер Туктаровка булышырга ашыкмады. Шиһабетдиновны күрергә кушты. Хәрби комиссар исә әллә кайда юкка чыккан иде. Амантайның йокысы качты, тамагыннан ризык үтмәде, башына әллә нинди хәвефле уйлар керде. Гыйждуванда бәк тылмачы булган чагында ук кансызлыгы, ришвәтчелеге белән халык арасында нәфрәт казанган кеше революциядән соң ничек шулай бик тиз тагын аякка баса алды икән? Андый намуссыз җаннан нинди мәрхәмәт көтәргә мөмкин? Бер куып чыгарган кешесенә нишләп болай чәер кебек ябышты соң әле ул яңадан? Аннан башка да хатыны була торып...

Амантай әнә шундыйрак уйлар эчендә инде ничәнче көн тинтерәп йөргәндә, Балҗан аны үзе килеп тапты.

— Качтым мин,— диде ул мышкылдап.— Өстемнән бикләп, ишегемә каравыл куеп киткән иде теге ерткыч, хәйләләп чыгып тайдым читлегеннән. Хәзер нишлибез инде, Амантай?

— Ул сине кыйнадымы?

— Юк,— диде Балҗан.— Кулы тимәде, кичтән аңа ниндидер кунаклар килде.

— Нишләде генә соң ул?

— Ирләр безне гадәттә нишләтә инде,— диде еламсырый башлаган хатын.— Бу ерткыч та...

— Кабәхәт! Син дә инде, аяклы каза! — диде Амантай йөрәге дулавына чыдый алмыйча.— Юлда ук ычкынырга иде аны!

Тик ул гайрәт орырга ашыгарак төшкән булган икән, ярты сәгать тә үтмәде, аларны Бохарага алып китәргә җибәрелгән кораллы милиционер килеп җитте. Әбдиев инде Амантай өстеннән кәгазь язып бирергә дә өлгергән иде.

Кем чакыртуын Туктаров белмәде. Ревкомның зур эшлеклесе хозурына керүен генә чамалады. Кабинет хуҗасы Гарипов килүчеләрне коры гына каршы алды да Амантайга:

— Кызыл гаскәри Туктаров, сез нигә болай кеше ашына катык катырга керештегез әле? — диде.

— Балҗан аш түгел, нәкъ безнең кебек үк кеше.

Амантай үз бәхетеннән хәзер һич тә җиңел генә колак кагарга теләмәде. Аның җавабы Гариповка ошамады.

— Күрәм,— диде ул тавышын күтәреп,— сез суган сатарга хирес икән шул. Тик буй җитмәс нәрсәгә үрелү файдасыз. Бераүнең никахлы хатынына нәфес сузу җинаятьнең дә җинаяте.

— Балҗан хәзер минем хатыным,— диде Амантай үзсүзләнеп.— Элекке ире аны талаклаган, без шуннан соң никах укытып кушылдык. Әбдиевкә калган хатыны җитмиме икән әллә?

Гарипов аның кыю сөйләшүен өнәмәдеме, аягына торып басты. Урта буйлы, имән кискәседәй, таза гәүдәле ир икән, галифе, кительдән, күн итектән. Амантайны баштанаяк күздән кичерде дә:

— Туктаров, кая килүегезне онытмагыз! — дип искәртте.— Бәхәсләшеп торырга вакытым юк. Ничәгә өйләнү һәркемнең үз эше, тик шәригатькә генә туры килсен. Әбдиев бу хатынын да бар йоласын китереп — калымын түләп, никахын укытып алган. Аның талак кычкыруына таныкларыгыз бармы?

Мәлҗерәп төшкән Балҗан кирәкле сүзен әйтәсе урында тагын балавыз сыга башлады, дулкынланудан Амантай да телдән язды. Гарипов исә кырыс кына дәвам итте:

— Таныкларыгыз юк. Менә шуңа күрә ашыгып укыткан никахыгыз да дөрес түгел инде. Без монда гадәләт комиссары белән дә киңәшеп алдык. Әгәр тагын Әбдиев җәмәгатенә дәгъва белдереп йөрсәгез, үзегезгә үпкәләгез. Оятыннан тыш җәзасын да татырсыз ул чакта. Хә-

зер бәхәсегез хәл кылыну турында боерык язам, болдырда көтеп торыгыз.

Комиссар кабинетыннан чыгуга, Балҗан Амантайга сарылды да зарларын такмаклый-такмаклый иңри башлады. Чәчләре тузган, ябык гәүдәсе дер-дер калтырый. Аны кызганудан, хөкемнең гаделсезлегенә нәфрәтләнүдән, Туктаровның да җаны актарылды. Менә шул вакыт болдырда ул ничә көн эзләп тә очрата алмаган Шиһабетдинов пәйда булды. Амантайны танып алды да:

— Нинди җәнҗәл бу, йөзегездән кан качкан? — дип эндәште.— Нишлисез монда?

Ярдәмнең кичегүенә ачыныпмы, Туктаровның бугазына кайнар төер килеп тыгылды, аны ничек кирәк алай йотып җибәрсә дә, күз төбеннән тәгәрәгән эре тамчыны тыеп кала алмады.

— Әнә... хатынымны миннән тартып алалар.

— Кемнәр ала?

— Әбдиев әшнәләре. Менә мондагы комиссар, Балҗанны элекке иренә кайтарырга, дип әмер язып утыра. Безне көчләп аералар!

Шиһабетдинов аларның кызганыч кыяфәтләренә бер мәл игътибар белән карап торды да, Туктаровлар әле генә чыккан бүлмә ишеген кискен генә каерып ачып, кабинет хуҗасы каршына килеп басты.

— Сәлам, Габделхәмит иптәш! Нәрсә язасыз?

Амантайлар белән әле генә яман да эре сөйләшкән түрә кеше тәкәллефсез сораудан каушап калды. Коридордагы аңлашуны ишетеп торганлыктан һәм хәрби комиссарга теше үтмәячәген сизгәнлектән күңеле төштеме, сүзне бүтәнгә күчерергә тырышып, тыенкы рәвештә:

— Нигә бу кадәр җилле бәреп кердегез әле монда?— диде.

Тик Шиһабетдинов дилбегәне кулыннан ычкындырмады.

— Нәрсә язасыз?

Ревком рәисе урынбасары Габделхәмит Гарипов, мин-минлеген тыя алмыйча:

— Сезнең ни эшегез бар соң?— дип мыгырданды.

Хәрби комиссар кайнар канлы кеше иде, чуен йодрыгын бар көче белән өстәлгә китереп орды да:

— Бар шул. Чөнки мин Бохара революциясенә хезмәт итәм! — диде.

Кара савыты сикереп, аның бар буявы өстәлгә түгелде һәм каләм кыштырдатып утырган Гариповка чәчрәде. Ул арада Шиһабетдинов аның кул астындагы язылып бетмәгән боерыкка күз йөгертеп:

— Сез халык хөрриятенә шулай хезмәт итәсезмени? — дип сорады.— Ревкомның үзендә утырып!

— Хөррият ул башбаштаклык, канунсызлык түгел.

— Берәүнең сөйгән кызын көчләп икенче хатынлыкка тартып алу, сезнеңчә, гадел, канунга сыя торган эш инде, ә?

— Калымны түләп, никахлап...

— «Калым» дигән нинди сафсата ул? Халыкны талаучы кабәхәт әмир өеренә калым түләү нәрсә иде? Төкерек кенә! Ә көне-төне чүлдә бай малын баккан көтүче Амантай елына сыңар тәңкә дә ала алмаган. Нәкъ менә әлеге әмирегез, бәкләрегез кануны аркасында! Шул да, сезнеңчә, гаделлек булганмы?

— Юк,— диде ниһаять Гарипов.— Әмма без шәригать буенча оешкан гаиләләрне тота-каба тарката алмыйбыз. Шикаять биргән Әбдиев өйләнгәндә калымга унбиш баш сарык түләгән. Шуларны кайтармыйча...

— Ху-у-уп,— диде Шиһабетдинов Ревком эшлеклесен карашы белән бораулап.— Менә сез — айнык акыллы кеше инде, Габделхәмит иптәш, ә?

— Шулай дип уйлыйк.

— Сез сәүдәгәрләрдән күлмәкләр сатып аласыз. Аларны тишелеп

беткәнче киясез икән, соңыннан, «товарыгыз тузды», дип әлеге сәүдәгәрләрдән акчагызны кире даулап йөрисезме?

— Юк, әлбәттә.

— Соң, калымга унбиш сарык түләгән бу ачкүз Әбдиев тә Балҗанны унбиш ай файдаланган лабаса инде. Җитәрлек туздырган!

Гарипов көлеп җибәрде.

— Тапкыр! Җиңдегез бу юлы.

— Ә хәзер, әйдәгез, әмерегезне болай төзәтик: «Икенче хатынына көчләп өйләнүен, түләгән калымы бәрабәренә аны җитәрлек хезмәт иттерүен истә тотып, шикаятьче Әбдиевнең дәгъвасын кире кагарга. Чалабай кызы Балҗанның Амантай Туктаров белән никахка керүе шәригатькә туры килүен танырга».

Шиһабетдинов Ревком рәисе урынбасарының элекке әмерен ертып ташлавын һәм яңасын теләмичә генә язуын, кул куеп, мөһер сугтырып, аны рәсмиләштерүен көтеп торды да, шул кәгазьне тотып тышка чыкты. Амантай белән Балҗанга карап:

— Менә сезгә никах  танытыклыгы! — диде.— Барыгыз, өегезгә кайтыгыз. Моннан соң сезгә берәү дә бәйләнмәс, берәү дә кагылмас!

Оператив отряд шәһәрнең Каршы капкасына килеп җиткәч, Байкучатов боерыгын көтеп, туктап калды. Амантай командирының түземсезләнүен күреп, соңгы сүзләрен әйтергә ашыкты:

— Җулдас Байкучатов, Бакә кайнар канлы, кыю йөрәкле, үтә дә гадел адәм иде,— диде.— Ул Әбдиев белән теге комиссарның хөкемен юкка чыгарып кына атмады, аларны Ревком җәнә хөкүмәт аппаратыннан себереп түгүне дә таләп итеп, җулдас Фәйзулла Хуҗаев белән дә сөйләште.

— Кайдан беләсез?

— Үзе әйтте. Шуннан соң минем аларны бүтән очратканым юк. Аңлыйсыздыр, мондый яман кешеләр Бакәгә теш кайрамый калмаска тиешләр иде.

— Аларны Бохарададыр дип уйлыйсызмы?

— Белмәймен, аныкларга иде,— диде Амантай.

— Яхшы, туган. Син анда үз иптәшләрең арасында бу кешеләрне яхшырак белүче берәрсен тапмассыңмы, эзләп кара әле. Тик кызыксынуыңны бик сиздермә.

— Җарар, җулдас командир.

— Аннары иртәгә кичке сәгать алтыда Газәли мәхәлләсенә мәчет янына кил. Хәрби киемеңне салып алыштыр, мылтыгыңны калдырып тор. Чалма, чапан таба алырсыңмы?

— Тырышырмын, Иргәш булышыр әле.

— Тик кая барасыңны берәүгә дә әйтмә. Авырыйм, диген, я бүтән берәр сылтау тап. Яшь кияүнең кичен юкка чыгарга атлыгуын гаеп итмәсләр, аңларлар, дип уйлыйм. Шулай да командирыңны үзем кисәтермен. Аңладыңмы мине?

— Әйе.

— Көтәчәкмен. Сау бул!

Байкучатов камчысын болгап, тимер-күгән колонна башына элдертте һәм, взвод командирларына соңгы әмерләрен биргәч, отряд белән саубуллашты. Сугышчылар ике төркемгә аерылып, һәркайсы үз казармаларына юл тотты. Фарукҗан исә, Чека башлыгына хәбәр бирер өчен, кәрвансарайга юнәлде.

## 10

Байкучатов, бүлмәсенә кереп, аяк өсте генә тамак ялгады, чәй урынына берничә телем карбыз белән генә сусынын басып, ашыга-ашыга

запас атларның берсенә атланды да чаптырып кәрвансарайдан чыгып китте. Әмма юл буе куып барса да, Кагандагы матәм сәгатенә бераз кичекте. Вокзал мәйданы кызыл гаскәриләр, эшчеләр һәм диһканнар белән тулган, уртадагы кызыл комач ябылган биек өстәлдә чәчәкләргә күмелгән табут калкып тора, шуның янәшәсендәге арбага менеп баскан чалма-чапанлы берәү кайнарланып үзбәкчә нотык сөйли иде. Фарукҗан аның калын кашларына, озынча йөзенә, җыйнак гәүдәсенә, җилбәгәй җибәрелгән буй-буй сызыклы чапаны эченнән күренеп торган европача киемнәренә бер күз ташлагач ук, сөйләүченең Халык Комиссарлары Советы рәисе Фәйзулла Хуҗаев икәнен чамалап алды. Аннары атын телеграф баганасына бәйләп куйды да, ризасызлык белдергән кешеләрне этә-төртә, табут янынарак якынаерга тырышты.

— Уртаклар! — дип дәвам итте ялкынлы тавыш,— мәрхүм Баһаветдин ерак Идел буенда туып үссә дә, аның барлык аңлы тормышы Төркестан михнәткәшләре[1]— Төркестан эшчеләре сафында үтте. Мөхтәрәм дустыбыз кадимчеләргә каршы көрәштә, Ташкентта совет хакимиятен урнаштыруда җаны-тәне белән катнашты. Төркестан Кызыл Гаскәрен оештыруга бөтен көчен биреп, кәмбәгалларны-ярлыларны яклар өчен Җидесу өлкәсенә барды, Верныйдагы залимнәр — икейөзле атаманнар һәм азгын байлар фетнәсен бастыруга күренекле өлеш кертте. Коминтерн вәкиле уртак Куйбышев әйткәнчә, Шиһабетдинов үзбәк, казакъ, уйгыр, дунгән, татар кәмбәгалларының күзен ачу, алар арасында аң-белем тарату, революцион фикер уяту вә залимнәргә каршы күтәрү өчен җөдә күп көч түкте. Төркестанның атаклы җәмәгать хадимен вә хәрби юлбашчысына әверелде. Әмир гөруһына ут ачкан Бохара әһле менә шуңа күрә аны үзенә ярдәмгә чакырды...

Фарукҗан янәшәсендәге колакка катырак бер абзый күршесенә:

— Нимә гәперәде[2] ул? — дип эндәште.

— Мәрхүм назыйр дөрес адәм иде,— ди.— Кәмбәгал[3] иде, безгә булышырга килгән иде, вакытсыз харап булды, дип кайгырады.

— Комнан бау ишәдер икән күң,— диде саңгырау абзый.— Бер кәмбәгал үлгәнгә сәүдәгәр Хуҗаев чынлап пошынмас, бикәр[4] сүз гәперәде икән.

Фарукҗан сәер абзыйга кызыксынып бер карап алды да, халыкны ерып, тагын да мәйдан уртасынарак елышты. Әмма табут янына ук барып җитмәде, Әминев, Симиниевләр күзенә чалынудан сакланды. Хәер, хәзер инде моннан да һәммәсе әйбәт күренә, яхшы ишетелә иде. Җыйналган халык шактый чуар, әмма арба тирәсен кызыл гаскәриләр, Каган эшчеләренең тыгыз сафлары чолгап алган, алар сөйләүчене зур игътибар белән тыңлый иделәр.

— ...Уртак Шиһабетдинов Бохара Кызыл Гаскәрен оештыруга да ялкынланып керешкән иде, тиз арада анча[5] михнәткәшләрне кызыл байрак астына туплап, әмир бәдбәхетләренең койрыгын кисә башлаган иде,— дип дәвам итте Хуҗаев.— Әмма бүрек астында бүре юк димәң, яр астында яу юк димәң, дошманнар безгә һәрвакыт дәһшәт салырга әзер. Баһаветдин уртакның акылга хилаф рәвештә фаҗигале һәлак булуы шуңа мисал. Ләкин без әмир золымын татыган Бохара әһле — диһканнар вә укымышлылар, михнәткәшләр вә сәүдәгәрләр, мал багучылар вә шәкертләр — барыбыз, барыбыз да биттә[6] сафка басып, якты хыялларыбызны гамәлгә ашырырбыз, революция куйган гали вә мөкатдәс максатларга ирешкәнче, кадерле дустыбызның эшен дәвам кылырбыз!..

---

[1] Михнәткәш — хезмәт иясе.
[2] Нимә гәперәде — ни сөйли.
[3] Кәмбәгал — ярлы.
[4] Бикәр — буш.
[5] Анча — күп.
[6] Биттә — бер.

Фарукҗан барлык сөйләүчеләрне игътибар белән тыңласа да, фаҗигане ачыклап әйткән бер генә сүз дә ишетмәде. Хәер, бөтенләй файдасыз да булмады монда килүе. Шиһабетдиновлар гаиләсенең Верныйга 1910 елда сәфәр чыгуын, Баһаветдинның яшьли сәүдәгәрләрдә олаучы, почтада йөкче хезмәтләрен башкаруын, аннары өч ел буе фронтта нужа шулпасы эчүен белү шулай ук кирәк иде. Әгәр ул чынлап та үзенә-үзе кул салган икән, сәбәбен читтән генә эзләү акланмаячак.

Хәрби оркестр матәм маршын уйный башлауга, мәйдандагы халык тагын хәрәкәткә килде — алдагылар артка чигенде, арттагылар кысыла-кысыла табутка якынлашырга тырышты. Байкучатов аты янына сызарга торганда гына, үзенә таба ике таныш кеше — Шәмгун Аксолтанов белән Таштимер Тураевлар атлавын күреп, туктап калды. Таныш дип әйтү күбрәк, чөнки ул аларны ишетеп һәм читтән танып кына белә иде. Әмма хәзер Бохара компартиясенә нигез салган шушы кешеләр белән бер-ике авыз сүз алышу аның өчен күктән көткәнне җирдә очрату бәрабәрендә иде. Шуңа күрә Фарукҗан, болар килеп җитүгә:

— Кичерәсез, иптәшләр, сездән бер генә нәрсә сорыйм әле? — дип эндәште.— Хәрби комиссарның ничек һәлак булуын әйтмәделәрме?

— Ишетмәдек,— диде Аксолтанов.

— Иптәш Хуҗаев, илчылар белән сәүдәгәрләрне янәшә куеп, революция икесенә дә бердәй хезмәт итәргә тиеш сыман сөйләде. Шулай да мөмкинме соң ул?

— Бусы инде, туган, икенче сорау,— дип көлемсерәде Аксолтанов.— Аңа Хуҗаев үзе җавап бирсә яхшырак.

— Бәлки аңа Шиһабетдинов фаҗигасен аңлатып бирү дә җиңелрәк булыр,— дип өстәде Тураев.

— Ни өчен?— дип гаҗәпләнде Фарукҗан.

— Серле нимәләрне Фәйзулла җөдә яхшы күрәде дә...

— Куегыз, Таштимер,— дип туктатты аны Аксолтанов.— Халык Комиссарлары Советы рәисе күбрәк белергә тиеш, дисәгезче.

— Хуп, мәйле, өстәвенә сәүдәгәр дә булса, бигрәк тә күп беләде күрас,— дип көлде Тураев.— Үзегез кем буласыз? Комиссарның якыны имәсме?

— Юк, гади кызыл гаскәримен. Шундый кешенең үлеме турында ачыклап берни әйтмәү мине таң калдырды.

Аксолтанов ят егетнең чәер төсле ябышуын өнәмәгәнлеген сиздерсә дә, Тураев әңгәмәне кырт кисмәде, Байкучатовны күздән кичереп:

— Коры гәп колакка якмас,— диде.— Кайбер нәрсәләр хакында дәстәрхан янында сүз куерту уңайрак. Кайда торасыз үзегез?

— Ябык базар янындагы кәрвансарайда.

— Килеп каптыгыз болай булгач, Таштимер әкә! — дип көлде Аксолтанов.— Чека егете икән ич юлдашыбыз.

— Пуф дисәң, Бохарага очып китәде ул, курыкма,— диде Тураев, өрергә җыенган сыман.— Әйтсәм телем көяде, әйтмәсәм күңелем көяде. Йөрәмез, әйдә!

Фарукҗан аның сабантуй батырыныкыннан таза гәүдәсенә ирексездән кызыгып карап, артларыннан иярергә дә, калырга да белми таптанып торды. Егетнең икеләнүен тойган Аксолтанов артына борылды да татарчалап:

— Кайсы якныкы сез? — дип сорады.

— Тәтеш өязеннән.

— Исемегез?

— Фарукҗан.

— Исән булсак, очрашырбыз әле. Сау булып торыгыз, якташ!

Байкучатов аның җылырак эндәшүен тойса да, үзгәрешнең сәбәбен

төшенмәде. Чибәр кеше, дип уйлады ул Аксолтанов артыннан карап калганда. Буй дисәң — буй бар, йөз дисәң — йөз. Киң маңгай, гайрәтле мыек, чая караш. Бераз корырак мөгамәләле, ләкин бу алдын-артын уйлап эш итүенә бәйледер. Ә Таштимер Тураев ягымлырак, ачыграк җанлы кеше икән. Менә кемнәр белән дуслашырга иде Фарукҗанга. Сереңне уртаклашырга да, киңәшергә дә лаек кешеләр. Көймәсе комга терәлсә, һичшиксез, эзләп табачак ул аларны.

Фарукҗан шундый уйлар белән атына атланыйм дигәндә генә кемдер аны танып алып:

— Иптәш Байкучатов! — дип эндәште.

— Ә-ә, иптәш Гарипов,— диде Фарукҗан янә атыннан сикереп төшеп.— Исәнмесез!

— Исән, исән әле. Я, ничек, күнектегезме Чекага?

Эндәшүче кеше Бохара Ревкомының рәис урынбасары Габделхәмит Гарипов иде. Монда килгәч, Фарукҗан нәкъ менә шуңа юлыккан, таныклыгын да шуңа күрсәткән иде. Аның ыспай хәрби киеменә, папаха шикеллерәк көрән каракүл бүрегенә һәм ялтырап торган өр-яңа кылыч каешларына күз салгач, бу монда ялгыш кереп утырган рус офицеры түгел микән, дип шөбһәләнеп куюы да хак иде. Әмма Гарипов аның белән бик көйле итеп татарча сөйләште, кызыксынып Идел буендагы хәлләрне сорашты, аннары мондагы тормыш белән таныштырды. «Рус монархиясе басып алган әмирлек урынында хәзер бәйсез Бохара мәмләкәте барлыкка килде,— диде ул.— Әмма аның байтак дошманнары әле дә исән, алар яшь дәүләтнең тернәкләнеп китүенә даими аяк чала. Сыйнфый көрәш, Русия белән дуслык, хезмәттәшлек, фәлән-фәсмәтән дип җилдән җиң тегүчеләр, шулай төрле сылтау белән аның мөстәкыйльлегенә баз казучылар ишле. Гавәм үтә надан һәм аңсыз, төрле эт җаннар коткысына колак салып, бушбугазлар корбанына әйләнүе дә ихтимал. Кыскасы, монда Русиядәге, Татарстандагы бизмәннәр аслан ярамый. Милли пролетариат юк. Әмирне һәм аның бәкләрен тар-мар кылганнан соң, бер уч сәүдәгәрне искә алмасак, монда хәзер бер генә сыйныф калды. Мал багучымы, игенчеме, аларга хезмәт күрсәтүче сәүдәгәрме — барысының да максаты, мәнфәгате уртак: артта калган элекке колония — Бохара әмирлеген Европа дәүләтләре шикелле иркен тормышлы, алдынгы вә хөр республикага әйләндерү безнең иң мөкатдәс бурычыбыз. Менә шул изге максатка җитәр өчен, барлык дошманнарга каршы аяусыз ут ачарга туры килә...»

Фарукҗан ул чакта Ревком рәисе урынбасарын сабыр гына тыңлады, сөйләгәннәрен чынлап торып исендә калдырырга тырышты. Яшь егетнең әнә шулай җитди колак салып утыруы Гариповка ошаса кирәк, киләчәктә Ревкомга һәм үзенә ныклы таяныч булуны теләп, тиз генә боерык язды да Байкучатовны Чека карамагына җибәрде. Бу хәл моннан нәкъ ике атналар чамасы элегрәк булган иде.

— Мин сезгә кергәләп йөрергә кушкан идем ич, кайда югалдыгыз? — диде Гарипов әле һаман җавап кайтармаган чекистка.— Әллә хәзер сез Ревкомны санга сукмыйсызмы инде?

— Үзегез тобага тотып ташладыгыз да,— диде Фарукҗан.— Менә бүген дә төнге дежурдан соң керфек тә какмадым әле. Иртә таңнан Сипулян кышлагына ябырылдык...

— Кемнәрне эләктердегез соң?

— Дошман дип әйтерлек берәүне дә очратмадык.

— Ничек инде «очратмадык»? Анда ниндидер фетнәчеләр җыйналуы турында ышанычлы хәбәр алыйк та, сез ул кабәхәтләрне кулдан ычкындырыгыз имеш.

— Шикле бер генә адәмне дә күрмәдек ич. Кышлак исән-имин яшәп ята, халкы тыныч йокыга оеган иде.

— Димәк, кисәткәннәр! Һич югы төнлә астыртын хәрәкәт сизелүен дә әйтмәделәрме? Кораллы мәлгуньнәрне берсе дә күрмәгәнме?

— Телгә дә алмадылар.

— У-у-у, пешмәгәннәр! — диде Гарипов тешен кысып.— Яратам Шәрыкне, әмма шуның йөрәксезлеген, җебегәнлеген, берни булса, күзгә яфрак төсле калтыранып торуын җенем сөйми. Ярар, уятырбыз без ул изелгән салмаларны йокымсыраудан, исләренә төшерербез шанлы чакларын, ә, Байкучатов?

— Ул уянды бугай инде, революция ясады.

— Әйе, ясады. Тик бу хакта аяк өсте сөйләшү генә җитми шикелле. Иртәгә төштән соң рәхим итегез әле миңа. Кирәкмәгән чакта сукыр черки сыман күзгә кереп, кирәктә авыз ачып калуыгызны да тикшерербез.

Гарипов ничек кинәт пәйда булган булса, шулай ук елдам гына юкка да чыкты — мәйдан тулы халык арасына кереп күмелде. Фарукҗан да тизрәк кыймылдауны хуп күрде, тагын бер җаны теләмәгән танышы белән йөзгә-йөз очрашудан сакланганлыктан, атына очып менде дә Бохара юлына кузгалды. Кичке караңгылык иңгәнче ачыклыйсы тагын бер эше күтә иде аны шәһәрдә. Ике төннең йокысын бергә кушмаса, ул аңа бүген өлгермәячәк, димәк, кулына кергән язулардагы ихтимал серне дә күздән ычкындырачак иде. Шуңа күрә ул, ару-талуны онытып, тузанлы юл буйлап атын каулый бирде.

## 11

Чекада эшли башлаганнан бирле Байкучатовка бары тик өч агентның хатларын гына кабул итәргә һәм теркәп барырга туры килде. Хәбәр бирүчеләрнең берсен дә күргәне юк, язмаларының ничек һәм кайдан җибәрелүен дә белми иде. Хатлар ходайның һәр бирмеш көне махсус ярык аша аның кабинетындагы стенага беркетеп куелган шкафка төшерелгәнлектән һәм ул яшерен почта тартмасының ачкычы бары берәү генә булганлыктан, агентларның һәр хәбәре Фарукҗан кулыннан узарга тиеш иде. Байкучатов аларны махсус кенәгәсенә теркәп, тәртип санын суккач кына, хатлар агентура бүлеге башлыгы Латыйфхан Нурморатовка тапшырыла иде. Төрле оешмалардан килгән рәсми кәгазьләр дә, аерым кешеләрдән алынган үтенечләр һәм аларга Чеканың үз җаваплары да шулай ук теркәлеп барырга тиеш иде. Менә шушы вазифа аңа йөкләнгәнлектән, Фарукҗан теркәү бүлеге башлыгы санала иде, ахры. Югыйсә ул вакытының күбрәк өлешен бөтенләй башка нәрсәләргә багышлый, көн саен Чека председателенең әллә нинә ашыгыч йомышын берьюлы үтәр өчен чытыр чаба иде. Иң кирәген башкарырга да көчкә генә өлгергәнлектән, агентларның ни хәбәр итүләренә ул әлегә кадәр беркайчан да игътибар бирмәде. Хәер, ике агент тик таҗикча гына язганлыктан, теләсә дә, Фарукҗан ниятен эшкә ашыра алмас иде. Ләкин бүген шундый зур шәхеснең — Республика хәрби комиссарының серле рәвештә кинәт фаҗигагә очравы Байкучатовны тирә-якка башкачарак карарга мәҗбүр итте. Изге Бохарада бик үк изге булмаган җаннар да ишле, аларның кыңгыр эшләрен һәм ихтимал ниятләрен Чека хезмәткәренең алдан чамалап торуы, вакытында саклану чаралары күрүе хаҗәт икән. Нигә соң әле ул кемнәргәдер ышанып, үз кулы аша узган кәгазьләргә дә ни гомер күз салмады? Аларда җеп очы күрсәтелмәгән тәкъдирдә, бәлки ниндидер ишарәләр булгандыр? Гомумән, агентларның кемлеген ачыклау, аларны революциягә үзенчә хезмәт иттерү дә акланыр иде, ләкин Нурморатов моңа ризалык бирер, юл куяр сыман түгел күренә шул. Әгәр сәбәбе мин-минлектә генә булмаса?..

Фарукҗан кәрвансарайга кайтып җиткәннән соң ук, яшерен почтаны барлады, анда, гадәттәгечә, таныш куллар язган яңа өч хат ята иде. Ул язуларның үзбәкчәсен күздән кичергәч, гаҗәпләнми булдыра алмады, чөнки хатта базар бәяләре, кайсы сәүдәгәрнең нәрсә сатуы гы-

һа хәбәр ителгән иде. Әлбәттә, моның киная генә булуы да ихтимал. Тик шифрның ачкычын белмәгәч, Фарукҗан хәбәрдән бер генә юньле мәгънә дә чыгара алмады. Таҗикчаларына исә бөтенләй теше үтмәде— мәдрәсәдәге укуын ярты юлда өзеп, анда үзләштергән кадәресе белеменең дә инде байтагын онытып бетергәнлектән, хатларны күпме кыштырдатып утырса да, сүзнең ни турыда барганлыгын төгәл аңламады. Бохараның байтак халкы ике телле — үзбәге таҗикча, таҗигы үзбәкчә белә, андыйлар Чека аппаратында да бар иде. Ләкин Фарукҗан әлеге хатларны чекист иптәшләренә күрсәтүдән сакланды, читтә исә ул әле якын танышлар булдырырга өлгермәгән иде. Агентура язуларын тәрҗемә итеп бирерлек ярдәмче йә фикердәш, йә сәясәттән ерак торучы, әмма сер сыярлык тотнаклы кеше булырга тиеш иде. Кайдан табарга андый кадерле сердәшне?

Фарукҗан кабинетында ишекле-түрле йөри-йөри үзе белгән барлык танышларын күз алдына китерде, әмма берсен дә мондый вазифага яраклы тапмады. Димәк, яңа дуслар эзләргә кирәк иде. Кайдан? Мөгаен, Ревком ачкан уку өйләреннән. Чөнки нәкъ менә шундагылар белән уртак тел табу җиңелрәк булыр кебек.

Аларның берсен ачуда ул үзе дә катнашкан, «Кызыл шәрык» агитпоездыннан революцион әдәбият, газета-журналлар алып баруда булышып та йөргән иде әле. Уку өйләрендә эшләргә укымышлы һәм алдынгы карашлы кешеләр җәлеп ителүен дә чамалый иде Фарукҗан.

Әлеге таныш уку өенең бинасы гадәти торак йортны хәтерләтә, якын күршеләреннән ул балаханәсе — ачык әйваннан һәм ялгыз бүлмәдән гыйбарәт икенче каты булу, капкасына язулы комач элену белән генә аерылып тора иде. Байкучатов исәбенчә, балаханәсендә, әлбәттә, мөдир үзе торырга тиеш иде. Башка җәһәттән бу бина Бохараның меңләгән бүтән йортлары шикелле үк: ишеге һәм кечкенә тәрәзәләре ишегалдына караган, тышны дөньядан хәйран биек һәм калын дувал белән аерып куелган. Йортның эчке ягы да малханә, дирбияханә, кунакханә һәм бүтән ханәләре белән тирә-яктагы бүтән корылмалардай салынган, тик соңыннан гына бу бүлмәләрнең берсе уку өе итеп үзгәртелгәнлек сизелә иде. Моны Фарукҗан ханәләрнең төрле зурлыкта булуларыннан гына түгел, ачык әйваннарының да, бүлмәләрнең дә Бохарада гадәткә кергән тәртиптә тезелеп китүләреннән үк чамалап алды. Ишекләрнең, әйван баганаларының һәм матчаларының сырлап ясалган матур бизәкләр белән каплануы исә аны шактый хәлле хуҗа салдыруы хакында сөйли иде.

Таныш капканың һәм ишекнең ачык булуы табигый тоелса да, үзен хатын-кыз каршылар дип көтмәгән иде Фарукҗан. Бохарада ят ир кеше сирәк тап була торган очрак! Бу үзе үк Идел буйларындагы тормышны һәм гореф-гадәтләрне искә төшереп күңелне җылытса, хуҗа кешенең ягымлы каршы алуы Байкучатовны тәмам дулкынландырды.

— Монда да якташларны күрермен дип исәп итмәгән идем,— диде ул исәнләшкәч.— Эшегездән аермадыммы?

— Зарар юк, хуш киләсез.

Алар өйалды буйлап атлаганда алгы бүлмәдән бер үсмер малай башын тыгып күз салды, кара-кучкыл йөзе, кысыграк күзләре аның, әлбәттә, үзбәк икәнлеген раслый иде. Бөркү урамнан салкынча иркен бүлмәгә килеп кергәч, Байкучатов җиңел сулап җибәрде.

— Сез хәл ала торыгыз,— диде аңа хуҗа кеше,— минем кичектергесез эшләрем бар иде әле.

— Әлбәттә, барыгыз, бар!

Фарукҗан аның килешле буй-сынына, ак эшләпәсе астыннан сузылып төшкән юан кара толымнарына тансыклап карап калды, аннары урындыкларның берсенә җәелеп утырды да фуражкасы белән маңгаен, битен һәм муеннарын, изүен ычкындырып, күкрәген җилләтә башлады. Кеше-кара заты күренмәгән бүлмәдәге гади генә китап шкафын,

стенага эленгән карталарны, өстәлдә яткан «Бохара әхбаре» гәзитен һәм төрле-төрле уку әсбапларын — күңеленә якын мөхитне күздән кичергәч, әченнән: нинди рәхәт монда! — дип уйлады. Бүген аңа шактый эләкте,ияр өстендә генә төнне көнгә ялгап ничәмә сәгать чайкалды ич ул, шушы эсседә күпме юл узды — бөтен гәүдәсе, эван суккан кешенекедәй ватылган, тир тамчылары бәреп чыккан тәне чымырдапмы чымырдый иде хәзер. Бераз черем итеп алу һич тә зыян итмәс иде, шайтан алгыры, монда искитмәле тыныч, искитмәле...

Байкучатов уку өен күзе белән бер айкап чыккач, алдындагы китаплар өемен арткарак этәрде дә фуражкасын өстәлгә ташлады. Шуннан соң каз кебек башын кыңгырайтып, аргы бүлмәдәге хатын-кызның әлеге үсмер белән нидер сөйләшүләренә колак салып торды һәм, үз алдына бәхетле елмаеп, урындык аркасына сөялебрәк, җайлабрак утырды. Әмма бераздан аңа бу әзрәк тоелды, идәнгә төшеп, иркенләп сузылып ятасы килә башлады. Монысына ук базмады базуын, ләкин таш аскандай авырайган башы, сабагы күтәреп тоpалмаган кабак төсле, биек урындык аркасына килеп терәлгәч, соңгы дәрманын җигеп муенын турайтты, аннары гәүдәсен алга бөгеп, өстәлгә таянды һәм маңгаен беләкләренә төртте дә бөтен буыннарын оетырга, аңын томаларга керешкән көч ихтыярына бирелде.

Шулай күпме вакыт узгандыр, әмма ул ниндидер саңгырау тавышка уянып башын күтәргәндә, тышта караңгылык җәелгән, өстәлдәге керосин лампасы бүлмәгә сыек саргылт нурларын тарата иде инде. Фарукҗан, гадәтенчә, йокылы-уяулы хәлдә көн итек куныч ын капшады — револьверы урынында иде. Аның бу хәрәкәте хуҗа ханымның игътибарыннан читтә калмады, тик ул тыныч тавыш белән:

— Калыгып киттегез, ахры! — дип елмайды.

— Әйе, гафу итегез,— диде Байкучатов, чын мәгънәсендә уңайсызланып.— Бөркү һавадан соң монда тәмам эрегәнмен. Сәгать ничә икән әле?

— Сигез.

— Уһу, йокы мәчегә тансык, дигән булалар тагын.— Фарукҗан көлеп җибәрде.— Артык озак черем иткәнмен ләбаса, нигә уятмадыгыз инде?

— Кызгандым, талчыгуыгыз йөзегездән күренә иде. Менә хәзер кайнар чәй эчкәч...

— Рәхмәт, борчылмагыз. Йомышымны гына әйтим дә...

— Кулыгызны юасызмы?

Фарукҗан бит-күзен чылатырга кирәклеген тоеп, ирексездән госелханәгә атлады. Ул бүлмәгә кире әйләнеп кергәндә, кәсәләргә хуш исле чәй ясалган иде инде. Яртылаш кына итеп, үзбәкчә!

— Җитешегез,— диде хуҗа ханым.— Җимешләрне дә авыз итегез.

— Рәхмәт, минем тарафтан мәнсезлек кебегрәк булды инде бу. Тиз генә әйләнеп чыгармын дисәм, менә ничек батып калдым.

— Ашыга идегезме?

— Әйе, вакыты шундыйрак,— диде Фарукҗан чәйне уртлап.— Еш кына юньләп тамак ялгарга да форсат тими бу арада.

— Безнең калган пылавыбыз да бар ич әле, хәзер җылытам!

— Юк, юк, мин болай гына, сүз уңаеннан гына, зинһар кузгалмагыз, кирәкми. Бакчы, таң калып торам: уку өеме соң бу, ашханәме? Сезгә халыкны ашау-эчү белән дә «агартырга» кушылмагандыр ич?

Хуҗа ханым, аңа җавап бирмәстән, тагын житез генә бүлмәдән чыгып китте һәм тәлинкә белән яңа ашамлык алып керде.

— Ул әле суынырга да өлгермәгән, кыенсынмагыз. Үзебезгә әзерләнгән ризык. Сез монда китаплар китерешкән, уку өен ачуда катнашкан идегез ич, әйеме?

— Туры килгән иде үзе.

— Шулай булгач, сез инде монда үз кеше. Әйдәгез әле, җитешегез!

Байкучатов озак кыстатып тормады. Шәһәрдә кыйммәтчелек, Чека түли торган айлык ачлы-туклы җан асрарга гына җитәрлек иде. Пылау пешерергә ит, боткага май алу кыенга килгәнлектән, пәтер дип аталган көлчә белән ширчәй иде аның көндәлек ашамлыгы. Ә мондый кунак сые эләксә, атнага бер генә эләгә иде.

Тәлинкәне солдатларча җитез ялтыраткан Фарукҗан ризыкны мактап:

— Бик тәмле пешергәнсез, аш-суга осталыгыгыз сөбханалла икән, и,— диде.— Тәрбияне һәрчак шуңардан башлый торган булсагыз, бусагагыздан кеше бер дә өзелмәстер.

— Сынамый булмас.

— Үгетчеләрне болай ук бай яшиләрдер дип уйламый идем.

— Бай? — Хуҗа ханым каршы төшәргә җыенса да, баштагы ниятеннән сүтелгән сыман булды.— Йортыбызда байлык, чыннан да, юк түгел, бүтәне генә...

— Үз йортыгызмыни әле бу? — диде Фарукҗан гаҗәпләнеп.

— Әйе. Аны революциягә кадәр үк ирем сатып алган иде. Хәзер Ревком карамагына тапшырды.

Гаилә башлыгы телгә алынгач, Бохарадагы кырыс гореф-гадәтләрне искә төшергән Байкучатов уңайсызлана калды.

— Уку өе мөдире ир-ат иде шул. Хәзер кайда соң ул? — дип хәвефләнде.

— Әле кышлакларга чыгып киткән иде, халыкка җәдитчеләр сәясәтен аңлата. Сез үзегез Ревкомның үгет-нәсихәт бүлегеннән түгелмени?

Менә ни өчен кунакчыл каршыланган икән ул! Фарукҗан көлемсерәп:

— Әз генә ялгыштыгыз, якташ,— диде.— Ләкин зыянсыз, без чыннан да бер тутәл җимешләре. Мине монда шул эшне алып барырга җибәрүләре рас. Тик хәзергә көтелмәгәнрәк тармакка беркеттеләр әле. Сез ирегезгә ярдәм итәсезме?

— Туры килә.

— Егет икәнсез. Кайда белем алдыгыз?

— Казанда.

— Кызык. Заманында мин дә шул шәһәрнең урамнарын таптап йөргән идем бит,— диде Фарукҗан.

— Күптәнме?— дип кызыксынды хуҗа ханым.

— Җиде-сигез еллар элек.

— Әйтәм аны кайдадыр күргән кешем сыман тоелдыгыз. Мин сезне шунда очраттым микәнни?

Байкучатов хуҗа ханымның әсәрләнеп китүенә гаҗәпләнмәде. Чөнки ул хәзер үзе дә аның түгәрәк йөзенә, тулы битләренә, куе кашларына һәм калын керфекләренә игътибар беләнрәк күз салгач, бигрәк тә түгәрәк йөзенең туткыллы икәнен дә абайлагач, йөрәге дулкынланыбрак тибә башлавын тойды. Шулай да, алданудан куркып, үткәнне ачыкларга тырышкан соравын әйтеп салды:

— Ә сез Шәрык клубына йөри идегезме?

— Әйе,— диде йөзе алсулана башлаган ханым.— Анда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре дә театр уенын карарга килә иде.

— Ничек күрешкәч үк танымадым соң мин?— дип сикереп торды тавышы калтыранган егет.— Димәк, сез — Зөһрәгөл?!

Фарукҗан мондый очрашуны көтмәгән иде, шуңа күрә хәзер тагын ни дә булса авыз ачып әйтергә дә, сорарга да кыймады, йотылып каршысында утырган кешесенә төбәлде. Ул бер адым атларга яки бер селкенергә өлгергәнче, Зөһрәгөл урыныннан кузгалды да, ләм-мим дәшмәстән, артка чигенә барып, аркасы белән стенага килеп терәлде һәм йөзен куллары белән каплады. Хәзер инде Фарукҗан

аның кем булуына шикләнмәстән һәм сөенүен яшермәстән:

— Соң булса да уң булсын,— дип сүз катты.— Барыбер очраштык ич менә.

— Очрашумыни инде бу?!

Зөһрәгөлнең күз яше аралаш сытылып чыккан сүзләре Фарукҗанга салкын су тондыргандай тәэсир итте. Аларның сәбәбенә төшенә, мәгънәсен башына сыйдыра алмый торганда, каршы якта тыптып яңгыраган аяк тавышлары ишетелде, аннары яртылаш ачык ишектән йөгереп кергән нәни кызчык:

— Әни, әни, син нишлисең?— дип Зөһрәгөлгә сарылды.

Ул арада ишектә аннан да яшьрәк тагын бер елтыр күз пәйда булды. Хуҗа ханым, кулъяулыгы белән күз төпләрен сөртеп:

— Әле сез йокламадыгызмыни, балакайларым? Әйдәгез, ятырга вакыт ич инде,— дип, аларны бүлмәдән алып чыгып китте.

Боларның барысы да берничә секунд эчендә булганлыктан, Фарукҗан, исе китеп, аларның артларыннан карап калырга гына өлгерде.

Язмышның биткә төкерүе шушы икән! Бу дөньяда гаделлек юк икән, мәңге булмагандыр һәм булачагы да икеледер! Хәер, тукта әле. Синең бәхетеңне корт ашаган өчен генә арт белән киртә җимерергә ярыймы соң? Кирәк микән? Синең кеше күңеленә керә алмавыңа, шунлыктан тиз онытуларына кем гаепле? Үзеңне тиңсенмәгәннәргә күз алартып йөрисең дә юк, бөтен дөньяга күсәк күтәрүең инде, гафу ит, акылсызлык, малай-шалайлык...

Күңеле уйнаган Фарукҗан әнә шундый уйлар эчендә янды. Башта зиһене таралгандай аптырап калса, соңыннан бар дөньяга ачуы кабарды, аннары үзен тагын: «Бу әле муеның сыну түгелдер лабаса!»— дип юатырга тырышты. Тик йөрәге барыбер урынына утырмады, эченә кату төшкәндәй тоелды. Авыр халәттән котылыр өчен ул ишекле-түрле йөренә башлады, әмма кем өендә таптануына хисап биргәч, тынычсызланып яңадан өстәл янына килеп утырды. Зөһрәгөл шым гына кире әйләнеп кергәндә ул әле һаман шул рухи өермәләр дулкынында бәргәләнә иде.

— Без йокларга җыендык,— диде басынкылана төшкән ханым.

Фарукҗан сискәнеп башын күтәрде, аннары әлеге сүзләр миенә барып җиткәч, кинаягә җәберсенеп:

— Әле без берни дә аңлашмадык лабаса,— дип телгә килде.— Нигә мине көтмәдегез инде?

— Үзегез оныттыгыз түгелме соң? Көзен Казанга әйләнеп кайтырмын, дидегез. Таш яуса да килермен, эзләп табармын, дидегез. Әмма икенче елны да, өченче елны да күренмәдегез.

— Мин булдыра алмадым, Зөһрәгөл. Бөтен дөньясы шулай зирзәбәр килгәндә, үз башыңа үзең хуҗа була алмаган заманда тәҗел генә кайтып килү мөмкинмени? Әгәр сугыш чыгып, егетеңне үз зилзиләләре эченә суырып алмаган булса... Әмма мин сезне беркайчан да исемнән чыгармадым, беркайчан да! Сез көтәргә тиеш идегез...

Зөһрәгөл арыган, рухсыз тавыш белән:

— Тиеш?— дип кайтарып сорады.— Ихтимал. Тик кызлар гомере күбәләк гомередәй кыска. Аның ихтыярын бездә кем санга суга инде?

Фарукҗан шушы минутта Зөһрәгөлнең никадәр хаклы икәнлеген бөтен күңеле белән тоеп, хакыйкатьнең шундый гади һәм рәхимсез булуына тетрәнде. Ул бит моны үзе әллә кайчан аңларга, аңларга һәм сөеклесен батканда тартып алырга, вакытында коткарырга тиеш иде.

Озакка сузылган тынлыкны тагын Зөһрәгөл бүлде.

— Хәтерегез калмасын,— диде ул кыенсынып,— тик сезнең болай караңгыга калуыгыз, мөгаен, яхшы түгелдер. Илнең күзе очлы.

— Кузгалам, хәзер кузгалам, Зөһрәгөл. Сезне тагын күрергә мөмкин булырмы икән?

— Белмим. Уку өе — кеше килә торган җир, билгеле. Эшегез төшсә...

— Эш? Ә, әйе, аңлыйм, аңлыйм. Мин әле кагылырмын алайса. Бохарага юл тотуыма сез генә сәбәпче булганны онытмагыз!

— Хәзер инде аны белүдән ни мәгънә?

— Юк, юк, мин алай дип уйламыйм, Зөһрәгөл. Ашыкмагыз әле.

Хуҗа ханым кунакны капка төбенә кадәр сүзсез генә озата чыкты. Фарукҗан ялгызы гына калгач, итек кунычындагы револьверын алып, билбавына кыстырды һәм күлмәк итәкләрен тарткалап куйды. Кулы кесәләренә орынгач кына ул кинәт хатларны исенә төшерде. Аһ, бу йокыны, адәм көлкесе, диде ул сүгенеп, иртәгә үзләрен укымаган көе Нурморатовка тапшырырга туры килер микәнни? Бәлки тоткарларгадыр? Ярар, анысын иртәгә дә күз күрер әле. Бүген ул алар турында бүтән уйларга теләмәде. Чөнки уку өендәге очрашу күңелен нык кузгаткан иде. Күпме бергә булып та, Зөһрәгөлнең хәл сорашмавын, ялгыш та аның исемен телгә алмавын Фарукҗан аеруча авыр кичерде. Бөтенләй-бөтенләй җиде ятка әйләнгәннәрмени, дустанә һәм гади генә итеп бер-беренә «син» дип эндәшергә дә кыймадылар лабаса!

## 12

Байкучатов кәрвансарайга кайтып кергәндә Чека председателе кабинетының тәрәзәләре яп-якты иде. Егет озак икеләнеп тормады, туп-туры шунда кагылырга һәм кайбер нәрсәләрне Эминевнең үзеннән сорап ачыкларга, аннары көндез телгә алган дәлилләрен тагын да тулыландырып кабатларга һәм, шуларга таянып, күңелен биләгән һәлакәтне яңабаштан тикшерү өчен рөхсәт сорарга тели иде ул. Сөйләшергә сәбәбе җитәрлек иде, хәзер инде аңа, янган йөрәген басар өчен, эшкә күмелүдән гайре чара да юк сыман тоелды. Шунлыктан башлыгының ишеген кыю гына шакыды һәм бүлмәсенә күз йөгертеп:

— Мөмкинме?— дип сорады.

— Ә-ә, Байкучатов, керегез, кер,— диде Эминев.— Узыгыз әйдә, утырыгыз. Сипулян хәлләре белән таныштырдылар инде мине. Шуны хәбәр итәргә керүегез идеме?

Фарукҗан, күңелен бөтенләй бүтән нәрсә борчыганлыктан, сүзнең иртәнге «һөҗүм»гә кагылуына бик сөенмәде. Җитмәсә, файдасыз көч түгүгә. Тик Ревком әһлен искә төшергәч:

— Иптәш Эминев, шул Сипулян турында сорашыр өчен иртәгә мине Габделхәмит Гарипов чакырды әле,— диде.

— Ревком председателе урынбасарымы?

— Әйе.

— Юлыгырга кирәк булыр.

— Тик мине хәзергә бүтән нәрсә борчый әле.

— Нәрсә инде ул?

— Төнге фаҗига. Иптәш Эминев, сез, ул хакта соңыннан иркенләбрәк сөйләшербез, дигән идегез. Берәр яңа нәрсә ачыкланмадымы әле?

— Оператив төркем: комиссар үзен-үзе атып үтергән, дигән нәтиҗәгә килде. Сәбәпләрен белмәсәк тә, шул фикергә кушылырга мәҗбүр булдык.

— Бүлмәдә пуля табылганмы соң?

— Әлбәттә. Таң ату белән аны Симиниев үзе табып алган.

— Аны карарга мөмкин булмасмы икән?— диде Фарукҗан җанланып.

— Аннары маузерын да күрәсегез килер инде, ә?— дип көлемсерәде Чека председателе. Фарукҗанның раслап баш игәнен күргәч,

дәвам итте: — Икесен дә җентекләп үзем тикшердем шул, иптәшкәем. Бернинди шикләнү уятырлык нәрсә юк.

Фарукҗан мондый тынычландырудан соң да пуля белән маузерны күздән кичерү уеннан сүтелмәде, тик әлеге үтенечен яңадан кабатлаудан тыелды. Чөнки Әминевнең моны үзенә ышанмау, артык мавыгу дип уйлавы һәм ачулана башлавы мөмкин иде. Байкучатов исә ул очракта теләгенә гомумән дә ирешә алмас иде. Сабырлык белән эш кылганда әле өмет тә, ышаныч та юкка чыкмый, пуля белән маузерга яңадан әйләнеп кайтырга һәрвакыт форсат калачак!

— Мин белдергән бүтән шөбһәләрне искә алмадыгызмы?— диде ул башлыгына текәлеп.

— Ныклы дәлилләрегез юк иде ич. Мин аларны искәрсәм дә, күпчелек иптәшләр оператив төркем нәтиҗәләрен дөресрәк санады, республика җитәкчелеге дә шуңа ышанды. Мәрхүмне, олы хөрмәт күрсәтеп, бүген төштән соң Ташкентка озаттык инде.

— Шуның белән бу фаҗигане тикшерү тәмамландымы?

— Әйе.

Әминев соңгы җавабын кыенсынып биргән шикелле тоелды Фарукҗанга. Аннары башлыгы урыныннан торды да, төсен үзгәртеп, Байкучатовка, баба шулпасы эчмәгән балага карагандай, бер күз ташлады һәм тавышын яңгыратарак биреп дәвам итте:

— Дөнья купкан чак бит, энем, бер вакыйганы көне белән үк икенчесе күмеп китә. Республикада хәл катлаулы — көнчыгышында басмачылык көчәя, шунда ук әмир, үз тәхетен кайтарып алыр өчен, гаскәр туплый, кан коярга әзерләнә. Чит илләрдән тыгылучыларны, контрреволюциягә төрлечә ярдәм итүчеләрне дә өстик.

— Ләкин монда без хуҗа ич әле,— дип каршы төште Фарукҗан.

— Дөрес, әмма монда да, мәмләкәтнең көнбатышында да тыныч түгел. Без халык вәкилләренең бөтен Бохара корылтаенда салымнарны бетерергә карар чыгардык, бәкләр исә, корал белән куркытып, аны һаман да үз кесәләренә җыюны дәвам итә. Инде ничә кышлакта халык сайлаган Аксакаллар советын юк иттеләр.

— Билгеле, без борын төбендәгеләрен дә игә китерә алмагач, хәтта хәрби комиссар башына җитүгә дә ирек куйгач...

— Паникага бирелмәгез, анысы гадәттән тыш рак вакыйга, бәлки сыйнфый дошман кулы уйнамагандыр да. Инде үзебезгә килсәк, булдыра алганның барын да эшлибез. Барын да!— диде Әминев, басым ясап.— Иртәгә партия активы, революция максатларын халыкка аңлатыр өчен, кышлакларга чыгып китә. Сезне байгуралар аеруча зәһәр чәчкән бер авылга җибәрәм.

— Башта Бохараның үзендә аяк астын ныгытырга иде.

— Үзсүзле егет син, Байкучатов.

— Иртәгә тагын берәребез «үзен-үзе үтерсә», бәлки фикерегез үзгәрер әле.

— Чикләвегегезне ватып бирегез, энем,— диде гаҗәпләнгән Әминев.— Әллә тагын ни дә булса ачыкладыгызмы?

— Вакыт һәм мөмкинлек бирсәгез, ачыклармын да,— диде Байкучатов кайнарланып.— Шиһабетдинов фаҗигасен болай томан эчендә калдырырга һич тә ярамый. Революция штабын беренче чиратта сакларга кирәк безгә. Иптәш Хуҗаевның бүгенге кайгы митингысында ясаган ялкынлы чыгышын тыңлагач, мәрхүмнең кем булганлыгын мин бигрәк тә...

— Сез анда килеп җиттегезмени?— дип бүлде аны Әминев.

— Әйе. Менә шунда мин кемне югалтуыбызны бигрәк тә ачык тойдым инде. Андый кеше үзен-үзе үтерә алмый,аңлыйсызмы, Галимҗан абый? Аңа теш кайраган мөртәтләрнең яңа каһарманнарга, әйтик, сезгә дә шундый ук үлем әзерләп йөрүе ихтимал.

— Миңа? Шикчел кеше сез, Байкучатов! Ярар, йөрәккә артык

тоз салмагыз әле,— дип кырысланды Чека рәисе.— Нинди әзер планыгыз бар?

— Мине кайбер эшләрдән азат итүегезне һәм шушы җинаятьне ачу белән шөгыльләнергә рөхсәт бирүегезне үтенәм.

Чека председателе, тәмәке кабызып, салмак адымнар белән ишекле-түрле йөренгәндә Байкучатовка да караштыргалап алгалады, аннары төтенне түшәмгә таба өреп, ниндидер катлаулы бер нәрсәне хәл иткән төсле, өстәленә килеп сөялде дә:

— Беренчесен башкарырга мөмкин, ә икенчесенә рәсми боерык бирә алмыйм,— диде.— Әгәр үзегез тәвәккәлләп казынырга керешсәгез, комачауламам, бәлки әле астыртын гына ярдәм дә итәрмен, тик шуннан артыгына өметләнмәгез.

— Ни өчен? Әгәр бу фаҗига киңрәк җинаятьнең бер тармагы гына булса?

Чека председателе, аның бу сүзләрен колак яныннан җибәреп, урындыгына килеп утырды һәм, әңгәмәне тәмамлаган төсле, кәгазьләренә иелде. Әмма Байкучатов моңа күңелен төшермәде, яңа соравын бирде.

— Иптәш Әминев,— диде ул,— миңа иң элек Шиһабетдиновның якынрак дусларын, фикердәшләрен табу хәерле. Кемнән башлыйм икән?— Чека председателенең канәгатьсез караш ташлавын күреп, Фарукҗан:— Рәсми тикшермәгәч, эш читенләшә,— дип акланды.— Бигрәк тә беренче адымда авыз пешүдән сакланырга кирәк, аннары бер эзгә төшкәч, бәлки җиңеләер иде.

— Бушка аптыратучы булсагыз, карагыз аны, егеткәй!— диде Чека председателе кырыс кына. Тагын бераз уйланып торгач, өстәде: — Шәмгун Аксолтановны күрергә тырышыгыз. Кирәк тапса, булышыр да, киңәш тә бирер.

— Ә Таштимер Тураев ниндирәк кеше? Аңа да мөрәҗәгать итү ярыймы?

— Ярый гына түгел, кирәк, егетем. Сердәше кебек булган ул Шиһабетдиновның.

— Димәк, шушы ике кешене күрергә инде?

— Тагын... Партия Үзәк Комитеты секретарена кереп чыгу да зыян итмәс. Мин аны алдан ук кисәтеп куярмын.

Әминевнең кайгыртучан хуҗага әйләнгән чагын файдаланып калырга ашыккан Фарукҗан:

— Хәзер инде, Галимҗан абый, комиссарның әлеге маузеры белән канлы пуляны да күрсәтсәгез иде?— диде.— Миңа аларны, һичшиксез, үз күзем белән күрергә кирәк.

Чека председателе ачуланмыйча гына:

— Төпченүчән егет сез, Байкучатов!— диде.— Карап карыйк, нинди мөгез чыгарырсыз икән аңардан.

Фарукҗан Галимҗан абыйсы сейфтан алып биргән унатарны, алтын остасы асылташлар тикшергән шикелле, күздән кичерде, соңра фаҗига урыныннан табылган дип беркетмәгә теркәлгән пуляны да искиткеч игътибар белән әйләндергәләп бакты. Шуннан соң аны кабинет хуҗасына тоттырып:

— Монысын «беренче пуля» дип билгеләп куйыйк,— диде.

— Икенчесе дә булырга тиешмени әле?— дип гаҗәпләнде Әминев.

— Шиксез. Сейфыгызга бер тамга салыйк инде.

Фарукҗан, пулясы рикошет ясап идәнгә төшеп китәрлек итеп, унатарны сейфка төзәде дә атып җибәрде. Аннары лампа белән шул почмакны яктыртып, идәнне тишеп кергән пуляны табып алды. Аның очын, беренчесеннән аерыр өчен, өстәлдәге карага манып:

— Хәзер без боларны чагыштырып карыйк инде,— диде.

Лампа кызуында буявын киптергәч, ике пуляны да учына салып,

әйләндерә-әйләндерә тикшерде. Аннары кызыксынып үзен күзәткән Әминевкә:

— Берсе икенчесенә бик нык охшаган икән,— диде.

— Бу нәрсәне исбатлый инде, сезнеңчә?

— Беренчедән, эзләнү шактый катлауланачагын күрсәтә. Әгәр без Симиниев табып китергән пуляның ул тапшырган маузердан атылмаганын белсәк, хәтсез табышмак чишелгән булыр иде. Әйтик, оператив төркем фаразы кире кагылыр иде. Чөнки, маузер комиссарныкы икән, бүлмәдәге пуля аңардан атылмаган очракта, аны башкача үтерүләре үзеннән-үзе аңлашылачак. Ул хәлдә әнә шул ят коралны, аның иясен эзләү мәҗбүриятен һәркем таныячак. Ләкин...

Байкучатовның киеренке рәвештә фикер йөртүен Чека председателе хәзер үтә ихлас кыяфәт белән тыңлый иде. Фарукҗан исә үз уйларын берәм-берәм тезә бирде:

— Ләкин бу очракта да бердәнбер таныклык Рахманколның раславын берсүзсез кабул итү акланмас иде. Чөнки җинаятьче комиссарны үз коралы белән үтереп, Шиһабетдинов унатарын һәм, хәзер күз алдыгызда мин эшләп күрсәткәнчә, аннан атылган пуляны, эздән яздыру өчен, юри бүлмәдә калдырып китүе ихтимал. Шулай ич?

— Мөмкин, әлбәттә,— дип килеште Әминев.— Болай булгач, теге хатын-кызны табып, сорау алу мәҗбүри.

— Әгәр ул чынлап та хыял җимеше генә булмаса,— дип елмайды Фарукҗан.

Әминев элек беркайчан да мондый эшләргә катнашмаган, серле йомгакларны сүтүдән ифрат ерак торган бер һөнәр иясе булганлыктан, хезмәткәренең белдеклелегенә гаҗәпләнүен яшермәде, шаярткан төсле:

— Карагыз әле, Байкучатов, сез элек охранкада хезмәт итмәдегезме?— дип эндәште.

— Өлгермәдем шул. Мәдрәсәдән соң кучерлыкка яллandым, аннары авылда — игенче, тегүче өйрәнчеге, тимер юлда — кара эшче, фронтта — солдат. Хәер, уналтынчы ел сугышларында полыгыбызның бик каты тетмәсе тетелгәч, безне тулыландыру өчен элекке төрмәчеләрдән һәм полицейскилардан тупланган марш батальоны китерделәр, шулар белән окопта бергә аунадым.

— Менә, менә, аралашуның файдасы тигәнлеге күренеп тора. Әле соңыннан махсус әдәбият та укыгансыңдыр?

— Заһир Бигиев романнарын...— диде Фарукҗан.— Фаҗигага әйләнеп кайтыйк әле. Димәк, әлеге очракта без нигездә Рахманкол белән теге серле хатын-кызны гына эзләр һәм тикшерер идек. Ләкин мәрхүмнең бүлмәсендә табылган пуля шунда аунап яткан маузердан атылган. Бу инде җинаятьне ачу өчен төрле алымнар кулланып, дәвамлы көч түгәргә мәҗбүр итәчәк.

— Әйе шул,— диде Әминев җанланып.

— Әйтик, кулыгыздагы пуля Шиһабетдинов тере чакта яки үтерелгәч кенә, хәтта, мин әлеге бүлмәдән чыгып киткәч атылганмы? Шул бүлмәдә атылганмы ул әллә бүтән җирдәме?

— Чынлап та, ачыклыйсы нәрсәләр күп икән әле...

— Икенчедән, янә бер нәрсәне беләсе иде: бу унатар чынлап та Шиһабетдиновныкымы? Фаҗигагә кадәр аның кулыннан төшмәгәнме? Ниһаять, комиссарның гомере әлеге бүлмәдә киселгәнме яки...?

— Сез, энем, төптән уйлыйсыз икән,— диде Чека председателе.— Белмәгәнмен генә икән элегрәк.

— Әле бу, иптәш Әминев, уйларның башы гына,— диде Фарукҗан дәртләнеп.— Атлаган саен аларның яңалары туачак һәм башка тынгы бирмәячәк. Ләкин сез булышмасагыз, уңышка өметләнү читен, мөмкинлекләрем чамалы. Менә мин хәзер бүлек башлыгы, тик кулымнан ни килә соң? Хәбәрләрен теркәп барган агентларымның кү-

ләгәсен дә күргәнем юк. Ничек була инде бу?

— Бәлки аларны хәзерге агентура бүлеге башлыгы Нурморатов та белмидер?— диде Әминев.— Аппарат ныгысын, сыналсын әле, хәзергә шулай яхшырак. Үзегез дә тирә-якка күз сала йөрегез, киләчәктә таяныч булырдай кешеләр очрамасмы?

— Агентларны, Шиһабетдинов фаҗигасе турында хәбәр җыярга җигеп булмасмы икән, дип телгә алуым иде.

— Уйлап карарбыз.

— Ревком председателе урынбасарына белгертергәме соң бу эшне?

— Гарипов «Кызыл шәрык» агитпоезды белән Мәскәүдән килде,— диде Әминев.— Бохара хезмәт ияләренә ярдәмгә Рәсәй теләсә нинди җилкуарны җибәрмәс, дип уйлыйм. Чека эшенә гел булышып торуын, үзегезне дә монда Габделхәмит абзагыз урнаштыруын онытмыйк.

— Димәк, сораса, ачыктан-ачык сөйләшәм.

— Ул үзе дә чая кеше, хәлләрне бездән ким белми торгандыр.

— Аңлашыла.

— Тик шулай да иптәшләрегез турында фикер әйтергә ашыкмагыз. Яңа эзләнүегезне, гомумән, телгә алмау хәерлерәк.

— Бохара коммунистларының төрле төркемнәргә бүленүен дә искә алсак, ә?

— Абайладыгызмы инде?— диде Әминев.— Менә бусы — бик яхшы. Бәлки әле битлек кигәннәре дә бардыр. Гарипов сезне ничәгә чакырды?

— Көндезге икегә.

— Бүген бланкларны бастыра алдыгызмы?

— Өлгермәдем шул,— дип уңайсызланды Фарукҗан.— Төнге дежурдан соң Сипулян мәшәкате бөтен вакытны йотты.

— Кушылмаган эшләргә вакытыгыз калган үзе.— Чека председателе шелтәле караш ташласа да, орышып тормады.— Ярар, иртәгә кышлакка бармассыз инде, төшкә кадәр типография ягын җайлап бетерерсез.

— Тыңлыйм, иптәш Әминев. Гафу итегез, хәрби комиссарныкы дип исәпләнгән маузерны вакытлыча үземнекенә алмашка биреп тора алмассызмы икән?

Чека председателе үтенечнең сәбәбен аңлап, башта өстәл тартмасыннан чакма ташы чыгарды, шуннан соң аны комиссар маузеры белән бергә Фарукҗанга сузып:

— Коралга алдан ук тамга салыгыз әле,— диде.

Байкучатов үз алтатарын Әминевкә тапшырды һәм, лампага якынрак килеп утырып, маузер түтәсенә бер буй, ике аркылы сызык сызды. Аннары коралын күрсәтеп:

— Шушылай ярармы икән?— дип сорады.

— Ярар. Эшне мөмкин кадәр ыгы-зыгысыз үтәгез. Аңладыгызмы?

— Тыңлыйм, Галимҗан абый. Гафу итегез, Аксолтанов, Тураевларны кайдан табармын икән соң мин?

— Партия Үзәк Комитеты тирәсендә очрату җиңелрәк булыр. Һәрхәлдә, анда беләләрдер, әйтерләр.

Кайбер нәрсәләрне ачыклагач һәм Әминевнең теләктәшлегенә, хәтта, күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итәчәгенә дә ышангач, Фарукҗан шактый тынычланып үз бүлмәсенә атлады. Әмма Чека председателенең, шик-шөбһәләрне уртаклашкан тәкъдирдә дә, дөньяны онытмаска һәм кешегә каты бәрелмәскә өндәве, саклыкка чакыруы аны яхшы ук гаҗәпләндерде. Нәрсәнедер әйтеп бетермәвен тою, ничек инде шундый кешенең дә аягы-кулы бәйләнергә мөмкин, дип аптырау аның

йокысын качырганлыктан, Байкучатов байтак вакыт түшәктә әйләнеп-тулганып ятарга мәҗбүр булды. Пуляны нәкъ менә Симиниев табуын белү — бер яктан, боерыкны язса да, Фарукҗанга типография эшләрен йөкләүдә аның кулы уйнамавын ачыклау — икенче яктан, егет күңелендә төрле уйлар кузгатты. Мендәр астына кыстырып куелган ят маузер, ипи телеменә сыланган хәрдәл-горчица шикелле, ул уйларга нервларны кытыклый торган аерым бер хасият өстәде.



## 13

Зөһрәгөл балаханәдә йокларга әзерләнә иде. Ул урын-җирен түшәгәндә торып-торып: ярый әле Фарукҗан вакытында чыгып китте, дип сөенде. Чөнки аның артыннан ук ниндидер ир кеше иярткән Нәзире кайтып керде. Өшәнгән кыяфәтле, кырыс йөзле ирнең телен ватып-сындырып сөйләшүенә караганда, кунагы рус иде, ахры. Ят кешенең искерәк чалма-чапан киюен Зөһрәгөл ничек юрарга да белмәде, әмма үз-үзен тотышыннан аның аксөяк икәнлеген шактый анык чамалады.

Дүрт кешелек табын әзерләргә кушылгач, Зөһрәгөл тагын кемнәрнеңдер киләсен төшенде, әмма аларның кемлеге белән кызыксынмады, тиз генә чәй кайнатырга, калган пылавын җылытырга керәште.

Нәзир берзаман яшь кәләш алып мәйханә килгәч, Зөһрәгөл дуамалланып баш күтәргән, әмма язмышын үзгәртерлек бүтән юл тапмавы, гореф-гадәткә һәм ата-анасы үгетенә буйсынуы аркасында, гаилә җепләрен өзә алмаган, бары тик үз эченә бикләнгән, әле кайчан гына араларына кыл да сыймый төсле тоелган бәйләнешләрне үзгәртеп, сөмсерен коеп сүзсез генә йөрергә тотынган иде. Көндәшенең үзенә тиң кеше булмавы аны гарьләндерде дә, сөендерде дә. Нәзиренең яшь кәләштән бик тиз күңеле суына башлагач, йөрәге сызлауларын тантанага алыштырырга да әллә ни ерак калмаган иде. Ләкин ул тора-бара ирендәге бу үзгәрешнең революция тудырган шартларга, шул шартларда кайсыдыр Хуҗаевларның бик тиз калкып китүенә бәйләнүен, Нәзирнең хәзер нәкъ менә шулар нәселенә өмет баглавын чамалап алды. Шактый какшаган хәлен төзәтү, көчлеләр канаты астына сыену өчен, Нәзирнең кеше алдында Хуҗаевларны күкләргә күтәреп мактавын һәм аларның бер кыз туганына хәтта күз салуын да белеп өлгергәч, Зөһрәгөлгә үз хәлен аңлау, төрле уйларының очына чыгу шактый җиңеләйде. Әмма бу җанны әрнетүдән тыш аңа башка берни дә өстәмәде. Шунысы гаҗәп, Нәзирнең икенче хатынга өйләнүе Бохара җәдитчеләре арасында да бер дә гайре табигый хәл саналмый, хәтта әле бу нәкъ менә шулай тиеш сыман кабул ителә иде. Революция мондый карашларны какшата башласа да, аның ире әле чигенергә һич тә җыенмый, киресенчә, яңа хыяллар белән яна иде.

Зөһрәгөл аскы каттагы кунак бүлмәсендә табын әзерләп, ризыкларны тезеп бетергәч, балаханәгә — икенче каттагы әйванга менеп утырды. Кызлары инде йоклый, эшләнәсе эшләре тәмамлангач, хәзер палас түшәлгән сәкегә кырын ятып, ачык һавада бераз ял итәргә дә мөмкин иде. Ул әнә шунда урнашкач кына капка ачылуы һәм Нәзирнең яңа кунакларны каршы алуы ишетелде.

Аяк тавышлары тынгач, Зөһрәгөл тагын үз уйларына бирелде. Сәгать ун тулып килә, башка көннәрне ул инде бу вакытта әллә кайчан йокыга тала торган иде. Тик бүген истә юк чакта Фарукҗанның килеп керүе аның гадәти тормыш агышын чыгырыннан чыгарды. Хәер, соңрак шул инде, кичекте, чамасыз кичекте, дип кабатлады ул эченнән, әмма үзе һаман егетнең килеш-килбәтен күз алдына китерүдән, әйткән сүзләрен исенә төшерүдән туктый алмады. Гаҗәп, ул

аның итек кунычына кагылып коралын барлавын да, каеш белән биленнән буган күлмәк итәкләрен тарткалап төзәтенүен дә, киеменең тәненә сыланып, ыспайлык өстәп торуын да күздән ычкындырмаган булып чыкты. Арыган шикелле иде Фарукҗан, әмма беләкләре нык, гәүдәсе тыгыз, ә күзләре һаман зәңгәр — монысын инде Зөһрәгөл бик ачык хәтерендә калдырды. «Мин сезне беркайчан да исемнән чыгармадым. Беркайчан да!»— диде ич әле ул. Әйе шул, нәкъ менә шулай диде. Һич югы биш ел элегрәк әйтергә кирәк иде бу сүзләрне. Әмма ул чакта Зөһрәгөл әти-әнисенең: «Нәзир — итагатьле, укымышлы бала, нәселләре дә әйбәт. Тыңла сүзебезне, кызым, мал таба торган егет белән тормышың да рәхәттә узар»,— дип колакка тукуларын гына ишетте. Оренбург мәдрәсәсендә укуы өстенә бераз русча да белем алуын һәм шактый төшемле урынга кереп төпләнергә өлгергән Нәзир, офыкта бер пәйда булгач, әллә кайда югалып тормады, яучысын да, бүләген дә вакытында җибәрде. Тиз тоттылар ул чакта эшне, чөнки Зөһрәгөлнең әтисе яңа җирдә тирәнрәк тамыр җибәрергә талпына, аның уенча, булачак кияү кеше бу җәһәттән ходай үзе җибәргән таяныч шикелле тоела иде.

Хатынына Нәзир башта, чыннан да, жил-яңгыр тидертмәде. Хезмәтендә шомара барган саен кереме дә елдан-ел ишәя килде, әмир әле тәхетендә исән-имин утырса, ихтимал, ул һаман шулай баюын дәвам итәр иде. Хәер, революция дә аны бик әзгә генә сафтан чыгарды бугай. Борыны исне яхшы сизеп, кайчандыр исем өчен генә уку өе ачарга риза булган кеше, хәзер шул эшен калкан дәрәҗәсенә күтәрде. Койрык борганнары урынына яңа дуслар да табып алды. Әле үзе шулар янына китеп югала, әле тегеләре моны эзләп килә. Дөресен әйткәндә, Зөһрәгөл иренең мондый мөгез чыгаруларына әллә ни исе китеп карамый иде. Тышы мамык, эче кабык икәнлеген белгәч кенә, Нәзирдән җаны бизә башлады...

Аскы катта ишек ачылу аны уйларыннан бүленергә һәм тәмәке тартырга чыккан ирләр сүзенә колак салырга мәҗбүр итте. Әмма кунаклар ул аңламый торган ят телдә сөйләшәләр иде. Зөһрәгөл күпме тырышса да, Бохара, Ташкент, Байсын, Мөшһәд дигән исемнәрне телгә алудан бер мәгънә дә чыгара алмады. Тавышы буенча, гәп коручыларның беренчесе ул күреп калган, үзбәкчә киенгән кеше булырга тиеш иде. Тик әңгәмәнең русча да, таҗикча да яки гарәпчә дә алып барылмавы ачык иде. Бу хәл Зөһрәгөлнең кызыксынуын бермә-бер көчәйтте, ул, сулыш алырга да куркып, тәмам сәкегә сеңеп бетте. Бераздан чапанлы ир-ат өйгә кереп китте һәм аның урынына шунда ук Нәзир килеп чыкты. Кунак хәзер сүзен Зөһрәгөл бераз төшенә торган фарсы телендә дәвам итте.

— Диләм бә дидәни шумо кашол шуд,— дип тезеп китте ул,— Сезне күрәсем килде, Нәзир әфәнде. Һәм мин моның тормышка ашуына бик шатмын. Изге Бохара сезнең шикелле каһарманнары белән чын-чыннан горурлана ала.

— Рәхмәт, Блеккер әфәнде.

Исеме телгә алынгач, хәвефләнгән кунак тавышын басып:

— Монда безгә колак салып торучылар юкмы икән?— дип сорады.

— Борчылмагыз. Бохара хәзер тавыклар белән бергә йокларга ята. Безгә аның файдасы да тими түгел үзе.

— Әйе, әйе, беләм, Нәзир әфәнде, мин сезнең хакта тиешле урында үз сүземне әйтми калмам. Шундыйрак эшләрне киләчәктә дә дәвам итә алсагыз...

— Хәтәр бу, Блеккер әфәнде. Әле хәрби комиссар шау-шуы да басылып бетмәгән. Чеканың Фарукҗан Байкучатов дигән бер яшь әтәче иснәнә башлаган икән.

Зөһрәгөл, таныш исемне ишетеп, колакларын торгызды. Кунак

киңәш бирүдән бигрәк боерыкка охшаган кискен тавыш белән:

— Сез аларны «кых» итегез!— диде.— Азат Бохара тарафдарлары рәхимсезрәк көрәш алып барырга, Чеканы үз кулына алырга тиеш.

— Дошманнарыбызга Совет Русиясе ярдәм итә шул.

— Сезгә кодрәтле Бөекбритания булышмыймыни? Ул чын дусларын авыр минутларда беркайчан да ташламаячак. Үзегезнекеләргә белдерегез: кораллар төягән зур кәрван килешенгән җиргә иртәгә килеп җитәчәк. Егетләрегез каршы алсыннар, аннары шул күчтәнәчләр белән кызыллар өерен сыйласыннар!

— Каратаудагыларга да өлеш чыгармы икән анда?— дип сорады Нәзир.

— Барысына да җитәр. Русиядән килә торган большевикларны, аларга хезмәт итә торган тимер юлны кызганмасыннар. Онытмагыз: Бохарага афәт бары шуннан гына яный!

— Сүзегез рас, Блеккер әфәнде, шәригатькә кул күтәрүче кяферләр барысы да шуннан килә.

Кунак эндәшмәде. Бераздан ул:

— Комиссар әфәнденең очрашырга омтылмавы аяныч, билгеле,— диде.

— Бу аның ихтыярына гына бәйләнмәгәндер,— дип аңлатты Нәзир.— Утырыш арты утырыш, мәмләкәтебездә шул кадәр буталыш купты, җитәкчеләребез утка баскан кебек хәзер. Бәлки ул соңрак күрешү мөмкинлеген табар әле.

— Мән фәрда бә Мәшһәд рәфтәни — мин иртәгә Мәшһәдкә китәргә җыенам инде.

— Кызганыч, бик кызганыч, Блеккер әфәнде.

Алар тәмәкеләрен тартып бетереп, өйгә кереп киткәннән соң да, йөрәге сикергән Зөһрәгөл сәкедәге урыныннан кузгалырга җөрьәт итми байтак утырды. Фарукҗанның «Бохарага юл тотуыма сез генә сәбәпче булганны онытмагыз!» дигән сүзләрен исенә төшергәч, алгысынып кисәк сикереп торды да йокы бүлмәсенә таба атлады. Шулчак аста яңадан ишек ачылды.

— Иң кирәге — саклык. Берәү дә күреп, ишетеп калмаслык, эзегезгә басмаслык итеп башына җитәргә тиеш сез аның, төшенәсеңме, «Бум»? Ашыгып эшне бозмагыз, әмма тугарылып китеп, элең-салың йөреп, озакка да сузмагыз. Чека әтәче зыян китерергә өлгергәнче...

Зөһрәгөл ярты юлда туктап, кунагын озата чыккан ире сүзләренә колак салды. Бу юлы Нәзир үзбәкчә сөйләшә иде. Капка төбендә «Бум» кушаматлы бәндә үзе артыннан атлаган хуҗага таба борылып:

— Болай ук чәйнәп салмасагыз да мөмкин, бала имәсмен,— дип саубуллашыр өчен кулын сузды.

Ишектән төшкән яктыда аның озынча йөзен, кара сакалын, чыршы ботакларыдай кашларын Зөһрәгөл шактый ачык төсмерләп калырга өлгерде, әмма шуннан арысы инде аның хәленнән килмәде — «Бум» шундук урам караңгылыгына чумып гаип булды.

Мөсафирларның икенчесе исә алардан таң сызылыр алдыннан гына чыгып китте. Хуҗа кеше балаханәгә менмәде — төнне шул кунагы белән серләшеп уздырды.

## 14

Октябрь ахыры булуга карамастан, көндезләрен Бохарада әле һаман эссе иде. Һава бөркүләнгәнче юлга чыгарга җыенган Фарукҗан, таң алдыннан гына каты йокыга талганлыктан, шактый соңгарып уянды. Сәгатенә күз салгач, ашыгып киенде, солдат гадәтенчә, елдам гына юынды һәм кичәге чәен җылытып, коры-сары капкалады, аннары җи-

тез генә кабинетына йөгереп керең, яшерен почта тартмасын карады — яңа килгән хатларның икесен дә ачты, үзбәкчәсен укып та чыкты, таҗикчасын исә элеккеләре янына куен кесәсенә тыгып куйды. Шуннан соң атын эчерде дә, кирәк кәгазьләрен онытып калдырмастан, юлга кузгалды.

Почтага кичә үк кагылырга кирәк булган икән. Бәлки Шиһабетдинов берәрсенә хат җибәргәндер, шунда киләчәкне ачыкларлык нинди дер бер ишарә ясалгандыр? Хәзер инде соңгарды, әлбәттә, ләкин кичәге почтаны озаткан булсалар да, элемтә бүлегенә барыбер керең чыгарга кирәк. Бүген Рахманкол белән әңгәмә ясау да акланыр иде үзе. Билгеле, Фарукҗан, бүтән каналлар аша нәрсәдер ачыклаганчы, кайберәүләрне өркетмәскә, һәлакәтне тикшерү дәвам иткәнлеген сиздермәскә омтыла, комиссар йомышчысын да менә шул сәбәпле юри борчымый иде. Әмма башка юллар, ни тырышып та йомгак очын күрсәтмәсә, тәвәккәлләми хәл юк...

Фарукҗан, Каганга килеп җитүгә, кушылган йомышын йомышлаганчы, иң беренче эш итеп почтага сугылды. Андагы хезмәткәр, Байкучатовның үтенечен тыңлый-тыңлый, таныклыгына күз салгач:

— Бүген берни дә юк шул, хөрмәтлем,— диде.

— Сезнең кулдан кичә дә шундыйрак хат-фәлән узмадымы?

Почта хезмәткәре гаҗәпләнеп башын күтәрде:

— Сез нәрсә, барыгыз да бер оешмадан түгелмени? — диде.— Кичә кара мыеклы егетегез керең, һәммә нәрсәне карап чыкты ич инде.

— Кем булды икән ул?

— Кечтеки кара мыеклы, тәбәнәк буйлы кара-кучкыл. Яһүдкә охшаган, үзен шулай ук Чекадан, диде.

— Чибәр, җитез хәрәкәтле егет, әйеме? — дип сорады Байкучатов.

— Әйе, әйе.

— Симиниев, димәк. Без аның белән кичәдән бирле күрешмәдек шул. Ни дә булса алып киттеме ул?

— Бу хакта кергән үзе сөйләр инде ул, хөрмәтлем.

— Сез чамадан тыш шикләнмәгез,— диде Фарукҗан, хезмәткәрнең сүзне дәвам итәргә теләмәвен күреп.— Таныклыгымны янә бер кат карый аласыз. Көне буе Бохара белән Каган арасында гына киләп сарып йөреп булмый, миңа хәзер һәр минут кадерле.

Элемтәче аның таныклыгына тагын да җентеклэбрәк күз салгач:

— Мондый эшләр белән берегез генә кызыксынса да җитә ләбаса,— диде.

Фарукҗан түземлеге кими барганлыгын сиздереп, юри унатары кабына кагылды да коры гына:

— Кичәге чекист сездән ни дә булса алып киттеме? — диде.

Аның хәрәкәтләрен күздән ычкындырмаган почта хезмәткәре җәберләнгән төстә:

— Алды,— диде.

— Нәрсәләр?

— Берничә хат.

— Иптәш Шиһабетдинов үзе язганнымы, әллә аңа килгәннеме?

— Анысын да, монысын да.

— Күптән шулай диләр аны, абзый кеше. Ярар, төгәл җавабыгызга рәхмәт. Әгәр мәрхүм исеменә тагын хат-хәбәр килсә, җыеп куегыз, үзем алып чыгармын. Килештекме?

— Ихтыярыгыз.

Фарукҗан «Кызыл шәрык» агитпоезды басмаханәсендә сүзен бик тиз түгәрәкләде һәм, бланкларны иртәгә үк өлгертергә вәгъдә алганнан соң, кайтыр юлга кузгалды. Әмма шулчак ул кире борылып, әле үзе дә анык хисап бирмәгән бер өмет белән вокзалга күз салып чыгарга карар бирде.

Бохараны тышкы дөньяга бәйләп торган аеруча әһәмиятле юллар төенен караштыру бүгенгесе көнне чекист өчен мәҗбүри икәнлеген күңеле дөрес тойган икән. Бер почмакта ишеккә арты белән утырган ир кешенең чалымы таныш кебек тоелды аңа. Юан муены, киң җилкәсе әллә кайдан игътибарны тартканлыктан, Фарукҗан туп-туры шунда таба атлады. Каршысына чыгып, сирәк кашлы, туры борынлы кояшта янган йөзне дә күргәч, сөенми булдыра алмады: эскәмиядә күзен йомып йокымсырап утырган ир-ат ул эзләп табарга теләгән Таштимер Тураев иде. Фарукҗан җиңел сулап, аның янәшәсенә фуражкасын салып куйды һәм, кулъяулыгы белән муенын сөртә-сөртә, күзләре белән залны капшады — бүлмәдә бүтән таныш-белеш тә, шикләнерлек зат та күренмәде. Янәшәсенә утырып, бераз хәл алыйм әле дип уйлавы булды, Тураев керфеген күтәрмәстән:

— Кемгә хезмәт итәсез, чекист хәзрәтләре? — дип эндәште.

Тавышы аяз чыгуга караганда, ул һич йокымсырамаган, тирә-якны күзәтер өчен генә юри керфекләрен төшергәнгә охшый иде. Көтелмәгән мондый хәл Фарукҗанны янә бер мәртәбә залга күз йөгертергә мәҗбүр итте, әмма, Тураев каршысында утырган кара сакаллы үзбәк картын исәпләмәгәндә, бу почмакта бүтән бер кеше дә юк иде. Ул тынычлап эскәмиягә утырды һәм кызыксынып күршесенә төбәлде.

— Сез йокламыйсызмыни, Таштимер әкә? Исәнлек-саулыкмы? Кая болай юл тотуыгыз әле бу?

Әмма Тураев, Фарукҗанны шаккаттырып, салмак беләгең аның иңбашына салды һәм, тыштан шаярткан шикелле генә, чынлыкта исә тыгыз мускулларының бөтен авырлыгын тоярлык итеп таянды да:

— Мин бер сорауны ике бирергә яратмыйм! — диде.

Фарукҗан моны әле һаман чынга алырга теләмәстән, хәленнән килгәнчә нәзакәтле илтифат күрсәтеп, сүзен дәвам итәргә талпынды, тик Тураевның кырыс йөзен абайлаганнан соң, шып туктады.

— Йә, телегез бардыр ич сезнең? — диде Тураев таләпчән рәвештә.

Ни өчен тәртәдән чыккан соң әле бу? Бохара халкына хас әдәп, ягымлылыкның әсәре дә калмаган төсле үзендә. Фарукҗан да керпе кебек инәләрен тырпайта ала, билгеле, тик җәнҗал куптарудан файда гына чамалы. Киресенчә, җене кузгалган Тураевның тел төбен чамаларга кирәк иде Байкучатовка. Шуны исендә тотып, ул күндәм генә җавап бирде.

— Чекист партиягә, халыкка гына хезмәт итә ала.

— Бикәр гәп бу,— диде Таштимер кулын селтәп.— Сез күзгә төтен җибәрмичә, анығын гына әйтегез: үзегез кемгә хезмәт кыласыз: Фәйзулла Хуҗаев гөруһынамы, әллә...

Бохара компартиясенең соңгы корылтаенда бәхәс купканлыгын, вәкилләрнең икегә, хәтта, өч төркемгә аерылганлыгын ишетсә дә, Байкучатов әлегә кадәр кайсысының иң дөрес, туры юлда икәнлеген тәгаен генә билгели алмаган иде. Чөнки сүздә аларның һәммәсе дә хак, җитмәсә, әлегә кадәр барысы да бергә эшли, еш кына кемнең кайсы төркемгә өстенлек бирүен дә аңлап булмый иде. Бүтәннәр дә әллә әнә шулай сай йөздеме, әллә күңелләре кемгә тартуын белдерәсе генә килмәдеме — Фарукҗанга серләрен ачмадылар. Бу төркемнәр төрле караштa торгангамы, әллә баш булыр өчен көнчелектән генә үзара сүзгә килгәнгәме — анысын да ачык белештерми иде ул. Шуңа күрә сорауга сорау белән генә җавап бирүне кулай күрде:

— Фәйзулла Хуҗаев белән Баһаветдин Шиһабетдинов иптәшләр кайсы гөруһта соң? Мин шулар яклы!

— Хәйлә корабызмы, чекист хәзрәтләре? — дип көлемсерәде Тураев.— Болар икесе ике калыптан сугылган шул!

— Ничек инде? — дип таң калды Фарукҗан.— Халык комиссар-

лары Советы председателе белән хәрби комиссар Бохара революциясенең төп терәкләре булырга тиеш ич. Бер җан, бер тәнгә әверелергә.

— Дөрес.

— Коминтерн вәкиле Куйбышев үзе дә иптәш Хуҗаевны дус күрә, диләр.

— Шуның белән нимә димәкче буласыз?

— Шиһабетдиновны хәрби назыйрлыкка Төркестан фронты әмерчесе Фрунзе белән иптәш Куйбышев беравыздан тәкъдим итүе расмы?

— Тугры.

— Димәк, бер арык буенда үскән байтирәкләр ич инде алар. Хуҗаев иптәш тә, әгәр ошатмаса, үз хөкүмәтенә Шиһабетдиновны кертмәс иде.

Тураев аңа карап-карап торды да көлеп җибәрде. Аннары:

— Юри күңел ауларга йөриме дисәм, менә хикмәт нәрсәдә икән,— диде.— Инде хәзер сез аларның икесенә дә ничек тугрылык сакларсыз икән?

— Шиһабетдиновка атучыны фаш итәргә телим. Без аны вакытында кулга алмасак, мөртәтнең иптәш Хуҗаевка да һөҗүм итүе ихтимал. Сез миңа менә шушы эштә ярдәм итәргә тиеш.

— Җәдә кызык,— диде җанланып киткән Тураев.— Ничек булыша алырмын икән соң мин?

Байкучатов, тезгенне кулга ала башлавына канатланып, эшлекле кыяфәткә керде.

— Мин әле монда яңа кеше,— диде ул.— Бохарага аяк басуыма да барлы-юклы ике атна чамасы гына. Кешеләрегезнең чын йөзләрен дә танымыйм...

— Күренеп тора,— диде Таштимер.

— Төрле көрәшләрне дә, астыртын бармак уйнатуларны да белеп бетермим. Хәрби комиссар белән дә аралашмадым. Аның дуслары кем иде дә, дошманнары кем? Бәлки сез менә шуларны ачыклар идегез?

— Ай, белмәймен, белмәймен, ансат йомыш имәс.

— Кичә үзегез, бу хакта иркенләбрәк сөйләшергә кирәк, дидегез ич. Бәлки менә хәзер дәстәрхан янына кереп утырырбыз?

Тураев аңа көлемсерәп карап торды да болай дип искәртте:

— Мин «кайбер нәрсәләр турында» дидем. Аннары кичә сез Хуҗаевка үзегез шик белдерсәгез, бүген аның турыдан-туры тарафдары икәнлегегезне ачтыгыз.

— Сез аның яклыларга каршымыни?

— Фәйзулла авызына карап торучылардан имәс шул мин. Сәүдәгәр белән ялчы арасында нинди дуслык була алсын инде?

— Ләкин иптәш Хуҗаев — коммунист.

— Астына су кера башласа, муенына тавык тәпие дә асады кү бу адәм. Мөселманлыгын да сатады!

— Алайса шундый зур урынга ничек сайладыгыз соң аны?

— Хуҗаевнымы? У-у-у, юха ләгыйнь бит ул, беркатлы җаннарны сабынсыз юып, башларына гына менеп атланады. Менә юлдаш Шиһабетдиновны да... Ул үзен-үзе үтергәнме әле?

Тураев мыскыллы карашын әңгәмәдәшенә төбәде. Фарукҗан аның да мондый фаразга ышанып җитмәвен сизеп:

— Шундый фикергә килделәр,— диде.

— Аны кемнәр ачыклады соң?

— Чека хезмткәрләре Юлтай Симиниев, Латыйфхан Нурморатовлар.

Байкучатов фаҗига урынын ничек карауларын һәм үзенең әлеге чекистлар белән ни өчен бәхәскә керүен, аннары тикшерү тәмамланганчы ук кайтарып җибәрелү хәлләрен бәйнә-бәйнә Таштимергә сөйләп бирде.

— Төшенмәймен,— диде Тураев,— инде сер ачылган саналады, мәрхүм күмәргә озатылган, сез ни майтармакчы буласыз соң? Сими-

ниевләр чын мөнәсәбәтен сиздергән ич инде, хәтта үзегезне вакыйга булган урыннан куып җибәргәннәр.

— Хакыйкать әле һаман томан пәрдәсе артында калды, дип саныйм мин.

— Алар ачышыгызны хуплап көтеп торыр, сөенерләр, дисезме?

— Мин ник ялганга күрәләтә күз йомыйм соң әле? Шиһабетдиновның җан дуслары ни дип хыянәтне белмәмешкә салынырга тиеш?

— Хыянәтне?

— Әйе. Безгә болай бик тиз шыр җибәрү гафу ителми!

Таштимер бөтен кыяфәтеннән дәрт һәм тәвәккәллек бөркелеп торган Фарукҗанга хуплап һәм үсендереп карап торды, аннары урыныннан кузгалды да:

— Йөрегез, тышка чыгаек әле! — диде.

Байкучатов мөмкин кадәр әкренрәк сөйләшергә тырышканлыктан, үзләренә берәүнең дә игътибар итмәвенә, каршыларында утырган картның исә әллә кайчан йокыга оюына шикләнми иде. Әңгәмәдәшенең кинәт урыныннан кубуын нәрсәгә юрарга белмәсә дә, бер адым да калмый артыннан иярде.

Перронга чыккач, Тураев тирә-якка карый-карый чуен юл буйлап вокзалдан читкәрәк китте, аннары кул сузымы биеклектә аш тәлинкәсе кадәр калай — юл билгесе беркетелгән бер багана янына туктап, калган араны эрерәк атлап узды.

— Илле адым! Әйдәгез, кардәш, көчебезне сынап карыйк әле. Өчәр пуля җибәреп, әнә шул калай мәрәне иләккә әйләндерикче!

Байкучатов сорау-фәлән бирмәде, унатарын чыгарды да, сынатмаска тырышып, бер-бер артлы өч мәртәбә гөпелдәтте. Таштимер йөгереп барып карады да:

— Берсе генә тигән, кардәш, анысы да кырыйгa гына,— дип кычкырды.— Исемегез кем әле? Менә хәзер, Фарукҗан мәргән, мине карагыз!

Ул уң кулын алга сузды да, әлеге түгәрәк калайга җитез генә төзәп, шулай ук өч мәртәбә атты. Байкучатов алтатар тавышына йөгерешеп килгән бер көтү ир-ат белән бергә әлеге юл билгесен карады — калайның уртасында өч яңа тишек пәйда булган иде.

Тураев, станция дежурының сукрануына тамчы да игътибар итмәстән, Фарукҗанны иңеннән кочаклап, аулаккарак алып китте.

— Ниятегез әйбәт, тәвәккәллегегез дә мактауга лаек,— диде ул.— Әмма коралыгызга чынлап ия булмый торып, Нурморатовларга баз казый башлау ярамайды кү.

— Өч ел һаман мылтык сөйрәп йөреп, авыр коралга күнегелгән,— диде Байкучатов акланып.— Моңардан юньләп аткан да юк.

— Дошман пулясы аңлатма сорамас,— дип уйлыймын. Миңа инде биш мәртәбә һөҗүм кылдылар. Соңгы вакытта арттан артык якын килергә куркалар куркуын, бигрәк тә икесен аяктан егып, ярыйсы сабак биргәннән соң. Җитмәсә, дошманнарның арттан сагалап йөрүчеләрен чүкедем!

Беренче күрүгә үк ягымлы тәэсир калдырган Таштимер Фарукҗанга торган саен ошыйрак бара иде. Хәзер инде ул аңа бөтенләй иптәшләрчә эндәште:

— Кемнәр атты соң сезгә?

— Артта күз юк шул, белмәймен. Үзем дөмектергәннәре таныш бәндәләр имәс иде. Монда арттан гөпелдәтәләр, кардәш, шуны исегездә нык тотыгыз. Кемнәргәдер аяк кына чала башлагыз, үче озак көттермәс.

— Димәк, Шиһабетдинов та кемнәргәдер комачаулаган?

— Шиксез. Әле кемнәргә диегез!

Таштимер кояшка арты белән борылып, күләгәсен үлчәп карады да үзенә генә билгеле исәп-хисапны йөртеп алгач:

— Хәзер уникенче яртылар икән,— диде.— Тагын сәгать ярымнан поездым киләде, анча көтәсем калмаган. Әле минем сезгә янә бер-ике авыз гәбем бар.

— Тыңлыйм, Таштимер әкә.

— Мин теге Латыйфханны бикәргә телгә алмадым.

— Нурморатовны әйтәсезме?

— Нәкъ шул купшы һәдһәдне. Үтә дә шикле бәндә. Заманында Шәмгун әкә тирәсендә күп бөтерелде, тасма телләнеп бер алдына, бер артына төште. Ул чакта Латыйфхан өчен Аксолтановтан да изге кеше юк иде. Канэчкеч әмир өерен туздырыр көннәр җиткәч, Шәмгун әкә шуның татлы теленә ышанып, Нурморатовны штурмга баручы кәмбәгаллар отрядының йөзбашы итеп билгеләтте. Әмма моның өчен тиздән үкенергә туры килде. Бөтен кызыл гаскәрләр, коралланган кәмбәгаллар мәмләкәткә золым чәчүче агулы елан өненә җаннарын аямый ташланганда, тинтәк һәдһәд, постын ташлап, сугыш кырыннан качты — кукыраеп Каганга кайтып килде.

— Ни өчен?

— Булачак Бохара мәмләкәте хөкүмәтендә назыйр булырга — министрлык җитәкләргә өметләнә иде ич ул. Кадерле башкаен канлы гарасаттан исән-имин сакларга кирәк кү! Ак костюм, панамалар киеп, муенына затлы галстук тагып, Каган күчәсендә[1] буталу хәвефсезрәк. Кулдагы мылтыкны болгый-болгый, ачык авызларга: «Җанаҗан кардәшләр, инкыйлап[2] җитте кү, түңкәрешне күрең, хөррият килде кү!» — дип гәперә бирәсең. Әнә шулай революционер атагың да чыга. Бер атуда ике куян!

— Штурмнан качуын ничек аңлатты соң ул? Ничек акланды?

— Җөдә ансат,— диде Таштимер.— Әле Бохара компартиясе секретаре Шәмгун Аксолтановның үзенә гаеп такты!

— Булмас!

— Һәй, Фарукҗан кардәш, безнең арада нинди иблисләр йөргүен белмәйсез кү. Әле кайчан гына үзе алланы теленнән төшермәгән Латыйфхан юлдаш Аксолтановны диндарлыкта гаепләде.

— Менә монысы кызык,— диде Фарукҗан җанланып.

— Җөдә,— диде Тураев мыскыллы елмаеп.— Кызыклар күрәсегез алда әле, Нурморатов кына исән булсын.

— Таштимер әкә, Латыйфханны хуплавым түгел лә бу минем,— диде Фарукҗан.— Сөйли бирегез. Ничек гаепли алды соң ул Аксолтановны?

— Шәмгун әкә отрядка, атакага күтәрелгәндә, тәкбир әйтергә куша.

— Нинди тәкбир?

— Тәкбир нинди булсын инде,— диде гаҗәпләнгән Таштимер. «Аллаһы әкбәр, аллаһы әкбәр, лә илаһы иллә аллаһы...»ны белмисезмени? Ходайның иң бөек зат икәнен әйтеп такмаклау. Нурморатов менә шул тәкбир әйтүгә каршы баш күтәргән. Коммунистик әхлакка туры килмәйде бу! — дигән.

— Ул хаклы түгел идемени? — диде Фарукҗан.

Таштимер шпал санап йөрүеннән туктап, Байкучатовка күтәрелеп карады, тик аның әчкерсез җитди йөзен күргәч, башын кагып көлемсерәп куйды. Аннары:

— Чәйханәгә кереп тамак чылатаекчы,— диде.— Бу гәпләр җаныма тиде, җитәде.

Әңгәмәдәшенең кәефе китүен тойгач, өстәде:

— Дәстәрхан янында дәвам кыламыз кү.

Фарукҗан күндәм генә аңа иярде. Алар вокзал мәйданын атлап узып, уңга борылдылар. Якындагы чәйханәгә кереп, икесенә зур бер

---

[1] Күчә — урам.
[2] Инкыйлап — революция.

чәйнек чәй, ике касә алдылар да, түрдәге тәбәнәк өстәл янына бармыйча, сәкенең бер аулаграк почмагына менеп, аякларын бөкләп утырдылар. Монда халык шактый ишле, гәп корыр өчен урыны бик уңайлыдан түгел иде. Бая вокзалда каршыларында йокымсырап киткән карт та, ялгызына бер чәйнек алып, сусынын кандыра иде. Чәйханә, ашханәләрдә була торган кыздырылган суган, аш исләре, күңелле шау-гөр, дәртле җанлылык. Шуның өстенә, Бохарага үтә хас чуарлык — ефәк чалма, банорас чапанлы муллалар, ыспай киемле шәкертләр, төенчекләрен яннарына теркәп куйган, инде күрәсен күргән кара бишмәтле диһканнар, һөнәрчеләр һәм европача киенгән Рәсәй кешеләре. Кай тарафка күз салма, ирләр, ирләр — картлар, егетләр, балалар. Әйтерсең лә, Бохарада бер генә җенес яши! Аларның күпчелеге, чалмасын салып куеп, түбәтәйдән генә калган һәм кәефләнеп күк чәй эчә иде. Чәйханәдә озын колаклы кеше булса да, монда Таштимер белән Фарукҗанның сүзен аулый алмас, чөнки алар, иңгә-иң утыруга карамастан, бер-берсен ишетер өчен дә тавышларын шәбәйтебрәк сөйләшергә мәҗбүрләр иде.

Тураев юл төенчеген чишеп, бер-ике пәтерен сындыргалады һәм аларны Фарукҗан алдына табарак этәрде, аннары абынәбат — Бохара хәлвәсен дә төртеп күрсәтеп:

— Канә, җитешең! — дип кыстады.

— Рәхмәт, Таштимер әкә!

Тураев бүтән бер сүз дә эндәшмәстән, бер-бер артлы өч касә чәй эчте, аннары перрондагы баягы сүзен һич тә өзмәгән төсле, болай дип дәвам итте:

— Нурморатовка коммунистик әхлак нимәгә? Сәүдәгәр токымының шуңа йөрәге әрни дип беләсезме?

— Сәүдәгәр малаемыни ул? — диде Фарукҗан.

— Әле ниндие генә — Оренбурда, Истанбулда белем җыеп кайтканы. Латыйфханга әхлак кайгырту имәс, ниндидер бер хәйлә табарга кирәк иде кү. Менә шуңа күрә ул тәкбиргә бәйләнәсе иткән дә инде. Төкерәге белән чүлгә дым кертергә маташкан дивана шикелле.

— Бәлки тәкбирсез генә дә һөҗүм итәргә...

Таштимер Фарукҗан сүзләрен кискен бүлеп:

— Кирәк иде шул безгә аны әйтү,— диде.— Мәҗбүр идек без, Фарукҗан мәргән. Чөнки мәкерле әмир Бохара әһеле арасында: «Динислам бишегенә кяферләр ябырылды, мөселманнарны чукындырырга, үтерергә яу чыкты, барыгыз да изге сугышка күтәрелегез, газават!» дип күпләр йөрәгенә дәһшәт салды, коткы таратты. Ныгытмага тәкбир әйтеп якынлашуыбызны ишеткәч, башта әмир ялганына алданган мәхәллә халкы аптырашта калды, аннары безгә ут яудырудан тыелды һәм Каршы капкасын үзләре ачып, баш күтәрүчеләрне кулларын күкрәгенә кушырып каршы алды, шуның аркасында анча гөнаһсыз канны коюдан котылдык. Әмма гәп башкада...

Тураев чәен уртлап сулу алгач кына, тавышын тагын да әкренәйтә төшебрәк, әңгәмәсен дәвам итте.

— Халык хөкүмәтен корганда, гаҗәпмени, без дә Нурморатов «каһарманлыгын» онытмадык, сугыш кырыннан качуын кайберәүләргә вакытында искә төшердек. Егеткәй өметен зурга сузса да, яшь бохаралылар күпме тырышса да, Нурморатовка назыйрлык тәтемәде. Хуҗаев ярдәмендә Чекага кереп урнашуга гына ирешә алды. Әлбәттә, Латыйфхан монда эшләргә дә лаек имәс, тик без, алла бәндәләре, шул көннәрдә аның кая борын тыгып маташуын сизеп өлгермәдек, хәзер инде күпшы һәдһәднең Бохара революциясенә ут кош икәнлеген исбатламыйча, ул аяклы казадан котылу мөмкин имәс. Чекада ул байтак яхшы эшкә таяк тыга алады, бәла китерәде кү...

— Партия моңа юл куймас,— диде Фарукҗан.

— Нинди партия?

— Минемчә, Бохарада хәзер бер генә партия бар. Коммунистлар.

— Шул кадәр бәдбәхетләр кереп тулгач, партиямени инде ул хәзер? Сәүдәгәрләр, муллалар мыжгып торган Яшь бохаралылар партиясенә әйләнде ул хәзер безнең оешма. Коммунист битлеген кигән миллионер Хуҗаевлар, Мөхетдиневләр баш булды анда, шуңа күрә алар белән бер калыптан сугылган дезертир Нурморатовка да шәп урын табылды. Берсе ым кагуга, икенчесе өрә башлый, өченчесе итәк астыннан ут йөртәде. Латыйфхан кебек еланнары шуны капларга ашыгады.

— Хәрби комиссар да шулар корбаны булгандыр, дип уйлыйсызмы?

Тураев сорауга сорау белән җавап бирде:

— Үз тарафдарыбызга без үзебез тозак кормабыз ич инде?

Алар хәлвә белән пәтердән дә авыз итеп, тагын бер-ике касә чәй эчкәннән соң, һавага чыктылар. Баганага бәйләнгән тимер-күгенә күз салгач, Фарукҗан сәгать икедә Бохарага кайтып җитәргә тиешлеген хәтерләде. Шуңа күрә ул соңгы сорауларын бирергә ашыкты:

— Шиһабетдинов иптәшнең хатын-кызлардан нинди якын танышлары булган икән?

— Әкият бу, ышанмагыз, кардәш. Шәмгун әкә генә хатынын үзе белән ияртеп йөртә ул. Нюрасы нугытманы штурмлаганда катнашып, җәрәхәт тә алды әнә. Ә Шиһабетдиновның җәмәгате җәркәнттә, монда бүтән андый һичкеме юк иде, яхшы беләмен.

— Таштимер әкә, Аксолтанов шигырьләр дә чыгармыймы ул?

— Элек язгалый торган булган. Шуннан нимә? — диде Тураев өнәмәгән төсле.

— Болай гына соравым,— дип елмайды Фарукҗан.— Моннан ничәдер ел элек бер татар журналында мәшһүр шагыйрьләребездән берәү менә мондый ике юллык бастырган иде:

> «Әй син, Шәмгун Аксолтан, шөһрәт дип күзең кыздырма,
> Каргышлы шигырьләр язып, бушка гомерең уздырма!»

Димәк, шул танышыбызга багышланган һәҗү икән бу.

Таштимер Фарукҗанны да, шигырьне дә хупламады, ахры. Чын күңелдән дустын якларга теләп:

— Шәмгун кардәш безнең арада алтынчы ел яши инде,— диде.— Солдат хезмәтеннән качып килгән михнәткәш. Намуслы, гадел, кыю. Бохара компартиясенә әсас салучыларның берсе.

— Әмма ул да мулла баласы бугай ич?

— Булса соң? Аның каравы Бохара революциясендә шундый дәртләнеп катнашучы да сирәк булгандыр. Халыкка мөрәҗәгать язумы, диһканнарга корал өләшүме, Нурморатов ташлап качкан отрядны һөҗүмгә алып барумы — һәммәсен дә шул арыслан йөрәк үз өстенә алды. Шиһабетдинов та нәкъ менә шундый каһарман иде.

— Таштимер әкә, сез таҗикча беләсезме?

— Ипи-тозлык сукалыйм.

Фарукҗан вокзалга кергәндә үк куен кесәсендәге хатларын барлады. Моннан да кулайрак бүтән ярдәмчене табу икеле иде, шунлыктан, эскәмиягә килеп утыруга, ул аларны Тураевка сузды.

— Безгә менә шушындый хәбәрләр дә килгәли, әмма минем таҗикчам үтә чамалы, ерып чыгарга булышмассыз микән?

Хатлар әллә ни озын түгел иде. Таштимер аларны уку барышында тәрҗемә дә итеп бирде. Бүген килгәнендә үзенең, Аксолтановның һәм тагын кайбер якын фикердәшләренең исемен укыгач, таң калып:

— Кем соң ул «Бум»? — дип сорады.— Таҗикча ябалакны аңлатуын беләм.

— Кушамат. Нәрсәсенә исегез китте аның?

— Мин аны иблис дияр идем! Безнең кая барып нишләвебезне астыртын гына күзәтәде икән кү бу мөртәт!

Фарукҗан да нидер төшенгән шикелле булды. Бохара Совет Республикасының дошманнары турында хәбәр биреп торырга тиешле агент ни өчендер аның җитәкчеләре һәм актив коммунистларның эзеннән йөреп, мәгълүмат җыйган иде.

— Җитмәсә, белеп хәбәр итәде, иблис ләгыйнь,— дип җенләнде Таштимер.— Аксолтанов кичә чыннан да Кызылтүбәдә кич кунды, ә мин Сәяхкаран мәхәлләсендә мәсләктәшләрем белән очраштым. Ни сөйләшкәнебезне ишетмәгән күренәде, вә ләкин хәтәр адәм бу. Бәлки миңа атучыларның да берсе шул булгандыр? Кемгә хәбәр итәде ул бу мәгълүматны?

— Агентура бүлеге мөдире Нурморатовка.

— Ала-ай, менә нимәгә куйганнар икән аны Чекага! Итәк-җиңне безгә икеләтә җыеп йөрү кирәк икән ләбаса. Кәттә рәхмәт, кардәш, ихлас рәхмәт! «Бум» дигән ябалакның алдагы хатларын да күрсәтеп барсагыз, җөдә тәшәккер кылыр идем.

— Килештек, Таштимер әкә. Мин үзем дә тәрҗемәчегә мохтаҗ идем.

Шул чакны алар яныннан инде ике мәртәбә күзләренә чалынган таныш кара сакал узып китте. Тураев аны шикләнеп карап калды һәм күңелсез генә:

— Бу карт та минем хакта Чекага хәбәр бирсә, гаҗәпләнмәм, ахры, хәзер,— диде.— Әмма артымнан ияреп бер үк вагонга менсә, поезд кузгалгач, мин бу адәм хурын тамбурдан тотып тондыруым җөдә ихтимал.

Фарукҗан елмаеп баш какты.

— Хәерле сәфәр! — диде ул.— Киләчәктә Аксолтанов белән икегезне кайда, кайчан эзләп табарга мөмкин булыр икән? Ары табан безгә дә бергәләп тырышу, киңәшеп хәрәкәтләнү мәгъкульдер сыман.

— Хуп булады.

Байкучатов бу очрашудан бик канәгать төстә кайтыр юлына кузгалды. Каганнан чакрым ярымлап ераклашкач, юлдан байтак читкә кагылды һәм калкурак җиргә камчы сабын кадап, шуңа кулъяулыгын бәйләп куйды. Аннары атын җитәкләгән көе илле адым кире чигенде дә аягүрә хәлдә унатарын кул яссуы кадәр генә булып асылынып торган мәрә яулыгына төзәде һәм өч мәртәбә чакмасына басты. Шуннан соң тимер-күген сөйрәп диярлек кулъяулыгына таба йөгерде, аны җирдән иелеп алып, ияренә җәеп карады һәм ачуы килеп, пешмәгән, дип пышылдады. Пуляларының икесе генә тигән иде. Әгәр караңгыда чабып барганда яки бахбае өстендә чакта атарга туры килсә? Болай җибеп йөргәч, аның үз башын чәрдәклэп ташлаулары ихтимал бит.

Ул унатарын яңадан корды, бу юлы аягына иплэбрәк баскан хәлдә, кулын ышанычлырак тотарга тырышып һәм яман да үҗәтләнеп, күнегүен кабатлады. Биш пулясының дүртесе кулъяулыгын тишеп узгач кына беркадәр тынычланып, тимер-күгенә атланды һәм камчысын уйната-уйната олы юлга чыкты. Моннан соң кулын көн дә күнектерәчәк ул, көн дә!

## 15

Нурморатов, мәрхүм хәрби комиссарны соңгы юлга озату мәшәкатьләренә күмелеп йөрсә дә, Кагандагы кайгы митингысында Байкучатовны күрми калмады. Мәйданнан халык таралышканда Фарукҗанның бер кырыйда Тураев, Аксолтановлар белән сөйләшеп торуы исә бигрәк тә аның күзенә көя булды. Чөнки ул Тураевның да, Аксолтановның да кем икәнлеген яхшы белә иде. Күптән танышканмы икән бу күн танау алар белән? Нинди серләрен уртаклашты ул? Бүген иртән бәлки нәкъ менә шул эшлекләләр йогынтысында кирле-мырлы

сукалап маташкандыр әле егеткәй. Әллә соң Шиһабетдиновның үзе белән дә ботка пешерүе расмы? Чекага ревком тәкъдиме белән урнашты урнашуын, тик суллар белән болай урамда әҗе-гөҗе килеп торгач, белмәссең, бер авызга килеп кыймылдаулары да бик мөмкин. Һәрхалдә, Байкучатов турында кайберәүләр белән вакытында фикер алышырга кирәклеге ап-ачык. Агентура бүлеге башлыгын ниндидер бер килмешәк аркасында бәлагә тыгып куйсалар һәм, шулай итеп, Бохара республикасының ышанычлы терәген какшатсалар,— Нурморатов үзен нәкъ менә шундый олы шәхес дип исәпли иде,— моны ни намусы, ни көрәштәшләре беркайчан да гафу итмәс. Ул болай үзенә генә түгел, бөтен Бохара революциясенә дә хыянәт иткән саналыр иде. Чөнки күпләр белән бәйләнгән иде Латыйфхан. Чылбырдагы бер генә буын да өзелергә яки тутыгырга тиеш түгел, бигрәк тә Нурморатов шикелле өстенә зур җаваплылык алганы — ничә дистә еллар буе ак патша җәбере астында интеккән Бохара әмирлеген хәзер чын бәйсез мәмләкәткә әйләндерергә омтылучы каһарман.

Башында Байкучатовка бәйле төрле планнар туса да, көннең калган өлешен сәүдә эшләренә багышлаганлыктан, Нурморатов егерме беренче октябрьдә Чекадагы барлык мәшәкатьләрен онытып торырга мәҗбүр булды. Империядә революция кабыну, шуңа ялганып озакка сузылган гражданнар сугышы башлану, Дутов яуларының Төркестанны Рәсәйдән аерып куюы, аннан да бигрәк ханлыкның вассаллыктан баш тартуы, Төркестан Халык Комиссарлары Советының Бохара әмирлеге мөстәкыйльлеген тануына карамастан, әмирнең Ташкенттагы яңа хакимнәрен санга сукмавы аркасында, инде күптән юлга салынган һәм ике якка да файдалы булган алыш-биреш өзелгән иде. Өч ел буе Рәсәй белән юньләп сәүдә итмәү нәтиҗәсендә Бохара халкы күп кенә товарларга — чагыштырмача арзанрак тукымага, шырпыга һәм сабынга, табак-савытка, тагын әллә нәрсәләргә кытлык кичерде, чөнки ак патша ярты гасыр буе әмирлекне сыкса да, мондый әйберләрне шушында җитештерү турында уйлап та карамады. Хәтта әле җирле сәүдәгәрләр берәр завод-фабрика корырга теләсә дә, теше-тырнагы белән карышты. Аның өчен Бохара әмирлеге үз товарларын кыйммәт бәядән сату, ярты хакка мамык, йон, каракүл, җиләк-җимеш алу урыны гына иде. Инде хәтсездән көйләнгән мондый багланышлар өзелгәч исә, Рәсәйдән әлеге тансык әйберләр килү тукталды, әмирлектә сатып алучысын тапмаган миллионлаган пот мамык, йон, миллионлаган данә каракүл тупланды. Революция башланганчы Бохара экспортының һәм импортының уннан тугыз өлеше Рәсәйгә туры килгәнлектән, яңа шартларда сәүдә тәмам тугарылды. Әфганстан, Иран, Һиндстан кебек күрше дәүләтләр Рәсәй урынын берничек тә тутыра алмый, җылы якта үстерелә торган нәрсәләргә алар үзләре дә тук, завод-фабрика малына исә алар үзләре дә мохтаҗ иде. Менә шуңа күрә аталы-уллы Нурморатовлар, Рәсәйне күрәлмасалар да, аның белән сәүдә багланышлары җайга салынуын, мичтән бәлеш көткән кебек, тансыкладылар. Латыйфхан, беренче мөмкинлек туугач, РСФСРның сәүдә вәкиле белән зур гына сумага килешү төзеде һәм өч ел буе җыела килгән мамык хәзинәсен тимер юл станциясенә ташыта башлады, егерме беренче октябрьдә исә ул әнә шул товарның икенче партиясен вагоннарга төятеп йөрде һәм бары иртәгәсен генә Чека эшләренә әйләнеп кайта алды.

Әминевне агентлар белән хәбәрләшүне теркәү бүлеге аша уздырырга кушуы Нурморатов планнарын шактый бутады. Ул болай эшләүнең конспирация кагыйдәләренә туры килмәвен, яшерен мәгълүматларның күп кеше кулыннан узганда читкә сарку мөмкинлеге артуын искәртте, әмма башлыгы әлек биргән әмерен барыбер үзгәртмәде. Теркәү бүлегенә ни үзбәкчә, ни таҗикча белмәгән рус егете җитәкчелек иткәндә әле артык пошынмаска да яраса, тиздән аның урынына Байкучатов билгеләнү Нурморатовның бөтен тынычлыгын алды.

Аның да таҗикча юнь чыгара алмаячагын ачыклагач, бераз кәефе рәтләнде рәтләнүен, әмма эчтән сызуы тәмам басылмады, чөнки барлык хәбәрләшүне ул таҗикчага күчереп бетерә алмый иде. Моның шунда ук күзгә бәреләчәгенә, шик уятачагына икеләнмәскә мөмкин иде. Анnetworks... үз туган телен эш йөртүдә куллана алмагач, нинди бәйсез мәмләкәт ди инде ул? Нинди республика ди?!

Кул астындагыларга базар хәлләрен генә түгел, үзенең политик дошманнарын һәм көндәшләрен дә күзәтергә кушкан Нурморатов яшерен почтаны хәзер бигрәк тә зарыгып көтеп ала иде. Бу — Әминев кушкан йомыш түгел, әгәр аның чамасыз мөгез чыгаруы фаш ителә калса, яначак иде. Дөрес, ул кайберәүләрне үтә мөһим очракларда урау юлдан хәбәр бирергә өйрәтте,тик бу тәвәккәллекнең дә үз кимчелекләре бар, шуның өстенә рәсми юлларны да сакларга кирәк иде ич әле. Кичәге һәм бүгенге яшерен хәбәрләрне теркәү бүлегеннән вакытында алмагач, Фарукҗанны Чекада бөтенләй күрмәгәч, ирексездән төсе качты. Әгәр бу күн танау Тураевларга хезмәт итсә? Чапкан җирдән өзә торган Таштимергә!

Мондый уйлар башына килүгә, Нурморатов, ут эченә төшкәндәй, кыбырсый башлады. Көндәм генә давыл көтә торган җан булмаганлыктан, күңеле уйнавын басар өчен, Комиссарлар Советына юнәлде һәм, Госманхуҗа Булатхуҗаев утырыштан бушауга, ургылып аның кабинетына керде. Йола буенча исәнлек-саулык сорашкач, шунда ук үзен борчыган мәсьәләләргә күчте.

— Госманхуҗа акә,— диде ул каударланып.— Чекада сулу алырга да рәт калмады.

— Ни булды? Нәрсә, кайнап торган сөт кебек күперәсең?

— Мин хәзер Бохараны гомумән танымыйм,— дип дәвам итте Нурморатов.— Элек әмирлек ак патшага буйсына иде, әмма Петербургның бердәнбер вәкиле пайтәхетебездән даими читтә яши иде. Хәзер без бәйсез мәмләкәт, ләкин кая карама, җилкәбезгә илбасарлар менеп атланган.

— Минемчә, безнең хөкүмәттә бер генә урыс та юк,— диде Госманхуҗа.

— Аның бөтен сере, чын бәласе дә шунда шул: үзе юк, кулы уйный! Илбасарлар хәзер углы күмерне үзләренең тугрылыклы ялчылары нугайларга — әлеге «татар» дигән башыбозыкларга чүпләтә. Тыштан берәү дә бәйләнерлек түгел, эчтән исә һаман шул ук империя сәясәте уздырыла! Чынлыкта безне кысканнан кыса баралар, ирек дигәннең «и» хәрефе дә калмады инде.

— Нинди дәлилләрегез бар?

— Чека рәисе итеп килмешәк Әминевне куйдыгызмы? Куйдыгыз.

— Ул минем кандидатура түгел иде,— диде Госманхуҗа.— Партия Мәркәз Комитеты тәкъдим итте.

— Башында нугай утыргач, тәкъдим итәр ул. Бик кызык килеп чыга: берсен төшерергә өлгермибез, секретарь итеп шуларның икенчесе сайлана! Җил уңаена башын игән агачлар сыман, барыбыз да килмешәкләр ихтыярына буйсына.

— Лаеклы үз егетләребез булмагач, нишлик соң?

— Нигә булмасын? Истанбулда укып кайткан күпме азаматларыбыз эшсез йөри ләбаса.

Госманхуҗа елмаеп куйды, әмма Латыйфханның үртәлә башлавын күреп, җитди төскә керде.

— Сез бу хакта Ревком рәисенә дә әйттегезме? — диде ул.

— Хаҗәт икән, әйтермен дә.

— Хаҗәт кенә түгел, сез моны кичекми эшләргә тиеш,— диде Госманхуҗа.— Бохара компартиясен «юлаучылардан» тазарту бара. Сез телгә алган азаматларның байтагы якын арада партиядән куылуы һәм, өзелгән тәсбих төймәләре кебек, пыран-заран китерелүе ихтимал. Ка-

ла оешмасын ныгытуга Мәркәз Комитеты секретаре Хәкимев үзе тотынды.

— Сайламаска кирәк иде аны,— дип Нурморатов чыраен сытты.

— Бала булмагыз, Латыйфхан. Үз егетебез, дип Таштимерне куярга идемени? Байлар, сәүдәгәрләр, дип күсәк күтәрә башласа, бүтән күн танаулардан аның кайсы ягы яхшырак булыр иде икән? Ә Хәкимев хәзергә бик ярап тора. Әгәр аңа бердәм рәвештә басым ясап, үз тарафдарларыбызны партиядә күбрәк саклап кала алсак, киләчәктә күз күрер.

— Партиядән кемнәрне чыгармакчылар?

— Күпләрне. Беренче җил революция чорында аулакта посып ятканнарга тиячәк. Таштимер комиссия хозурына килеп бик каты төкерек чәчкән инде. Без әмир өнен штурмларга барганда хәзер революционер исемен күтәрүче Яшь бохаралыларның байтагы өенә бикләнеп, асылга төренеп, пылау белән сыйланып кына ятты, дигән!

— Үз башына котырына инде ул мөртәт, килмешәкләр юри үсендерүен төшенми. Бик яхшы белеп торам: бөтен бәлане шул читтән тыкшынучылар чыгара.

— Нәрсә тәкъдим итәргә телисез соң сез?— дип сорады Госманхуҗа.

— Рәсәй Халык Комиссарлары Советының шәрык мөселманнарына мөрәҗәгатен хәтерлисезме? Алар 1917 елда ук: «Сез үз илегезнең хуҗасы булырга тиеш. Тормышыгызны үзегез теләгәнчә һәм үз күңелегезгә ошаганча корырга тиеш. Сезнең моңа тулы хакыгыз бар, чөнки язмышыгыз үз кулыгызда», дигәннәр иде.

— Бик дөрес.

— Дөрес икән, нишләп соң әле безнең Бохара компартиясенә керү-кермәвебезне нindидер нугай хәл итә?

— Беренчедән, партиядәге хәлне ул гына түгел, тулы бер комиссия тикшерә. Икенчедән, Хәкимевне бу югары постка Коминтерн вәкиле иптәш Куйбышев тәкъдим итте.

— Әйтерсең, алардан башка без берни эшли алмыйбыз.

— Март вакыйгаларын оныттыгызмыни?— диде Госманхуҗа.— Моннан ике ел элек әмиргә каршы үзебез генә күтәрелгән идек. Читтән ярдәм алмагач, карбыз ярган шикелле генә безне бик тиз канга батырып ташладылар.

— Мин элекке көрәштәшләремне хәзер гомумән аңлый алмыйм, Госманхуҗа ака. Җен алыштырмагандыр ич? Әллә сез дә, Хуҗаев шикелле, урыс шымчысына әйләнеп беттегезме?

— Кызмагыз әле, өрекне күмер дип читкә тондыру көлке, энем.

— Ничек инде кызмагыз? Рәсәйнең яңа хакимнәре милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын, аерылып чыгып мөстәкыйль дәүләт төзү хокукын игълан итте ләбаса. Хәрәзем булып Хәрәзем РСФСР белән килешү төзеп, үзенең бәйсезлеген ныгытып куйды. Ә без, Бохара егетләре, һаман күктән әмер көтәбезме?

— Рәсәй Бохара республикасының бәйсезлеген кире какмый ич. Корылтайда Төреккомиссия вәкиленең бәйсез БХСР төзелүен котлап чыгыш ясавын ишетмәдегезмени? Төреккомиссия безнең мөстәкыйльлекне әмир тәхетеннән куылганчы ук таныды.

— Төреккомиссия шул,— диде Нурморатов мыскыллы көлемсерәп.— Бохара әмирлеге белән элек Ташкент генерал-губернаторы гына эш иткән шикелле. Автономия аның боерыкларына каршы авыз ача алмый иде, билгеле. Ләкин бәйсез мәмләкәт дипломатик тиңлекне таләп итәргә тиеш, юкса ул бәйсезлекнең поты бер тиен. Без РСФСР хөкүмәте белән турыдан-туры рәсми килешү төзергә тиеш. Сез шуны да аңламыйсызмыни соң? Хәер, мин әмир сараен штурмлап алган көнне, беләсезме, нәрсә ишеттем?

Нурморатов Булатхуҗаевка карап, аның бөтен игътибарын үзенә

җәлеп итәргә теләгән шикелле, беравык тынып торды. Аннары сүзен дәвам итеп:

— Галиҗәнап ныгытмасына беренче бәреп кергән нугай полыгы тупчысы капка манарасы башыннан Бохара мәхәлләләренә, Регистан мәйданына күз ташлады да: «Ниһаять, соңгы әмир дә тез чүкте. Русия байрагы Азия уртасында яңадан горур җилфердәр!» дип кычкырды.

— Кабәхәт!

— Янәшәсендә басып торган нугай комиссары шуңа нинди искәртү ясады дисез? «Революция байрагы, иптәш Владимиров», дип кенә төзәтте. Бер генә сүз белән дә Бохара мәмләкәтен, аның Рәсәйгә буйсынмаганлыгын һәм буйсынмаячагын телгә алмады. Шул да мөселман булдымы инде? Тефү, мөртәт! Ю-у-ук, без андыйларга дәүләтебез дилбегәсен тоттырырга тиеш имәс, Госманхуҗа әкә.

— Әмма шулай да без Рәсәй белән бөтен әлемтәләребезне өзә алмыйбыз,— диде Булатхуҗаев.— Аның белән бәйләнешләребез зәгыйфьләнүгә, бәхетсезлегебезгә, соңгы елларда мамык алты тапкыр арзанаюын, шулай да әле ул чималны сатып алучы табылмавын үзегез яхшы беләсез. Каракүл бәясе өч ярым, йоннык — өч мәртәбә кимеде.

— Без сәүдә итик,— диде Латыйфхан.— Әмма сәяси бәйсезлекне югалтмыйк, үзебезгә үзебез хуҗа булыйк, җилкәгә менеп атланырга һәвәс «ярдәмчеләрдән» котылыйк. Бохара халкына илбасарлар ихтыярын көчләп тагучы нугайларны туган җиребездән сөреп чыгарыйк. Теле, гореф-гадәтләре ягыннан якын һәм мәдәниятлерәк булсалар да, кыйблаларын югалтулары аркасында, ул имансызлар безгә аеруча яман үрнәк күрсәтә, кара халыкны ил агаларына каршы котырта. Урысны кан дошманыбыз, кяфер, дип танытып була, ә бу аумакай нәгъләтләрне ни кылабыз? Алар хәзер безгә урысның үзеннән дә зыянлырак ләбаса!

— Барысы да имәс. Шуларның илбасарларга ничегрәк каршылык күрсәтү яхшы икәнлеген төшендерүчеләре дә җитәрлек.

— Менә шулай дип аларны куеныгызга аласыз да артыннан казасы көттерми. Җан дустыгыз Габделхәмит Гарипов Чекага Фарукҗан Байкучатов дигән якташын урнаштырган иде. Муенга тагылган таш булып чыкты бәдбәхет.

— Нәрсәсе белән кәефегезне кырды соң ул?— дип сорады Госманхуҗа.

— Фаҗига урынын юньләп карарга өлгермәстән, хәрби назыйр Шиһабетдиновның үзен-үзе үтерүенә шик белдереп, сафсата чәйни башлады. Кичә күзәтә торгач, мин бу көчекнең Таштимер, Шәмгуннәр белән дә иснәшүен белеп алдым.

— Кайсы бүлекне алып бара әле ул?

— Теркәү.

— Егетне кулга ияләштереп булмыймы соң? Комиссар һәлакәтен тик үзенчә юрасын, әмма Тураевлар белән әшнәлек коруы батмас. Чеканы сулларга бирергә ярамас!

— Әгәр ул түшәмгә сикерә башласа, нишләргә соң безгә?

— Үзе урнаштырган булгач, Гарипов кайгыртыр аны,— диде Госманхуҗа.— Төреккомиссия вәкиле белән дә очрашыгыз. Халык ихтыярын Таштимерләр имәс, нәкъ менә без чагылдыруны исбатлауга ирешәек. Фикерегез дөрес. БХСРның бәйсезлеген РСФСР хөкүмәте үзе турыдан-туры танырга һәм шуны дипломатик килешүдә теркәп кул куярга тиеш. Күпләр беренче җыйнүдән исерде, хәзер инде калганы көч түкмичә дә майлагандай тәгәрәр, дип ышана башлады, бәйсезлекне ныгыту юлларын ачык кына күз алдына китермәйделәр. Шундый чакта үз фикерегезне белдерү аклана гына имәс, бәлки үтә әһәмиятле фарыз эшкә әйләнәде.

— Сез моны аларга төшендермәдегезмени?

— Мин тукып тору гына җитмәйде кү,— диде Госманхуҗа.— Бер хәйләкәр эт каешы бар ич әле бездә. Аңа Бохара бәйсезлеге имәс, үзенең эш башында утыруы кадерлерәк.

— Фәйзулланы әйтәсезме?

— Башка кем булсын?! Шул җан көеге, төчкерәсе килсә дә, башта Төреккомиссия вәкиленнән рөхсәт алып кайта.

— Мәскәүдә укып йөргән чагында дагалаганнардыр аны.

— Белмәймен. Хөкүмәт башлыгыбыз, Бохараның бәйсезлеген кайгыртасы урында, җиде ятларга койрык болгап, «басмачылар, басмачылар!» дип лаф ора. Үзебезнең әнә шундый арт аягында торучы бер бәндәбез ун нугайдан, йөз урыстан яманрак!

— Алайса Шиһабетдинов бушка харап булган. Аның урынында шул төлкебез каза тапса...

— Белмәймен. Тик сез саграк, саграк авыз ачыгыз,— дип Госманхуҗа ишек ягына баш изәде.— Әмма ул төлкенең койрыгын бераз кыскарту зыян итмәс иде.

— Моңа ике куллап риза каһарманнар Бохарада бетмәгәндер, дип уйлыйм,— диде Нурморатов егетләнеп.— Тик сез үзегез дә, Госманхуҗа әкә, вакыты җиткәч ярдәм итсәгез иде.

— Истән чыгармыйм мин. Теге ният барып чыкмады әлегә. Ләкин киләчәк өметсез имәс, үзгәрешләр булмый калмас.

— Җөдә рәхмәт үзегезгә. Әле... эти кеше кышлакта ярлы-гидайлар белән бәрелешкән икән. Ул фетнәчеләрнең уллары хәзер Кызыл Гаскәрдә хезмәт итә, ди. Яшь әтәчләр гайрәт чәчми калмас, менә шул чак эткәйне канат астыгызга алсагыз, мин һәрвакыт...

— Карарбыз. Тик хәзергә теләсә кайда ризасызлык чыгармый тору хәерлерәк булыр иде.

— Нигә?

— Вакыты андый имәс, РСФСР белән килешү төзеп, Бохарабызның бәйсезлеген ныгытканчы, бигрәк тә бердәмлек кирәк. Төшенәсезме? Гидайларга шәфкать күрсәтү, мөселманнарның үзара тату, ярдәмләшеп яшәве яхшырак. Төшенәсезме? Шомарган таш булырга...

— Мин үзем, әлбәттә, аңлыйм. Картлачыбыз гына дуамалрак, сәясәт кешесе имәс.

— Аңлатыгыз үзенә. Инде... төп эшегезгә күчсәк, сулларны күзәтәсезме соң?

— Әйе. Тегендә-монда фәкыйрь диһканнарны, ялчыларны оештырып йөриләр. Тик әлегә кышлакларда эшләре бик пешми.

— Араларына үз кешеләребезне мүкләргә иде. Эчтән таркатырга.

— Мин үзем нәкъ менә шулай хәрәкәт кылырга тырышам да инде. Юк эшне бар итеп, койрык кебек тагылгалыйм.

— Суллар оештырган җыелышларга әләгеп, сыбызгы борыннарга Бохарадагы хәлләрнең Рәсәйдәгегә бер дә охшамавын, ат азгынының гына тайга иярүен иплән искәртә алсак, тагын да яхшырак булыр иде.

— Әлбәттә. Тик аларның телен белү җиңел имәс.

— Җыелышларын кайда, кайчан җыячакларын алдан ачыклап, моннан соң миңа хәбәр итеп торыгыз әле.

— Баш өсте.

— Фәйзуллага да, Таштимергә дә яманлык теләмәйбез, бәйсез Бохара мәмләкәте язмышын кайгырту гына бу. Төркия, Иран кебек дәүләтләр сафына бассак, безгә шул җитәде.

— Әмма Хуҗаев, Тураевлар менә шушы юлда киртә имәсме?— дип гаҗәпләнде Латыйфхан.

— Алар революция алдына чамасыз күп бурычлар куеп ялгыша. Кайсы яктан чагыштырсак та, Бохара Европадан ерак, тормышта аның үзенә генә хас юлы бар. Саташучылар белән рәхимсез бәреле-

шеп, үзебезнең хаклы икәнлекне исбатларга, Бохара Халык Совет Республикасын ят көчләр йогынтысыннан азат итәргә тиеш без.

Латыйфхан Госманхуҗаны күптән белгәнлектән, бәхәскә кереп тормады. Ул үзе күрәшнең сәяси юл белән генә хәл ителеп бетәсенә ышанмый, мондый тартышның кискенрәк тукмашуларга китерәчәген күздә тота һәм шуңа әзерләнә иде. Чөнки ул атасына каршы күтәрелүчеләрнең иртәме-соңмы баласына да кагыла башлаячакларын сизенә, әмма үзендә әнә шул үсеп-тернәкләнеп килүче күпчелек ягына чыгарлык дәрман таба алмый иде. Булатхуҗаев исә гади миллионердан чын дәүләт эшлеклесенә әверелә башлаган сыман тоелды Латыйфханга. Билгеле, бу аңа кесәсен кабартырга бер дә комачауламас. Кара син аны, ничек шомартып маташа, дип уйлады ул көнчелеге кузгалып. Үзе Тураевларга баз казый, үзе аларга бер дә яманлык теләми имеш. Төлке дисәң дә төлке инде, бәлки гыйбрәт алырга кирәктер менә шулардан?

Нурморатов, билгеле, көнчелеген тышка чыгармады, саубуллашыр алдыннан янә бер фикерен генә уртаклашты.

— Госманхуҗа әкә,— диде ул,— мәмләкәтнең бәйсезлеге бәйләнешләрне киңрәк җәюне таләп итә. Безгә шәрык дәүләтләре белән тыгызрак аралашу бигрәк тә хаҗәт. Ләкин хәзергә кадәр Бохара иң якын күршесе Әфганстан белән дә илчеләр алмашырга ашыкмый.

— Әйе шул. Революциябезнең беренче көннәреннән башлап диярлек мин бу хакта иптәшләргә гел тукый киләм инде.

— Пар күгәрчен кебек тату яшәү начармыни? Моңа кем каршы?

— Фәйзуллалар төркеме. Имеш, Әфганстан үзара ярдәм итешү турында әмир белән хәрби килешү төзегән ил.

— Әмир мәмләкәт башлыгы чагында булды ич ул,— диде Нурморатов, ачуы чыгып.— Күрше дәүләт дусларча ярдәм күрсәтүне үтенгәч, нишләргә тиеш иде икән соң Әфганстан? Ә хәзер эш башка. Аманулла хан әлек тә Яшь бохаралыларга теләктәшлек белән карый иде, алар идарәгә килгәч исә, бәйләнешләребезне яңартуга ул бигрәк тә сөенеп тотыначак.

— Мин дә шулай уйлый идем. Үгетли торгач, моңа бүтәннәрне дә күндердем шикелле. Аптырагач, Фәйзулла да бирелергә мәҗбүр булды.— Сез телгә алган һәр ике мәмләкәткә рәсми тәкъдим җибәрергә җөрьәт итте.

— Җавап бирделәрме соң?

— Әлегә юк. Тик без РСФСР белән төзеләчәк килешүне алдан ук аермачык күз алдына китерергә тиеш. Хәрәзем риза булган шартлар сезгә ошадымы?— дип кызыксынды Булатхуҗаев.

— Бөтенләй үк имәс. Килешүдә Хәрәземнең бәйсезлеген чикләгән урыннар бар.

— Хуҗаев, Хәкимев, Куйбышевларга юллыкканда сез менә шуларга басым ясагыз. Алдан ук теләкләребезне белеп торсыннар. Әңгәмә ясап чыккач, курерсез әле мине. Ә хәзер, кичерәсез, монда утырышыбыз башланачак.

Нурморатов комиссар Булатхуҗаев белән җылы саубуллашып, кабинеттан чыгып китте. Үзен борчыган кайбер нәрсәләрнең ачыклануына ул бик канәгать иде.

## 16

**Телеграмма**

РСФСР Тышкы Эшләр Халык комиссары
Г. В. Чичеринга

Бәреп төшерелгән хыянәтчел һәм интектергеч әмир хакимияте урынында барлыкка китерелгән Бохара Совет Республикасы, баш күтәргән халык ихтиярын үтәп,

бөтен дөнья әһеленә, бигрәк тә изелгән Шәрык милләтләрен азатлыкка чыгару көрәшендә алгы сафта баруы белән мәхәббәтебезне казанган тугандаш рус халкына, барлык илләр белән иң тыгыз дуслык һәм хезмәттәшлек бәйләнешләрендә яшәргә какшамас нияте барлыгын белдерә.

Бохара Республикасы, шушы карарын кабул итеп, РСФСР Тышкы Эшләр халык комиссарына, ике дус республика мәнфәгатьләрен күздә тотып, үзара даими Дипломатик Вәкилләр алмашырга тәкъдим итә.

Бохара Халык Совет Республикасы Халык Комиссарлары
Советы Рәисе, Тышкы Эшләр комиссары Ф. Хуҗаев
Бохара, 1920 елның ... сентябре

**Телеграмма**

Бөек Әфганстан Дәүләте әмире
Аманулла хан Галиҗәнапләренә

Әлегә кадәр үз хөкүмәте тарафыннан акылга сыймаслык дәрәҗәдә изелгән Бохара әһеле халык мәнфәгатьләрен илбасар инглиз империализмына саткан, Совет Русиясенә дошманнарча хәтәр маҗаралар әзерләгән әмиргә каршы баш күтәрде һәм аны тәхетеннән бәреп төшерде, үз вәкилләре җитәкчелегендә тулы бәйсезлеккә ирешәчәгенә, милли тормышын тыныч юл белән уңышлы рәвештә алга җибәрә алачагына ышанып, мәмләкәт өчен республика идарәсе рәвешен сайлап алды.

Бохара Халык Совет Республикасының Тышкы Эшләр Халык Комиссариаты шушы хакта Сез Галиҗәнапкә хәбәр итеп, бөтен мәмләкәтебез исеменнән Әфганстан һәм Бохара халыклары арасындагы күп гасырлы күршеләрчә дуслык мөнәсәбәтләрен киләчәктә дә сакларга һәм үстерергә ныклы нияте барлыгын белдерә. Бохара Совет Республикасы Тышкы Эшләр Халык Комиссариаты, дусларча дипломатик бәйләнешләрне ныгыту өчен, Сез Галиҗәнаптән иң якын арада үзара Тулы вәкаләтле Вәкилләр алмашуны билгеләвен үтенү хәерле дип саный.

Бохара Халык Совет Республикасы Халык Комиссарлары
Советы Рәисе, Тышкы Эшләр Халык комиссары Ф. Хуҗаев
Бохара, 1920 елның ... сентябре

## 17

Каганнан кайтып килүче Фарукҗан Чека урнашкан кәрвансарай капкасы төбендә Амантайны күреп, гаҗәпләнә калды. Җитез генә атыннан сикереп төште дә, исәнләшергә дә онытып:

— Ни булды? Нигә болай иртәләдең? Без кичен күрешергә килешкән идек ич?— диде.

Амантай бер кырыйдарак чүгәләп торган кызыл гаскәригә ымлап:

— Без иптәшем Иргәш белән эле,— дип җавап бирде.— Сезне инде байтактан сагалап торабыз. Фарукҗан шунда гына дувал күләгәсенә чүгәләгән ят солдатка күз салды. Утыз яшьләр тирәсендәге дәү гәүдәле, ачык чырайлы, кыйгачрак кашлы бер егет икән. Үз исемен телгә алуны ишеткәч, ул да Байкучатов янына килеп басты.

— Сез ашыгасызмы?— диде Фарукҗан.

— Безне иртәгә басмачыларга каршы Байсын ягына җибәрергә җыеналар. Шуңа күрә бүген ял бирделәр.

— Сәгать ничәләр бар икән әле?

— Төш ауды бугай инде,— диде Амантай.

Фарукҗанга бу гәп уйланырга вакыт отар өчен генә кирәк иде. Сәгате беләгендә, әмма егетләр күрерлек түгел.

— Алайса мине шушында бераз көтеп торыгыз,— диде ул.— Якындагы берәр чәйханәгә кереп, ял итә-итә гәпләшербез.

Фарукҗан тезгенне Амантайга тоттырды да ашыга-ашыга үз кабинетына юнәлде. Нурморатов сукрана башлаганчы, яшерен почтаны тизрәк агентура бүлегенә тапшырырга кирәк иде. Сере беленгән хатларны эшлекле генә кыяфәттә Латыйфханга кертеп биргәндә, үзенең типографиядә чамадан тыш озак торуын, хәзер исә Ревкомга йөгерәсе барлыгын аңлатып, сүзен бик кыска тотты һәм, хезмәттәше ни дә бул-

са эндәшкәнче, бүлмәсеннән чыгып та сызды.
Яңа танышларын Чекадагыларга бик үк танытасы килмәгәнлектән, Амантай белән Иргәшне үзенә ияртеп Фарукҗан бүтән мәхәлләдәге аулаграк чәйханәгә юл тотты. Тиздән алар бер ачык әйванның күләгәдәге сәкесенә аяк бөкләп менеп утырдылар да, касәләренә чәй ясап, сусын баса-баса әңгәмә корып җибәрделәр. Фарукҗан, вакыты кысанрак булса да, егетләр белән гәпләшмичә Ревкомга китәсе итмәде. Чөнки аңа торган саен ачыклана төшкән катлаулы шартларда ниятләрен тормышка ашыру өчен ныклы таяныч, ышанычлы ярдәмчеләр кирәклеге сизелә башлаган, ул инде яңа планнар корырга тотынганчы ук, Амантайны нәкъ менә шуңа яраклы егет дип уйлап куйган иде.
— Димәк, сезне ерак сәфәргә җибәрмәкчеләр?— диде ул эченнән пошынып.
— Әйе. Әгәр отрядтан аерылып калмасак, иртәгә таңнан кузгалачакбыз,— диде Амантай.
— Аерылып калу теләгегез дә бармыни?
— Бар иде шул, сезнең янга тора-сала йөгерүебез дә бушка-бикәргә генә түгел. Мин әллә кайларда озак-озак юлга чыгып йөрсәм, Балҗанны кем кайгыртыр? Аңа тагын берәр этлек эшләмәсләр, дигән ышанычым юк гуй. Җулдас Шиһабетдинов та дөнья куйганнан соң...
— Анысы хак инде үзе.
— Менә Иргәшнең дә күңеле тыныч имәс.
— Ни өчен?
— Кичә туган кышлакларыннан килгән бер якташын күргән ул. Бик зур бәла чыккан анда, дустымның атасы белән энесен хәбескә ябып куйганнар.
— Кемнәр?
— Нурморат байлар,— диде Иргәш телгә килеп.— Кышлактагы байтак кешегә үз кырларын уртагыннан эшкәрттерә торган карун алар. Җирләре әз булганлыктан, менә безнекеләр дә өлешкә кергән булган. Аның шарты буенча, әнә шул уртагыннан игелгән мамыкның үзенә тигән уңышын да ярлылар җир хуҗасына сатарга тиеш. Ул билгеләгән арзан бәядән. Быел безнекеләр, минем сүзне тыңлап, үз мамыгын югарырак хакка кем алса, шуңа сатачагын белдергән, аңа бүтәннәр дә кушылган икән. Бай абзыйның шуңа җене чыккан, кирегә сукалаучыларны үзенчә акылга утыртырга керешкән.
— Халык революция булганын белмимени? Күмәкләшеп бер байны да җиңә алмыймы?— диде Фарукҗан.
— Юк шул. Кайсы аңа бурычка баткан, кайсы сәдакасын алган. Туган-тумачалык, күршелек хакы дип, байның улы Бохарада зур урында эшли икән, дип тә кыймыйлар. Аннары безнең якта да басмачылар хәрәкәт итә башлаган икән, бай абзый шуларга да таяна торгандыр инде. Халык өркетелгән.
— Кышлагыгыз кайсы якта?
— Зәрәфшан елгасы буенда. Шуннан Каратау итәге башланып китә, усаллар яшерен оя корырлык аулак җирләр.
— Иргәш Байсын якларына китеп югалса, кардәшләрен якларга кеше дә калмый,— дип Амантай иптәшен куәтләде.— Җәберләнгән карт белән якын энесенең бердәнбер өмете хәзер ул гына.
Фарукҗан тәмәке кабызып, бу ике егеткә ничегрәк булышырга мөмкин икәнлеген уйлый башлады. Йөрәкләрендә байгуралларга карата нәфрәт кайнаган сугышчыларны, әлбәттә, үзеннән ерак җибәрергә ярамый иде аңа. Тугрылыклы таяныч буласыларына шикләнәсе дә юк.
— Кызыл Гаскәрдә күптәнме сез, Иргәш туган?— дип сорады ул.
— Елдан артык.
— Шулаймыни?— дип гаҗәпләнде Фарукҗан.— Бохара революциясе күтәрелүгә ике ай да тулмады ич әле.

— Ә мин Нурморат байлар эзәрлекләвеннән Төркестанга качкан идем, беренче мәртәбә шунда кулга корал алдым.

— Сөйләтсәгез, Иргәш әкәнең тормышы үзе бер кыйсса,— диде Амантай.— Ул инде Шиһабетдинов кулы астындагы мөселман батальонына язылып, Җидесуга барып та сугышкан.

Фарукҗанның сораулы карашын күреп, Иргәш:

— Әйе, андый хәлләр дә булды,— диде.

— Бохарага күптән әйләнеп кайттыңмы?— дип сорады Байкучатов.

— Өч-дүрт айлар чамасы элек. Яраларым төзәлгәч, Каган мамык эшкәртү заводында эшли башлаган идем, революция тагын хәрби кием кияргә мәҗбүр итте мене.

— Шиһабетдинов сине шәхсән белә идеме?

— Каганда яңадан очрашкач, бик тиз танып алды. Җидесуга баручылар арасында без — үзбәкләр әллә ни күп имәс идек, бәлки шуңа күрә исендә калдырган булгандыр,— диде Иргәш.

— Яшермә инде Фарукҗан жулдастан,— диде аңа Амантай.— Шиһабетдинов сине Җидесуда чакта ук бервакыт мактаган булган гуй.

Байкучатов Амантайга карап көлемсерәп куйды. Иптәше өчен юкка гына бу кадәр тырышмыйдыр егеткәй, дип уйлады. Дөньяны ерып бара торган чая адәм булса, мичәүгә җигәр өчен Фарукҗанга бүтәнне эзлисе дә юк. Тик менә Ревкомга барыр вакыт җитү аны сүзен түгәрәкләргә ашыктырды.

— Сез, егетләр, Чекада хезмәт итәргә ризамы?

— Җарайды.

— Риза, риза!

— Алайса кирәкле абзыйлар белән сөйләшеп карыйм әле, сез мине шушында көтеп торырсыз.

Амантай бик ялынган төстә Фарукҗанны урамга кадәр озата чыкты.

— Өмет сездә генә Байкучатов жулдас.

* * *

Чакырылган җиргә Фарукҗан шактый кичегеп килгән булып чыкты — Ревком председателе урынбасары Габделхәмит Гарипов сүзен аны шелтәләүдән башлады. Шуннан соң кичә сорашырга җыенган Сипулян кышлагындагы хәлләргә ләм-мим кагылмастан, иппе генә хәрби комиссар вакыйгасына күчте.

— Теләсә нинди эштә төгәллек яхшы,— диде ул.— Ат урлангач, абзар бикләүдән ни файда? Шиһабетдинов та, әгәр яңадан терелә алса, үзенә-үзе кул салуны бәлки уйлап та карамас иде. Әмма эш узган. Чөнки һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Ә бит Баһаветдин революция эшенә нинди бирелгән кеше иде. Сез аның белән танышырга өлгергән идегезме әле?

— Юк, туры килмәде.

— Кызганыч. Ифрат та хөрмәткә лаек комиссар иде ул. Намуслы, тугрылыклы, дәртле. Әмма кайнаррак канлы, мавыгыбрак китүче каһарман иде. Калган сыйфатларыгызны әлегә юньләп белмим, тик мавыгу ягыннан Шиһабетдиновка охшагансыз икән. Мәрхүмнән гыйбрәт алыгыз: мавыгу яхшыга илтми. Үзегезне йөгәндә тотарга, вәгъдәчел булырга кирәк.

— Тырышам инде тырышуын, тик Кагандагы эшләремне дә үтәргә кирәк иде ләбаса.

— Мин кичегүегезне генә әйтмим, башка яктан да гайрәтне чигермәвегез хаҗәт. Илнең күзе очлы, безгә хәбәрләр килә тора...

Гариповның йоны кабару сәбәбен чамалый башлаган Фарукҗан, Тураев искәртүләрен һәм Чека председателе кисәтүен хәтерләп, берни

белмәгәнгә сабышты. Йөрәге кымырҗуын басарга тырышып, Симиниев чаккандыр инде, дип уйлады. Аның исәбенчә, эчен тырнаган хәбәрне Ревком әһеле үзе белдерергә тиеш иде. Әмма көтеп-көтеп тә Гариповның ни дә булса өстәргә ашыкмавын күргәч, Фарукҗан ирексездән телгә килде. Чөнки ул һаман шулай авызын йомып утырса, Габделхәмитнең: бу егет сырт кабартып маташа икән әле, дип уйлавы һәм тагын да җенләнәрәк бирүе ихтимал иде.

— Тел сөяксез,— диде Фарукҗан.— Кемнәргәдер ышанып, Сипулян кышлагына да йөгерттегез ич безне, нәтиҗәсе генә, белгәнегезчә, ташка үлчим булып чыкты.

Гарипов әңгәмәне үзе теләгән юнәлештән читкә борып алып китәргә ирек бирмәде, Фарукҗан әйткәнне бөтенләй ишетмәгәндәй:

— Яңа җирдә нинди шәп дуслар таптыгыз соң?— дип сорады.

— Бохара революциясенә хезмәт итүчеләр миңа барысы да дус.

— Эредән кубарга яратабыз да инде без,— диде Гарипов.

— Дөресе генә.

— Ә исемнәрен атасак? Күзгә төтен җибәрмәсәк?

— Монда бөтен гомер эштә уза инде,— диде Фарукҗан.— Кеше белән шунда танышыла. Миңа иптәш Әминев тә бик ошый. Юлтай Симиниев белән Латыйфхан Нурморатовлар да күңелгә якын әйбәт егетләр.

— Шулаймыни?

Гариповның чәнечкеле тавышы буенча Фарукҗан үзенең артыграк бөгеп ташлавын чамалады һәм тизрәк хатасын төзәтергә ашыкты:

— Билгеле, эш барышында үзара бәхәскә дә кергәлибез, әмма...

— Йә, йә, нәрсә «әмма»?

— Әмма сер сыйдырырлык, кирәк чакта ярдәм кулы сузарлык кешеләр алар.

— Шулай икән, нинди ике төрле сүз булырга мөмкин? Безнең максатыбыз бер генә: Ревком һәм Халык Комиссарлары Советы карарларын үтәү. Ревком рәисе аңлатканча, бөтен Бохара мәмләкәте халкы бер сулыш алып яшәргә, бер сафка басып көрәшергә тиеш. Үзара баш бирми, һәркайсыбыз мөгез чыгарырга тотынса, потыбыз бер тиен!

Фарукҗан Ревком председателе урынбасарының партияне бөтенләй телгә алмавына игътибар итте. Гаҗәп! Әйтерсең лә, Бохара революциясе коммунистлар җитәкчелегендә ясалмаган. Әйтерсең лә, Ревком башына менеп утырган бай сәүдәгәр бер сынык икмәккә мохтаҗ диһканнарны гына көне-төне кайгыртудан бушамый! Нәрсәдер сәеррәк акыл сатып тора шикелле бу Гарипов. Үзенең чын уйларын әйтеп бирүдән ни өчен сакланырга тиеш соң әле Фарукҗан? Бер сүзгә килә алмаудан куркыпмы? Билгеле, андый очракта хәлләр катлауланмый калмас. Чека председателе юкка гына сак булырга өндәмәгәндер инде егетне. Тик хәзер ул Ревкомда коммунист белән йөзгә-йөз сөйләшә ләбаса! Фронтларда бет симертеп, нужа шулпасы эчеп тапкан хакыйкатен нигә ярып салмаска тиеш соң әле ул?

— Бай белән ярлы бер сулыш алырмы икән?— диде ул ниһаять.— Изүче белән изелүче бер сафка басармы?

— Монда байлыкның ни катнашы бар?

— Хакимлекне кесәсе кабарган сәүдәгәрләр эләктереп алгач...

— Тураев исе килә бу сүзләрдән,— дип чыраен сытты Гарипов.— Сәүдәгәр гаиләсендә туу гына кешегә ышанычны какшатырга тиеш түгел, агай-эне.

— Аларның эчкерсезлегенә шикләнми карау мөмкинмени?

— Сез Коминтерн вәкиле Куйбышевны, Бөтен Русия Чекасы башлыгы Дзержинскийны да дошман күрәсезме?

— Тәүбә, тәүбә. Аларны миллионер Мөхетдиневләр белән чагыштырырга ярамый ич инде,— диде Фарукҗан ачуы килеп.

— Ә нигә ярамасын? Беренчесе — кадет корпусын тәмамлаган

офицер малае, икенчесе — Польша морзасы.

Байкучатов үзенә үрнәк, чын коммунист дип санаган бу кешеләрнең кем баласы икәнлеген бөтенләй белмәгәнлектән, аптырап калды, әмма Гарипов алдында наданлыгын күрсәтәсе килмәгәнлектән, бәхәстән тыелды. Ревком әһеле исә дәлилләрен тагын да ныгытып куйды:

— Гаҗәп түгел,— диде ул,— өстен катламнарның иң намуслы, иң алдынгы вәкилләре элегрәк тә хезмәт ияләре ягына чыккалаган. Маркс көрәштәше Энгельснең фабрикант булуы һәр укымышлы кешегә билгеле. Мөхетдиневне дә нәкъ менә шундый каһарманнар исәбенә кертү табигый булачак.

— Ул үзенең байлыгын фәкыйрьләр белән уртаклашканмы соң?

— Монысы һич тә мәҗбүри эш түгел,— диде Гарипов.— Мөхетдиневләр мөлкәте болай да Бохара мәмләкәтенең байлыгы санала. Берничә көндәшен генә искә алмасак, кем дә алар малына күз алартмый.

— Революцион аңга ия кеше башкаларның мохтаҗлык кичерүен үзе күрергә һәм тоярга, аларның хәлен җиңеләйтүне кайгыртырга тиештер,— диде Фарукҗан.— Югыйсә, аның революционер исемен күтәреп йөрүеннән ни мәгънә?

— Әйдәгез, без бу хакта сөйләшмик әле,— диде йөзе кырысланган Гарипов.— Бала кеше исән-сау атасының малына хуҗа була алмый. Габделкадыйр әкәнең юмартлыгын, үз тормышын куркыныч астына куеп, әмир золымына каршы җаны-тәне белән көрәшүен монда олысы-кечесе бик яхшы белә. Без аларга акыл өйрәтергә килмәдек, бары булышырга гына. Шулай килештек ич инде?

Фарукҗан эндәшмәде, ул инде хәзер Габделхәмит Гариповның Мөхетдиневлар тарафдары булуын да, үзенә карата аның мөнәсәбәте үзгәрүен дә ачык төшенде. Әмма бу үзгәрешнең сәбәбен бик үк аңлап бетермәде. Беренчедән, Тураев искәрткәнчә, ике сыңар — бер кием булган Мөхетдинев белән Хуҗаевның соңгысын ялгыш та телгә алмавы белән сәерсендерде Гарипов. Икенчедән, Шиһабетдиновны Мөхетдиневкә ялгап олылавы белән дә гаҗәпләндерде. Монысы инде Таштимер Тураев фаразына бөтенләй каршы килә иде. Ут белән бозны бергә куш, имеш! Монда нindидер сер, хәйлә-мазар булырга тиеш, күрәсең. Югыйсә Байкучатов Шиһабетдиновны кайгыртуын сиздереп кенә сөйкемсез сөяккә әйләнмәскә тиеш иде. Үзенең күңел сындырырлык бүтән кимчелеге, җан биздерерлек адымы күзгә чалынмавына иманы камил иде аның. Димәк, нindидер астыртын уй борчый Гариповны, шунлыктан капшыйдыр инде ул якташын.

Ревком председателе урынбасары аның дәшмәвен килешү билгесе санапмы, сүзен эшлекле йомыш кушу белән тәмамлады.

— Сезне берәр атнага Ташкентка җибәрергә булдык әле,— диде ул.— БХСРның сәүдә вәкиллегенә йөк озата барырсыз.

— Кайчан?

— Иртәгә үк юлга җыену кирәк. Командировка якларын иптәш Әминев үзе аңлатыр. Чекага кайткач та, аның хозурына керегез. Йомыш җаваплы, сынатмагыз. Бохара республикасы финанс кыенлыкларын җиңә алмаса, халык революцияне кабул күрмәячәк. Шунлыктан безнең өчен сәүдә хәлиткеч әһәмияткә ия.

— Аңлашыла.

— Урысча да белә торган дөнья күргән егет, тырыш чекист булуыгызны исәпкә алып кушабыз бу җаваплы эшне.

— Рәхмәт.

— Барыгыз, хәерле юл телим!

* * *

Әңгәмә сугу әллә ни барып чыкмаса да, очрашуның болай эшлекле тәмамлануына бик риза иде Фарукҗан. Ләкин Чека председателе Әми-

нев бер дә уйламаганда аны яңадан пошаманга төшерде.
— Кисәтүләремне күңелегезгә юньләп салмагансыз, ахры, егеткәй?— диде ул.
— Нигә, Галимҗан абый?
— Саксызлыгыгыз көттермәгән ич.
— Нинди саксызлык?
— Көтелмәгән командировканың серен аңларга башыгыз җитмимени соң, җанкисәгем?
— Сер?
— Бәласеннән башаяк, дип ераккарак олактырырга тырышулары түгелме икән болай сезне?
— Шул сәбәп булдымы икәнни?
— Вакыйгалар куерган җирдән читләштереп, хәтәр кызуыгызны сүрелдерергә омтылу сыман бу, минемчә.
— Чыннан да... Ташны менә кая тәгәрәткән икән Гарипов! Әмин, тиле, җаваплы эш куштылар, дип кәперенә яздым тагын.
— Моны инде мич башыннан төшмәгән җан аңламаса гына. Йөк озата баручылар сездән башка да җитәрлек булачак анда.
— Таманысы... Чека мине ул сәфәрдән йолып кала алмыймыни? Бүтән берәр йомыш кушыпмы, авырый дипме?
— Ревком сүзен санга сукмау ярамый шул. Гарипов сезне тәгаенләп атагач, тәкъдимне кире кагу кыенрак. Уйларга кирәк.
— Моны уйлап баш ваткан арада ашыгычрак бер нәрсәне хәл итәсе иде, иптәш Әминев,— диде Фарукҗан.— Чека таяна алырдай кешеләрне барлый йөрергә кушкан идегез ич әле сез.
— Әйе.
— Әзләнә торгач, менә дигән ике егеткә юлыктым мин. Үзебезнең эшкә тартасы иде аларны.
— Нindirәк кешеләр?
— Икесе дә кызыл гаскәри, хәрби комиссарның аерым отрядыннан. Элек берсе көтү көткән, икенчесе иген иккән, аннары бераз Каганда, заводта эшләп алганнар. Икесе дә әмир өенен штурмлауда катнашканнар.
— Кайдан белдегез?
— Үзләре сөйләде.
— Сайрамыйлар гына микән соң алар? Тикшердегезме?
— Өлгермәдем. Тик безнең сөяк булулары әллә кайдан сизелә.
Чека председателе Фарукҗанга карап көлемсерәде дә:
— Болай ярамый, Байкучатов,— диде.— Башта яхшылап аныкларга кирәк кешене. Әгәр аларның һич югы берсе генә дошман шымчысы булса да, күпме бәла чыгасын чамалыйсызмы? Безнең кебек тәҗрибәсез, махсус әзерлексез чекистләрнең ышанычын казанып, серебезне ятларга ташый башласа, халыкка зыян-зәвер китереп, яман атын үзебезгә күтәртсә?
Фарукҗанның, Амантай белән Иргәштән шикләнмәсә дә, Әминевкә каршы килергә теле бармады. Аның ни әйтергә дә кыймый торуын күреп, Чека председателе йомшый төште.
— Төп Бохара егетләреме соң үзләре?— диде.
— Әйе. Берсе үзбәк, икенчесе казакъ.
— Монысы яхшы, күздән ычкындыру ярамас аларны.
— Егетләрне иртәгә басмачыларга каршы Байсын ягына җибәрергә җыеналар. Аларны шушында калдыру күбрәк акланыр иде.
Фарукҗан Чека председателенә Амантай белән Иргәш турында бөтен белгәннәрен сөйләп биреп, үз тәкъдимен кыюрак нигезли башлады.
— Мин бүген кичен аерым отрядның командиры белән очрашам әле, сөйләшеп карармын,— диде Әминев.— Соңрак кагылырсыз, утым янып торуы тәрәзәдән күренер.

Фарукҗан инде чыгып китәргә кузгалганда гына Чека рәисе аны бусагада туктатып:

— Монда сезне бер хат көтә бит әле,— диде.— Ниндидер үсмер малай китерде. Дежур кулына да бирмәгән, мине көтеп алды.

Байкучатов, коридорга чыгып, үтә пөхтә һәм җиренә җиткереп ябыштырылган конвертны ачкач, иң элек хат язучының кулы таныш булмавына игътибар итте, аннары кәгазь битенең аскы почмагындагы имзаны укыды. Хәбәр бөтенләй өмет итмәгән кешедән — Зөһрәгөлдән килгән иде.

## 18

«Фарукҗан!

Кайчан да булса сезгә хат язарга туры килер, дип бөтенләй башыма китермәгән идем. Шуңа күрә кайда эшләвегезне, яшәвегезне дә сорап тормаганмын. Тик бүген очраклы рәвештә исемегезне ишеткәч, аннан да бигрәк, гәп коручыларның нәкъ менә сезне күздә тотуларын чамалагач кына, кулыма каләм алдым. Фарукҗан, моннан соң бик каты сак булыгыз. Бохарада сезгә теш кайраучылар бар икән. Алар берни алдында да тукталып калмаячак, уңны-сулны карап, итәк-җиңне җыеп йөрегез. Бу сүзләрне язасым килмәсә дә, бәлагә таруыгыздан, харап булуыгыздан куркып, үтенәм: тормышыгыз кыл өстендә, китегез сез тизрәк бу яклардан! Үз арагыздагы хыянәтче бик хәтәр, серегезне зинһар теләсә кемгә чишмәгез. Уку өенә бүтән аяк баса күрмәгез, безнең танышлыкны берәү дә белмәсә яхшырак. Шуның өчен исемемне телгә алмагыз, бу хатны да укыгач юк итегез.

Үзебезнең язмышны уйлагач, торып-торып елыйсым килә: нинди гаебебез булды икән тәңре һәм аның бәндәләре алдында? Ә сез соңгы тапкыр күрешкәндә шул кадәр йончыган идегез, мин әле дә бүлмәдә ничек өстәлгә таянып утырган көе йокыга талган кыяфәтегезне оныта алмыйм. Әле дә, икейөзле хаиннәр җанын гына кыймаса ярар иде, дип сезнең өчен шул хәтле куркам, эшем эш, ашым аш түгел, йокыларым да әллә кая очты хәзер. Бохарада чын революция ясарга әле иртәрәк. Мондагы халыкның хәлен дә, гадәтен дә беләм ич мин. Дөнья кырылган чакта кеше гаугасына тыгылып нигә тозакка кабарга? Ыгы-зыгы басылгач, ихлас күңелдән булышып йөрүебезне җирле халык онытсын яки гаепләсен өчен генәме? Күр дә тор, бу бер заман нәкъ менә шулай булачак әле. Кайтып китегез сез, Фарукҗан, илкәйгә! Гомер ике килми, мөмкинлегегез барда үз бәхетегезне кайгыртырга тырышыгыз. Минемчә, сез хәзер бик үзгәргән, кем күңелен дә эретерлек егет булып җитешкәнсез. Хәвеф-хәтәрдән исәнаман котылуыгызны теләүче яшьлек дустыгыз...»

Фарукҗан, Зөһрәгөлнең бу хатын укыгач, иңенә ишелгән авырлыкны тоймый кала алмады. Симиниевләрнең өнәми каравы, Тураев искәртүе, Гариповның сәер әңгәмәсе һәм ул кушкан йомышның яшерен серен Чека председателенең аңлатып бирүе, ниһаять, яшьлек дустының кисәтүе — болар барысы да аның баш очында болыт куеруын раслый иде. Кем икән соң ул араларында йөрүче елан? Дошманы кем булса да, койрыкны кысып аулакка шыла торганнардан түгел шул Байкучатов. Муены сынганчы яки җиңеп чыкканчы көрәшәчәк ул алар белән. Яхшылык тели теләвен Зөһрәгөл, әмма яңа Фарукҗанның, әйе, әйе, моннан җиде еллар элек күргән шәкерттән бөтенләй аерыла торган егетнең нindirәк кеше икәнлеген белми шул кызыкай. Кызыкай?

Фарукҗан яңадан хатка күз йөгертте. «Харап булуыгыздан куркып... үзебезнең язмышны уйлагач... оныта алмыйм... кем күңелен дә эретерлек егет»... Хәвеф-хәтәр барлыгын гына хәбәр итми, тагын ниләр турындадыр ишарәли шикелле бу хат. Әллә соң күңеле кузгалганмы Зөһрәгөлнең? Хәзер нишли ала инде ике бала анасы? Кияве нинди кеше икән? Яшьлек хисләренә таянып кына алар тормышына бәреп керә аламы соң Фарукҗан? Юк, юк шул! Еллар буе исеннән чыгармавы рас, аны яратуын да яшерә алмый ул, әмма хәзер кайбер нәрсәләр ачыклангач... Мин-минлегенә кагылганлыктан гына түгел, инде язмышны үзгәртү мөмкин булмаганлыгын төшенүе, шуңа күрә яшьлек мәхәббәтеннән өмет өзүе аркасында да Зөһрәгөлгә баглы планнар корырга җөрьәт итми иде Фарукҗан. Иллэр язмышы капылт

үзгәргән заманда нindидер бер егетнең хыяллары чәлпәрәмә килүен кем санга тыга? Җәрәхәтле аның бәгыре, хаты күрсәткәнчә, сөйгәне дә тыныч түгел, ахры, әмма шул кадәр ераклашкан ярларга хәзер күпер салу мөмкинмени? Зөһрәгөл үзен телгә алуны үзе үк тыеп торганда кая инде ул!

Байкучатов шырпы сызып, хатка ут төртте дә аның дөрли-дөрли янып бетүен сабыр гына күзәтеп торды. Кемнәр янавын әйтә алмаса да, кисәтүе өчен рәхмәт Зөһрәгөлгә. Һөҗүмне көндәм генә кәтеп тормаячак инде Фарукҗан, ышаныгыз!

* * *

Аны күреп алгач урыннарыннан сикереп торган Амантай белән Иргәшне Байкучатов бер ишарә белән кире сәкегә утыртты һәм үзе дә алар янына теркәлеп:

— Хәлдән килгәннең барын да эшләдем, егетләр,— диде.— Калдырырларммы, юкмы — бүген кичен хәл ителергә тиеш.

— Рәхмәт, җулдас Байкучатов. Өметебез сездә генә гуй, көтәрбез.

Фарукҗан кесәсеннән берничә көмеш чыгарып:

— Берегез чәй дә алып килегез инде,— диде.— Иркенләп гәп корырга да була хәзер.

Иргәш җитез генә йомышны үтәргә торып киткәч, Байкучатов кеше-карадан бушый төшкән чәйханә залына бер караш ташлап алды да:

— Амантай, яхшы беләсеңме син бу иптәшеңне?— дип эндәште.

— Нигә алай дисез?

— Буламы аңа ышанырга?

— Булады гуй, отрядта да үз итәләр аны. Гидай. Аның белән бергә сугышка керүчеләр Иргәшне тәвәккәл, куркусыз, дип сөйләделәр. Менә миңа да ярдәм кулын беренче ул сузды.

— Кара аны, мөгез чыгарса, башың белән җавап бирәчәксең!

Берәр чынаяк чәй белән тамакны чылаткач, Фарукҗан үзен кызыксындырган нәрсәләрне сорашырга тотынды.

— Иргәш туган,— дип эндәште ул,— син Рахманкол белән танышмы?

— Хәрби комиссар йомышчысын әйтәсезме?

— Әйе. Тик икегез дә миңа «син» дип кенә эндәшегез әле, егетләр, дусларча булсын!

Иргәш, Амантайның «менә күрдеңме?» дигән төсле карашына елмаеп, сүзен дәвам итте:

— Мин аны Җидесуда чакта ук белә идем. Чөнки ул анда да гел Баһаветдин уртак тирәсендә чуалды.

— Чуалды? Нигә алай дисең?

— Ә нәрсә?— диде Иргәш сорауга сорау белән.

— Өнәмәгән шикеллерәк телгә алдың түгелме?

— Мин генә имәс, баштарак аны уртак Шиһабетдинов үзе дә бик үк хуп күрмәде бугай.

— Алайса нигә үзенә йомышчы итеп алган соң?

— Ул Җидесудан киткәндә иптәшкә бөтенләй бүтән кешене сайлаган була. Акларга каршы иңгә-иң торып сугышкан. Верный фетнәсен дә бергәләп бастырышкан егетне.

— Нигә сүтелгән соң?

— Сүтелмәгән. Верный политбүлеге бирмәгән. Тиздән ул егетне запас батальон комиссары итеп билгеләгәннәр. Менә ул азамат ичмасам егет дисәң дә егет иде. Атакага барганда алга ургыла, чигенгәндә иң арттан, бүтәннәрне каплап, атыша-атыша иң соңыннан гына чигенә иде.

— Ә Рахманкол? Начар сугыштымыни ул?

— Начар түгел,— диде Иргәш төмсә генә.
— Шиһабетдинов аны баштa ни өчен ошатмаган икән соң?
— Рахманкол революциягә кадәр полициядә хезмәт иткән.
— Шулаймыни? Кызы-ы-ык... Сез моны белә идегезме?
— Ул яшереп маташмады. Хәер, теләсә дә, бу эш кулыннан килмәс иде. Безнең арада Верный егетләре җитәрлек иде ич.
— Кызыллар ягына кайчан чыккан икән?
— Былтыр Ташкенттан безнең мөселман батальоны килү белән үзе кушылырга омтылган. Чая егет ул, урысчасы да яхшы.
Фарукҗан Иргәш сүзләреннән аның Рахманколга бик үк дусларча мөнәсәбәттә булмавын ачыкласа да, әле үзен канәгатьләндерерлек дәлилләр ала алмаган иде. Ни өчен ошатмаган икән ул аны? Ошатмавы яки Рахманколга бик үк битараф карамавы сизелеп тора лабаса.
— Ярый, егетләр,— диде Байкучатов,— кичке эшкә дә әзерләнергә кирәк ич әле безгә. Киемнәрегезне берәр җирдә алыштырып, мылтыкларыгызны шунда яшереп килерсез инде. Сәгать җиде-сигезләр тирәсендә Газәли мәхәлләсенең чәйханәсендә хозурлана башларбыз. Сез Каганга кайтып тормыйсыздыр ич инде?
— Юк, билгеле.
— Хәер, вакыт та калмаган икән ләбаса. Монда борын төртерлек берәр урыныгыз бармы соң?
— Бохарада Иргәшнең танышлары яши икән,— диде Амантай.— Чәйханәдә нишлибез инде?
— Анда хәзер төрле тынгысыз халык җыйнала икән. Ләбихәвез Әрбаб мәхәлләсендәге шундыйрак бер оя әфьюн тартучылар аркасында туздырылганнан соң, Бохараның кайбер әһелләре Газәлидә күңел ача башлаган. Чәйдер, гәптер, җырдыр, төрле планнар корудыр — барысы да шунда икән.
— Әлә-лә, күрәбез икән тамашаны,— дип елмайды Иргәш.
— Безнең бурыч — әнә шундыйларга тыныч кына колак салып утыру,— диде Фарукҗан. Хәбәрдаррак кешеләр тирәсенә елышырга кирәк. Сез, Иргәш, бездән аерым җиргә кунакларсыз.
— Хуп мәйле.
— Иптәшләрегезне, алар белән кызыксынган шикле бәндәләрне дә караштырырсыз. Әмма төп бурычыгыз — Шиһабетдинов һәлакәте турында берәр яңалык ишетү.
— Әле ул вакыйга тәмам ачыкланмадымыни?— дип сорады Иргәш.
Борчыла, вакыйганы авыр кичерә, күрәсең. Әмма ничек тынычландыра ала соң инде ул Иргәшне? Шуңа күрә саран рәвештә:
— Үзара гына әйткәндә — юк,— дип кенә җавап бирде.
— Гаҗәп!
— Әгәр чәйханәдә безгә берәр куркыныч янаса, тавыш-тынсыз юкка чыгарга. Мөшкел хәлдә лампаны бәреп төшерергә мөмкин. Бәрелеш була-нитә калса, бәлагә тарымас өчен, чәйханәнең бар тарафын алдан ук караштырып куегыз. Бигрәк тә керү-чыгу юлларын.
— Җарайды,— диде Амантай.— Анда безне шундый әкәмәтләр дә көтәмени соң?
— Белмим, бу инде һәр очракка әзер булыр өчен кисәтүем. Газәли мәхәлләсен беләсезме?
— Беләбез.
— Без, Амантай, шундагы чәйханә янында кыл җидедә очрашачакбыз. Ә сезгә, Иргәш, алданрак яки бераз соңрак килсәгез дә ярый. Хәзер, әйдәгез, Чекага кузгалдык. Икегезгә дә алтатарлар бирим әле. Калганын шунда юл уңаенда аңлатырмын.

*Дәвамы киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ

## Камил Мостафин

### Әзлибез...

Төркем-төркем, бергәләшеп,
гел сөйләдек күмәкләп.
Безнең алда кемдер барды,
төркемнәрне җитәкләп.

Әнә шулай керә килдек
язларга һәм көзләргә...
Җыелышып, төкердек без
чиста, якты йөзләргә...

Төшкә һаман бердәм заллар,
дәррәү алкышлар керә,
төшкә бүген без хуплаган,
аткан тавышлар керә!

Артка борылып карыйбыз да
шаккатып торабыз без,
иң изге хатирәләрне
бөртекләп җыябыз без.

Бер-беребезнең күзенә
карарга оялабыз,
йөгерәбез авыртканга,
йокыдан уянабыз.

Үз-үзебезне әзлибез,
заман ачысын татып...
Без бик озак төркем булдык, —
кеше булырга вакыт!

### Табылмаган кабер турында

*Фәхрине үтереп ташладылар...*
Г. Ибраһимов. «Тирән тамырлар»

...Үтереп ташладылар...

Кая барыйк? Көньяктамы,
төньяктамы кабере?
Ачса иде шушы серне
белгәннәрнең гаделе.

Кая илтик чәчәкләрне —
акларын, кызылларын?
Әгәр белсәк, узар идек
юлларның озыннарын.

Барып җиткәч, туктар идек
һәм торыр идек тынып,
чирәмнәренә кагылып,
уйланып, онытылып...

Куелмаган булса әгәр —
ташларын куяр идек;
намусыдай ап-ак ташка
исемен уяр идек...

...Кая барыйк? Кычкырабыз!
Белгәннәр дәшми икән...
Ә үтереп ташлаучылар
һаман да яши икән.

Алар да кайчак уза ди
юлларның озыннарын,
ярата ди чәчәкләрнең
кан кебек кызылларын...

---

Камил МОСТАФИН *(1932) — шагыйрь. «Җыр сафка чакыра», «Горур ташлар», «Урман баласы» һ. б. татар, рус телләрендә дөнья күргән шигырь китаплары авторы. Чиләбедә яши.*

## Кайтып була

Гомер уртасында күңелең тулса,
сагыш басса, чәчәкләрең сулса —
узган көнгә кире кайтып була, —
сине белгән, сине күптән сагынып көткән,
   син яраткан туган ягың булса.

Йолдызларың сүнсә, җырың тынса,
сүзең, юлың, моңың онытылса, —
кире кайтып була үз-үзеңә,
язмышыңа, күптән җуйган өметеңә, —
   син саклаган туган телең булса.

Һәлак булсаң, янсаң, бугазыңнан
явызлык һәм кабахәтлек буса, —
кайтып була исән кешеләргә
китап, рәсем яки якты бер сер булып, —
   син сатмаган Туган илең булса.

❁

Дусларга ышанмаганда,
ятларга ышанмаганда,
хатларга ышанмаганда, —
җырларга ышанабыз.

Акыллылар арасында
юләр мәллә без генә?
Тыңлыйбыз да, җырлыйбыз да —
үзәгебез өзелә.

Заманалар да үзгәрде,
үзгәрдек үзебез дә...
Нинди нурлар элеккечә
агыла йөзебезгә?

Әллә безне соңгы чиктә
туган тел тарта микән?
Миһербанлык кимегәндә,
әллә моң арта микән?

❁

Корал итеп була фигыльне дә, шигырьне дә,
ләкин башта
көрәш кырын табыйк, ачыклыйк.
Туган якта үскән әрем өчен сугышып була,
ләкин әрәм узган көнебезне
җыр итәргә берүк ашыкмыйк.

## Яшь музыкант

Кич булдымы, агач йортта, аулакта, ярсып-ярсып,
яшь пианист уйный башлый, клавишларга басып.

Аккордлары яңгырыйлар — пьесалар, вальслар,
ах, бу иске ноталарда нинди таныш тавыш бар?

Аларда нинди газап бар — кем аңлатсын балага?
Малай уйный, ә бүлмәсе, нәни өе тар аңа.

Ул сизми татлы күз яше битләрен чылатканын,
аңламый бу аккордларның күңелен җырлатканын.

Шаша! Нечкә бармакларын ташлый акка, карага.
Көлә! Алга талпынганда, бөдрәләре тарала.

Кинәт туктый: башын игән, бөккән ябык аркасын, —
әллә алкыш шавын көтә, әллә җәллад балтасын...

## Шигърият

Сөйли, елый, көлә. Ялгыз йөрәкләрне
ташлый шашкын, сихри дулкынга.
Моңлы гүзәлләрне, япь-яшь юләрләрне
кочагына өнди, упкынга.

Ташланалар аңа, шатланалар аңа,
үртәләләр, әллә нишлиләр.
Әллә ничә гасыр әллә нәрсә эзли
бу диңгездә сәер кешеләр.

Тапмыйлар шул һаман! Тегеләрдән көлә
шамакайлар, җеннәр, патшалар.
...Хисләр сүнәр иде, сүзләр сулыр иде,
җырлар тынар иде —
тапсалар.

# Нурия Измайлова

## Язын

Яз житсә, бөтен барлыгым
Сулый башлый авылча.
...Шәһәрдә үскәннәр ничек
Сулый икән, яз булса?

Илгә кайткан каз моңнарын
Туктап тыңлыйлар микән?
Шатлыгында кайгы барын
Ни дип юрыйлар икән?

Алар сыерчык килгәнгә
Шатланамы, юк микән?
Шатланмаса, алар өчен
Яздан ни шатлык икән?

Язны кыштан ничегерәк
Аера икән алар? —
Язда — яшәү төсе, шуны
Аңлыйлар микән алар?

Торна юлына тотынып
Күккә менәләр микән?
Каен суына кушылып
Тама беләләр микән?..

Тал исләренә исереп,
Акыл җуялар микән?
Былбыл булып, талга кунып,
Сайрар булалар микән?

Язын ни дип җырлый алар?
Төш күрәләр нindирәк?
....Алар миңа — башка галәм
Кешеләре кебегрәк...

## Айлы төндә

Ай шартларга житкән балкуыннан,
Якты япкан төнгә, ут яккан.
Абагалар чәчәк ата булыр
Мондый төндә. Теләк теләп кал!
Бу авылда нәрсә кирәк миңа?
Миңа — бернәрсә дә, тик бары —
Мәңге калсын иде бу авылның
Айда йөзгән гүзәллекләре:
— Әй!
Бу илләрне саклый күр!
Халыкларга саулык бир,
Җир-суларга байлык бир,
Иделләргә балык бир,
Җан биргәнгә — азык бир,
Урман, һава, сазлык бир!
Яшьләренә тәүфыйк бир,
Картларына шатлык бир,
Кызларына сафлык бир,
Сүзләренә хаклык бир!
Эшләренә ярдәм бир,
Җаннарына ял да бир,
Һәр ел саен бала бир, —
Уйлап торма, ал да бир!
Балаларга иман бир,
Ил ташламас чыдам бир,
Ил сөйдергеч сулар бир!
...Корымасын туган җир!

---

Нурия ИЗМАЙЛОВА — *шагыйрә, «Яратам», «Алтын тарак» һ. б. шигырь китаплары авторы. Проза әсәрләре дә яза. Мәскәүдә яши.*

❁

Тугыз катлы таш капчыкта
Эт улый да эт улый...
(Аңлашылмас ярсу белән
Тугыз катлы өй тулы.)
Ул үзе дә аңламыйдыр,
Һаман «Уһ!» ди — тоядыр
Бер гомердә әллә ничә
Төрле яшәп булганын:
Әгәр ул болай булмаса,
Әгәр ул башка булса,
Урман-далалар эченә
Кереп адашкан булса,

Янында әти-әнисе
Талпынып чапкан булса,
Язмышыңны сайлап алу
Серен аңлаткан булса!..
Их, алар барсын белергә
Тиеш тә бит югыйсә!
Тик беркем дә берни белми...
Дөнья киң, бүлмә кысан...
Урманнарда, далаларда
Кемдер бар да, эт юктыр...
«Уһ!», дип әйтә белгәч, инде
Урының шулдыр, дустым!

❁

Елга буйлап чәчәк килә,
Килә, дулкыннарда.
Җирнең гүзәл бер баласы!
Ә чүп булып ага...

Балык — суда, ә гөл — җирдә
Чакта гына күркәм...
И кадерсез! Бу хәлеңдә
Син соң чәчәк микән?..

Әллә тамыр җәяр урын
Язмаганмы сиңа?

Җанын куяр урын тапмый
Тамырсызлар гына!

Җисемеңә, исемеңә
Җаның, ахры, яттыр!
Кем соң ирекле көненнән
Дулкыннарга аксын!..

Җирдә тапмаган урыныңны
Эзлисеңме судан?
...Минем газиз гомеркәем
Агып бара сыман!

## Тормышта көз

Без булмаган заманнарга
Күчте кошлар тын гына...
Калды моңсыз-телсез бушлык
Көзнең кошсыз куенында.
Чыңлый иде җирдә сазлар,
Кылын җилләр чиртсә дә.
Киләчәккә киттеме алар?
Калдыларммы үткәндә?
Шаулы урманнар урнында
Чир-сырхау манзарасы.
Каный миләш тәлгәшләре,
Гүя йөрәк ярасы:
«Ямьсезлекне ямьлим!» дидер,
«Җылытыйм суыклыкны!»
Шәрә ботакларны бизәп,
Тутырмакчы бушлыкны...
Утын, дәртен, мәхәббәтен
Куйсын соң ул кайларга! —
Яз сайраган кошны көзен

Чакырмакчы сайрарга...
— Әй, миләшем! Киләчәккә
Йә үткәнгә кит инде! —
Син — шигырьнең кадере беткәч
Туган шагыйрь шикелле!
Үзми сине ач-кернә дә,
Чөнки рухи ач алар...

— Яныйм! Туңыйм! Газапланыйм!
Ачы язмыштан балланыйм!
Кыш килерләр, ашарлар...

## Дөньяга карап

Кырмыскалар сөйрәгәннәр
Үзләреннән зуррак кисәк...
Тагын әллә кемнәр сөйрәр
Кирәгеннән зуррак кисәк.

Хозурланып, адым саен
Эт тә, әнә, «тамга сала»:
Монда аның хуҗалыгы!
Аяк басма! Иснәп кара!

Кошлар сайрый: «Монда мин!» дип,
Башкаларга янап тора.
Чекерәеп, әрләннәр дә
Берсен-берсе санап тора.

«Гомер бик күп, ә җир бик аз...» —
Әй ташбака уйлы-гамьле!
Таш капчыктан башын сузып,
Үлчәп йөри биләмәне!

Нәкъ ташбака гаме белән
Адәм балалары килә:
Җирне бүлеп, кисәк-кисәк
Күтәргәннәр иңнәренә... —
«Кояш астындагы урын
Җитми калды миңа гына!
Акчадан да, дачадан да
Быел тагын күрше уңа!»

Ә бүленми торган кояш
Карап тора көлә-көлә:
«Шушы кыска гомерендә
Әллә кемнәр тыз-быз килә!»

*

Кырмыска кебек чагымнан
Җырлап кердем урманга.
Кырмыска да тешләмәде,
Курку белмим шуңарга.
Бер яктан да мәкер көтмим,
Юк итү җиңел мине.
Ах, чынлыкка чыгармагыз
Бүректәге бүрене!
Каргар ул җылы бүрекне,
Токымын, тәрбиясен...
Килә: «Бүре арасында
Яшәү авыр», диясем!
«Бүре» дию сүздән генә.
Яшим таш урамнарда.
Таш атыш монда! Баш ватыш!
Читен иманы барга!
Ташка өйрәнгән башларда
Акыл күптер — иман юк...
Безне «Ак бүреләр» итеп
Әкияткә куярлык.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Гурий Тавлин

# АФӘТ

РОМАН

### Сигезенче бүлек

1




р-егетләрне эти «солдат уйната». Авылдагы хәрби хезмәткә барасы яшь-яшь егетләрдән алып, инде армия хезмәтендә булган һәм анда булмаган кырык яшькә кадәрге ирләр — барысы да «солдат». Эти аларны иске мәчет янындагы ачыклыкта тезеп, тигез сафларда такыр басудагы Шалкан атавы дигән җиргә алып китә. «Солдатлар» агачтан үзләре ясап корымга буяган «мылтыклар»ын түтәсеннән сул кулларына тотып иңнәренә салалар да, дүртләп тезелгән тигез сафта этинең айт-двасына гөрес-гөрес басып, урамнан җырлап үтәләр:

Дошман килсә ил өстенә,
Кол буласын белсен ул!
Эх...
Ленин юлы — якты нур
Коммунага юл ача...
Юллар ача, гөлләр чәчә,
Коммуна мәңге яшә!..

Җыр башлану белән хатыннар, кызлар, малайлар, әби-бабайлар, яшь киленнәр, бала-чага — бөтенесе, әле көн иртә булса да, урамга ябырылалар.

Сафтагы рәтләр чуар, җирдә аунарга уңай нинди иске киемнәре бар, «солдатлар»ның өсләрендә әнә шул. Аякларында бик азларының гына күн итек яки ботинка, зур күпчелегенең — чабата. Әмма чабаталы аяклар да нык, тигез басалар. Гәүдәләр төз, күкрәкләр киерелгән, йөзләр җитди, тавышлар көр.

Сафта адымын бутаган кешене эти шундук күреп алып, аңа:

— Кызылармеец Фәлән Фәләнов, левый, левый, айт-два, айт-два,— дип гомуми ритмга җайлашырга булыша.

Хатын-кызлар:

— Кара, ничек матур атлыйлар,— дип «солдатлар»га сокланып карыйлар.

---

Ахыры. Башы 3 нче санда.

Соңгы көннәрдә без дә бүтән уеннарны оныттык. Чүлмәк тау итәгендә «солдат уены» белән мавыгабыз. Өлкәннәрнең үз айт-двасы, безнең үз айт-двабыз.

Әти элек тә җитди кеше иде, хәзер тагын да җитдиләнде. Өйгә ул, тәмам арып, йокларга гына кайта. Әни белән дә, минем белән дә бик аз сөйләшә.

— Син яңадан нәкъ Урта Азиядәге вакытыңдагы кебек, Сабир,— ди аңа әни.

Әти саран гына елмая.

— Шул чактагы шикелле яшьтәме?

— Шул чактагы шикелле үк җитди, шундагыдай ук каралдың, тешләрең генә ак калды...

«Солдатлар» Шалкан атавыннан алҗып, тир-тузанга батып, кич кенә әйләнеп кайталар. Ләкин көтүдәге сарыклар шикелле тәртипсез таралышып түгел, иртә беләндәге төсле үк сафка тезелеп, җырлап кайталар:

Данлы Кызыл Армияңә,
Партиябез, ышан!
Партиябез, ышан!
Нинди генә алышта да
Җиңелер дошман,
Җиңелер дошман!..

Әти сафны бөтен авыл аша үткәреп, иске мәчет янындагы ачыклыкта туктата. Агач мылтыкларны иңнәрдән төшерергә кушып, «К ноге!» әмерен бирә. Команда бердәм үтәлмәсә, шундук «Отставить!» ди. Мылтыклар яңадан иңнәргә менеп кунаклый. Кабат «К ноге!» командасы яңгырый. Әти арыган, алҗыган кешеләрнең тизрәк өйләренә таралып ял итәргә теләүләрен бөтенләй күрми шикелле. Ниһаять, мылтыклар иңнәрдән ул теләгәнчә төшәләр. Әти «Вольно!» әмерен бирә һәм:

— Иртәгә дә көндәгечә шушында җыйналабыз, соңга калучы булмасын. Разойдись! — дип кычкыра.

Иртәләрен иске мәчет янына соңга калып килгән «солдатлар»ны авыр «җәза» көтә. Алар хәрби өйрәнүләрне үтәр өчен район үзәгенә җибәреләләр. Анда авылдагыдан күпкә каты, ди. Әнә физкультура укытучыбыз Габбас абый өч рәт соңга калгач, шундый «бәхеткә» иреште. Ул авылдашларын хәрби хәзерлеккә өйрәтүдә этинең уң кулы булырдай кеше, югыйсә. Әмма аның уенда, хәрби өйрәнүләрдән бигрәк, Гөләндәм апа. Ул Чокырлыда укыта. Үзе үтә чибәр. Габбас абый аның янына һәр кичне барып, таңда гына кайта, дип сөйлиләр.

— Каран кадәр җирдән Гөләндәме янына кайтып йөрми торгандыр инде хәзер. Зарар юк, икесенә дә бераз ял булыр. Ни кушылмыйлар, ни ташлашмыйлар шулар. Нинди мәхәббәттер ул, аңламыйм,— ди әти алар турында.

«Солдатлар»ны сафка тезгәндә Зиннәт абый беренче булып баса. Ул авылда иң озын, иң чандыр кеше. Тик аңа «солдат уены»нда сирәк катнашырга туры килә. Колхоз председателе дә, шул ук вакытта партия оешмасы секретаре да ул булгач, аны көн дә диярлек районгамы, бүтән берәр ярымы чакырып кына торалар. Телиме, теләмиме, Зиннәт абый чакырган җиргә китә.

Хәзер этине Бәештә Сабир-фитфебль дип атыйлар. Фитфебль сүзенең нинди мәгънә аңлатуын белмәгәнгә, миңа ул үтә яман кушамат булып тоела. Бүген түзмәдем, ул сүзнең мәгънәсен этинең үзеннән сорадым.

— Фельдфебль иске патша армиясендәге солдаттан бер баскычка өстен чин ул, улым. Аларны бик кансыз булганнар, солдатларның, бигрәк тә рус милләтеннән булмаганнарның теңкәләренә тигәннәр,

дип сөйлиләр. Кайдан казып чыгардың син ул сүзне? — диде эти.
— Авылда хәзер сине Сабир-фитфебль диләр, шуңа сорадым,— дидем мин, унайсызланып.
Эти башта минем сүзләремнән аптырап калды, аннары шаркылдап көләргә кереште.
— Сабир-фельдфебль диген ә?!. Мин — фельдфебль! Ха-ха-ха.
— Сиңа көлке, ә кешеләр зар җылыйлар синнән,— диде әни аңа, киная белән.
Эти көлүдән туктады, җитдиләнде.
— Ничек зар елыйлар? Кемнәр, мәсәлән?
Әни бу сораудан югалып калды. Аннары авыр көрсенеп:
— Бик таләпчән, дип зарланалар. Зар елыйлар диюем шул,— диде.
— Бу инде башка сүз. Өйрәнгәндә кыен булса, сугышта җиңел була, дигән бөек рус полководецы Суворов. Бүген фельдфебль дип таләпчәнлегемнән зарланган кешеләр кайчан да булса рәхмәт әйтерләр әле миңа.
Эти бу минутта үз-үзеннән канәгать иде.
— Сугыш булыр дисеңмени син, Сабир?
— Булырга охшый, Мәликә. Радиодан көн саен ишетәсеңдер, газеталарга да язалар. Франко Испаниядә кан коя, Муссолини — Хәбәшстанда. Японнар Кытайны инде күпме еллар баш идерергә азапланалар. Германиядә немец фашистлары, Ерак Көнчыгышта япон самурайлары ашкынып коралллана. Бөтен империалистлар безгә теш кайрыйлар. Иртәме, соңмы, сугыш котылгысыз безгә.
Әни куркып калды.
— Авызыңнан җил алсын бу сүзләрне, Сабир. Коточкыч сүзләр сөйлисең син.
— Аңла, мин сөйләмим, дөнья шуңа бара, Мәликә. Ләкин нинди генә сугышта да без җиңеп чыгачакбыз. Моңа аз гына да шигем юк. Әнә, күрә торгансың, бер Баештә генә дә никадәр кызылармеец бар. Бөтен Советлар Союзында алар никадәр! Бихисап, беләсең килсә. Өстәвенә техника, танклар, самолетлар, диңгез кораблары, бөек юлбашчыбыз Сталин бар. Революциядән соң безнең сугышырга мылтыкларыбыз да, булган мылтыкларыбызга җитәрлек кадәр патроннарыбыз да юк иде. Шулай да җиңелмәдек, җиңдек. Хәзер исә безнең көчебез ул чактагыдан мең өлеш артык.
— Көчебез барын мин дә беләм, Сабир. Тик яңадан да күпме кан коелыр...
— Сүзең хак, Мәликә, сугыш кансыз булмый. Без бит үзебез сугыш теләмибез, ул бәлки булмас та. Империалистларның да башлары ике түгел, безне бүрек атып егарга мөмкин булмавын үз тәҗрибәләрендә беләләр...

## 2

Хәйрүш абзый үлгәннән соң Зада апа алмаштырып куйгандай үзгәрде. Ике-өч көн эчендә аның чәчләре ап-ак булды, битенә тирән җыерчыклар уелды, аякларын көчкә атлап йөри башлады.
— Бик нык бетерештең син, күрше,— ди аңа әни.
Зада апа сулкылдап елый башлады. Гомумән, ул хәзер кайчан күрсәң дә елый.
— Тамагыма аш үтми, күзләремә йокы керми, Мәликә. Уемда гел Хәйрүш кенә. Аның миңа гомере буена бер генә авыр сүз дә әйткәне булмады бит...
— Хәлеңне аңлыйм, күрше. Тик үлгән артыннан үлеп булмый, дигән сүз бар. Кызың турында уйла күбрәк, боектырма аны. Сиңа

карап ул да әнә күләгә кебек йөри. Хәлегез авыр, беләм. Шулай да ярамый үз-үзегезне бетерү. Элек кәртинкә күк йөргән хатын бит син. Хәйрүш абый бу кыяфәттә күрсә, һич тә хупламас иде сине,— дип үгетли аны әни.

— Әй, үз башыңа төшмәгәч белмисең хәлемне, Мәликә, белмисең! Дөньяда минем хәзер бер көн торасым килми, бер көн...— Зада апа яулык чите белән йөзен каплый.— Аккош булсаң икән,— дип такмаклый ул күз яшьләре аша,— аккош парын җугалтса, бер көн җәшәми, ди. Күккә биеккә күтәрелә дә, канатларын җыеп, шуннан җиргә таш шикелле атылып төшеп һәлак була, ди...

— Җүләр сүзләр сөйлисең, Зада җаным. Акылыңа кил, тиле хатын түгел бит син.

— Акыллы булып җалгызым нишлим суң?

— Ялгыз түгел син, кызың бар.

— Мине дөнҗәдә Миләүшәм генә тота да инде...

Сүз арасында әни тиз генә табын хәзерләп Зада апаны көчләп диярлек өстәл артына утырта.

— Әйдә эч әле шушы чәйне как белән, җаның тынычланып, күңелең ачылып китәр. Ҭашла елавыңны, күрше. Олы кеше өчен бертуктаусыз яшь сыгып йөрү, үпкәләмә, әйбәт түгел.

Зада апа әнинең сүзләрен бөтенләй ишетми бугай, бернигә карылмый, өстәл артында таш сын кебек утыра.

— Зада җаным...

Кунак, сискәнеп, нурсыз, моңсу күзләрен мөлдерәтеп әнигә карый.

— Әйдә, ашап эч әле.

Зада апа, авыр сулап, чынаяктан тәлинкәсенә чәй сала. Мин аның кызганыч кыяфәтен артык күрмәс өчен өйдән чыгып китәм.

Хәйрүш абзыйны мин дә онытa алмыйм. Бүген аны төшемдә дә күрдем. Чуал ярына аякларын салындырып утырган да курай тарта, имеш. Янында чыбыркысы да, көтүе дә юк, бер ялгызы. Башындагы беләүләнеп беткән кәләпүшен кырын салган, йөзендә шат елмаю балкый, кесәсеннән, күзләрне чагылдыргыч нурлар сибеп, абага чәчәге күренеп тора. Мин, ул үлмәгән, абага чәчәгенә генә киткән булган, дип уйлыйм, имеш. Кинәт йокымнан уянып ялт итеп торып утырдым. Өй эченнән бик дәртләнеп курай тарткан тавыш ишетелде. Хәйрүш абзый исән икән бит, исән! Чоланнан атылып чыгып өйгә кердем. Хәйрүш абзый урынына анда радиодан иртәнге концерт тапшыралар булып чыкты...

Төшемне мин берәүгә дә сөйләмәдем, уңайсызландым.

Көндез Миләүшә белән тау буена чыктык. Ул да, этисе үлгәч, әнисе шикелле  үк күзгә күренеп үзгәрде. Ябыкты, уйчанланды. Без аның белән һәр икебез үз уйларыбызга бирелеп озак йөрдек. Ул да сөйләшмәде, мин дә. Тау буена таралган көтүне күргәч, Миләүшәнең күзләреннән яшь бәреп чыкты.

— Миңа эти исәндер, шундадыр кебек, барып карыйбызмы? — диде ул.

— Бармыйк, Миләүшә. Яхшысы — этиең чишмәсе янына төшеп, ул утырткан тирәкләрне карыйк.

Миләүшә каршы килмәде. Без Кызылъяр астына юнәлдек. Анда бик  шәп чишмә бар. Ул, тау астыннан ургылып чыгып, Чуалга агып төшә. Чишмә авызына имән улак көйләнгән, тирәсенә бик пөхтә итеп таш җәелгән. Чишмәдән ерак түгел ундүрт төп тирәк  үсә. Чишмәгә улак куючы да, аның тирәсенә таш җәйгән кеше дә Хәйрүш абзый. Тирәкләрне дә ул утырткан. Миләүшә тугач ел саен бер тирәк утырткан  ул монда. Миләүшәгә инде ундүрт яшь — тирәкләр саны да шул кадәр үк. Бу чишмәне Баештә Хәйрүш чишмәсе дип атыйлар. Хәйрүш абзый үзе юк, ә чишмәсе бар, ул элеккечә үк ургылып чыгып, шаулап ага.

— Тәмле дә соң шуның суы,— дип мактый аны халык.

Коры елларда яңгыр боткасы да шушы чишмә янында пешерелә, диләр. Яңгыр боткасын минем ашаганым да, аның ничек пешерелүен дә күргәнем юк. Гайфинең сөйләвенә караганда, бик тәмле булырга тиеш ул. Башта авылдагы һәр хуҗалыктан ярма, йомырка, сөт, май җыялар, аннары җыелган нәрсәләрне бөтенесен бер казанга салып пешереп сыйланалар, ди. Ботка ашалгач, яңгыр теләү башлана, кешеләр бер-берләрен кайда очратсалар, шунда су белән коендыралар, беркем дә моңа ачуланмый да, үпкәләми дә ди.

Чишмә яныннан без, үзебез дә сизмәстән, таштан-ташка сикергәли-сикергәли Кызылъярга күтәрелә башладык. Кызылъяр — Каршы тауның иң текә һәм иң биек җире. Аның нәкъ яртысында ерактан караганда коңгырт билбауга охшаган өч-дүрт метр калынлыгындагы комташ катлавы бар. Нинди генә язулар юк ул билбауда! Кызылъярга күтәрелгән һәр кеше анда үзенең истәлеген калдырырга тырышкан. Укый-яза белмәүчеләр тамгаларын салганнар. Һәр язу, һәр тамга ташка тирән, вакыт сынавына бирешмәслек итеп уелган. Андагы күпчелек истәлекләр гарәп хәрефләре белән тырналган. Яңалифчә язылганнары да аз түгел. Менә монда менгән һәркемнең игътибарын үзләренә тарта торган ялкынлы сүзләр: *«Без комсомоллар — искелеккә бомбалар! Рәхи, Зиннәт, Хөршидә, Гыйльфан. 1930. Май».*

Бу язуны ташка уйган кешеләрдән Рәхи дигәненнән башкаларын мин күреп беләм. Зиннәт абый хәзер колхоз председателе һәм парторг, Гыйльфан абый район үзәгендә милиционер, Хөршидә апа безгә рус теле укыта, ул — Зиннәт абыйның хатыны. Рәхи юк, аны кулаклар үтергәннәр. Ут егет иде Рәхи, дип кешеләр аны әле дә сагынып искә алалар. Такташ абый сүзләрен монда ташка уючы да, бәлки, ул булгандыр. Язуда аның исеме беренче бит. Кеше үзе күптән юк, ә ядкаре саклана.

Менә тагын бер язу:

«Хуш, авылым, дуслар,
Армиягә китәм көзгә.
Таштагы шушы язуым
Истәлек булсын сезгә.
Хәлим Гатин. 1936 ел. август».

Бу кешене мин беләм. Миләүшә аның турында:

— Түбән очның Хәлим абый язган моны, ул хәзер Ерак Көнчыгышта чик сакчысы,— диде.

Кара, кара, Гайфи белән Кәрим дә истәлек калдырырга өлгергәннәр икән инде монда. *«Монда миндек дүртенче сыйныф укучылары Гайфи Б. Кәрим М.»* Быел без алтынчы классны тәмамладык, димәк, дусларым инде Кызылъярда моннан ике ел элек үк имзаларын салганнар. Аларның кәкре-бөкре хәрефләрдән оештырылган ядкарь язуларын мин ничек бүтән менүләремдә искәрмәгәнмен, гаҗәп. Бәешкә килгәч тә, малайлар кыерсытканда бик еш менә идем бит бу тауга. Булачак дусларымның чатан-ботан язулары ул чакта ук күзләремә чалынгандыр бит югыйсә.

Миләүшә белән без үзебез таный алган барлык язуларны укып чыктык. Шулай язудан язуга күчеп йөргәндә, аяк астымнан бер очлы тимер кисәге күтәреп алдым.

— Миләүшә, әйдә без дә ташка исемнәребезне язабыз?

Күршем күзләрен тутырып миңа карады.

— Бергәме?

— Син ничек теләсәң, шулай язарбыз.

— Бергә языйк.— Ул бу минутта элекке Миләүшәгә әверелде.— Ташның иң әйбәт җирен сайлыйк, кешеләр бозарлык та, бетерерлек тә булмасын.

Мин таш билбауның иң калку җиренә: *«Миләүшә. Ирек. 1937 ел, июнь»*, дип яздым. Ташка язу җиңел эш түгел икән, манма тиргә төштем, бармакларым, уч төпләрем кабарып бетте. Минем арттан Миләүшә язуны тирәнәйтә төште. Ахырда миңа борылды да, серле итеп:

— Хәзер син монда исемеңне бүтән берәү белән дә янәшә яза алмыйсың инде,— диде.

Аның бу сүзләре миңа барып җитмәде.

— Нигә?

Миләүшә көлде.

— Кара әнә, монда берәү дә ике истәлек калдырмаган. Син дә калдырмассың. Калдырмам, диген, йә?

Кызылъярга менгәч, сөекле әтисен югалту кайгысын беразга онытып торган күршемнең кәефен кырасым килмәде.

— Калдырмам,— дидем.

— Бел, Ирек, синең бу вәгъдәңә әнә күктәге кояш шаһит.

Таш билбаудагы язуларны уку белән мавыгып, үзебез күтәрелгән биеклектән тирә-юньгә күз ташларга да оныткан идем. Миләүшә әйткәч, ирексездән кояшка карадым. Ул инде баюга якынлаша иде. Күзләрем такыр басуга төште. Юл өстенә тузан болыты күтәреп, «солдатлар» атлыйлар. Юл читеннән тузансыз якта әти бара. Кызылъярдан әти дә, аның «солдатлары» да кырмыскалар кебек кенә булып күренәләр. Мин дәртле җыр тавышын ишетергә теләп тыңландым, ләкин бернинди тавыш та ишетелмәде.

### 3

Иртән, әни эшкә китәргә өлгермәгән иде әле, безгә Гайфи килеп керде.

— Исәнмесез!

— Сау-сәламәт без, Гайфи. Нишләп бусага аша гына сәлам бирәсең, үт өйгә,— диде аңа әни.— Кая югалган идең, бу арада күренмәдең?

Җирән иң элек борынын тартып куйды.

— Кереп тормыйм, Мәликә апа, өй эчендә һава аз кебек миңа. Урманда идем мин. Анда әти белән күмер яндырдык, печән чаптык.

— Мактана торгансың?

Гайфинең борын яфраклары киерелде.

— Юк, Мәликә апа, ышанмасагыз, әтидән сорарсыз әнә.

— Инде кул астына керә башладым дисең алайса?

— Әйе. Ирек, тегермәнгә төшәсеңме?

Мин сагая калдым, Җирән тагын нәрсәдер эшләргә җыена булыр.

— Нишләмәкче буласыз анда? Арыкта су кермәгез тагы...

— Кермибез. Тегермән күләгәсенә ашлык суктыру җайланмасы көйлиләр, шуны карыйбыз.

Әни бүтән сүз озайтмады, без урамга чыктык.

Гайфигә урман һавасы килешкәнгә ошый, ничектер тазарып, чибәрләнеп киткән кебек. Йөзе кояшта янган, учлары сөялләнгән. Бездән чыгып бераз киткәч, ул:

— Яңалык ишеттеңме? — диде.

— Нindине?

— Адәм ышанмаслык. Бичура кияүгә чыккан бит, ишетмәдеңмени шуны?

Мин аптырап калдым.

— Кемгә чыккан?

— Дагалы бүрегә.

— Ә?!.— Туктадык.— Юктыр ла, ирештерә торгансың.

— Ялганласам, күзләрем чәчрәп чыксын менә!

Юк, Җирән шаяртса, алай ант итмәс, дөрестер. Тик Чокырлыдагы Гөләндәм апаны ничек Бичурага алыштыра алды икән Габбас абый? Ни буе, ни чибәрлеге, ни кешелеге юк бит ул чәрелдекнең. Шул какча ләтчә янәшәсендә ничек кешеләргә күренер ул? Гарип-гораба булса бер хәл иде, Зада апа әйткәндәй, грунадирдай егет бит...

— Төшеңә генә кергәндер ул синең?

Гайфи йөзен чытып миңа каш астыннан карады. Аннары аяк астындагы кечкенә генә йомычка кисәген бер читкә тибеп очырды да:

— Кемнәр дип уйлыйсың соң син аларны ул кадәр? — диде.— Пар алар. Ике чабата бер кием. Чиләгенә күрә капкачы. Әтиеңә Сабир-фитфибль кушаматын кем такты? Дагалы бүре. Безнең директорның ордены үзенеке түгел, ул аны сугышта һәлак булган бер командирның күкрәгеннән йолкып алган, шуңа иркенләп тагып йөрергә дә базмый, дип тә лыгырдап йөри әле ул. Тыштан елмайган була, эче аның ташландык баз кебек. Бичурасы ничек бар — шулай, чын йөзен яшерә белми. Бөтен нәселләре шундый аларның. Авыл җитәкчеләре өстеннән бөтен жалуларны районга тик Габбас калай әтәч кенә яза, ди әти. Юньле булса, аңа Гөләндәм апа чыгар иде. Егет булган егет Бичураны хатын итеп аламы? Үлсә дә алмый.

Әтинең ордены үзенеке түгел, ниндидер башка кешенеке имеш. Уйлап чыгарырга кирәк бит! Битендәге кылыч ярасын да ул бәлки кешедән алгандыр, Михаил Васильевич кул куйган тәбрикләү кәгазен дә? Тагын Сабир-фельдфебль. Тәки эт икән Габбас абый. Әти аны авылдан хәрби әзерлекне районда үтәргә җибәреп, бик дөрес эшләгән...

— Без аларга туй бүләге әзерләргә тиеш,— дип Гайфи минем уйларымны бүлде.

— Кирәкләре бар!

Гыйфи көлеп җибәрде.

— Әбәзәтелне кирәк,— диде ул.— Без чит кешеләр түгел ич аларга. Укучылары. Бүләкнең кемнән икәнен белмәсәләр дә, истәлекле булсын.

Дустымны мин аңламадым. Ничектер сәерләнеп кайткан түгелме соң ул урманнан? Һаҗәр апаны да, Габбас абыйны да яратмый үзе. Бүләк, ди. Бүләкне, минем белүемчә, яраткан кешегә генә бирәләр бит аны.

— Яхшатлы буласың киләме?

— Җүләр син, шыр җүләр,— диде Гайфи миңа, ачуланып.— Нинди бүләк икәнен белмисең, акыл сатасың.

— Чәтертәнгә барып тагын еланнар алып кайтабызмы әллә? — дидем мин, кыюсыз гына.

— Чәберчек күкәйләр табабыз.

— Шуннан?

— Тугыз калган уннан,— диде Гайфи, үртәлеп.— Туйларын бөтен авылга сасытабыз, бөтен авылны көлдерәбез. Әллә син миңа Басарга барып уку күңелле булыр дисеңме? Кем аркасында барам? Бичура аркасында.

Дустым чыннан да хаклы төсле тоелды миңа. «Бүләк» икән «бүләк»! Нигә шундый «әйбәт» кешеләрнең туйларын котламаска?

— Чәберчек йомыркаларны аларга ничек «бүләк» итәрбез соң? — дидем мин.

— Ә менә бу нәрсәгә? — Гайфи кесәсеннән рогатка чыгарды.— Чәберчек күкәйне стакангамы, бүтән бер кечкенә савыткамы салабыз да тәрәзәдән бах түшәмнәренә. Туйдагылар аңнарына килгәнче үзебез таябыз. Шул. Тик менә чәберчек күкәйләр каян табарга?

— Ничә кирәк?
— Ике-өч булса җитә.
— Табарбыз...
— Кара, бу турыда берәүгә дә теш агартасы булма!
— Мине кем дип уйлыйсың? Тузбашлар турында әйттемме кешегә?
— Әйтмәдең, егет шул син!
Без бер-беребезгә карап алдык та тегермән янына йөгердек.

## Тугызынчы бүлек

### 1

Бәештә ике мәчет бар. Берсе яңа, берсе иске. Икесенең дә айраклы биек манаралары әллә кайлардан күренеп торалар. Яңа мәчеттә хәзер мәктәп — анда без укыйбыз, искесе буш, бикле.

Ике мәчетнең дә тирәләрендә карт тупыллар үсә. Алар авылны яшеллеккә күмеп, аңа ямь биреп утыралар. Һәр тупылда өем-өем карга оялары. Быел яз көне әти, мәктәпне карга тавышыннан аз булса да арындыру нияте белән, унлап тупылны кистерде. Ләкин моның берниндидә файдасы булмады. Киселгән тупыллардагы ояларыннан мәхрүм калган каргалар исән тупылларга күчеп ояладылар. Тупылларны кискән көнне үк Түбән очның Чепи Гайнетдин үзе кебек үк дүрт диндар картны ияртеп безнең өйгә килде. Ул, авызыннан күбекләр чәчеп, әтигә:

— Мәчет тупылларын кисеп авыл ямен җибәрергә сиңа кем хокук бирде, килмешәк?! — дип акырды.

— Ипләбрәк сөйләш, абзый, мин килмешәк түгел, мәктәп директоры,— диде аңа әти, тыныч кына.— Тупыллар күләгәсендә балаларга классларда караңгы. Өстәвенә, аларга оялаган каргалар тавышы укучыларга дәрес тыңларга комачаулый.

Гайнетдин карт ярсып таягы белән идәнне төйде.

— Мәсҗеттә сез өйдәш кенә, бел шуны. Аны бездән мәктәп салганчы вакытлыча гына алдылар. Син дырыктор икән, сал үз мәктәбеңне. Кул якма мир әйберенә. Мәсҗеткә, аның тирәсендәге агачларга син түгел, без хуҗа. Бүтән үз белдегең белән анда кыл да кыймылдатасы булма!

— Моны син кем исеменнән әйтәсең, Гайнетдин абзый? — дип сорады әти, аның каршына басып.

— Голәмә исеменнән, безнең исемнән,— диде моңарчы тыныч кына басып торган картларның берсе.

— Ие, ие, безнең исемнән,— дип телгә килделәр бүтән картлар да.

— Мин сезгә совет власте исеменнән, коммунист буларак әйтәм: мәчетегез инде мәчет түгел, мәктәп. Анда сезнең оныкларыгыз укый. Моңарчы аның манарасына кагылырга базмый йөри идем, бүгенге килүегез белән сез миңа аны кисеп төшерергә кыюлык бирдегез, рәхмәт,— диде әти.— Мәктәп түбәсендә манара булмаячак, белегез шуны!

Чепи Гайнетдин дә, аның иптәшләре дә бер мәлгә өнсез калдылар. Аннары картларның берсе кызганыч тавыш белән әтигә инәлде:

— Кагылма манарага, дырыктыр, мөселман бул!

— Тагын кем булырга, үзегез кебек намазлык өстенә дә менәргә кушасызмы әллә миңа?

— Юк, менмә намазлыкка, анысын сорамыйбыз, кеше бул, безнең сүзгә колак сал, тимә манарага.

— Әйтергә теләгән сүзегез шул гына булса, аңлашылды миңа. Хушыгыз, агайлар,— Әти картлардан кырт борылып, барып радионы тоташтырды.

Чакырылмаган кунаклар, баскан урыннарында бераз таптанып торгач, мыштым гына чыгып киттеләр.

Тирә-күрше авылларның берсендә дә мәчет манаралары юк инде. Халык арасында, Бөреледә мәчет манарасын кискән Шәрифулла исемле кеше телсез калган, Каенсарның Мәҗит атлы кеше аяксыз-кулсыз булган, Чистай ягындагы бер авылда манара кисәргә менгән кешене аяз көнне яшен суккан, манара кискән кешеләргә мөгез чыга, аларның бала-чагалары хайванга әверелә икән, дигән сүзләр йөри. Рус, керәшен авылларындагы чиркәүләрнең чаңнарын төшергән, хачларын алган кешеләр дә игелек күрмиләр, имеш. Кайсы йә бумалыга әйләнә, йә бәвеле тотмый башлый, кайсын җир йота, кайсы сөйләшкәндә дуңгыз булып чыелдый, ат шикелле кешни, үгез кук мөгри башлый, имеш.

Бәеш — базарлы авыл. Һәр җомгада базарга килүчеләр шундый имеш-мимешләрне мыскаллап кына түгел, потлап тараталар. Һәр сөйләүче андый нәрсәләрне бик якын белешемнән ишеттем, бу тәгаен чын, дип сөйли. Бу сөйләүләрдә киселгән мәчет манаралары төбеннән көлтә-көлтә утлар күтәрелүе дә, манарасыз мәчетләрдә җен-париләрнең, убырларның, бичураларның караңгы төшү белән туй итә, күңел ача башлаулары да, кыерсытылган мәчетләрнең тәрәзәләрендә көн саен кан таплары пәйда булу да сөйләнә. Кыскасы, кеше хыялы нинди тузга да язылмас нәрсәләр уйлап чыгарырга сәләтле, берсе дә калмый. Безгә кызык, без дүрт дус — Гайфи, Кәрим, Сөләй һәм мин — һәр җомга саен чәчләрне үрә торгызырлык шундый «яңалыкларны» тыңлап йөрибез. Каникул бит, теләгән җирдә теләгән кадәр киләп сарып була, беркем бер сүз әйтми.

Сөләй бөтен имеш-мимешләргә ышана, ул аларны хак, чыннан да булган хәлләр, дип һич икеләнүсез кабул итә. Аның әтисе Лотфулла абзый бик диндар кеше. Аңа хатыны Сорур апа белән танышырга мәчет булышкан. Сөләй шулай ди. Лотфи абзый бик яшьли әтисенә ияреп мәчеткә, намазга йөри башлаган. Егет булгач ул Чуал буена ат сугарырга төшкәндә бер көнне чишмә юлында Сорур апаны ялгызын гына очраткан. Ул чакта егет белән кызга икәүдән-икәү генә аулак калып гәпләшергә ярамаган, бу зина саналган. Лотфи абзый Сорур апага, иртәгә әтиең мәчеттән кайткач, аның уң кәвешенең олтырагы астыннан минем мәктүбемне ал, мин сиңа йөрәк серләремне язармын, дигән. Сорур апа алырмын да, алмамын да димәгән, йөзен яулык почмагы белән каплап, сүзсез узып киткән. Намазга барган кешеләр мәчеткә кергәндә аяк киемнәрен өйалдында салып, эчкә оекчан гына үтә торган булганнар. Лотфи абзый мәчеткә башкалардан соңрак килеп, Сорур апаның әтисе Зарифулла картның уң кәвешенә мәктүбен салып, башкалар янына намаз укырга кергән. Ул хатына җавап көтеп төнен йокысыз үткәргән. Лотфулла абзый мәктүбенең Зарифулла карт кулына эләгүеннән курыккан. Мәктүбенә исемен язмаган булган, әлбәттә. Ләкин барыбер курыккан. Бер атнамы, ун көнме үткәч, картның сул кәвешенең олтаны астында Сорур апаның җавабын тапкач, башы күккә тигән егетнең. Алар өйләнешкәнче шулай бер-берсенә хатлар язышканнар. Кызы белән булачак киявенең хатларын тәкъва Зарифулла карт кәвешләренең олтырагы астында һич нәрсә белми үзе ташыган. Тагын шунысы кызык, Лотфулла абзый да, Сорур апа да үзләре укый-яза белмәгәннәр, хатларын кешедән яздырып, кешедән укытканнар.

Лотфулла абзый яңа мәчетне мәктәпкә әйләндергәндә, изге йортны мөртәтләрдән пычраттырмыйк, мәчет ул алла йорты, аңа динсезләр аяк басарга тиеш түгел, мәчет өчен шәһит китсәм китәм, әмма ләкин аны мәктәп иттермим, дип бик хәтәр дулап йөргән, имеш. Аны яклаучылар да шактый табылган, тик шулай да мәчет мәктәпкә әверелми кала алмаган.

Бездә эти белән Зиннәт абый арасындагы сөйләшүдән соң икенче

көнне иртүк клубка коммунистлар, комсомоллар һәм авыл активы җыйналды. Анда киңәшмә барганда ук Бәештә өйдән-өйгә төрле хәбәрләр таралды. Колхозга керми ятучы аерым хуҗалыкларны ерак утрауга, кешеләр яшәми торган җиргә сөрергә җыеналар, имеш. Намаз укыган, ураза тоткан кешеләргә бик зур налог салачаклар, бөтен дин китапларын, тәсбихләрне, намазлыкларны, тәһарәт комганнарын җыячаклар, имеш. Шәһәрләрдә ит беткән, кемнең ике терлеге булса, берсен алачаклар, ун яшьтән узган балаларның барысын да приютка җыячаклар, чукындырачаклар, имеш. Һәм башкалар, һәм башкалар. Боларны кемнәрнең тыелгысыз фантазиясе уйлап чыгарып бетергәндер, билгесез.

Клубта җыелыш бетүне бөтен авыл куркулы сагаю белән көтте. Җыелыштан чыгучыларның йөзләре сүрән иде, аларга төрле яктан төрле сораулар яуды:

— Ишек төбегезгә кизү куеп нәрсә хәл иттегез?

— Авылдан кемнәр куылачак?

— Приютка барлык балаларны да алачакламы?

— Дин тотучыларны нишләтәчәкләр?

Җыелыштан чыгучыларда бу тозсыз сораулар көлке уяттылар.

— Туксан яшьлек Сафура карчыкны йөзнең аргы ягына чыккан Габдразак картка кияүгә биреп, туй итү турында сөйләштек. Алар икесе дә ялгызлар бит, бичаралар. Берсе тол, икенчесе буйдак, ишлекушлы, булып, картлык көннәрендә рәхәт кичерсеннәр, дидек,— диде клуб мөдире Фәхри.

— Җүләр сата ул, тыңламагыз аны,— диде Зиннәт абый, Фәхри ягына кул селтәп. — Сүз колхозны ныгыту, авылны культуралаштыру турында барды. Беркемгә дә берни дә булмаячак. Фәхри, син тузга язмаганны сөйләмә, мәктәп өстендәге манараны кисеп төшерәбез, шуны хәл иттек. Шул гына.

— Их, Зиннәт туган, Бәешне чуваш авылы ясыйсыз икән. Хурлыктан авылны хет ташлап кач хәзер,— диде Лотфулла абзый, үртәлеп.

## 2

Мәчет манарасының үзәк баганасына бәйләнгән арканны тракторга таккач, Хатип абый руль артына утырды.

— Әйдә, кузгал! — дип кычкырды аңа Зиннәт абый, башы өстенә күтәргән уң кулын кискен генә аска төшереп.

Трактор моторы үкереп эшли башлады. Мәчет тирәсенә җыйналган бөтен халыкның күзе манарага кадакланды. Трактор урыныннан салмак кына кузгалды. Аркан башта акрын гына тартыла, аннары дугаланып җир өстеннән күтәрелә башлады. Шул чак, һич уйламаганда, ап-ак сакаллы Сәлим карт, халык арасыннан йөгереп чыгып, трактор алдына сузылып ятты.

— Туктат трактырыңны, кешене хәрап итәсең бит, алласыз! — дип акырды Хатип абыйга Лотфулла абзый.

Тракторчы алга түгел, артка, соңгы минутларын сизеп утырган биеклеге белән саубуллашучы манарага текәлгән иде, мотор гөрелтесе аша үзенә кычкырганны ишетмәде. Аркан тартылганнан тартылды. Манара төшерү тамашасына җыйналган кешеләр арасында тәшвишле шау-шу купты. Трактор җирдә яткан карт өстенә инде барып җитә язды. Шунда халык арасыннан клуб мөдире Фәхри, Хатип абыйга кепкасын атып, аны үзенә каратты һәм, кулларын болгап, тракторны туктатырга кушты.

Трактор туктады. Аның тирәсендәге кешеләр җиңел сулап куйдылар.

— Нәрсә булды, ник туктаттың? — дип кычкырды Хатип абый, куркудан йөзе киндер төсенә кереп агарынган клуб мөдиренә.

Фәхри абый трактор алдында яткан картка төртеп күрсәтте.

Хатип абый руль артыннан җиргә сикереп төште.

— Сакаллы сабый, тешсез исәр, әҗәлең җиткәнне көтәргә тәкатең калмадымыни, мине төрмәдә чертергәме исәбең? Юк, черетмитор! — дип ул Сәлим бабайны, якасыннан эләктереп, аякларына бастырды.

Мәчет ягыннан Зиннәт абыйның:

— Әй, Хатип, ник туктадың, ник тарттырмыйсың? — дип кычкырганы ишетелде.

— Сәлим бабай трактор алдына ятты, шуңа туктады ул,— диделәр аңа.

Трактор тирәсендәгеләрдән кемнәрдер арканны трактордан ычкындырырга, кемнәрдер Хатип абыйны кыйнарга итә башладылар. Тавыш-гауга купты. Трактор янына эти белән Зиннәт абый килделәр.

— Кем монда буза куптара? Йәле алга чыгыгыз, кемнәр тарих тәгәрмәчен кирегә тәгәрәтергә чамалый?

Әтинең ныклы һәм көр тавышыннан кешеләр тынып калдылар.

— Менә ул эшне туктатты,— дип Хатип абый Сәлим бабайга күрсәтте.

— Туктаттым шул, тагын туктатам.— Карт, яңадан җиргә сузылып ятып, чал башын тәгәрмәч астына тыкты.— Манара өчен шәһит китәм, җәмәгать, яманлап телгә алмагыз!

— Алай, алай, Сәлим абзый, безгә манараны төшерергә аяк чалам дисең инде алайса. Тик син моның белән, Каран базарында тегетары белән каз күтәреп йөргән чагыңдагы кебек, берни дә чыгара алмаячаксың, көлкегә генә калачаксың бит. Синең яңадан таш капчыкка бик керәсең килгән, ахры. Үтермибез, ихтыярың бәрәңге дигәндәй, теләгең шул булгач, кертәбез анда сине. Ишетәсеңме мине, Сәлим абзый?..

Зиннур абыйның тавышын күтәрми генә картка мөрәҗәгать итүе трактор тирәсенә сырышкан кайнар башларны сагайтты. Алар берәмберәм артка чигенә башладылар. Сәлим бабай, яткан җиреннән кузгалып, башта дүрт аякланды, аннары зур авырлык белән гәүдәсен язды. Аның төссез күзләрен яшь пәрдәсе каплаган иде.

— Ник тордың, Сәлим абзый, бер яткач тормыйлар инде, яталар аны. Без монда кәмит күрсәтүеңне карарга килмәдек, авылны күләгәләп торган искелек албастысыннан арынырга җыйналдык бит. Син безнең эшне тоткарларга телисең. Моны эшләргә кем кушты сиңа? Ник дәшмисең, таш капчыкны исеңә төшергәч, телдән яздыңмы әллә?

— Көчленеке замана...

Карт, халык арасыннан чыгып, башын иеп, исерек шикелле кыешмыеш атлап өенә, түбән очка юнәлде.

— Трактор астына ятып рәт чыкмагач, яңадан Каран базарына юл тотты бугай картлач,— дип көлде шунда Габбас абый.

Аңа кушылып көлүче булмады.

Сәлим бабайны, Бәешнеке түгел, кыр ягыныкы, диләр. Сөйләшкәндә, Мирсәет абый шикелле үк, ул да «з» авазын анык әйтми, дылаштыра. Бәешлеләр аның Зәбих байда озак еллар тамак хакына хезмәт иткәнен, гомеренә йорты-җире дә, семьясы да булмаганын, Зәбих бай үлгәч, аның хатыны Зөлхиҗә Сәлим бабайны йортка керткәнен сөйлиләр. Алар әйбәт кенә торып киткәннәр. Революциядән соң, хәрби коммунизм заманында, нинди генә авыр салымнарны да Сәлим бабай түләп барган. Колхозлашу вакытында да атларын, терлекләрен алуга каршы килмәгән. Аның үзен, син кулак, дип колхозга алмаганнар. Бай варисы, байның бар байлыгы аңа калган бит. Башта хезмәтче, аннары гомере буе үзе бил бөккән бае йортының формаль хуҗасы бул-

ган ич. Үзен колхозга алмаганга Сәлим бабай бик нык үпкәләгән совет хөкүмәтенә. Бервакыт Каран базарына чыгып, кулаклар коткысы белән, бер кулына каз тотып, билендәге алъяпкычына күпмедер тары салып: «Колхоз тары аламы икән, сәвит каз аламы икән?» — дип шыран ярып кычкырып, шуның үчен алып йөргән. Базардагы халык аның сүзләренең кучермә мәгънәсен тиз аңлаган. Милиционер чакырып китергәннәр. Колхозның таралуы, советның кадалуы белән дөнья сасытып кызыксынганы өчен, аны бер елга якын «таш капчык»та акылга өйрәтеп чыгарганнар. Бу: «Ләгънәт төшсен Николайга, ике сыер саудырды, рәхмәт яусын Сталинга, кәҗәдән дә яздырды»,— кебек чәнечкеле җырлар, «Татарстан алга чыккан, ашта пешерелә кычыткан, куәсләр ялга чыккан, самавыр базарга чыккан»,— шикелле такмазалар туган заман булган.

Сәлим бабай әле дә колхозчы түгел, аерым хуҗалык. Зәбих бай дирбиясеннән аларда инде берни дә калмаган, мунчада торалар. Бар куанычлары — бик шәп алма бакчалары, шуның исәбенә яшиләр.

Сәлим бабайның кыерсытылган малай кебек башын иеп мәчет яныннан өенә шым гына кайтып китүе башкаларга да тәэсир итте, шаулашу тынды. Хатип абый кабат руль артына утырды. Зиннәт абый, трактор алдына басып, тагын команда бирде:

— Тарттыр!

Трактор, ярсу ат шикелле, алга ыргылды. Манарага бәйләнгән аркан яңадан тураеп кыл кебек тартылды. Манара, кайсы яккарак түним икән, дигән сыман аз гына чайкалды да тракторга ияреп янтайды һәм мәктәп түбәсенең бер өлешен шатыр-шотыр җимереп, гөрселдәп җиргә ауды. Ул ауган урында, бомба шартлагандагы кебек (кинода күргәнем бар), төрле якка куе тузан болыты таралды. Тупыллардагы ояларыннан, ямьсез каркылдашып, каргалар күтәрелде. Манара төшергәнне тамаша кылган халык авыр сулап куйды.

Бер читтә кара көеп басып торган Лотфулла абзый:

— Тәки матурлыкның башына җиттеләр, муеннары аска килгереләр! — дип мыгырданып, Чуал ягына атлады.

Без, малайлар, ауган манараны янына барып карарга чаптык. Ул авыл өстендә утырганда әллә ни дәү күренми иде, ә җирдә әнә күпмегә сузылган! Түбәннән бәләкәй генә булып күренгән ае гына да минем буе бар. Ул җиргә кинәт бәрелүдән урталай сынып, үзен куе итеп бизәгән төрле төстәге пыяла мәрҗәннәрен кояшта җемелдәтеп, тузан эчендә аунап ята.

Кемдер:

— Карагыз, мылтык бар монда, мылтык! — дип кычкырып җибәрде.

Зиннәт абый бу тавышка шундук килеп җитеп, манараның калай түбәсен җимереп тышка чыккан мылтыкны кулына алды.

— Хәрби винтовка бит бу, мәчеткә каян килгән ул?!

— Зиннәт абый, манара эчендә әнә тагын бар алар, күп,— диде малайлар арасыннан Кәрим.

Кулына тоткан мылтыкны нишләтергә аптырап калган парторг янына әти килеп җитте. Кешеләр манараның түбә калаен куптаргач, аннан тагын унҗиде винтовка һәм дүрт тартма патрон табып алдылар.

Халык аларны күреп ах итте!

— Тулы арсенал монда. Манарага кем яшергән аларны? — диде әти, кашларын җыерып.

— Хөснулла мәзиннән сорагыз, ул белергә тиеш, әлек бу манарага көн дә менә, аңа ул хуҗа иде,—диде көч-хәл белән укырга-язарга өйрәнгән «шәкертем» Ярулла абзый.

Каргалар ояларына кире әйләнеп кайттылар. Манара төшергәнне күрергә җыйналган халык акрынлап таралды.

3

Мәктәп өстеннән манара төшерелгәннең икенче көнендә, истәсанда юкта, безгә төштән соң райком секретаре Җәгъфәров абый килеп керде. Ул, барыбыз белән дә кул биреп күрешеп чыккач, әтигә җитди итеп:

— Ну, Сабир, мин синнән, русларча әйтсәк, йомычка юнарга килдем, әзерлән,— диде.

Әти, аның бу сүзләрен күптән көткән кеше төсле, тыныч кына җавап кайтарды.

— Гаебем бар икән, Борһан, миннән йомычка юну гына түгел, чөй ясасаң да риза.

Җәгъфәров абый өстендәге пиджагын салып чөйгә элде.

— Кичә, бөтен авылыгыз күз алдында эшләгән партизанлыгыңны нәрсәгә саныйсың син, безнең эштә файдагамы, зыянгамы? Йә-ле, бәялә шуны үзең...

Әтинең битендәге яра җөе тартышып куйды.

— Манара кисеп төшерүне күздә тотасыңмы син?

Кунак, кесәсеннән зур кульяулыгы чыгарып, изүен соңгы төймәсенә кадәр чиште дә тирләгән калын муенын озаклап сөртте.

— Нәкъ өстенә бастың. Бүген райкомга өстеңнән жалу килде, йөзләп кеше кул куйган, бездән мәктәбебезнең директоры иптәш Сабир Кадыйров вәхшиләрчә көлде, дигәннәр. Алар сиңа безнең кичекмәстән катгый чара күрүебезне таләп итәләр.

— Эш эшләнгән, күрегез.

Кунакның ачуы чыкты.

— Эш эшләнгән, имеш! Гасабиланма әле, зинһар,— диде ул, кульяулыгын чалбар кесәсенә тыгып.— Җиңүчеләрне хөкемгә тартмыйлар, дисеңдер син, бәлки? Юк, Сабир, тарталар. Мондый җиңүең белән син коммунист исеменә кара яктың. Утызынчы ел түгел, утыз җиденче ел хәзер. Халыкның аң дәрәҗәсе, фикерләве чиксез үсте. Эш синең мәктәбең өстеннән манараны аударуда түгел, аны чәнчелдереп син бик әйбәт иткәнсең, тагын авылыгыз өстендәге икенче манараны да капландырасы булыр, сүз аны ничек төшерү турында бара. Авылыгыз халкына манараның заманы үткәнен, аның инде бөтенләй кирәксезлеген, артыклыгын түземлелек белән аңлатырга, якын тирәдәге башка авылларның манаралардан күптән арындырылганлыгын, тик сезнең авылыгызда гына искелек варисының бүгенге яңа тормышка кара күләгә төшереп, аның ямен җибәреп тормаска тиешлеген иренмичә төшендерергә кирәк иде. Эшебездә беренче нәүбәттә халыкка таянсак кына, без теләгебезгә ирешә, максатыбызны тормышка ашыра алабыз. Син сайлаган юл хәзер эшебездә җинаять белән бер ул...

Кунак кызып-кызып сөйләде, әти аны бүлдерми тыныч кына тыңлады.

Җәгъфәров абый — мичкә кебек юан кеше. Аның гәүдә калынлыгы җайдак чакта әллә ни сизелми, иярдә ул егетләрчә, коеп куйгандай утыра. Аттан төшкәч, аю шикелле килбәтсезләнә, иңнәре салына, зур корсагы мендәр сыман алга чыга, бүрәнәдәй юан аяклары чалыш-чолыш атлыйлар. Авыру кеше ул, сәламәт түгел.

— Мине тагын мәктәбегез түбәсенә патроннар һәм мылтыкларның кайдан килүләре кызыксындыра. Өстеңнән райкомга жалу язучылар яшерен арсеналларының фаш ителүенә үчлекләнмиләрме икән сиңа?

— Ул турыда берни дә әйтә алмыйм, Борһан. Минем өчен чишелмәс табышмак ул.— Әти четерекле әңгәмәне йотылып тыңлавыма игътибар итеп:— Улым, бар, Борһан абыеңның атын тиз генә дворга төшер әле,— диде.

Мин теләр-теләмәс кенә бүлмәдән чыгып киттем.

## Унынчы бүлек

### 1

Чуал буенда ялгызым гына балык каптырып утырганда яныма Ярулла абзый килеп чүгәләде.

— Нихәл, Ирек, кабамы ташбашлар?

Балык капмауга ансыз да эчем пошып утырам, юри үртәгәндәй сорый бит, күр! Нәрсә калгандыр аңа су буенда, ник кешегә комачаулап йөридер?!.

Теләр-теләмәс кенә җавап кайтардым:

— Капмыйлар...

— Шулайдыр. Балык вакыты түгел көндез.— Ярулла абзый гәүдә торышын үзгәртми генә, күлмәк җиңе белән тирләгән битен, кәләпүшен салып, такыр башын сөртте. Боларны мин аның тын тугайга төшкән шәүләсеннән күрдем.— Көн эссе чакта җимгә исе китми балыкның. Кояш чыкканда, җә кич төш син балыкка, бөтенләй башкача булыр. Хәзер әнә калкавычың су өстендә үле кебек ята, селкенеп тә карамый, кояш чыкканда мин әйтте диярсең менә, ул биеп кенә торыр. Таңнан төшәргә кирәк балыкка, аяк астында чык кипкәнче...

Әңгәмә куертырга атлыгып тормавымны шәйләп, абзам бәлки торып китеп барыр, дип мин аның сүзләрен җавапсыз калдырып, калкавычыма текәлеп утыруымны дәвам иттем.

— Бүре балалары күрәсең киләме, Ирек?

Күзләремне калкавычтан аерып, башымны Ярулла абзыйга борганымны сизми дә калдым.

— Бүре балалары тоттыгызмы әллә?

Ярулла абзый аякларына калкып, башына кәләпүшен киде.

— Тотмадым, ояларында әле ул эт токымнары. Тик җырак түгел, теләсәң, әйдә барабыз, шушында гына, күрерсең. Әмма башта аналарын дөмектерергә бер таза күсәк табыйк. Күсәк эзләп килгән кеше бит мин монда.

Ярулла абзыйның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Авылдан җиде-сигез йөз метр җирдә нинди бүре оясы булсын инде, Чуал читендәге таллык урман түгел бит, ирештерәдер, дип уйладым. Шуңа күрә:

— Безнең икебезне дә ботарлап ташламасмы соң бүре?— дидем.

Ярулла абзый тавышсыз гына көлде.

— Ташламый. Капкында шыңшып утыра инде ул мур кырган. Төнәген оясын тапкач, килеп капкын салганыем мин аңа, бүген килеп карасам, эләккән терлек-туар газраиле. Бүредән курыкма син, Ирек, адәмнән курык. Бүре җәй көне түгел, кыш көне бик ачыкканда да, ялгызы гына булса, бәндәгә тими, курка. Әйдә.

Кармагымны җыеп үләннәр арасына яшергәч, Ярулла абзыйга ияреп, яр чите үзәнлегендәге куе куаклар арасына атладым. Ярулла абзый күсәк эзләп төрле якка сугылды, ташудан калган төрле агачларны күтәреп карады, тик берсен дә алмады. Мин аның артыннан ике-өч адым гына калып, тагылган кебек бардым. Таллык эчендә ышык, җил исми, үтә бөркү иде, бик тиз тиргә баттым, күлмәгем тәнемә сыланып, эчемне пошырды. Күсәк эзләп без таллык эчендә шактый тулгандык. Вакыт узган саен Ярулла абзыйга ачуым чыга барды, турыга гына барсак ни булган, нигә урап йөрергә? Без монда буталганда бүре, капкыннан ычкынып, балаларын алып китсә, авыз ачып кала бит инде ул...

Ниһаять, без еллар дәвамында язгы сулар ярган тирән коры чокыр читенә барып чыктык. Чокыр эче котырып үскән эрекмән, ат кузгалагы, шайтан таягы, кычыткан, билчән шикелле эре сабаклы күләгәле үләннәр белән капланган. Бераздан Ярулла абзый аяк ас-

тыннан җилле генә имән казык күтәрде.

— Өйгә кайтып, лом алып килергә туры килмәгәе, дигән идем инде, табылды, рәхмәт төшкере!.. Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, мөгаен, шушыдыр,— диде ул, казыкны җиргә сугып нык-лыгын тикшергәч.— Соры каракны моның белән иярләпме иярлибез хәзер, аллаһы теләсә.

— Кая соң ул?— дидем мин, түземсезләнеп.

— Шушында инде, гелләр уйламаган төштә. Бу чокырның яры бер бик тә аулак урында мәгарә сыман эчкә уелып кергән. Анда җил дә, яңгыр да үтәрлек түгел. Мур кырган мәлгунь шуны оя иткән, хәерсез. Өч көн тоташтан эзләдем разбунникны, аяк ите ашап әллә кайларда урап йөрдем. Эзләгәнем, менә күрерсең, борын төбемдә үк яткан. Оятсыз димә инде син ул ут күзне, авыл читенә үк килеп балалаган, ләгънәт төшкере. Һич уйларлык җирдә түгел. Тик үз башына булган оятсызлыгы, үз башына булган мәлгуньнең. Менә килеп җиттек инде.

Бу сүзне ишеткәч, эчемә салкын йөгерде. Миңа бүре инде капкыннан ычкынып, безне сагалап утырадыр төсле тоелды. Өстебезгә кинәт ташланса, икебез дә бетәчәкбез, нигә килдем монда, дигән уй узды башымнан.

Ярулла абзый чокыр эченә төшә башлады. Мин аңа иярергә дә, кире Чуал буена китәргә дә курыктым. Бөтен тәнем туңгандагы шикелле калтырана башлады. Шунда:

— Авылга кайтып китик, Ярулла абзый, бармыйк бүре янына, бетәрбез икебез дә,— дидем, як-ягыма каранып.

— Курыкма, Ирек, ир малай бит син. Бүре бик теләсә дә бетерә алмый безне. Җыры җырланган инде аның, капкында ул. Көтүләре белән йөргәндә генә кыю алар,— дип тынычландырырга тырышты мине аучы.

— Куркак булса, авыл читенә килеп балаламас иде әле...

— Уңай урын тапкан да балалаган. Оясының кайда икәнен белдермәс өчен безнең авыл терлекләренә кагылмаган да шуңа күрә. Чалмаларны корткан. Анда өченче көн көпә-көндез көтүгә килеп җиде сарыкны буган. Чалмалар әйткәч, эзләп таптым аны монда.

— Бәлки анысы бүтән, бусы бүтән бүредер?

— Шушы бер бүре. Гомерем буе аулыйм бит мин ул ил корткычларны, беләм. Шуңа үземне дә Бүре Ярулла диләр ич, ишетә торгансың.

Әйе, Ярулла абзыйның авылда кушаматы — Бүре. Әмма кыяфәте белән ул бүрегә бөтенләй охшамаган. Гәүдәсе базык, таза, аяклары нык, бите бераз озынчарак, күзләре үткен, ияге алгарак чыгып тора, көрәктәй куллары сөялле. Нинди генә эшкә тотынса да, ялт итеп эшләп ташлый Ярулла абзый. Бура да бурый, өйләр дә җиткерә, мич тә чыгара, өстәл, урындык, шкаф кебек нәрсәләр дә ясый. Әмма арада иң яраткан һөнәре — сунарчылык. Күбрәк ул бүреләр аулый. Кушаматы да шуннан. Колхозчы түгел. Аерым хуҗалык булып яшәвен дә сунарчы булуына ишарәли. Мин болай берәүгә дә бәйле түгел, үзем-үзем түрә дә, хезмәтче дә, теләгән чагымда теләгән җиремә чыгып китәм, кайда йөрдең дип сораучы, чокчынучы юк, колхозда алай итеп кара, персидәтел бар, бригадир бар, идарә бар, алардан рөхсәт алмый кирәк җиреңә кит, шундук койрыгыңа басып, трутдиныңны штрауга шалт кисәләр, эх тә итә алмыйсың, ди.

Бүреләрне Ярулла абзый, капкын салып, тере килеш тотып алып кайта. Алып кайта да ишегалдында чылбырга утырта. Шуннан соң тере бүрене Ярулла абзыйларга килеп бөтен авыл тамаша кыла. Соры явыз чылбырда нишләргә белми, табан ялтыратырга ниятләп ары йолкына, бире йолкына, ләкин юкка изалана, ычкына алмый. Ахырда, борынын күккә төбәп, арт санына утыра да, тоткынлык

гарьлегеннән сузып-сузып улый башлый. Бүре улавы галәмәт тә ямьсез бит ул, шуны гына көткән шикелле, бөтен авыл этләре дәррәү телгә киләләр. Авылда купкан эт гаугасына аучы түзми, өеннән лом күтәреп чыгып, бүренең башына берне кизәнеп тондыра. Улау кинәт өзелә һәм ямьсез тавыш тынгач, авылда этләрнең ярсып өрүләре дә акрынлап төкәнә.

Ярулла абзый бүреләр газраиле булуы белән тирә-юньдә дан тота. Якын тирәләрдәге авылларда бу ерткычлар үзләренең ишәюләрен сиздерә башласалар, көне-сәгате белән аның янына илчеләр килеп җитә. Аучы ялындырып тормый, чакырган җиргә бара һәм аннан бүреләрне бетерми әйләнеп кайтмый.

Бүреләргә мәрхәмәтсез булса да, башка җан ияләрен кызгана Ярулла абзый. Кан күрсәм, күңелем болгана, дип тавык тә суймый диләр аны. Йомшак табигатьле, кече күңелле, бала җанлы кеше ул. Кәшәкә юндырасы, шар кырдырасы, кыекбаш калагы ясатасы, бура таяклары һәм шакмаклары кистерәсе булса, без малай-шалай аңа керәбез. Беребезне дә борып чыгармый, ни сорасак та ясап бирә.

— Ходай тәгалә үзебезгә балалар бирмәде, кызганды. Бөтен авыл баласы безнеке булса да, сүз әйтмәс идем, ди Ярулла.— Хатыны Хәбибә түти ачы сагыш белән шулай сөйли икән.

Шундый яхшы кешеләрнең нигә булмагандыр балалары, аңлашылмый.

Бүре, безнең якынлашуны күргәч, колакларын шомартып читкә сикерде һәм, шундук кызганыч чинап җиргә ауды. Тоньк кына булып капкын чылбыры чылтырап алды. Ярулла абзый бүре янына йөгереп барып кулындагы күсәге белән аңа алагаем кизәнеп сукты. Бүре, күзләрен ут кук яндырып, үткен сары тешләрен ярсулы ыржайтып аучыга ташланмакчы булды, ләкин күсәк аның арт санын имгәткән иде, ахры, аякларына күтәрелә алмады. Күсәк иркен селтәнеп ерткычның киң маңгаена төшкәч, ул тынсыз калып җиргә сеңде. Аның кан баскан, утлы күмер кук янган ачулы күзләре йомылдылар, авызыннан - борыныннан кан китте.

— Безгә ташланыр дип котың очкан иде, бетте бүре, җан тәслим кылды,— диде Ярулла абзый миңа, күсәген читкә атып.

Үлеп яткан бүренең сөт тулып бүрткән имчәкләрен күргәч, миңа ул үтә кызганыч булып китте. Балалары ятим калдылар бит хәзер, алар әнисез нишләрләр, дип уйладым.

— Инде балаларын да үтерәсезме, Ярулла абзый?

— Юк, аларга тимим, аларның гаепләре юк. Менә аналарының тиресен тунап алгач, аларны капчыкка төйим дә илтеп тапшырам районга. Анда теләсәләр нишләтсеннәр, эшем җук.

Мин кечкенә мәгарә эчендәге бүре балаларын карап тормадым, кан күреп күңелем болгана, косасым килә башлаган иде. Ярулла абзыйга ләм-мим сүз әйтмичә, чокырдан өскә күтәрелеп, таллык эчләп авыл ягына юнәлдем.

## 2

Төнлә фермада кемнәрдер унбер сыерны пычаклар белән ярала бетерүләре турындагы хәбәрне әни иртән сепараторга сөт аертырга баргач ишетеп кайтты.

— Берәрсенең чираттагы уйдырмасын сөйлисеңдер,— дип эти аңа башта ышанмады.

— Уйдырма түгел бу, Сабир,— диде әни.— Ферма каравылчысы Әндәр карт терлекләр янына төшеп тә карамаган, өендә кичтән үк ятып йоклаган булган. Бик зур каза бит бу.

Этинең бу күңелсез яңалыкка нәтиҗәсе катгый булды.

— Корткычлар эше ул. Кичекмәстән авылдагы шикләнердәй кешеләрне берәм-берәм чакыртып, җитди сөйләшергә кирәк. Мин идарәгә барам, белергә кирәк, бәлки манара үчен алудыр бу.— Ул тиз генә гимнастеркасын киде һәм өйдән җәһәт кенә чыгып китте, ләкин шундук әйләнеп тә керде.

— Итекләрне тапмыйм, кая тыктың аларны, тизрәк бир әле.

— Мин тимәдем итекләреңә, кайда салып калдырсаң, шундадыр.

— Салып калдырган җирдә булсалар, синнән сорап торыр идемме мин аларны?— диде эти, гасабиланып.

— Ирек улым, этиеңнең итекләрен син берәр яры куйдыңмы әллә?

— Тимәдем мин аларга.

Этинең коры чакта да, пычракта да аякларын чишенеп, итекләрен болдырда калдырмыйча өйгә кергәне юк. Мине дә шуңа өйрәтә. Безнең болдыр каплаулы, аяк киемнәре чыланырлык түгел. Бәештә, гомумән, аяк чишенми өйгә керү гадәте юк. Шуңа күрә кайсы гына өйдә дә идән балавыз кук сап-сары, чип-чиста.

Авылда урлашу булмаганга күрә, этинең итекләрен берәрсе шаярып яшереп куйгандыр дип, эзләмәгән җирне калдырмадык, ләкин тапмадык. Эти колхоз идарәсенә аякларына галошлар гына элеп китте. Аның бер пар күн итекләреннән башка аяк киемнәре юклыгын бөтен авыл белә, шуңа күрә кем дә булса киселгән мәчет манарасы өчен үч итеп алып киткән, күрәсең, аларны. Эти яланаяк йөрмәс йөрүен, кибеттә аңа ярарлык бер дигән хром итекләр бар, теләсә бүген үк шуларның бер парын алып кияр. Беләсе иде, кем эше икән бу? Мәктәп директорын тәки яланаяк калдырдым, дип авыз ерып утырадыр ул явыз хәзер. Һәй, нинди кара эчле, башкаларга этлек эшләүдән тәм табучы кешеләр дә никадәр әле дөньяда, берсен калдырмаска иде шуларның...

Зада апа керде. Ул соңгы көннәрдә Хәйрүш абзыйны югалту хәсрәтеннән бераз айный төшкән иде инде, шулай да электәгечә түгел, салпы иде әле. Бүген аның йөзе күпкә җанланган иде.

— Чәкән Мәдинәсе лыгырдый анда, имеш, Сабир районга баргач, бик нык төшергән дә трантасында җул буе берни сизми җоклап кайткан, җулда очраучылар аның итекләрен салдырып алганнар, шуңа күрә бүген аякларына кәлүш киеп, авылда адәм мәсхәрәсе булып җөри, ди,— диде ул әнигә.

— Лыгырдасын әйдә, гайбәт таратудан бүтән эше юк бит аның. Сабирның эчмәвен бөтен кеше белә. Болдырдан аның итекләрен алып китүче дә бәлки шулдыр әле. Ул аларның югалуларын кайдан белер иде башкача?

Зада апа гаҗәпләнеп әнигә төбәлде.

— Сабирның итекләре чынлап та югалдымыни?

Мин әнинең җавабын тыңлап тормадым, яралы сыерларны карарга фермага чыгып чаптым. Ишетмәсәң ишет менә, дип уйладым урамнан барганда, этинең юл буе йокларлык исергәне түгел, аракыны иснәп караганы да юк бит. Эчеп организмнарын агулаучыларны, акча түләп үзләренә чир алучыларны һич аңламыйм мин, ди ул. Аның итекләренең югалганын Чәкән Мәдинәсе каян белеп өлгергән диген? Әни хаклыдыр, үзе алып киткәндер ул аларны. Әйе, чыннан да аның эшедер ул. Без этинең итекләре югалуны берәүгә дә әйтмәдек ич әле. Этинең кичә район үзәгенә баруы дөрес. Анда аңа орып-бәреп манара кискәне өчен райком бюросында шәхси карточкасына язып каты шелтә биргәннәр. Халыкны санга сукмаганы, аның изге дип йөргән әйберен, алдан берниндн аңлату эшләре үткәрмичә, көпә-көндез вәхшиләрчә җимерткәне өчен аны хәтта партиядән куарга кирәк, диючеләр дә булган. Җәгъфәров абый этине, ул бу ялгышын усал ният белән эшләмәгән, сәяси сукырлык кына күрсәткән, иптәш Кадыйров ялгышын

һичшиксез аңлар, киләчәктә партизаннарча түгел, тиешенчә уйлап эш итәр. Кадыйровның төп хатасы — манараның совет мәктәбе өстендә кукраеп утыруы урынсыз икәнен халыкны җыеп түземле аңлатмавында һәм аны шау-шусыз гына сүттермәвендә, дип яклап чыккан. Ялгышын эти хәзер үзе дә таный. Алып-бәреп, ду кучереп эш итү гражданнар сугышы вакыты һәм аннан соңгы чор өчен генә яраганын, хәзер инде бүтән заман икәнен исемнән чыгарганмын, ди. Манара төшереп үзенә күпме борчу алды, күпме эш ясады ул. Мәктәп түбәсенең җимерелгән җирен төзәттерәсе, манара урынын яхшылап яптырасы, аннары бөтен мәктәп түбәсен, яңа ямавы әллә каян кычкырып тормасын өчен, тоташтан бер төскә буятасы бар. Әмма авылда бу эшләрне башкарырга теләүче юк. Бәештәге осталарны эти белән Зиннәт абый идарәгә чакырып сөйләшкән, алар: «Җимергәндә безне чакырып мәшәкатьләнмәдегез; ул эшләрне бездән башка гына хәл итегез, авызы пешәсен белгән кеше кайнар нәрсәне өреп каба»,— дип киреләнеп, риза булмаганнар. Әтинең итекләрен болдырдан алып китүчеләр дә шулардыр әле, бәлки. Манара булмады ул манара этигә, бәла булды. Әмма аның эшләгән «хатасы» өчен борчылуы да, үкенүе дә сизелми. Мин үземчә хаклы, ди. Хаклы булса, ай-һай, исәп карточкасына язып каты шелтә бирерләр идеме икән?!. Райкомда ул бар гаепне үз өстенә алган. Манара төшерүне башлап йөрүче дә, аны эшкә ашыручы да мин, партоешма секретарена җәза бирмәгез, ул бары минем таләпләремне генә үтәде, дигән. Мәктәп түбәсен төзәттерергә аңа осталарны башка авыллардан эзлисе була хәзер. Бүген аларны эзләп Чокырлыга барырга җыенган иде, бара алмас, фермадагы төнге фаҗига һәм итекләре юклык тоткарлар аны.

Колхозның сыер фермасы Яңа урам башында Кондыз инеше буена урнашкан. Бик ямьле җир ул. Ферма янында кәүсәләренә ике-өч кешенең колачы җитмәслек карт өянкеләр үсә. Элек анда май заводы булган, диләр. Киндер орлыгыннан, көнбагыштан, мәктән май чыгарганнар. Колхоз төзелгәч, аны җимереп, шул урында авылдан сөрелгән кулакларның төрле каралтыларыннан укмаштырып, сыер фермасы ясаганнар. Май заводы хәзер бүтән җирдә, авылның түбән очында, Кәримнәрдән ерак түгел.

Мин барганда фермада халык шактый иде. Фаҗига монда, чыннан да, зур булганга охшый. Биш-алты ир яраларыннан савыкмаслык сыерларны суеп, эшкәртеп яталар. Араларында Гыйльмулла абзый белән Лотфулла абзый да бар. Сөләй белән Кәрим дә этиләреннән калмаганнар, шунда. Сугымда катнашмаган кешеләр утарны каннан арындыралар.

— Ирек, монда кил,— дип Сөләй мине үз янына чакырды. Мин баргач, күзләрен шарландырып, борынын тарта-тарта сөйләп китте: — Пычакларын күрсәң, чәч пәкесе кук үткен булган. Финка, ди Зиннур абый. Төбеннән сынган. Сынмаса, бөтен сыерларны харап итәсе булган алар. Пычак сабын утар читеннән Кәрим тапты. Пычакның сыныгы бер сыерның эченнән чыкты.

— Барысы ничә сыерга тигәннәр?— дип кызыксындым мин.

— Унбергә. Бишесе үлгән. Берсенең яралары тирән түгел, төзәлерлек. Калганнарын суйдылар. Әнә никадәр ит булды.

— Кемнәрдән шикләнәләр?

— Шикләнеп торасы да юк, аерым хуҗалыклар эше икәне күренеп тора. Нинди колхозчы үз терлекләренә үзе кул күтәрә? Җүләр түгел колхозчы. Зиннәт абый, авылда финка берәүдә дә юк, читтән килгән кеше эше бу, дип финканың сабын да, пычагын да идарәгә алып китте. Милиция чакырып тикшертәбез, табылмый калмас җинаятьче, ди. Авылда безнең андый кансыз адәмнәр юк, дип авыл кешеләрен буйыйсы килми аның. Аерым хуҗалыклар эше икәне күренеп тора югыйсә. Шуларны ник авылдан сөрми яшәтә торганнар-

дыр? Сезнең күрше Бүре Ярулла эшедер әле бу. Бүрене бер сугуда дөмектергәнне, сыерларны харап итүне чүпкә дә санамый инде ул.

— Каннан курка ул, тавык та суйганы юк Ярулла абзыйның,— дип якладым мин күршемне. Әмма шунда күз алдыма моннан берничә көн алда гына бүрене күз дә йоммый күсәк белән сугып үтерүе килде. Икеләнә калдым.

Сөләй, икеләнүемне куәтләгәндәй, бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп:

— Миңа ышанмасаң, әнә өлкәннәрдән сора, алар әйтер Бүре Ярулланың кем икәнен. Аерым хуҗалык булып колхозга керми ятуы юкка түгел аның, корткычлык эшләр өчен,— диде.

Мин күршебезне яклап Сөләйгә бер сүз дә әйтә алмадым.

Бәештә унлап аерым хуҗалык бар. Аларның күбесе җир чәчми, терлек асрамый инде. Промартельгә кап сугу, лесхозда күмер яндыру, деготь чыгару, мунчала салу, кабык төшерү, урман кисү исәбенә көн итәләр. Бәрәңге бакчалары бар. Авылда нинди генә явызлык эшләнсә дә — янгын чыгамы, ат, мал-туар югаламы, Чәтертәндә нинди дә булса терлек батамы — алардан күрәләр, бу аларның гына эше, дип карыйлар. Аерым хуҗалыклар арасында төрле кеше бар: кайберләре элек хәлле хуҗалык булып, коллективлашу чорында бөтен терлек-туарларын сатып, колхозга буш кул белән керергә теләгәннәр, билгеле, аларны колхозга алмаганнар. Кайберләре чи диндар, күмәкләшү шайтан фигыле, чын мөэмин-мөселман өчен әртил булып яшәү гөнаһ, дип иртәме, соңмы колхозларның таралуын көтеп яшәүчеләр, берәүләре атлы-туарлы вакытта кермәгәч, хәзер таякка калгач, гариза күтәреп колхоз идарәсенә барырга тартыналар. Безнең күрше Ярулла абзыйда әнә сунарчылык чире. Сыерларга вәхшиләрчә һөҗүмгә ташланучы чынлап та ул микәнни?.. Һич ышанасы килми.

Төш алдыннан авылга ике милиционер килде. Ләкин алар да төнге фаҗигагә бернинди ачыклык кертә алмадылар. Ферма утарын, утар тирәләрен караштырып бернича тапкыр әйләнгәч, идарәдә ферма мөдире Заһид абый һәм Зиннәт абый белән сөйләштеләр дә, ферма каравылчысы Әндәр картны тарантасларына утыртып китеп бардылар.

Әтигә мәктәп түбәсен төзәттерергә осталар эзләп Чокырлыга барырга туры килмәячәк. Идарәгә чакырылган осталар сүз тыңламаганнары өчен гафу үтенгәннәр һәм, әти аларны кайчан чакырса, шул сәгатьтә эшкә тотынырга әзер икәннәрен әйткәннәр.

Таһир исемлесе хәтта:

— Мәктәп безнеке бит ул, анда үз балаларыбыз укый, хак-фәлән таләп итмәбез. Без биш иргә ике көнлек эш анда. Материаллар да эзләмә, төшерелгән манарадагы такталар да, калай да мәктәпнең бүтән кирәкләренә дә артып калырлык, без барып чамаладык инде аны,— дигән.

Әти моңа шатланып бетә алмады. Төшке ашны ашаганда әнигә:

— Әйбәт шушы Бәешнең кешеләре, ачу саклый белмиләр, ярдәмчелләр, гадиләр. Фермага һөҗүм оештыручыларның авыллар түгеллегенә иманым камил минем. Солдат уйнатканда өйрәндем мин бәешлеләрне, берсен дә кара уйлы дия алмыйм,— диде.

Мин сорау бирдем.

— Аерым хуҗалыкларны дамы?

Әти миңа сынаулы карап алды.

— Аларны да. Аерым хуҗалыкларны башка камырдан әвәләнгән кешеләр, дип уйлама, улым. Безнең кебек үк кешеләр алар. Тик аңнары гына тиешле югарылыкта түгел. Без, авыл коммунистлары, кирәк кадәр аңлату эшләре алып барсак, алар да инде күптән колхозчы булырлар иде.

— Ферма сыерларын кемнәр чәнчеп йөргәннәр соң төнлә?

— Хәзергә билгесез, улым.
— Ә синең итекләреңне Бәеш кешеләре урламаганмыни?
— Нәтиҗә ясарга ашыкма, улым, син кечкенә әле, күп нәрсәне аңламыйсың.

Әти белән әни гел шулай, берәр нәрсә турында җентекләп сораша башласам, шып туктаталар. Әле син кечкенә, имеш. Кечкенә булсам да, кичә мәче куганда амбар кәрнизеннән маузер табуымны белми шул әле әти. Әйтмим дә мин аны аңа. Кулларыма тоттырып та караткмый ул аннары коралны. Менә алар чыгып киткәч, өйгә алып төшеп, әнинең машина мае белән әйбәтләп майлыйм әле, ялтырап торсын.

Төштән соң амбар түбәсенә менсәм, маузер урынында юк иде инде. Төшемдә генә күргән идемме соң әллә мин аны? Әллә әти аның кәрниздә ятканын күптән белеп, төнге вакыйгадан соң башка җиргә яшердеме икән? Белсә, ул аны амбар түбәсендә тутыктырып яткырмас, чистартып үзенә якынрак җирдә саклар иде.

Амбар түбәсеннән мин кәефем кырылып төштем.

Йокымнан якында гына мылтык аткан тавышка уянып киттем. Өй артында аяк тавышлары, кемнеңдер калын, карлыккан тавыш белән бик әшәке сүгенгәне ишетелде.

Әти дә уянган икән, ул чалбарын тиз генә киде дә ачык тәрәзәдән тышка сикерде.

Әни аның артыннан:

— Сабир, зинһар, сак бул, харап итеп ташламасыннар,— дип кычкырып калды.

Мин чоланның ачык ишегеннән әнинең ашыга-ашыга күлмәк кигәнен күрдем. Аннары ул өйдән чыкты. Мин дә урынымнан торып тышка атылдым.

— Ник тордың, улым, бар кереп ят урыныңа, йөрмә!

Әнине тыңламадым, түрбакча ягына юнәлдем.

Ай яктысында бөтен нәрсәләр кичке эңгердәге шикелле аермачык иде. Мин әтинең өй почмагында посып торганын күрдем.

— Мәликә, Ирек, йөрмәгез монда буталып, өйгә керегез,— диде әти безгә шыпырт кына.

Шулчак өй артыннан Ярулла абзый килеп чыкты. Ул яланбаш, яланаяк иде.

— Сабир туган, милиция чакырт, кеше үтердем мин,— диде ул, ят тавыш белән.

Әти поскан почмагыннан аерылды.

— Кемне?

— Менә сезнең өйнең элекке хуҗасы Исмай байны. Әйдә, күрсәтәм.

Ярулла абзый борылып яңадан өй артына кереп китте, әти аңа иярде. Әни белән мин алар артыннан киттек. Почмакны борылуыбыз булды, өй ышыгындагы караңгыда безнең якка очкын чәчрәде һәм колакны тондырып мылтык шартлаганы ишетелде.

— Ятыгыз!— дип кычкырды әти.

— Дөмекмәгән икән әле бу мәлгунь! Үзең дә ят, Сабир энем, атып җыкмасын,— диде Ярулла абзый әтигә.— Тик күп атарлык рәте калмагандыр инде, корсагына дүрт җәпле сәнәк кададым мин аның.

Караңгыдан ачулы чырылдык аваз ишетелде.

— Ялгышасың, Бүре, сине генә чәнчелдерерлек дәрман бар әле миндә. Кичә колхозыгызның сыерларын үләт базына юллаган шикелле, иманың укып кал, сине дә зиратка олактырам...

Мин, яткан җиремнән башымны бераз күтәреп, күзләремне ачыбрак карагач, өебез нигезе буенда ниндидер карачкы кыймылдавын күрдем. Шул арада әти урыныннан тиз генә сикереп торып карачкыга барып капланды.

— Ай!..

Бу әни тавышы иде. Тагын мылтык шартлады.

Мин пуля әтине дә, әнине дә бетерде дип уйладым. Йөрәгем шашынып тибә башлады, күз алдымдагы бөтен нәрсә асты-өскә капланган сыман булды.

Әти кулында аңыма килдем. Әни елый, ишегалдына кешеләр җыйналган, сөйләшәләр.

— Әти, әни, сезнең икегезгә дә берни дә булмадымы?

— Юк, улым, юк, без икебез дә сау-сәламәт. Соңгы пулясын ул үзенең чигәсенә атты.

Кешеләр арасыннан Ярулла абзый тавышы килә. Аның сүзләренә колак салдым.

— Ишегалдымда кемнеңдер җөргәнен ишетеп тәрәзәгә килсәм, берәү кочагына салам күтәреп, чатанлый-чатанлый күршеләр ихатасына кереп бара. Исмай бай икәнен шундук таныдым моның. Син, бандит, ут салырга җөрисең түгелме соң, мин исән чакта барып чыкмас синең бу эшең, дип өйдән чыгып, сәнәкне эләктердем дә чаптым артыннан. Саламын Сабир күршенең өйалды астына тутырып ята бу. Кулларыңны күтәр, иблис, юкса хәзер чәнчим үзеңне, дип кычкырдым. Күтәрмәде кулларын, мылтыгы булган икән, шуннан атып җибәрде минем җакка. Алла саклагандыр, алда әле җыясы ризыгым бар, күрәсең, тимәде җәдрәсе. Шуннан озак уйлап тормадым, җен ачуым белән кададым сәнәкне эченә. Бандитның догасы сүгенү бит, бикләр дә ямьсез сүгенеп йөзтүбән капланды бу. Аннары тавышка өеннән Сабир күрше чыкты. Киттек икәүләп янына. Тагын атты. «Колхоз сыерларын бетергән шикелле, сезне дә җәһәннәмгә олактырам»,— дип гыжлый үзе. Сабир җегет икән, аның ырылдавын колагына элеп тормады, барып капланды өстенә. Исмай әзерләнеп торган булгандыр инде, тере килеш бирелмәде, үзен-үзе атты.

— Өенә ут төртмәкче идемени соң ул?— дип кызыксынды арадан кемдер.

— Саламны үз нигезендә ятып йокларга минем ихатамнан алып чыкмагандыр дим мин,— дип җавап кайтарды аңа Ярулла абзый.— Карагыз әнә өйалды астын. Шунда тутырып җатадырые ул аны...

Ферма сыерларын харап итүче дә, узган төнне болдырдан әтинең күн итекләрен урлап китүче дә шул Исмай бай булган икән. Маузерны да ул алган. Шуңардан ук аткан да. Итекләр аягында, «Акбатыр Хафиз Исмаевка» дигән язулы маузер кулында иде аның. Ярулла абзыйның бүре түгел, кеше куркыныч дигәне дөрескә чыкты. Җәһәннәм астыннан кайтып, колхозга никадәр корткычлык эшләде ул бәндә. Чак кына Ярулла абзыйны, әтине атып үтермәде. Монысына мин гаепле. Маузерны тапкач та әтигә алып төшеп бирсәм, уңасы икәнмен. Ә Ярулла абзый егет икән. Коралды бандиттан куркып тормаган, барган да чәнечкән. Мин исә, мәми авыз, шул Тәкәрлеккә Ярулла абзыйны яклап бер сүз әйтмәдем. Күршебезнең, үзем наданлыктан арындырган кешенең намуслы бәндәме, түгелме икәненә икеләнеп, колакларымны ишәктәй шәлперәйтеп басып тордым. Күрсен хәзер сипкел оясы Ярулла абзыйны, аерым хуҗалык булса да, йөзе ак, намусы пакь аның. Әти, аерым хуҗалыклар да без әвәләнгән камырдан, дип дөрес әйткән ич.

## Унберенче бүлек

### 1

Печән өсте — авылда иң күңелле, иң хозур чак. Ул озакка сузылмый, кыска вакытлы була. Кошлар сайравы астында, чәчәкләр хуш

исенә өртелгән сыек томанлы бер иртәдә башлана да, таң вакытындагы матур төш кебек, күңелгә рәхәт моңсулык иңдереп, үтеп тә китә. Аллы-гөлле чәчәкләргә бизәлгән, төрле бөҗәкләр авазыннан зыңлап торган иркен болында башта күперенке печән теземнәре барлыкка килә, аннары алардан җыйнак чүмәләләр салына, ул да булмый, чүмәләләр дәү-дәү кибәннәргә оеша.

Бәеш болыны басу читендә урман куелыгына дугаланып кергән Олачык дигән җирдә. Кайчандыр анда куе урман булган, диләр. Тик ул урман кая киткән, янып юкка чыкканмы, әллә төпләнгәнме — белүче юк. Хәзер анда зур агачлар түгел, хәтта кечкенә куаклар да үсми, өсте чокыр-чакырлар белән уйгаланмаган, ындыр табагы шикелле тигез.

Олачык — авылга шактый ерак. Печән өстендә, бару-кайтуга вакыт әрәм итмәс өчен, анда куныш-төнеп эшлиләр. Яшьләр моңа куанып бетә алмый. Печән вакытында Чүлмәк тау итәгендәге уенлык Олачыкка күчә һәм урман куены берничә көн һәр кичне җыр, гармун тавышларыннан таңга кадәр гөрләп тора.

Быел да печәнчеләр Олачыкта башка еллардагыча куныш-төнеп эшлиләр. Мин мәктәп атында печән ташыйм. Арбамны өлкәннәр төяп бастырыклап җибәрәләр, мин аны кибәннәр куйган җиргә илтеп аударам. Анда да үзем аудармыйм, өлкәннәр аудара. Минем вазифам ат йөртү генә. Арбага төялгән хуш исле яшел печән өстенә сузылып, җирдән биектә, зәңгәр күк бушлыгында, очынып-очынып сайраган тургайларны тыңлап, тирә-юньне күзәтүе үзе бер бәхет. Болында кешеләрнең үзара сөйләшүләре, егетләр-кызларның бер-берләре белән шаярышулары, көлешүләре, кемнәрнеңдер дәртләнеп җыр сузып җибәрүләре күңелдә чиксез шатлык уята, үзеңне ничектер бәйрәм-тантана үзәгендә итеп сизәсең, хезмәт кешеләре арасында булуыңа, алар белән бер үк һаваны сулавыңа куанасың. Мондагы җанлылык сине иркәли, үзеңнең зур, кирәкле, файдалы эш*ке* кечкенә генә булса да өлеш кертүеңне тоеп горурланасың. Болын өстендәге печән чүмәләләренең күзгә күренеп кимүләре, алардан дәү-дәү кибәннәр салыну сине тылсым дөньясында итеп сиздерә. Атны кибән төбенә барганда үз җаена атлатасың да, арбадан печән бушатылгач, башкалардан калышмас өчен, куалыйсың. Бахбай да эшнең мөһимлеген, ашыгычлыгын, кичектерергә ярамаганлыгын сизә шикелле, күндәм йөри, үшәнләнми.

Бәештәге эшкә яраклы бөтен кеше болында. Укытучыларның да кайберләре монда. Хөршидә, Һаҗәр апалар печән җыя, Габбас һәм Җамалый абыйлар арбаларга печән төяшәләр. Мирсәет абый кибән өстендә — эшнең иң җаваплы җирендә. Кибән аннан-моннан, килдекитте, ничек кирәк алай гына өелсә, көчле җилдә тарала, я яңгырлар башлангач, очыннан нигезенә кадәр чыланып әрәм була, имеш. Шуңа күрә кибән куйганда аның өстенә астан бирелгән печәнне тиешенчә салырга маһир кешене генә менә, диләр. Мирсәет абый йөзенә кызыллык китерүчеләрдән түгел, нинди эшкә алынса да, аны җиренә җиткерә.

Әнә ул кибән өстенә печән атучыларны:

— Ипләбрәк, егетләр, чәбәләндереп бирмәгез печәнне, саклар өчен өябез бит аны, ничек ята, шулай бирегез,— дип кисәтә.

Егетләр аның сүзләрен авырга алмыйлар:

— Була ул, сез дигәнчә эшлибез, Мирсәет абый,— диләр.

Минем әти белән әни болынга килә алмадылар. Әтине мәктәптәге ремонт эшләре тоткарлады, әни медпунктын саклап калды. Әмма мин монда үземне ялгыз итеп тоймыйм, Сөләй белән Кәрим — янымда. Дуслар да, минем кебек үк, печән ташыйлар. Арабызда Гайфи генә юк, урманда этисе белән күмер яндыра, авылда ул инде күптәннән күренми.

Арбамны кибән төбенә бушатып, атымны яңадан чүмәләләр ягына юырттырганда печән җыючы хатын-кызлар ягыннан Зиннәт абыйның:

— Ирек, Ирек, борыл әле монда!— дип кычкыруы ишетелде. Бөтенләй кире якка чакыра, нәрсәгә икән? Орышырга дисәң, йөгемдәге печәнне түгеп-чәчеп йөрмим бугай, иптәшләремнән дә ким эшләмим кебек, Сөләй белән Кәрим ничә йөк илтеп аударсалар, мин дә шул кадәр үк илттем...

Чакыргач тыңламый ярамый, туры бияне Зиннәт абый ягына бордым.

— Нәрсә бар, Зиннәт абый?

— Хөршидә апаңны тиз генә әниең янына кайтарып куярга кирәк, туган.

Менә сиңа мә! Миннән бүтән кешене җибәрсә, ни була инде аңа?

— Авырдымы әллә Хөршидә апа?

— Авырды шул...

Зиннәт абый, арбама сикереп менеп, дилбегәне үз кулына алды. Минем күз алдыма һәрвакыт кырыс Хөршидә апа килде. Иртә белән генә күрдем бит мин аны, берни юк кебек иде, кызу суккан, күрәсең...

Зиннәт абый атны зур гына бер печән чүмәләсе янына туктатып, арбадан сикереп төште. Хөршидә апа шул чүмәләнең күләгә ягында ярым ятып тора икән. Хәле аның, чыннан да, мөшкел булырга охшый. Ниндидер көрән тимгелләр ямьсезләгән йөзе тирләгән, еш-еш сулый, күзләре калайланган.

— Ничек, Хөршидә, бераз җиңеләймәдеме?

Хөршидә апа җавап урынына калку корсагын тотып бөгелеп төште.

— Тудыргач кына җиңеләер инде ул, Зиннәткәем. Ай...

Мин укытучымның газаплануын күрмәс өчен читкә борылдым. Зиннәт абый чытыр арба үрәчәсен күмеп тиз генә печән төяде һәм шул печән өстенә хатынын күтәреп салды.

— Бик үк борчылма инде син, Хөршидә. Төштән соң мин үзем дә кайтып җитәргә тырышырмын.

— Йөрмә, эшеңне кара. Миңа синең барыбер файдаң тимәс.

Зиннәт абый хатынына җавап кайтармады, мине ашыктырды.

— Әйдә, Ирек, утыр да куала атыңны. Хөршидә апаңны әниеңә кайтарып тапшыру белән борылып кил монда. Йә, Хөршидә, уңыш телим сиңа. Хәерле юл сезгә!

Кузгалып киттек. Авыл белән болын арасы биш-алты чакрым бар. Монда яңадан әйләнеп килгәнче ким дигәндә сәгать ярым, ике сәгать вакыт узачак. Ашыгырга булгач ашыгырга!

— Йә, бахбай, күрсәт әле җитезлегеңне, на!..

Ат болын өсләп юыртканда Хөршидә апа аны-моны әйтмәде, аратирә ыңгырашкалап кына алды. Юлга чыгып юырта башлагач, бер йөз адым да китмәдек, җиңемнән тартты.

— Ирек үскәнем, зинһар, атыңны туктат, бераз сулу алыйм...

Мин аптырап аңа карадым. Ни дигән сүз инде бу? Зиннәт абый, тизрәк кайтып җитегез, диде, ә ул туктатырга куша. Туктадык. Бераз торгач, мин атны кузгатып яңадан юырттыра башладым.

— Ирек үскәнем, юырттырма атыңны, туктат, зинһар, туктат!..— Хөршидә апа корсагын куллары белән кысып арбадагы печән өстендә йомгак кебек тәгәри башлады. Кыяфәте кызганыч та, әллә ничек куркыныч та иде аның. Бераздан тынычланды. Яңадан кузгалып киттек. Мин атны куарга да, кумаска да белмәдем. Хөршидә апа юлда үлмәсә генә ярар иде, дип уйладым. Әнә ничек газаплана бит, үлүе дә мөмкин. Үлә калса, Зиннәт абый җанымны алачак... Күңелсез, бик күңелсез булып китте миңа. Мине җибәрми үзе кайтса нәрсә булган инде аңа? Әнә тагын атны туктатырга куша. Үлә, валлаһи үлә Хөршидә апа

юлда. Әллә болынга кире барып, Зиннәт абыйга: «Хатыныңны үзең алып кайт авылга».— дияргәме? Юк, алай булмый, болынга инде кире барырга байтак ара. Тагын кузгалдык. Бераздан тагын туктадык. Тагын... тагын... тагын... Мин шабыр тиргә төштем, кайтасы юлыбызның чиге дә, ахыры да булмас шикелле тоела башлады. Без кайтмыйбыз, әйтерсең, бер урында таптанабыз кебек иде. Артымда авыз эченнән нәрсәдер мыгырданып, ыңгыраша-ыңгыраша Хөршидә апа арбадагы печән өстендә тәгәрәп йөри. Акрын кайтуыбызга борчылудан, Хөршидә апаның чыелдап-чыелдап җибәрүләреннән йөрәгем кага, җитмәсә үлеп эчәсем килә. Шуның өстенә, ат тирәсендә очкан кигәвеннәрнең безелдәве эчемне пошыра.

Күп азаплангач, ниһаять, Олачык белән авыл арасының яртысындагы әрәмәлеккә җиттек. Анда аз гына тау төшәсе. Әрәмәлек уртасында иренеп кенә агып яткан, аркылысына каз утырса бүәлерлек инеш тә бар. Инеш өстендә бәләкәй генә күпер, күпернең ике ягында чикләвек, шомырт, миләш, тал куаклары.

Атны акрын гына атлатып таучыкны төшкәч, Хөршидә апа:

— Ирек үскәнем, атыңны уңга куаклар арасына борчы, зинһар,— диде.

Нишләмәкче була икән инде ул анда? Болай да ташбака адымнары белән кайтабыз, әнә төш тә җитте, ә юлның яртысы гына үтелде әле. Куаклыкта нәрсә калган безгә? Кайтырга икән, кайтырга кирәк.

Мин укытучы апамны тыңламадым. Атым юлдан атлавын дәвам итте. Күперне чыктык.

— Туктыйк, Ирек...

Туктадык. Хөршидә апа, зур авырлык белән арбадан төшеп, мүкәләп диярлек куаклар арасына юнәлде.

Шул гына җитмәгән иде, ничек утыра инде ул хәзер арбага? Эх, бар икән күрәселәрем...

Әмма күрәселәрем минем әле алда булган.

Шулай күпмедер вакыт үтте. Көттем, укытучы апам куаклар арасыннан чыкмады. Нишли ул анда? Ыңгырашканы да ишетелми, әллә үлдеме икән?

Шактый икеләнеп торгач, арбадан төшеп, куаклыкка кердем. Уңга, сулга күз ташладым, Хөршидә апа күренмәде. Кая киткән ул? Тыңлана башладым. Озакламый тоньк кына булып ыңгырашуга охшаган тавыш ишетелде. Алдымдагы куакны әйләнеп үтеп кечкенә генә ачыклыкка чыктым һәм алдымдагы сәер күренештән имәнеп киттем. Хөршидә апам ярым шәрәләнеп, тезләрен чәнчеп җирдә ята. Күзләрен чытырдатып йомган, авызын киереп ачкан... Мин уңайсызлануымнан нишләвемә хисап бирмичә атым янына йөгердем. Битем, кулларым ботакларга сыдырылды. Ник кердем инде мин анда, исән калса ничек йөзенә карармын, ничек күзенә күренермен Хөршидә апаның? Ничек? Арбадагы печән өстенә капланып, гарьлегемнән үксергә керештем. Бу минутта миннән дә мескен, миннән дә бәхетсез беркем дә юктыр төсле иде миңа.

Шулай күпме үткәндер, белмим, бервакыт зәгыйфь кенә булып Хөршидә апаның тавышы ишетелде.

— Ирек үскәнем, зинһар, яныма килче...

Барыргамы, бармаскамы? Барыйм, бәлки үләр алдыннан берәр сүз әйтеп калдырырга телидер...

Бу керүемдә Хөршидә апа шул ук ярым шәрә килеш куак төбенә сөялеп утырган иде. Аңардан башымны читкә борып куак артында туктап калдым.

— Мин килдем, апа.

— Яныма ук кил, үскәнем, булыш миңа...

Барсам да бардым, бармасам да. Шуннан соң нәрсәләр булганы өзек-өзек кенә хәтеремдә калды. Башта мин тартынудан күзләремне

йомган килеш Хөршидә апаның кулларына тотынып нәрсәдер тарттым бугай. Күпмедер вакыттан соң укытучы апам иркен сулап җибәрде шикелле. Аннары бала елаган тавыш ишетелде. Аннан соң Хөршидә апа күлмәк итәген ертып, аннан берничә бөртек җеп сүтеп алды һәм баланың кендеген бәйләде. Аннары тагынниләрдер эшләде...

Зиннәт абый белән Хөршидә апаның кызлары булды. Алар аңа, минем исемгә тәңгәл итеп, Иркә исеме бирделәр. Шул рәвешчә Олачык белән Бәеш арасындагы юл беркайчан да онытылмаслык булып күңелемә уелды. Куаклыктагы кечкенә генә ачыклыкта Хөршидә апаның баласын тудыруда катнашуым бик озакка кадәр төшемә кереп йөдәтте. Шул көнне күңелемә, үскәч берәүгә дә өйләнмим, дип беркетеп куйдым. Чөнки Хөршидә апаның бала тудырганда кичергән газаплары минем бала күңелемне тетрәтеп, астын өскә китерде.

Мин куаклыкта Хөршидә апага булышкан арада ат, кигәвеннәр бимазалавына түзә алмый, киткән булып чыкты. Авылга җәяү кайтырга, Хөршидә апаны алырга ат белән әнине җибәрергә туры килде.

Болынга мин кабат бармадым.

## 2

Иртән, турыбызга теге вакытта Ярулла абзый белән бергәләп утырткан шомыртларыма су сибеп йөргәндә, яныма уйламаганда Гайфи килде. Ул ничектер гадәттәгечә түгел, кәефсез төсле күренде миңа. Очрашмавыбызга атнадан арткан иде бугай инде, кызыксынып:

— Күптән күренмәдең, әллә авырдыңмы? — дидем.

— Авырмадым, әти белән урманда зелпе тамыры әзерләдек,— диде дустым, кашларын җыерып, капыл гына.— Мин сиңа яңалык әйтергә килдем.

— Нинди яңалык?

— Калай әтәч белән Бичураның туйлары булачак. Алар бүген кич үз күргән кешеләрен язылышуларына багышланган кичәгә чакыру белән чикләнәчәкләр. Яңалык шул.

Әһә, юкәдә икән чикләвек, Җирәннең «балтасы» менә ни өчен суга төшкән икән...

— Кызганыч,— дидем мин, көлеп,— туй үткәрмәгәч, «бүләксез» калып, күп нәрсә югалтачаклар бит алар.

Дустымның күзләре ачулы кысылды.

— Син теләсәң нишлә, әйткәнемне мин барыбер җирenә җиткерәм.

— Ничек, көпә-көндезме?

— Көндезме, кичме, төнләме — анысын күз күрер. Йомыркаларың ничек, «тәмләнделәрме» инде?

— Яннарына якын бармаслыктыр, аларны мин сөйләшкән көнне үк тишкәләп амбар түбәсенә кояшка тездем.

Дустым, авызын турсайтып, йөзен читкә борды.

— Ишкәнсең ишәк чумарын, син тезгән көнне үк каргалар сыйлангандыр инде алар белән...

Курка калдым, Җирән әйткән дөрескә чыкса, мин, кем әйтмешли, күке мие эчкән тинтәк, сүзендә тормаучы такылдык булам бит...

Текә баскыч буйлап амбар түбәсенә күтәрелгәч, күз алларым караңгыланып китте. Тезгән йомыркаларым чыннан да юк, аларның тик буш кабыклары гына калган иде. Гайфи:

— Бу теге без күпме тырышып та тота алмаган сыңар бәбәкле ала каракның чираттагы «шаяруы». Шәп тыгындыргансың аны, иреннәрен ялый-ялый рәхмәт укыгандыр үзеңә. Ирек дус,— диде, мыскыллы елмаеп.

Үртәлүдән, башым иелеп, өнсез калдым.

— Мәлҗерәмә, чәнчелсен йомыркалар, баш ярылып күз чыкмады,

əйдə симерсен сыңар бəбəк, төкер. Яшəсен яңа план!..— дип дустым, борчылып өтəлəнүемне күрептер, аркамны какты.

— Нəрсə?..

— Тозлы кəбестə! — Җирəн шаркылдап көлде.— Озын колга башына алама чүпрəк бəйлибез дə аны абзар тиресендə чылатабыз. Аннары шул «хушбуйлы» чүпрəкне тəрəзəдəн мəҗлес табынына, һоп, ташлыйбыз.

— Тотылсак, аның өчен минут та яшəтмилəр, бəреп үтерəлəр безне...

— Тотмыйлар. Авыз ачып, аякларыбызны кесəлəребезгə тыгып көтеп торабызмы анда? Тормыйбыз. Мəҗлестəгелəрдəн кем дə булса акылына килгəнче мамолт табан ялтыратабыз.

— «Бүлəк» синнəн икəнне Бичура шундук төшенеп, моны разбунник Бəдретдинов кына эшлəде, диячəк. Бу көн кебек ачык.

— Дисə, аны дəлиллəргə дə кирəк ич əле. Дəлилсез гаеп — агусыз җылан ул, күренеше имəнгеч, ə зыян салыр чамасы тирес кортыныкы белəн бер, ди əти. Гаеплəргə нигез калдырмыйм Бичурага, бүген мин авылда булмыйм бит.

— Кайда буласың?

— Аптыратыйммы, йөдəтимме уеныңдагы кебек син, Ирек дус, сорау арты сорау яудырасың. Камали бабайга ияреп атлар сакларга барачагыбызны оныттыңмыни?

— Онытмадым, аны белəм, «бүлəкне» ничек һəм кайчан тапшырачагыбызны белмим.

— Үкчəлəрең белəн уйлый башлагансың бугай син, дус. Караңгы төшкəч атларга атланып урманнан авылга җилдерəбез һəм үзебезгə нəкъ кирəк вакытка кайтып җитəбез. Без кайтканда мəҗлеснең иң кызган чагы була. Эшебезне тиз-тиз майтарабыз да атларыбызда яңадан урманга сызабыз. Кем əйтмешли, шулай без ике куянны берьюлы тотабыз — урманда атлар да саклыйбыз, «бүлəк» тə тапшырабыз...

Шулчак, ни гаҗəптер, мин үземне «бүлəгебез» ташланганда мəҗлестəгелəр арасында итеп күрдем һəм кинəт ныклы карарга килеп Гайфигə:

— Без син уйлаган хулиганлыкны эшлəргə тиеш түгелбез! — дидем.

— Нəрсə, хəзер үк шыр җибəрдеңме əллə? — диде ул миңа.

— Хикмəт шыр җибəрүдə түгел. Уйла, без Бичурадан үч алабыз, ə мəҗлескə җыйналган кешелəрнең ни гаеплəре бар, аларны шакшыга коендырудан безгə ни файда?

— Син нишлəргə киңəш итəсең соң?

— Берни дə эшлəмəскə, мəҗлесне бөтенлəй юк дип санарга.

— Мин сине дус кешегə исəплəп йөргəн булам, син ике аяклы куян икəнсең бит, куян!..— Җирəн, кырт борылып, янымнан китеп барды.

Күр инде, яман эштəн баш тартырга киңəш иткəч үпкəлəде, адəм көлкесе! Аның хəтерен калдырырлык нəрсə əйттем мин? Бичураны түгел, мəҗлескə җыеласы кешелəрне якладым. Ике аяклы куян, имеш. Ə үзең, үзең кем син?

Кичкə таба көчле яңгыр явып үткəч, юештə урманга атлар сакларга баруны мин кирəк тапмадым. Тирə-юньгə эңгер иңгəч, иртəн Җирəннең үземне аңламавына эчем пошып урамга чыктым. Ике аяклы куян син, диде бит ахмак. Кешенең хəтере калыр, борчылыр, үпкəлəр, дими, телəнə ни килсə, шуны əйтə исəр баш. Бүген ул уйлаган этлеген эшлəми тынычланмаячак, кая мəҗлес җыелачак өй тирəсенə барыйм əле, бəлки, очратып комачаулармын аңа...

Һаҗəр апа торган өйнең, эчендə бөркүгəдер, урам ягындагы өч тəрəзəсенең икесе шар ачык. Шуларның кырыйдагысыннан үрелеп өй эченə күз салдым. Табын өстенə үк тиеп диярлек асылмалы унлы лампа яна. Ишек катында клуб мөдире Фəтхи абый урындыкка утырып чайкала-

чайкала гармун уйный. Район осоавиахим оешмасы вәкиле Бикмуллин абый бөкрәя төшеп бии. Аның чырае кып-кызыл, шабыр тир, иңнәре салынган, язгы ана каз шикелле бер урында тыпырдавы уйналган көйгә туры килми. Габбас абый мич буенда кулларын чәбәкләп Бикмуллин абыйны дәртләндереп утыра. Һаҗәр апа казан янында кайнаша. Немец теле укытучыбыз Петр Иванович бер кулына буш стакан тотып, икенче кулындагы кыярлы чәнечкесен болгый-болгый янәшәсендәге Сәлимә апага нәрсәдер сөйли. Калган дүрт-биш кунак «Шахта» көенә җырлыйлар...

Миңа, оятыңны югалтып тәрәзә янында торма, кит, дигән шикелле итеп, яңгыр ява башлады. Мин, нәрсәгә дип чыланам монда. Җирән шыр җүләр түгел, уйлаганын җиренә җиткерергә яңгырда ул килми дә килми инде, дип тизрәк өйгә йөгердем.

Төн урталарында кемдер безнең ишекне шакыды. Әти урыныннан торды.

— Кем бар анда?

— Бу мин, Максимов. Петр Иванович. Вакытсыз борчуым өчен гафу итегез мине, Сабир Кадыйрович. Һаҗәр үлем хәлендә. Аның морҗасыннан кемдер бомба ташлады. Исаркин үлде бугай, яралганучылар да бар шикелле. Ут сүнде, мин тизрәк сезгә йөгердем...

Әти дә, әни дә, тиз-тиз киенеп, Петр Иванович белән бергә фаҗига урынына чаптылар. Әти бераздан әйләнеп кайтты. Мин аңардан Һаҗәр апаларда нәрсә булуы белән кызыксынгач, ят, йокла, берни дә булмаган, үлүче дә, яраланучылар да юк, морҗада бомба түгел, сүндерелмәгән известь тутырылган фляга шартлаган, диде. Мин, тәки үзенекен эшләгән Җирән, дип уйладым.

Әни, «бомба шартлагач» йөрәге сынаткан Һаҗәр апа белән төне буе мазаланып, аның яныннан тик иртә белән генә кайтты.

## 3

Йокыдан торып өйгә кергәндә әти кулына газета тотып идән буйлап ишекле-түрле йөри иде. Башын игән, чырае уйчан, күзләре ярым кысылганнар, битендәге яра җөе тартышып-тартышып куя, иреннәре кысылган. Нәрсәгәдер ачуланганда яки бик нык кәефе кырылганда гына әти шундый кыяфәткә керә. Әмма бүген ул ачулыга охшамаган, нәрсәгәдер аптыраган, югалып калган шикелле. Миңа ул йөрүеннән туктап, кулындагы газетага текәлде, аннары шуннан күзләрен алмыйча, өстәл янындагы урындыкларның берсенә утырды. Мин аның сәер кыяфәтенә гаҗәпләнеп түргә үтәргә дә, үтмәскә дә белми бусага төбендә катып калдым. Әтигә нәрсә булган, нигә ул шулай салпы, чирләде микән әллә? Әни өйдә күренми, ул кая китте икән? Бүген ничектер гадәттәгечә самавыр чыжлаганы да ишетелми, әнә инде кай вакыт җиткән, бүтән көннәрне иртәнге җидедә күптән чәй эчелгән була иде, әнине берәр авыру янына чакырганнар, күрәсең.

Капка шапылдады, кемдер керә. Мин өйалдына чыгып, ишектән башымны сузып, тышка карадым. Әни икән. Чишмәдән су алып кайтып килә. Чиләктә төн кунган суның тәме икенче, яңа алып кайткан су ише булмый, дип һәр иртәне чишмәгә йөгерә. Миләүшә өйдә чакта әнигә су ташытмый анысы, ул өйдә юк. Каранда, әнисе белән бертуган апаларында, инде ун көн чамасы кунакта ята.

— Әллә юынмадыңмы әле, улым? Ничек була инде бу, кемне көтәсең? Мин юындырыр дисеңме әллә? Әтиең нишли?

Әни бер чиләген өйалдындагы эскәмиягә утыртып, икенчесе белән өй эченә үтте һәм шундук бүлмәдән аның борчулы тавышы ишетелде:

— Төсең киткән, чирләдеңме әллә, Сабир? Ни булды сиңа, кай җирең авырта?

Эти әнигә тыныч кына җавап бирде:

— Борчылма, Мәликә, мин сау-сәламәт.

— Нигә төсең китте соң? Куй әле градусник, температураңны үлчик, аннары саумы, авырумы икәнеңне чамаларбыз. Беләм мин сине.

— Калдыр әле градуснигыңны, Мәликә. Әйтәм ич сиңа, авырмыйм мин.

— Бер дә юктан гына түгел ич бу кыяфәтең...

— Түгел. Кичәге газетада бер сәер мәкалә бар, шуны укыгач, аптырап калдым мин.

— Нинди мәкалә ул аптырарлык?

— «Җәгъфәровның чын йөзен ачарга» дигән мәкалә.

— Нәрсә, нәрсә?..

Этинең сүзләреннән соң өйгә атылып кердем. Әнигә бу ошамады.

— Син һаман юынмадыңмыни әле? Бар, юын! Аннан ташла шул үзеңә кагылмый торган сүзләргә колак салу гадәтеңне. Үз дөньяңнан тизрәк качарга тырышма, бала әле син.

Мин теләмичә генә юынырга чыгып киттем. Җәгъфәров абыйга нәрсә булган анда? Ялган йөзле микәнни ул? Аны эти белән әни генә түгел, мин дә беләм ич. Чын коммунист ул. Этине әнә мәчет манарасын ордым-бәрдем кискәне өчен башта өйгә килеп сүкте, аннары райкомга чакырып учет карточкасына яздырып каты шелтә бирдерде. «Ташла үзеңә кагылмый торган сүзләргә колак салу гадәтеңне», имеш, хурлап үләрсең...

Тиз-тиз генә юынып өйгә кердем. Мин кергәч, эти белән әнинең сүзләре бүленде. Әни миңа:

— Улым, бар, йөгереп кенә кибеттән шикәр алып кайт әле, шикәр беткән икән безнең,— диде.

Беләм мин әнине, хәйләли. Үзләренә сөйләшергә комачаулавымнан котылу өчен уйлап тапты шикәр бетүне. Йөгереп кенә ди тагын, аягыма кадак кадалганнан соң титаклаудан яңа арынуымны оныткан диярсең. Эх, әни, әни...

Мин кибеттән шикәр алып кайтканда эти дә, әни дә өйдә юк, эшкә киткәннәр иде инде. Әни миңа аягымдагы бәйләүне алмаштырырга медпунктка керергә кушып язу калдырган. Бәлки, медпунктка да йөгереп кенә барыргадыр?!.

Әнинең язуын укыгач, мин этине борчуга салган теге газетаны эзләп өстәл өстен, урындыкларны, шкаф түбәсен, тәрәзә төпләрен караштырдым, әмма эзләгән җирләремдә аңа юлыкмадым. Эти үзе белән алды микәнни соң аны? Өстәл тартмасын да ачып карадым, юк. Китап шкафында китаплар гына. Чоландагы иске газеталар арасында да ул булмаска тиеш. Эти анда кирәксезләрен генә чыгарта. Кайда гына яшерделәр икән соң алар аны? Әнинең үзенә кирәк буласы кәгазьләрне ашъяулык астына тыга торган гадәте бар, бәлки шундадыр ул? Ура, шунда! Менә ул мәкалә.

## ҖӘГЪФӘРОВНЫҢ ЧЫН ЙӨЗЕН АЧАРГА

Иптәш Сталин ВКП(б) Үзәк Комитетының февраль-март Пленумында ясаган докладында большевистик уяулыкны күтәрү, гамьсезлекне,тыныч күңеллелекне, семьячылыкны тәмам бетерү, халык дошманнарының тамырын корыту һәм кадрларны сәяси тәрбияләү мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән куйды.

Ләкин Каран райкомы җитәкчеләре, бюро членнары юлбашчының бу күрсәтмәләрен үтәмиләр. Алар большевистик уяулыкны принципиаль югарылыкка күтәрү урынына, эштә сәяси сукырлык, гамьсезлек һәм тыныч күңеллелек күрсәтәләр. Тәнкыйтьне томалап, берсен-берсе яклашып, семьячылыкны һәм ялагайлыкны тамыр җәйдерәләр. Халык дошманнарының контрреволюцион эшләрен рәхимсез фаш итү, җимерү урынына аларга килешүчәнлек, ачык авызлылык күрсәтәләр. Ягъни, чүпне өйдән чыгармыйлар.

Партия документларын тикшерү һәм алыштыру вакытында райком секретаре Җәгъфәровка партияне алдаучы троцкийчы Якушин турында берничә сигнал бирелә. Җәгъфәров бу сигналларга политик бәя бирми, ул халык дошманы Якушинга җиңел генә партия билеты тоттыра, аның белән дуслаша, аңа кунакка йөри, семьячылык обстановка-

сына кереп бата. Нәтиҗәдә райком секретаре Җәгъфәров үзенең сыйнфый уяулыгын югалта. Бу хәл бигрәк тә соңгы вакытта троцкийчы Якушинның чын йөзе фаш ителгәннән соң ачык күренә.

Җәгъфәров завод партоешмасында фаш ителгән халык дошманы Якушинның эшен өч ай буе төрле сәбәпләр табып, райком бюросына куймый килә. Бу факттан райком төрле партия оешмаларына тиешле сабак алу ясамый. Хәтта халык дошманы Якушин башлангыч партия оешмасы тарафыннан партия сафыннан чыгарылганнан соң да, райком секретаре Җәгъфәров аңа башлангыч партия оешмасының отчет-сайлау җыелышында катнашырга рөхсәт бирә.

Җәгъфәровның үзенең дә үткән юлы таза түгел. Ул — моннан берничә еллар элек Кәркәш оешмасында булган милләтчеләр төркеменең бер вәкиле. Партия документларын алыштыру вакытында Җәгъфәров үзенең бу пычраклыгын яшереп кала, партияне алдый. Ул шулай ук троцкийчы буржуаз милләтче Байсаров һәм Бакировлар белән булган бәйләнешен партиядән әлегә чаклы яшереп килә.

Җәгъфәровның Каран райкомында урнашып килгән зарарлы практикасы әле дә бетмәгән. Коммунистларның район күләмендәге отчет-сайлау җыелышында Якушин һәм Гозәеровларның иярченнәре сыйфатында фаш ителгән кешеләр әлегә чаклы райком тарафыннан тикшерелмәгәннәр. Райком пленумы членнарыннан Нәфыйгов һәм Аюкиннар тәнкыйтьне кысалар. Алар өлкә газеталарына хәбәрче булып торучы Илдарханов һәм Төхбәтов иптәшләрне төрлечә куркыталар, эзәрлеклиләр.

Каран райкомының яңа составы партиягә зарарлы булган менә бу күренешләргә тыныч күңеллелек белән карый, аңа килешүчәнлек күрсәтә. Мондый черек практиканы большевистик тәнкыйть уты астына алырга, партия оешмаларының эшендәге гамьсезлекне, идиотларча тыныч күңеллелекне җимереп ташларга кирәк.

Х. Бәдри.

Зур, бөтен Татарстан укый торган газета бит бу! Нәрсә булыр икән Җәгъфәров абыйга хәзер? Шаять, урынында калдырмаслар. Мәкаләдә хәтта аны бер урында да иптәш дип тә атамаганнар ич. Бу тикмәгә түгел. Халык дошманнары белән дуслашу, аларны үз канаты астына алу уен эшме? Юк. Үзе дә шулар сыңары булгач, бу табигый. Газета аны тагын буржуаз милләтчеләр төркеменең бер вәкиле дип атаган. Ә үзе райком секретаре! Этигә мәчет манарасын кискәне өчен шәхси карточкасына яздырып каты шелтәне юкка гына бирдермәгән ул, үзенең дуслары — халык дошманнары каршында яхшатлы булып күренер өчен эшләгән.

Мин газетадагы бу усал мәкаләне кат-кат укыдым, укыган саен фикерләрем ачыклана, ныгый, Җәгъфәров абыйга нәфрәтем арта барды.

## Уникенче бүлек

### 1

Колхоз уракка төште. Эшкә яраклы бөтен кеше кырда. Каерылып уңган ашлыкны МТСтан килгән бер «Коммунар» комбайны гына урып өлгерә алмый, өч атлы ургыч та иртәдән кичкә кадәр туктаусыз җилпенәләр, хатын-кызлар да, билләрен турайтмыйча, бер-берләре белән ярыша-ярыша кулдан уралар. Комбайнга ышаныч аз, эшләүдән бигрәк, ул күбрәк тик тора. Кайчан карасаң да, йә әвернәсенә салам чорналып тукталган, йә валлары тыгылган, йә механизмнарын хәрәкәткә китерә торган юк кына шкивы яки чылбыры өзелгән була, йә моторы, йә сугу аппараты көйсезләнә. Күрше колхозларда эшләүче комбайннар көнгә егермешәр гектар җирне ялап ташлагандай итә, диләр. Чындырмы ул, ялгандырмы — билгесез. Безнең комбайнчы Насыйб абый иң шәп урган көннәрендә дә дүрт-биш гектардан арттыра алганы юк.

Комбайнны тракторына тагып йөртүче Хатип абый, ургәлеп:

— Бу шайтан калтырчасы белән уру, амбарларга үзем керәм, дип торган ашлыкны әрәм итү генә, йөрәк әрни, ашлыкның яртысыннан күбрәген җирдә калдырабыз,— дип зарлана.

Насыйб абыйның комбайнын белүе дә чамалы бугай. Ул аның кай җире ватылса да, майга, тузанга батып карарлыгы калмаган китабын

кимендә ярты сәгать актармый төзәтергә керешми.

Хатип абый аңа әле кичә генә:

— Сихерче китабына охшаган кулга алырга чирканыч бу әфтиягеңне утка якмый булмас синең. Аның белән үзең дә газап чигәсең, комбайнны да газаплыйсың — диде.

Насыйб абый аңа ләм-мәм сүз әйтмәде.

Кәрим белән мин комбайннан ашлык ташыйбыз. Кәрим — колхоз атында, мин — мәктәпнекендә. Комбайн «кәҗәләнмәгәндә» эшебез рәхәт, бункерга җыелган ашлыкны йөкләребезгә төйибез дә ындыр табагына ашыгабыз. Кәрим юл буе җырлый, мин, арбамдагы гәрәбәдәй бөртекләр өстенә сузылып ятып, аны тыңлап кайтам.

Атлар кайта атлап-атлап,
Басу тузанын таптап.
Көннәр торсын гел кояшлы,
Китмәсен болыт каплап...

Уена ни килсә, шуны җырлый Шөлдер. Теләсә нинди җырның сүзләрен үзенә ошаганча үзгәртә, нинди генә көйне дә бөтен тавышына суза. Уракчы хатыннар аны, эшләреннән туктап, тыңлап калалар.

Атка юл таныш, ул үз җаена кайта. Йөгемнән төшеп, Кәрим янына күчеп утырам. Дустым йөгенә сузылып яткан, күзләрен зәңгәр күк бушлыгына төбәгән, елмая. Мин килгәч, ул торып утырды.

— Җырла, ник туктадын?

— Күр әнә, тургай да гел сайрамый, күктән җиргә төшеп ял итә. Аннары гына сөекле биеклегенә тагын күтәрелеп чыңлый башлый.

— Син дә, тургай кук, ял итәсең алайса?

— Ял итмим, уйланам.

— Нәрсә турында?

— Безнең менә бу кырлар, авылыбыз, аларның киләчәге турында.

— Һәм җырчы артист булу хакында, шулаймы?

— Артист булу минем гамемә дә кергәне юк.

— Кем булырга уйлыйсың соң син?

— Ә син үзең?

— Мин очучы булырга хыялланам. Челюскинчыларны коткарган герой очучылар шикелле, яки Чкалов һәм Громов абыйлар кебек булырга. Гүзәл җиребезгә һавадан, югарыдан сокланырга хыялланам.

Кәрим шаркылдап көлде.

— Сөләй дә, Гайфи дә, син дә — очучы. Бер Бәеш өчен күбрәк булмасмы соң бу? Өчегезне берьюлы нинди котырган чебен тешләде сезне? Сәламәтлекләре, буй-сыннары, күзләренең үткенлеге, тагын башка сыйфатлары очучы булырга яраклымы, түгелме, белмиләр, инде очалар, безнең өше җир кортларына биектән генә карарга чамалыйлар. Тумаган тайның атланып билен сындырасыз түгелме сез?

— Әллә көнләшәсеңме?

— Юк, көнләшмим.

— Без синең шикелле җырчы түгел. Синең кем буласың туганда ук маңгаеңа язылган. Рәшит Ваһапов, Фәхри Насретдиновлар кебек...

— Булмыйм.

— Нишләргә уйлыйсың соң?

— Кырчы-агроном булам. Барыгыз да канат ярып күккә күтәрелгәч, сезне туйдырырга кемдер икмәк үстерергә тиеш бит, шулаймы? Ул вазифаны мин башкарачакмын.

Туган кырлар, күңелем сезгә гашыйк,
Сез гел минем йөрәк түремдә.
Бабаларым сезгә көчен салган,
Атам тире сезгә түгелгән...

Тавышы, чыннан да, соклангыч Кәримнең. Тавыш кыллары гына

түгел, йөрәге җырлый аның. Агроном булам, ди бит, ә?!. Мөнә белән дип йөр иптәшеңне.

Инде ындыр табагына кайтып җитәргә күп калмаган иде, артыма борылып карагач, атымның ярыйсы ук еракта туктап торуын күрдем. Сүз бозау имезә, ди Зада апа, дөрес шул. Сүзгә алданып төп вазифамны исемнән чыгарганмын. Кәримнең арбасыннан төшеп тизрәк атым янына йөгердем. Ул тугарылган, шуңа туктаган икән. Аны яңадан җигеп азапланганда ындырлар артыннан килеп чыгып арбам янына Сәлим бабай туктады.

— Каян алып кайтасыз бу арышны, улым?— диде ул, күзләрен челт-челт йомып.

— Комбайннан.

— Камбайдан? И-и-и җык кергере, әпекәйгә крачин исе сеңдереп әрәм итәр заманнарны да күрәсе булган икән.

— Учыңа алып иснәп кара әнә, Сәлим бабай, бернинди керосин исе дә юк бу икмәктә. Иснә, иснә иснәгәч үзең дә әйтерсең.

Сәлим бабай йөктән учына арыш алып, башта озаклап иснәде, аннары берничә бөртекне тешсез авызына кабып теле белән шактый әвәләде.

— Арышта керосин тәме бармы, Сәлим бабай?

Карт, авызындагы бөртекләрне учына төкереп, төссез күзләрен миңа текәде.

— Крачин тәме дә, крачин исе дә җук сыман болай. Син кем малае әле?

— Бу авылныкы түгел мин, Сәлим бабай.

— Ничек инде бу авылныкы түгел, Бәеш икмәген ташыйсыңдыр бит?

— Әлбәттә.

— Әлбәттә, әлбәттә... җаннар хәзер рәхәттә... Иптәшең кайнар Гыйльмулла малае бугай?

— Шул.

— Шәп җырлый ул, тавышы матур. Син үзеңнең кем малае икәнеңне әйтмәдең инде мин карт кешегә, яшердең. Әллә минем алма бакчама кереп тотылганың барыемы, гөнаһ шомлыгы?

— Сабир директор малае мин.

— Алай икән. Синеңчә әйтсәң, мин дә Бәешнеке түгел, монда тумадым. Дырыктыр малае икәнсең, инде танырмын, җарар. Менә нәрсә әйтергә чыктым мин бу җулга улым. Сез җәнәдән камбай җанына барганда минем бакча артына туктагыз әле, алма бирермен мин сезгә. Күп итеп бирермен. Үзегез дә ашарсыз, уракчыларны да, камбайда эшләүчеләрне дә сыйларсыз. Авылдашларыма бер файда булыр, алмаларым череп әрәм булалар, җугыйса.

Мин Сәлим бабайга бернинди дә җавап кайтармадым, атымны кузгатып китеп бардым. Ул исә баскан урынында торып калды. Кулактан алган алма — эттән алган бер сөяк, үзе ашасын алмаларын...

## 2

Колхозның ындыр табагы — Чуал буенда, тегермән янында. Эш өчен бик уңайлы җир ул. Бердән, мәйданы өстәл өсте кебек тигез, икенчедән, тегермән кирәк вакытта сугу машинасын су көче белән эшләтә, моның өчен анда махсус җайланма көйләделәр, өченчедән әзер ашлыкны эшкәртү һәм вакытлыча саклау өчен шунда ук түбәсеннән яңгыр үтмәслек, тирә-ягыннан җил өрмәслек иркен әвен бар. Әвеннән ерак түгел зур киптергеч.

Уракка төшкәннән бирле ындыр табагы кешесез тормый. Төннәрен анда катлаулы машина белән ашлык сугалар. Көндезләрен сугылган

ашлык, эшкәртелеп, дәүләткә озатыла.

Урак өстендә колхозда теңкәгә иң тигән нәрсә — атлар азлыгы. Килде-китте эшләгән бер комбайн гына да биш атны үзенә бәйләгән шикелле тота. Комбайннан тыш тагын чәчү, дәүләткә ашлык тапшыру, төннәрен басудан ындыр табагындагы сугу машинасына көлтә ташу бар. Колхозда нибары кырык ике баш ат. Шуларның икесе янгын сараенда, өчесе трактор белән комбайнга ягулык-майлау материаллары ташыйлар, җидесе буаз, дүртесе карт. Кыскасы, колхозда эшкә яраклы атлар утыз тирәсе. Эшкә яраклы дигән атларның да камыт яки ыңгырчак сукканнары, аяклары авырта торганнары, чыгымчылары, үшәннәре бар. Шуңа күрә мактап атын колхоз бик теләп файдалана.

Ындыр табагына көлтә төннәрен генә ташыла. Бу эшкә күбрәк чәчүдәге атлар тартыла. Аңа дәүләткә ашлык тапшырудагы атларны алып булмый, элеваторга кадәр ара кырык чакрым, аннан кайтуы тагын кырык — барысы сиксән, аларның хәтта рәтләп ял итәргә дә вакытлары калмый. Кайтулары була, йөкләре шундук төялеп, тагын элеваторга юнәләләр. Шулай да колхоз дәүләткә ашлык тапшыру буенча койрыкта сөйрәлә. Районда барлыгы туксан дүрт хуҗалык, шуларның сиксән җидесе безнең «Марс» колхозыннан алда.

Кәрим белән мин төш вакытына ындыр табагына кайтып җитәргә ашыгабыз. Анда тегермән буасы янәшәдә генә, өстеңне чишенәсең дә чумасың суга. Ә җәйге кызуда су коенуга ни җитә!

Уракка төшкәннән бирле әтинең ындыр табагына килми калган көне сирәк. Монда аны көтеп алалар. Әти үзе белән бер кочак газета алып килә, ындыр табагында эшләүчеләрне Испаниядәге, Хәбәшстандагы, Кытайдагы һәм дөньяның башка почмакларындагы хәлләр белән таныштыра, районда һәм республикада урып-җыюның, дәүләткә ашлык тапшыруның барышы турында сөйли.

Ындыр табагына әти бүген дә килде. Ул, гадәтенчә, хәрби киемнән. Бу кызуда күн итекләрдән, галифедан, гимнастеркадан ничек түзәдер, билгесез. Гимнастерка якасының өске төймәләрен ычкындырып, фуражкасын кулына тоткан. Ындыр табагында эшләүчеләр лапас күләгәсендә төшке ашка утырганнар иде, әти килгән уңаена ук шунда керде.

— Мактап йөрисең, Сабир туган, әйдә утыр табынга,— диде Лотфулла абзый әтигә, үз янында урын күрсәтеп.

— Рәхмәт, Лотфулла, рәхмәт яусын, мин тук, яңа гына өйдә ашап килдем. Сезне мин бүген дә куандыра алмыйм, арттан караганда без һаман да җиденче, иптәшләр.

— Үзең беләсең, атлар азлык, элеватор ераклык ега бит безне, Сабир туган. Комбайныбыз да җүнле туры килмәде, хәерчегә җил каршы дигәндәй, пулный хут эшли алмый, менә шуларның бөтенесенең нәтиҗәсе инде ул артталык,— диде аңа Лотфулла абзый.

— Сез шуңа канәгать, ризамы?

— Ник риза булыйк ди? Әмма ни эшләмәк кирәк, кендектән югары сикереп булмый.

— Була, Лотфулла. Менә син ындыр бригадиры, әйт әле, күпме чистартылган ашлыгыгыз бар?

— Бер егерме тонна тирәсе булыр...

— Тәгәллеккә өйрәник, иптәшләр. Безгә МТСтан ярдәмгә йөк машинасы бирәчәкләр. Ул бер генә минут та тик тормаска тиеш. Йөк машинасына сезнең ашлык иң күбе ике тәүлеклек мәшәкать ул.

— Бирсеннәр генә, машинаны тик тотмабыз. Элеваторга хәзер ашлык илтә торган атларны басудан көлтә ташуга куярбыз да сугу машинасын тулы көченә кытырдатырбыз. Сезне бүген дә куандыра алмыйм, дигән буласың тагын! Шатлыклы хәбәр алып килгәнең өчен мең рәхмәт, Сабир туган. Әйдә, бераз дөнья хәлләре белән дә таныштыр инде.

Ындыр табагындагылар әти килгәч тә, гадәттәгечә, аның тирәсенә елышканнар иде инде.

— Бик теләп,— диде әти.— Менә сезгә кызыклы гына бер нәрсә укыйм әле, дикъкать белән тыңлагыз, соңыннан туган фикерләрегезне әйтерсез.— Әти тирләгән маңгаен кульяулыгы белән сөртте дә, көшел өстенә җайлап утырып, кулындагы газеталарның берсен җәйгәч, салмак тавыш белән укый башлады.

### БЕРЛИНДА ЯСАЛМА ФИЛЛӘР

Фашистлар матбугатында советка каршы котырынып саташуның чираттагы чәчәләнүе күренә. Берлинда чыга торган «Ангрифф» газетасының кичке басмасында һәм фашистларның бүтән кичке газеталарында Советлар Союзында берьюлы ике фетнә булу турында шаккатыргыч хәбәр басылды. Аларның берсе Алма-Атада, икенчесе Казанда булган, имеш. Икенче фетнә турында, «татарлар Мәскәүгә сугыш игълан иттеләр», диелә, ләкин татарларның яңа ханының исеме әйтелмәгән.

Җирәнгеч фашист алдакчылар, алдау никадәр оятсызрак һәм кабахәтрәк булса, үзләрен җинаять өстендә тоту һәм фаш итү шулкадәр кыенрак булыр, дип уйлыйлар. Хәлбуки, аларны тоту һәм фаш итү бер дә кыен түгел. Дөньяда ялган эшләп чыгаручы фабрикантлар гына түгел, бәлки намуслы совет матбугаты да бар. Алма-Атада да, Казанда да газеталар чыга. Фашист ялганчылар Алма-Атада һәм Казанда канлы вакыйгалар булды, Мәскәүгә поход хәзерләнде, дип язган көндә нинди нәрсәләр булганлыкны бу газеталар җитәрлек ачык һәм тулы итеп язалар...

Әти, укуыннан туктап, тирәсендәге кешеләргә карады.

— Ничек, ялыктырмыйммы мин сезне, иптәшләр?

— Юк, юк, бик кызыклы хәбәр бу, ялыктырмый, укыгыз, укы,— диде Мирсәет абый тавышы.

Мин артыма борылып карадым һәм Мирсәет абый белән Кәшиф абыйның колхозчылар арасында көшел читендә утыруларын күрдем. Бер генә түгел, биштер ул безнең биология укытучыбыз, дип уйладым мин Мирсәет абый турында, аның белән горурланып. Кайда эш тыгыз, ул шунда, ничек өлгерәдер...

Әти гимнастерка изүен соңгы төймәсенәчә чиште дә укуын дәвам итте.

Чынлыкта исә совет Казаны бәхетле һәм тук яши. Франциянең атаклы хатын-кыз очучысы Мариз Бастье егерме тугызынчы июльдә Омскидан Казанга очып килде. Аны бик яхшы каршы алдылар, ул: «Яхшы кабул иткәнегез өчен барыгызга да рәхмәт»,— дип язды һәм Мәскәүгә очып китте, анда да аны бик һәйбәт каршы алдылар. Шунысы гаҗәп, ул Казанда да, Мәскәүдә дә булып, «татарлар»ның «мәскәүлеләр»гә каршы сугыш алып баруларын күрмәде. Ә Берлин газетасының Варшава хәбәрчесе «күргән».

Ул көнне Казанда атыш булдымы? Әйе, булды. Иптәш Шевчук вак калибрлы винтовкадан атып 22,6 очко, ә иптәш Алексеев 16,8 очко алды. Татарлар руслар белән көрәштеләрме? Әйе, көрәштеләр һәм татар җиңде. Иптәш Нәҗметдинов шашкада уйнап унбер очко, ә Хрусталев ун очко гына алды. Казанлылар Союзның башка шәһәрләренә каршы чыктылармы? Әйе, чыктылар. Казан «Динамо»сының балалар командасы Киев «Локомотив»ының балалар командасына каршы чыкты.

Боларның барысы турында да һәм тагын бик күп нәрсәләр турында безгә Казан газетасы хәбәр итә һәм безнең алдыбызда — Советлар Союзының зур шәһәренең күңелле һәм матур тормышы. Анда төрле милләтләрдән булган хезмәт ияләре туганнарча яшиләр һәм эшлиләр. Билгеле, фашист газеталарының бу уйдырмалары гади саташу гына түгел, шуның өстенә мәгънәсезлек тә.

Гадәттә әлегә кадәр буржуаз матбугатта газета филләре чебеннән ясала иде. Чебен никадәр генә кечкенә булмасын, чебенсез фил ясап булмый. Ләкин фашист матбугатында чебеннәр барысы да әчпошудан һәм талантсызлыктан үлеп беткәннәр, күрәсең. Күмердән ясалма бензин, спирттан ясалма каучук, оннан ясалма сосиска җитештерү артыннан хәзер инде һавадан ясалма филләр эшләнә башлады. Хәзер инде күпертү өчен чебеннәр дә кирәкми, ялганны суырып алу өчен бармаклар да кирәкми. Мәгънәсезлек чиста, табигый юләрлек төсендә чыга. Акыл да, талант та булмаганда, идиотларча күңелсез ахмаклык кына кала. Ул бары тик Геббельс, Розенберг әфәнделәрне һәм аларга буйсынган язу карасы колларын гына характерлый. Дөньяда әле Германиянең фашистик журналистикасы төшкән түбәнлеккә һичбер төрле фәхишәлек тә төшкәне юк иде.

Әти, кулындагы газетаны төреп, тирәсендәге колхозчыларга карады.

— Яңа гына ишеткәнегезгә карата кайсыгызда нинди фикерләр туды, иптәшләр, әйдәгез сөйләшеп алыйк әле.

Беренче булып Мирсәет абый телгә килде.

— Фашистларның чираттагы бу пычрак чыгышлары бездә алар-

га карата җирәнү һәм нәфрәттән башка берни дә тудырмый. Минем үземне бу мәкаләдәге фашистлар уйдырмасы гаҗәпкә калдырды, аларның һәртөрле пычраклыкка барулары яңа эш түгел. Мин ышанам, илебез дошманнары берниндиюл белән дә безнең фикерләребезне чуалта алмаслар.

— Фашистларның уйдырмаларына җавап итеп, без дәүләткә ашлык тапшыру планын арттырып үтәрбез. Мин Мирсәет белән тулысынча килешәм. Минемчә, ул барыбызның да уртак фикерен әйтте. Рәхмәт, Сабир туган, дөнья хәлләре белән таныштырганың өчен. Ә хәзер эшкә тотыныйк, иптәшләр, МТС машинасы алдында сынатырлык булмыйк,— диде Лотфулла абзый, урыныннан торып.

Кәрим белән мин, атларыбызның аркалыкларын күтәреп, комбайн янына ашыктык.

Мин юл буе газетада әти яңа гына укыган мәкалә турында уйлап бардым. Күңелемдә фашистларга чиксез нәфрәт кайнады. Кәримнең уенда да шул мәкалә иде бугай, башка вакытта җырламый түзми торган иптәшемнең комбайн янына барып җиткәнче тавышы-тыны чыкмады.

### 3

Бөтен Бәешкә бер велосипед бар. Ул да авыл кешесендә түгел, мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире Нурулла абыйда. Бәешлеләр ике генә көпчәкле бу сәер машинаны әллә өнәмиләр, әллә аны алырга акча кызганалар, белмәссең. Авыл өчен нинди шәп транспорт югыйсә. Аңа бензин да, печән яки солы да юнәтәсе юк, шиннарына яхшылап һава тутырсаң, эшең бетә, утыр да көннәр яхшы торганда җаның теләгән җиргә бар аннары. Язгы-көзге пычракларда һәм кыш көне генә йөреп булмый аңарда. Җир коры чакта теләгән төшеңә элдерә аласың. Ат сорап кемгәдер ялынасы да, аны ашатасы, эчертәсе бар дип кайгырасы да юк. Нурулла абыйның җаны тыныч, кая булса да барасы килсә, велосипедына атлана да китеп бара, аннары озак та үтми, йомышын йомышлап әйләнеп кайтып та җитә. Ул бүген Каранга барган булган, кичен безгә килде. Чәй эчеп утыра идек, әти белән әни кыстап, аны да өстәл янына чакырдылар.

Нурулла абый алдына чәй ясап куйгач:

— Сабир Кадыйрович, мине чәй белән сыйларлык түгел, мин сезгә күңелсез хәбәр әйтергә кердем бит,— диде.

Әтинең күзләре аңа сагаюлы текәлделәр.

— Әйт хәбәреңне, тыңлыйм.

— Борчылмагыз, бәлки сез шатланырсыз гына аңа. Кыскасы, мине Әтрәч мәктәбенә директор итеп күчерәләр. Күңелсез диган хәбәрем шул.

Әти урыныннан торды.

— Дөрес, минем өчен күңелле хәбәр түгел бу. Әмма котлыйм сине, Нурулла Габитович. Мин кузгалганга карама, әйдә тынычлап кына эч әле син чәеңне.— Әти, башын иеп, кулларын артка куеп, идән буйлап берничә тапкыр ишекле-түрле үтте.— Әтрәч мәктәбенең элекке директоры Клеблиевне кая күчерәләр?

— Ул кулга алынган, Сабир Кадыйрович.

Димәк, тагын бер халык дошманы фаш ителгән. Кая борын тыгарга белгәннәр ул ыштыр битләр. Безгә, яшь буынга, үзләрендәге агуны мәктәп аша күчерергә ниятләгәннәр. Безнең сафлыкны Дзержинский — тимер Феликс варислары саклаганны хәтерләреннән чыгарган алар. Керпе бияләйле Ежов барын онытканнар. «Уңышларыбыз ишәя барган саен сыйнфый көрәш кискенләшә бара»,— ди әти еш кына иптәш Сталинның зирәк сүзләрен кабатлап. Чекистлар халык дошман-

нарын фаш итүгә җиң сызганып, яңа көч белән тотындылар, димәк. Әле күптән түгел генә газеталарда зур хәрби башлыклардан Тухачевский, Якир, Уборевич, Корж, Эйдеман, Фельдман, Примаков һәм Путнаның корткычлык һәм шпионлык эшләре белән шөгыльләнүләре фаш ителү турында хәбәр игълан ителгән иде. Корткычлар тик үзәктә генә түгел, илебезнең барлык урыннарында да бар, димәк. Радио, газеталар аша юкка гына уяу булырга, троцкийчы корткычларны, йөзләренә битлек каплаган шпионнарны аяусыз тар-мар итеп, тамырларын корытырга чакырмыйлар...

Нурулла абыйның:

— Барасым бер дә килми минем ул мәктәпкә, Сабир Кадыйрович. Тик өстән кушкач нәмә кыласың,— дигән сүзләре уйларымны бүлделәр.

Әти йөрүдән туктады.

— Нурулла Габитович, турысын гына әйт әле, безнең мәктәптә син үз урыныңа уку-укыту бүлеге мөдире итеп кемне калдырыр идең?

Нурулла абый бераз уйланып торгач, әтинең соравына сорау белән үк җавап кайтарды:

— Ә сез үзегез кемне күздә тотасыз, Сабир Кадыйрович?

Әти маңгаена төшкән чәчләрен артка сыпырып куйды.

— Безнең мәктәптә ул эшкә кулай, синнән кала, бер Мирсәет кенә инде. Тик мин аны уку-укыту мөдирлегенә җигәргә теләмәс идем. Үзең беләсең, ул укыткан фәннәренә җаны-тәне белән бирелгән, аларны табигатькә, әйләнә-тирәгә бәйләп укыта торган кеше. Көз керә менә, дәресләрен ул кырда, болында, елга буенда, урманда үткәрә башлаячак. Бу бик яхшы. Балаларга озын, ялыктыргыч кыш алдыннан саф һава сулау зарур. Алар караңгы, тынчу классларда айлар буе утырачаклар бит. Мирсәет завуч булып алса, укытуына зыян киләчәк.

— Ә Һаҗәр турында нәрсә әйтерсез?

Әти өметсез төстә кулын селтәде.

— Сәламәтлеге, холкы уку-укыту бүлеге мөдире булырлыкмы аның? Ю-ук, коллегаларының эшләрендәге кимчелекләрне күрә һәм аларны такт белән төзәттерә белә, укымышлы, методик ярдәмгә сәләтле, сабыр табигатьле һәм үз өстендә эшли ала торган кеше кирәк ул эшкә. Җамалыйны куяргадыр бәлки, ә?..

— Исаркин, үзегезгә мәгълүм, шешә белән дус, аннары җыйнаксыз да. Завучлыкка үзе дә риза булмаячак ул.

— Син дә директор булырга атлыгып тормыйсың ич әнә, шулай да китәсең. Кушкач, бәлки Җамалый да ризалашыр, ничек уйлыйсың?

— Аның белән миңа түгел, сезгә эшлисе, үзегез хәл итегез.

Районда утыручыларың, шул исәптән Җәгъфәров абыйның башларына тай типтеме икәнни шулай эшләмәсәләр? Нурулла абый урынына Әтрәчкә бүтән кешене күчерсәләр, ярамас идеме? Күчерсеннәр иде әнә Һаҗәр апаны яки Габбас абыйны. Юк, әйбәт укытучыны күчерәләр. Бәеш укучылары белем алмасыннар, надан калсыннар әйдә, дияләрдер инде.

Нурулла абый велосипедына атланып, шулай директорлыкка китеп барды. Ул киткәч уку-укыту мөдире булып Җамалый абый эшли башлады, ә география дәресләрен алып баруны немец теле укытучыбыз Петр Иванович Максимовка йөкләделәр.

## Унөченче бүлек

### 1

Җәйге каникуллар артта калды. Хәзер инде алар тик төштә генә булдылар кебек. Мин яңадан һәр иртәне мәктәпкә ашыгам, һәр иртәне

Сөләй мине элеккечә үк капка төпләренә чыгып көтеп ала. Без аның белән киләчәккә төрле планнар корабыз, хыялланабыз. Үскәч икебез дә очучы буласы кешеләр бит, әңгәмәбез башлыча самолетлар, атаклы очучылар турында бара.

Мәктәбебез, өстеннән манара төшкәч, ничектер зураеп, биегәеп киткән төсле тоела. Аның хәзер эчендә дә якты. Мәктәп тирәсендәге тупылларны җәй көне нык кына сирәкләделәр. Ямьсез тавышлар да юк. Тупылларның исән калганнарындагы карга оялары хәзер ял итәләр, аларның тынгысыз хуҗалары безне язга кадәр тынычлыкта калдырдылар. Җәйге каникуллар башланганчы колакларны тондырган каргалар мәйханәсен хәзер дәресләр барганда ишетмәү ничектер сәер дә, гаҗәп тә.

Мин инде җиденчедә. Миләүшә белән узган уку елындагыча ук бергә утырабыз. Сөләй безнең артта. Кәрим Гамбәр белән тәрәзә буенда. «Камчатка»да Гайфи урыны буш. Җирән көзге сынауларын бирмәде, рус мәктәбенә күчте. Ала көз Гайшә җәй көне Кәҗә Гыймадиена кияүгә чыкты. Беркөн без аның белән ул судан кайтып килгәндә очраштык. «Классташларыбызның барысына да сәлам әйт, Гайшә «кытый»лардан котылуына шатлана диген»,— диде ул миңа. Бераз ябыга төшкән, хәтта чибәрләнгән дә кебек. Кешегә бәхетенә ирешү өчен күп кирәкми, яраткан кешесе белән бергә булу да җитә икән, дип уйладым мин аннан аерылгач. Сәламен классташларыма тапшырдым, әлбәттә. Гайшәнең зур тормышка бернинди борчылуларсыз, шулай җиңел генә аяк басуына барыбыз да сөендек.

Мәктәп тормышы элекке эзеннән үк ага. Укытучылар коллективына өч кыз өстәлде. Өчесе дә Алабуга педагогия техникумын бетергәннәр. Икесе башлангыч классларда, Оркыя апа исемлесе Хөршидә апа урынында рус теле укыта. Ул безнең класс җитәкчесе дә. Җиденче чыгарылыш классы булгангамы, быел безгә караш икенче. Укытучыларның, Һаҗәр апа белән Габбас абыйдан калганнары, безне инде өлкәннәр саныйлар. Белемебез белән бер елдан без дә аларның кайберләрен куып җитәчәкбез ич.

Соңгы көннәрдә мәктәптә башлангыч класслар гына укый. Бишенче, алтынчы, җиденче класслар колхозның бодай басуында башак җыюда.

Кырда башак җыю тынчу класста дәрестә утырудан мең артык. Кырда син үзеңә-үзең хуҗа. Теләсәң эшлисең, арысаң, ял итәсең. Тик үзеңә бүлеп бирелгән кишәрлектә башаклар калдырма һәм норманы үтә. Һәр укучы көнгә өч арыш капчыгы башак тапшырырга тиеш. Бу — колхозга укучы үз куллары белән җыеп биргән илле-алтмыш килограмм чамасы өстәмә ашлык дигән сүз. Зиннәт абый, районнан безгә шундый күрсәтмә булды, үстерелгән игеннең бер генә бөртеге дә кырда калып әрәм булмаска тиеш, ди. Без кайбер көннәрне норманы икеләтә үтибез. Дүрт ат без җыйган башакларны ындыр табагына тоткарлыксыз ташый, өлгер генә.

Өченче көн басудан кайтканда Сөләй Кәрим белән миңа:

— Безгә, егетләр, башак җыеп азапланмаска, йомран оялары гына казырга кирәк. Йомран кыш көне ашарга үзенә поттан артык ашлык әзерли, ди эти. Әйдә, иртәгә басуга үзебез белән көрәк алып барабыз да, кешеләр күзеннән читтәрәк йомран оясы табып, шуны казыйбыз. Аннары безгә башаклар кыркып этләнәсе булмый,— диде.

— Син ялгыз нарат төбендә хәзинә дә таптың инде, йомран ояң да шулай булачак. Мин синең бу эшеңдә иптәш түгел,— дип, Кәрим Сөләйнең бу тәкъдимен хупламады.

— Ә син, Ирек, ризамы?

— Көрәк алып килсәң, карарбыз,— дидем.

Акылым тулмастыр минем, валлаһи! Гел шулай, башта ризалашам, аннары икеләнә, уйлана башлыйм. Кәрим әнә әйтү белән кырт

кисте дә эше бетте. Безгә бит башта кеше күзеннән читтәге йомран оясын табасы, аннары аны казыйсы бар. Йомран оясыннан бер пот бодай чыкса ярый да бит, чыкмаса — башак та җыймыйбыз, көлкегә дә калабыз. Бу — күктәге торнаны тотарга ымсынып, кулдагы чыпчыкны очырып җибәрү булачак. Юк, сипкел оясының сүзенә алданып, адәм мәсхәрәсенә калудан сакланырга, йомран амбарына алданмаска, башак җыярга кирәк. Йомран оясын табып үзе казысын Сөләй.

Иртәгесен дустым, кулына көрәк тотып, капка төпләрендә мине көтеп тора иде инде.

— Мин, дустым, йомран оясын эзләшмим дә, казышмыйм да. Күтәреп йөрмә көрәгеңне, калдыр. Кәрим хаклы,— дидем мин аңа.

— Әй, сыбызгы, сыбызгы, син сүзеңә хуҗа булсаң, үгез бозаулар, кәҗә тәкәсе буазланыр иде, көрәк алып кил, карарбыз, имеш. Менә карадың. Буш куык. Син ышандырмасаң, мин бүтән кеше табар идем,— диде ул, миңа үпкәләп.

— Тап, әле соң түгел ич.

— Тапмас дисеңме, табармын, авылда малайлар Кәрим белән син генәме әллә?

Сөләй, бишенчедә укучы ике малайны ияртеп, басуга бездән алда йомран оясы эзләргә китте. Без Тәкәрлекнең үзен дә, аңа ияреп киткән малайларны да ул көнне бүтән күрмәдек.

Икенче көнне мәктәп коридорында (кичә Сөләйнең басуда ни белән шөгыльләнүен кайдан белгәннәрдер) зур ватман кәгазенә бик шәпләп ясалган карикатура эленде. Карикатурада Сөләйне үзе зурлык йомран белән өстенә БОДАЙ сүзе язылган юан капчык өчен тарткалаштырып төшергәннәр һәм шунда ук эре хәрефләр белән: «7«Б» классы укучысы Лотфуллин Сөләйманнан үрнәк алмагыз. Ул кичә, башак җыюдан качып, пионер исеменә тап төшерде»,— дип язганнар иде.

Басуга китәр алдыннан Мирсәет абый безгә йомраннарның кышка бернинди дә азык әзерләмәүләре, аларның кышны аюлар, бурсыклар, янутлар, керпеләр кебек йоклап үткәрүләре турында сөйләде.

2

Мәктәптән кайтканда Гайфи очрады. Ул мине юлымда махсус көтеп торган. Зурлар шикелле кул кысышып күрештек. Үзгәргән Җирән. Өстендә яңа пинжәк-чалбар, аякларында күн итекләр, күлмәк якасының соңгы сәдәбе төймәләнмәгән, кепкасы кулында. Әмма үз-үзен тотышы элеккечә, анысы киемнәре белән бергә яңармаган.

— Ничек сез монда минсез? Бичура хәзер кайсыгызга каныга? — дип сүз башлады ул.

— Без укулар башланганнан бирле гел басуга башак җыярга йөрдек бит әле, дус. Үзең ничек? Бөтенләй чит кешеләр арасында ялгызыңа гына күңелсездер инде. Уку авырмы русча? Анда үзеңне ничек каршыладылар?

— Син хаклы, миңа Басарда бик үк күңелле түгел. Шулай да күнегә барам инде. Фатирым бик әйбәт кешеләрдә. Фатир хуҗаларым Денис абый белән Маша апа: «Син туганда ук Басарныкы буласы булгансың, сине ләкләкләр ялгыш Бәешкә илтеп ташлаганнар, татар җирән булмый, татар кара»,— дип көләләр. Җирән аларча «рыжий» икән. Әти миңа русча-татарча сүзлек сатып алды, шуннан карап белдем. Маша апа: «Син безне татарчага өйрәт, без сине русчага өйрәтербез»,— ди. Аларның ун яшьлек Федя исемле малайлары, Дуня исемле сигез яшьлек кызлары да бар. Мин хәзер телемне күнектерер өчен көн саен русча башта йөзгә, аннары йөздән кирегә саныйм. Баштарак авыр иде, инде күнектем. Маруся апа белән балалары татарча санарга өйрәнәләр. Мин инде атнадагы көн исемнәрен русча да бутамыйм. Мәктәптә

малайлар башта мине өнәмәделәр, «гололобый» — «шәрә маңгай» дип мыскыллыйлар иде. Беркөнне мин аларга бишташлы уйнап күрсәттем. Рус малайлары да минем уенымны кабатламакчылар иде, чыкмады. Менә болай уйныйлар аны дип тагын күрсәттем. Тагын маташып карадылар, булмады. Хәзер аларның бөтен шөгыльләре шул бишташлы уйнарга өйрәнү. Мине алар Гайфи димиләр, үзләренчә Гриша дип йөртәләр, «гололобыйны» онытгылар...

Безнең капка төбенә җиткәч Гайфи:

— Сезгә кереп тормыйм, Ирек, минем кордонга барышым. Күмер яндырган өчен аннан акча аласы бар. Әти биле кузгалып урын өстендә ята, мине җибәрде. Ашыгыч эшең булмаса, әйдә, барыйк бергәләп,— диде миңа.

— Бернинди эшем дә юк минем, хәзер, портфелемне калдырам да китәбез, дус.

— Син ашамаган бит, юлда ашарсың, бер кыерчык ипи алырга онытма.

Кордон Бәештән биш чакрым тирәсе читтә, тау битләвендәге урман аланында. Минем әле анда беренче баруым, әмма андагы өйләр һәм каралтыларны район үзәгенә барганда юлның сул ягында ерактан күргәнем бар.

Кордонга без урман аша киттек. Гайфи миңа көзге матурлыкка сокланырга комачауламады. Ул, үз уйларына бирелеп, як-ягына карана-карана, янәшәмдә тын гына атлады. Менә ул кинәт иелеп юл читеннән юан балтырлы, калын коңгырт эшләпәле бик купшы бер гөмбәне кулына алды.

— Кара, нинди хәзинә әрәм була урманда. Каен гөмбәсе бу. Иң тәмле гөмбәләрнең берсе. Туклыклы да, итең бер якта торсын. Без, татарлар, ашарга күнекмәгәнбез шундый шәп урман ризыгын. Кыздырганы, ашы, сумсасы бер дигән була гөмбәнең. Тозлаганын әйтмим дә инде. Быел эти белән без урманда җәй буе гөмбә ашадык. Синең, Ирек, гөмбә ашаганың бармы?

— Юк. Безнең өйдә аны җыючы да, ашаучы да юк.

— Сабир абый да, Мәликә апа да дөнья күргән культуралы кешеләр бит. Нигә алар гөмбәдән борын чөерәләр, аңламыйм.

— Бу гаҗәп түгел, әтинең дә, әнинең дә гомерләренең күп өлеше Урта Азиядә үткән. Бәлки анда гөмбә үсмидер, шуңа күнекмәгәннәрдер.

— Минем Басардагы фатир хуҗаларым Денис абый белән Маша апа иң тәмле гөмбәләрне кышка бер кисмәк тозлаганнар. Бәрәңгене алар йә тозлаган кәбестәсез, йә тозлаган гөмбәсез ашамыйлар. Әллә никадәр киптергәннәр дә. Хәзер юл буендагы бу гөмбәләрне Маша апа күрсә, «батюшки», дип ах итәр иде. Күр, әрәм булалар бит инде алар, кайтканда бәлки җыярбыз?

— Нәрсәгә салырбыз, савытыбыз юк бит.

— Ә күлмәк нәрсәгә? Якасын җиңнәре белән урап төйнәдең, менә дигән капчык була.

— Кордонга барыйк әле, кайтканда күз күрер.

Кайтканда без килгән юлдан түгел, тау итәгендәге сукмактан кайттык. Инде бөтен тирә-юнь караңгылыкка өртелгән, күктә йолдызлар калка башлаган иде.

3

Тормыш зур һәм кечкенә күңелсезлекләрдән генә тора шикелле тоела миңа. Ул эчпошыргыч күңелсезлекләр җирдә дә үсмиләр, күктән дә төшмиләр, ни өчендер аларны кешеләр тудыра. Еш кына мин, кешеләрнең кайберләренә нәрсә җитми, нигә алар безнең гомуми

бәхетебезне күпсенәләр, илебезне үткәнендәге кара көннәренә кайтарырга телиләр, дип уйланам. Әмма үз-үземә куйган сорауларыма җавап таба алмыйм, көннән-көн бутала барам. Мин малай гына әле, тормыш тәҗрибәм чыпчык томшыгы кадәр генә, сорауларыма җаваплар таба алмавымны шуңа сылтарга була, ә зурлар... зурлар да ул четерекле сорауларга анык җавап таба алмыйлар.

Бүген инде берничә көн тәрәзә төбендә аунаган «Кызыл Татарстан» газетасын кулыма алып ачуга, күзем бер мәкалә астындагы Н. Баян имзасына төште. Шундук хәтеремдә әле күптән түгел генә «Чаян» журналында басылган «Нур Баян комбайны» дигән карикатура һәм аның астындагы:

Минем белән яшьтәш кызлар
Комбайнны оста йөртәләр,
Комбайннар бара, артларыннан
Тезелеп кала билле көлтәләр...

— дигән юллар яңарды.

Күренекле шагыйрь тезмәдән чәчмәгә күчеп нәрсә язды икән, дип, ахырына аның имзасы куелган мәкаләгә күз йөртә башладым. «Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы социалистик чынбарлыкны бозып күрсәтә торган бер әсәр»... Бу җөмләне укуга, тәнем эсселе-суыклы булып китте. Нәрсә, шашканмы әллә ул Нур Баян абый? Мәкаләне ары укырга көчем җитмәде, газетаны өстәлгә ташлап, китап шкафына борылдым. Әнә ул «Тирән тамырлар». Аның «Фәхрине үтереп ташладылар» дигән беренче юлыннан, кулак Вәли Хәсәновка чыгарылган хөкем карары җиренә җиткерелеп, китап ябылганга кадәр булган вакыйгалардан мин чынбарлыкның ничек бозылып күрсәтелүен, контрреволюцион милләтчелек рухын табарга һәм күзалларга тырыштым. Башым буталды, бернигә дә ирешә алмадым. Бераздан газетаны яңадан кулыма алып, мәкаләне бик дикъкать белән укырга керештем.

«Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы социалистик чынбарлыкны гаять бозып күрсәтә торган бер әсәр. Ул турыдан-туры контрреволюцион милләтчелек рухында язылган һәм зарарлы идеяләр тарата. Ә әсәрендә шундый тирән хаталары булган Г. Ибраһимов ни өчен соң бу көнгә кадәр тавыш-тынсыз ята? Нигә матбугат битләрендә бер генә булса да мәкалә белән чыкмый? Нигә Татарстан язучылары һәм укучылар җәмәгатьчелегенә үзенең хаталарын танып бер хат та язмый? Күп хаталар эченә кереп чумган һәм тирә-ягы контрреволюцион элементлар белән чолганып алынган, соңгы көннәргә кадәр алар белән элемтәдә торган Г. Ибраһимов хаталарын танырга вакыт тапмыймы? Һич алай түгел. Ул әле соңгы көннәргә кадәр диярлек политик зарарлы әсәрләрен һичбер төзәтүсез бастыру турында кисәтә торган хатлар язып ятты. Язучылар союзының элекке җитәкчеләре белән ныклы элемтәдә булды.

Илебездә контрреволюцион троцкийчы-бухаринчы һәм милләтче шпион бандитларны тамырлары белән йолкып ташлау барган бер чорда Г. Ибраһимовның тик ятуы очраклы гына бер хәл түгел. Бу һәрбер укучыны шикка калдыра торган хәл һәм зарарлы күренеш. Шуңа күрә Г. Ибраһимовның иҗатын тикшерүдә бу мәкалә белән генә чикләнеп калмыйча, киләчәктә аны тикшерү эшен дәвам итәргә кирәк.

Н. Баян.

Бу — татар әдәбиятының иң зур язучысы Галимҗан Ибраһимов өстендә дә көйдергеч яшен утлары ялтырый башлады, дигән сүз. Язучылардан фәлән-фәләннәр кулга алынганнар, алар халык дошманнары икән, дигән сүзләр мәктәптә күптән йөри иде инде, димәк, алар һәммәсе дә хак сүзләр булып чыга. Ә бит Н. Баян мәкаләсендә дә, Язучылар союзының элекке җитәкчеләре белән ныклы элемтәдә булды, диелгән. Бу, Язучылар союзының элекке җитәкчеләре — халык дошманнары, дигән сүз түгелме соң? Кави Нәҗми, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбай китапларының җыеп алынулары юккадырмы? Һаҗәр апа Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнгәндә аның Габдулла

Тукайны шагыйрьгә санамавын, аны такмакчы дип кимсетүен, гарәп алфавитын яңалифкә күчергәндә бу күренекле язучының аңа тешетырнагы белән каршы торганын сөйләгән иде. Н. Баян аны, күп хаталар эченә кереп чумган һәм тирә-ягы контрреволюцион элементлар белән чолгап алынган, ди. Беләсе иде, нинди хаталар һәм нинди контрреволюцион элементлар икән ул? «Тирән тамырлар»ны миңа тагын бер тапкыр бик җентекләп укып чыгарга кирәк. Н. Баян аны гаять зарарлы әсәр дигән бит.

Укылган мәкалә тудырган четерекле сорауларга җавап табу хәлемнән килмәгәч, мин нишләргә аптырап, радионы тоташтырдым. Гөлсем Сөләйманова концертын тапшыралар. Атаклы артистканың йөрәк түреннән агылган тирән хисле җырлары миңа буталчык уйларымнан арынырга ярдәм иттеләр. Мин җырлар тәэсиренә бирелеп, үземне унунбиш минут элек кенә борчыган сораулардан күпмегәдер бушандым. Шулай концерт тыңлап утырганда әти кайтып керде һәм, минем янга түргә үтеп, радионы сүндерде.

— Мәликә...

— Әни өйдә юк, әти, ул эшеннән кайтмады әле.

— Йөгереп кенә барып чакырып кайт әле аны, улым.

Нәрсә булган әтигә? Аның беркайчан да радионы кайтып керү белән сүндергәне, әнине эшеннән чакыртып кайтарганы юк иде моңарчы. Авырыймы икән әллә ул? Гомер булмаган хәл: өй эченә аякларын чишенмичә кергән. Йөзе уйчан, караңгы, кашлары бер җыерылалар, бер язылалар, иреннәре ничектер мыскыллы елмаялар төсле. Битендәге яра җөе генә никтер, гадәттәгечә, тартышмый, тыныч.

Әти миңа ияреп урамга чыкты һәм шундук борылып яңадан өйгә кереп китте.

Әнигә мин әтинең аны өйдә көткәнен, үзен ничектер сәер тотуын, бүлмәгә хәтта итекләрен дә салмый керүен әйттем.

— Хәзер кайтам, улым, хәлен бик яхшы аңлыйм мин аның. Башындагы меңләгән сорауларга җавап таба алмый җанын кыйный ул хәзер.

— Нинди сорауларга җавап эзли ул, әни?

— Җәгъфәров абыең кулга алынган, шуны ишетеп хафалана булыр, бүтән түгел.

Димәк, безнең районда тагын бер халык дошманы фаш ителгән. Ә бит ул бөтен районга хуҗа исәпләнә иде. Кызык, әти нигә аның өчен хафалана икән?..

## Ундүртенче бүлек

### 1

Көтмәгәндә мине әтисез калдырып, гамьсез балачагыма иләмсез зур кара нокта куйган көзге шыксыз караңгы төн күңелемә гомергә җуелмаслык булып уелды. Мин аны берничек тә оныта алмыйм, сыкрыйм. Чәчләрне үрә торгызырлык еракта калган ул төндә булган күренешләр уйларымда яңарганда тыным кысыла, суларга ничектер һава җитми башлый, йөрәгемнең тибеше ешая...

Иптәшләрем белән төнгә кадәр шар сугып арыгач, өйгә кайттым. Үлеп ашыйсым килгән иде. Олы якта әти китап шкафыннан нәрсәдер эзли, кече якта әни, гадәттәгечә, үз эшләре белән кайнаша. Әтинең аяк астында унлап китап аунап ята, ул аларга игътибар итми, таптый. Ни булган аңа, үзе миңа китап битләрен бөкләргә дә рөхсәт итми бит, шкафтан укырга алган китабымны тиешле-тиешсез җирдә онытсам, орыша, бүген кадерләп саклый торган китапларын идәнгә чәчеп ташлап таптый, дип гаҗәпләндем.

Ашыйсым килү онытылды, мин, шкаф янына үтеп, идәндәге китапларны җыя башладым.

Эти:

— Улым, кагылма аларга, комачаулама миңа. Иң яхшысы — дәресләреңне карарга утыр,— диде.

Мин мәктәптән кайтып ашап-эчкәч, уенга чыкканчы ук карыйм бит дәресләремне. Эти моны белә. Нигә ул миңа бүген яңадан дәресләремне әзерләргә куша? Мин кулыма алган «Дошманнар», «Түбән елгада», «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр», «Өч нарат», «Дүрт туган», «Алар өчәү иде» китапларын нигә ул идәнгә ташлатты? Нәрсә булган аңа? Аларның кайберләрен мактый-мактый үзе укыткан иде ич миңа...

Эти, шкафтан калын гына бер китап алып, өстәл янындагы урындыкларның берсенә барып утырды.

— Шамил булып Шамилнең да дошманлыгына ышанмыйм мин, Мәликә. Аны үземне белгәндәй беләм бит мин. Син дә беләсең. Заманында безнең комиссар иде ич ул. Коммунистлар партиясенә җанытәне белән бирелгән саф намуслы егет иде. Башыма сыймый, неужели үзгәрде икән?

— Җәгъфәров кулга алынганнан бирле башым буталды инде минем, Сабир. Газеталарда көн саен халык дошманнарын фаш итеп язалар, әллә кемнәр бар бит араларында. Әмма Шамил Усмановның дошман булуына минем дә ышанасым килми.

Эти, авыр сулап кулындагы китапны әйләндерә-әйләндерә карагач, идәнгә ташлады. Әһә, шкафны менә кемнәрдән арындыра икән ул, дип уйладым мин. Советлар Союзы маршаллары Тухачевский һәм Егоров халык дошманнары булгач, нигә ниндидер Шамил Усмановның дошман булмавына шикләнә икән ул? Райком секретаре Җәгъфәров абыйны утырткач та аһ орды. Бу ниндидер аңлашылмаучылык. Борһан гадел һәм турылыклы коммунист, бүген-иртәгә ул, һичшиксез, акланыр, диде. Акланды, пычагым... Инде аның артыннан райком белән райисполкомда эшләүчеләрнең яртысыннан күбрәген утыртып бетергәннәр, ди. Әмма берсенең дә акланганын сөйләмиләр. Утсыз төтен буламы? Булмый.

Эти, урыныннан торып, аунаган китапларны аягы белән бергә җыйды да әнигә:

— Боларны хәзер үк мичкә тык, Мәликә, яндырырсың,— диде.

Ярар, ул китапларны язган кешеләр дошман да булсыннар, ди. Тик аларның китапларының ни гаебе бар? Аларны нигә яндырырга? Китаплар яндыру фашистлар шөгыле бит, нигә аларга ияреп, аларның вәхшилеген кабатларга? Нигә әни этигә каршы килми?

Әни, идәндә аунаган китапларны җыеп мичкә тыккач, өстәл әзерләде. Эти борчулы, сүлпән, уйчан иде. Ашарга утыргач, әни аны тынычландырырга тырышты:

— Әйдә, кунакта кебек утырма әле, Сабир, аша яхшылап. Борчылма әллә кемнәр өчен. Мәктәбең турында уйла әнә. Үз мәшәкатьләрең дә муеныңнан синең.

Эти йөзен чытып аны туктатты.

— Ташла юк сүзеңне, Мәликә, сару кайнатма. Әллә кемнәр өчен борчылма, дисең син. Нигә борчылмыйм, илебездәге хәзерге хәлләргә гамьсез кала, битараф була алмыйм, мин коммунист бит. Бүген кулга алына торган халык дошманнары турында башымда мең төрле сораулар бутала, аларга берөзлексез җавап эзлим, әмма табалмыйм. Бүгенебез һәм киләчәгебез турында ничек уйламаска, ничек тыныч калырга мөмкин? Фронтта чакта дошман безгә билгеле, ул яшеренми, безнең өскә качып-посып түгел, ачыктан-ачык килә иде. Хәзер кемнең дус, кемнең дошман икәнен аерырлык түгел, бөтенесе буталды. Иптәш Сталин безне уяу һәм сизгер булырга чакыра. Минем белән кулга-кул тотынып эшләп, мин уйлаганча ук уйлаган кешеләр кулга

алынганда нинди уяулык һәм нинди сизгерлек күрсәтим мин...

Әтинең бүгенге күк аптыраштa калган чагын күргәнем юк иде әле минем. Дөрес, Хәйрүш абзыйны яшен суккач, берничә көн, балтасы суга төшкән кеше кебек, уйланып йөргән иде ул. Тик ул чакта хәзергечә түгел, бөтенләй башкача борчылган иде әти.

Мин юынып урыныма барып яттым, әти белән әни сөйләшә калдылар. Иртәгә Басардан Гайфи кайтырга тиеш, без аның белән Ташпичне карарга барачакбыз, яхшылап ял итәргә кирәк. Кем белә, бәлки, мәгарә стеналарында борынгы кешеләр ясаган рәсемнәрне, идәннәрендә иске учак калдыкларын, мамонт сөякләрен очратырбыз? Әтинең борчылуы турында түгел, Ташпич турында уйланып йокыга талганымны сизмәдем дә.

Өйалды ишеген бик хәтәр дөбердәткән тавышка йокымнан уяндым. Әтинең үз урыныннан:

— Сабыр итегез, хәзер, хәзер ачам,— дигән тавышы ишетелде. Өй эче дөм-караңгы иде, әти döп-дөп басып ишеккә үтте.

— Ни булды? Нигә безне генә түгел, бөтен авылны аякка бастырырлык итеп ишек дөбердәтәсез?

Ачык ишектә электр фонаре яктысы күренде. Әни торып ут алды. Бүлмәгә башта майка һәм трусиктан гына әти, аның артыннан хәрби киемле өч кеше, Һаҗәр апа, Әюп һәм Зиннәт абыйлар керде. Хәрбиләрнең кулларында кесә фонарьлары һәм наганнар иде. Аларның берсе әтигә наганын төзәп:

— Киен! — диде.

— Мин аңламыйм, ни эш бу? — диде әти.

— Син кулга алынасың, менә ордер.— Әтигә киенергә кушкан хәрби, фонарен өстәлгә куеп, кесәсеннән бер кәгазь чыгарды.

Әти трусиктан гына килеш аягына чолгавын урап итеген кия башлады. Кесәсеннән кәгазь чыгарган хәрби ачуланып акырды:

— Чалбарың киярга оныттың, мерзавец!

Көтелмәгән кунаклар ябырылып бүлмәгә кергәч, югалып калган әни:

— Киемнәреңнең яңаларын ки, Сабир, хәзер бирәм,— дип кием шкафына омтылды.

Хәрбиләрнең берсе аңа:

— Урыныңнан кузгаласы булма, хәзер атам! — дип җикерде һәм шкафны үзе барып ачып, аннан әтинең яңа гимнастеркасын һәм галифесен алып килде.

Әни пышык-пышык җылый башлады.

— Елама, Мәликә, ниндидер аңлашылмаучылык бу. Үзең беләсең, бернинди гаебем дә юк,— диде аңа әти, аякларын киенә-киенә.

— Сөйләшмәскә!

Әни кинәт елаудан туктады.

— Ничек инде ул сөйләшмәскә? Кемнәр дип уйлыйсыз сез безне? Ул коммунист, мин аның хатыны. Ир белән хатын сөйләшмәскә тиеш дигән закон кайда бар?

Әтигә киенергә кушкан хәрби күзләрен акайтып әнигә карады.

— Синең иреңә ияреәсең киләме әллә? Бик теләсәң иярттербез. Беләбез без аның нинди коммунист икәнен. Өеңдә каласың килсә, тыныңны чыгарма!

— Шулаймы? Алыгыз алайса мине дә ирем белән бергә, бирегез миңа да киемнәремне!

Хәрбиләрнең моңарчы сүзсез торганы әни янына килде.

— Тынычланыгыз, апа. Әнә улыгыз бар сезнең, аны кем белән калдырырсыз? Уйлап эш итегез.

— Уйлыйсы юк, улыбыз да безгә ияреp.

Хәрби әни белән артык сүз куертмады, ишек катындагы элекке урынына барып басты.

Эти гимнастеркасын кигәч, хәрбиләр аның түшендә балкыган Кызыл Байрак орденын күрделәр. Аларның эти янәшәсендә торганы орденга ябышып, аны көч белән үзенә йолыкты. Кинәт кием ертылган тавыш ишетелде. Мин ирексездән күзләремне чытырдатып йомдым. Күзләремне ачканда этинең күкрәгендә орден инде юк, аның урынында йодрык сыярлык ямьсез тишек кенә калган, этинең йөзе ярсып күгәргән, кара күзләре хәрбигә ашардай булып текәлгән иде.

— Бу башбаштаклыгыгыз өчен сез җавап бирерсез,— диде ул, сүзләрен тешләре арасыннан сыгып.— Минем күкрәгемә Үзәк Комитет члены Ян Францевич Рудзутак кадады аны. Орденны миннән сез түгел, хөкүмәт кенә ала ала!

— Дәшмә!

Мин мендәргә капланып җылый башладым. Эти яныма килеп утырып башымны сыйпады.

— Елама, улым, пионер еламый. Мин дошман да, корткыч та түгел, сиңа дөресен әйтәм. Партия каршында да, халкыбыз каршында да, синең каршыңда да намусым пакь. Минем турыда начар уйлама. Менә күрерсең, берничә көннән әйләнеп кайтырмын. Елама, улым, нык бул...

Хәрбиләр ашыктылар, күрәсең, өйне тентемәделәр.

Этине әни белән саубуллаштырмадылар, аны минем яннан торгызып, өйдән алып чыгып киттеләр. Әни, үз-үзен белешмичә, юка халаттан гына килеш ишеккә ташланды.

— Сабир!

Тыштан этинең:

— Хәзер үк кер өйгә, Мәликә, кер, салкын тидерерсең. Бер гаебем дә юк минем, тиздән әйләнеп кайтырмын...— дигән тавышы ишетелде.

Мин этине шул шыксыз караңгы төннән соң яңадан беркайчан да күрмәдем. Ул, дөньяда бөтенләй булмаган кебек, кинәт юкка чыкты.

## 2

Иртән мәктәпкә киттем. Башым чатнап авырта иде. Әни белән без төне буе йокламадык, этине нигә кулга алдылар, аңа нәрсә булыр, дип ут йотып утырдык.

Мәктәптә этинең кулга алынуын бөтен кеше белә иде инде. Малайлар мине:

— Әнә корткыч малае килә, җимерик борынын фашистның! — дип каршыладылар.

Үземә якынрак торган малайларга мин портфелем белән уңлы-суллы кундырдым.

— Сез үзегез фашист!

— Ә, син шулаймы?! Җаныңны алабыз хәзер! — Малайлар өерләре белән миңа ташландылар. Кайсы аркама, кайсы башыма, кайсы борыныма төндырды. Озакламый мин җирдә ауный, мине малайлар җыйнаулашып типкәлиләр иде инде. Шулчак кайдандыр Мирсәет абый килеп чыкмаса, эш нәрсә белән бетәр иде, белмим, аның тавышы ишетелде.

— Нишләвегез бу, пионерлар бит сез, ничек оялмыйсыз?!

Миңа ябырылган малайлар, стенага атылган борчаклар кебек, төрлесе төрле якка сибелделәр.

Мирсәет абый миңа торырга булышты, класска алып керде.

— Бала атасы өчен җавап бирми, кимсеттермәгез иптәшегезне,— диде ул классташларыма.

Мин башымны иеп урыныма үттем. Яныма Сөләй белән Кәрим килеп җитте.

— Кемнәр башлады, әйт, киләсе тәнәфестә үк авызларын җимерәбез.

Дәшмәдем. Хәтеремә этинең: «Мин дошман түгел, сиңа дөресен әйтәм. Партиябез алдында да, халкыбыз каршында да, синең каршыңда да намусым пакь минем»,— дигән сүзләре килде. Күңелем тулды, сулкылдап елый башлавымны сизми дә калдым.

— Ирек, мә кулъяулыгы...

Нигә бирәләр миңа кулъяулык, кем бирә, аңламадым. Миләүшә бирә бугай. Әйе, ул. Мин йөзем белән партага капландым. Миләүшә генә аңлый шул мине хәзер. Аның да этисе юк, минем дә... Ничек юк? Эти исән ич, ул берничә көннән әйләнеп кайтырга тиеш. Үзе шулай диде бит. Кайтсын гына, күрсәтер кемнең фашист, кемнең фашист түгеллеген...

Класста кинәт шау-шу тынды. Бөтен укучыларның аягүрә басканнары ишетелде. Мин тормадым.

— Утырыгыз,— дигән чәрелдек тавыш ишетелде. Ә-ә, Бичура кергән икән.

— Кадыйров, йә, бас әле.

Мин, урынымнан торып, йөземне тәрәзәгә бордым.

— Букчаңны алып өеңә кайтып кит син. Халык дошманы баласына мәктәптә урын юк безнең. Бар, бар, катып торма, кайтып кит.

Артымда Сөләй тавышы ишетелде:

— Һаҗәр апа, Мирсәет абый, бала атасы өчен җавап бирми, диде бит, сез нигә куасыз аны?

— Мирсәет абыегыз дөрес әйтмәгән. Хәзер мәктәп директоры — мин. Шулай булгач, мәктәптә минем сүзем — закун!

Класста шау-шу купты.

— Тәртип! Тәртип! Тәртип бозмагыз! Җитте!.. Сезнең дә халык дошманы малаен яклап, төрмәгә утырасыгыз киләмени? — дип чәрелдәде Бичура, өстәл төеп.— Мин тыя белермен сезне. Кара, ничек остарганнар! Бүтән тыныгыз чыкмасын, телегезне тешләтмәсәм, мин мин булмам, туктагыз өрүдән, әрсез алабайлар!

Дөреслекме инде шул: директор вазифаларын шул канатсыз чүрәкәйгә тапшырганнар, бөтен районда юк микәнни аңа лаек башка кеше...

— Кадыйров, класстан артыңа тибеп чыгарганны көтмә, бар, үзең чыгып кит. Әниеңә әйт, бүген үк өйне бушатыгыз, торырга мин күчәм анда. Ул директор өе...

Мин, портфелемне алып, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, ишеккә юнәлдем. Миләүшә миңа иярде.

— Хәйриева, син кая барасың?

— Өйгә кайтам.

— Нәрсә булды сиңа?

— Башым авырта.

— Син әниеңнең мәктәптә эшләмәвен телисеңмени?

— Эшлим дигән кешегә колхозда да эш бетмәгән. Сабир абый булмагач, эшләде ни ул мәктәптә, эшләмәде ни...

— Бу сүзләрең өчен үкенергә туры килмәсен сиңа, кызый! — дип чәрелдәде Бичура, җене чыгып.

Миләүшә аңа җавап кайтармады.

— Сез нигә сабакта түгел? — диде әни, без кайтып кергәч.— Нәрсә булды сиңа, улым, кем белән сугыштың?

Минем өчен Миләүшә җавап бирде.

— Аны корткыч улы дип малайлар кыйнады, Мәликә апа.

— Ярабби, бар икән күрәселәребез!..— Әни, мине кочагына алып, елый-елый бит-кулларымны сыйпый башлады.

— Әни, кирәкми,— дидем мин үзем дә елап; җибәрүдән көчкә тыелып.— Торыр җир эзләргә кирәк безгә. Эти урынында хәзер

Һаҗәр апа. Ул, бу өйдән бүген үк чыгып китегез, анда мин күчәм, диде. Миңа мәктәпкә бүтән аяк атламаска кушты.

Әни югалып калды.

— Кыш авызыннан кая барыйк без, балам? Кая?..

— Безгә күчегез,— диде Миләүшә.

— Сезгә?.. Анаң нәрсә әйтер бит...

— Ул шатланып риза булыр, мин аны хәзер алып керәм.— Миләүшә йөгереп үзләренә чыгып китте. Озак та үтмәде, әнисен ияртеп безгә ул яңадан керде.

— Кызым дөрес әйткән, күчегез безгә, бүтән җирдән фатир эзләп азапланмагыз. Монда килеп рәхәт күрмәячәк Һаҗәр дәҗҗал. Бу нигезнең гүпче бәхете җук аның. Муены астына килсен монда какча шүрәле токымының, чәнчелсен аяклы тәре, бөтен теләгем шул минем аңа...

Без шул көнне үк җыенып Миләүшәләргә күчтек. Иртәгесен әни районга этине эзләп китте. Миләүшә мәктәптә, Зада апа кайдадыр бiләмдә иде. Мин чит өйдә ялгызым нишләргә белмәдем. Кагаеп бүлмәдә утырасым да, урамга чыгып нишләргә аптырап буталып йөрисем дә килмәде. Бәеш үзе дә, аның кешеләре дә миңа инде чит, ят төсле иде. Бераздан үз-үземә урын таба алмыйча Чуал буена, үзебезнең балык каптыра торган җиргә төштем. Әле ноябрь башы гына булса да, көн ярыйсы ук салкын, җилле иде. Бишмәт якамны күтәреп, яр читенә утырдым. Күз алдымда гел әти торды. Миннән малайлар кичә фашист ясаган кебек, ниндидер үчлекле кешеләр этидән дә халык дошманы ясарга телиләр. Тик бу барып чыкмас, әти чын коммунист, хаклык өстен чыгар, гаделлек җиңәр, дип уйладым мин. Шулай моңаеп утырганда, яныма Зиннәт абый килеп чыкты.

— Нихәл, Ирек, нигә син монда җил йотып утырасың? Яле тор, селкенгәлә, юкса тәмам күгәргәнсең, салкын тидерүең ихтимал, ярамый болай, ярамый, селкен, хәрәкәтлән әйдә!

Үзе этине кулга алуда катнашты, хәзер хәлем белән кызыксына, селкенгәләргә, хәрәкәтләнергә куша, көлә булыр.

— Кара, минем белән сөйләшергә дә теләмисең, ахры, син. Алай ярамый, энем. Мин сиңа да, этиеңә дә дошман түгел. Сабир абыйның начар кеше түгеллегенә иманым камил минем.

— Нигә этине алырга килгән кешеләргә әйтмәдегез, миңа әйтәсез аны?

— Их, энем, кечкенә кеше шул мин, бик кечкенә. Шулай да әйтеп карадым, «Син белмисең аны, тыгылма»,— диделәр.

Зиннәт абыйның сүзләреннән мин аның эти өчен борчылуын тойдым.

— Һаҗәр сине мәктәптән куды, диделәр миңа. Хакы юк аның моны эшләргә. Ул башбаштаклык турында мин райкомга җиткерәчәкмен, син мәктәптән читтә калырга тиеш түгел. Монда җил йотып утырганчы, ат абзарына Камали бабаң янына бар син. Иртәгә мине районга чакыралар, сөйләшермен, кайгырма юкка, барысы да җайга салынып, без дигәнчә булыр.

— Кирәкми, Зиннәт абый, сөйләшмәгез, Бичура укыткан мәктәпкә моннан соң мин үзем үк бармыйм.

— Барырсың, энем. Һаҗәрнең шәхси мәктәбе түгел, совет мәктәбе ул.

— Әни эти яныннан кайту белән, без Бәештән китәбез барыбер.

— Мәликә апа этиең янына киттемени? Казанга укмы?

— Юк, Каранга гына.

— Сабир абыйны кулга алынган төнне үк Казанга алып киттеләр аны, районда юк ул. Нигә Мәликә апа минем белән сөйләшмәде барганчы?

— Белмим.

Камали бабай янында мин кичкә кадәр булдым. Төшке ашка кайтмадым. Камали бабай, әйдә бергәләп тамак ялгап алыйк та, атларга башак болгатырбыз, өйгә кайтып йөрсәк, озак юанырбыз, дип үзе белән бергә өстәл артына утыртты. Ул, моның ярасына тоз салмыйм, дигәндер инде, этинең кулга алынуы белән дә, минем нигә дәрескә бармавым белән дә кызыксынмады. Бөтен гәбе атлар, яшь колыннар турында барды.

— Быел бездә атлар үрчеме узган җылгыдан алты башка артачак. Әле менә кичә генә Шоңкар колынлады. Колыны, синең дусың Гайфетдиннең атасы әйтмешли, кәртинкә күк. Маңгаенда җолдызы бар, алгы ике аягы, әнисенеке шикелле, оеклы. Хәзер үк күренә, үскәч ул бик җилле ат булыр, туу белән аякланды. Шуңа күрә исемне дә матурны табарга кирәк аңа. Бәлкем син булышырсың, Ирек, уйла әле, яшь баш карт баш түгел, тизрәк аңыша,— диде ул миңа сүз арасында, ирен читләре белән генә елмаеп.

— Күрергә ярыймы соң әле ул колынны? — дидем мин.

— Ник җарамасын, җарый. Анасы белән абзарның Чәтертәнгә караган башындагы җылы аранда ул. Әйдәле, таныштырыйм үзегезне...

Яңа туган колында мин искитәрдәй бер нәрсә дә күрмәдем, ул безгә хәтта игътибар да итмәде.

— Ничек, Ирек, ошыймы сиңа бәләкәч? Матур бит! Төкер өстенә. Күз тимәсен өчен аңа төсле чүпрәк кисәкләреннән тегелгән муенса кидерәсе булыр. Уйладыңмы, нинди исем бирергә бу чибәр бәләкәчкә?

— Очкын кушыйк, Камали бабай, үскәч бик җилле ат булыр дисең бит. Очсын Очкын киләчәккә чайкап яллларын...

— Безнең атларда җук әйбәт исем таптың, егет. Яшь баш яшь баш шул, тиз шәйли. Очкын... Очкын... Шәп исем, шәп, рәхмәт, улым.— Камали бабай мине үз итеп күкрәгенә кысты.

Шулчак безнең янга Миләүшә килеп басты.

— Бөтен авылны бетереп эзләдем, менә кая качкансың син.

— Качмадым мин, атлар карарга килдем.

— Әйдә кайтыйк, Мәликә апа, кайда йөри икән ул, дип борчыла.

— Әйе, кайт, улым, бүгенгә җитәр. Иртәгә тагын кил, без сине Очкын белән бергәләп көтәрбез монда. Бар, әниеңә, Камали бабай сиңа бик үк ут йотмаска, сыктап җаныңны кыйнамаска кушты, диң. Ярар, барыгыз, оланнар, хушыгыз бүгенгә...

Кайтканда мин Миләүшәдән яңа туган колынга күз тимәсен өчен төсле чүпрәк кисәкләреннән муенса тегүен үтендем. Колынның исеме Миләүшәгә дә ошады.

— Очкын — матур исем,— диде ул.— Очкын сүзен мин муенсага да чигәчәкмен.

### 3

Этине эзләп әни минем белән бергә Казанга барырга карар бирде. Хуҗалыгыбыздагы бердәнбер терлегебез Мүкләкне, әзерләнгән печәне белән бергә, колхозга тапшырдык. Утыныбызны соңгы пүләненәчә Кәшиф абый төяп китте. «Калай этәч белән Бичураның оятлары юк, ихахайлап ягарлар, әйебит. Хәрам аларга сезнең утыныгыз. Сабир абыйның көче кергән аңа. Димәк, изге утын бу. Этиеңнең өстеннән язып биреп башына җитүчеләр дә шулардыр, дип фикер йөртәм мин, әйебит. Кешегә этлек эшләү ул хайваннар өчен ләззәт кенә. Һаҗәре дә, Габбасы да бер калыптан сугылган күк, аермалары

берсенең акылы тулмас хатын, икенчесенең үз-үзен генә яратучы карун ир булуларында гына. Бер-берләрен аңладылар, уртак тел таптылар, серләре килеште, ике тишек чабата кушылып бер кием булды, эйебит. Атаңны өтермәгә яптырып, мәктәпне үз кулларына алдылар. Сизә идем, күптән кыҗрыйлар иде инде алар аңа, тәки ирештеләр теләкләренә. Син, Ирек, әтиең өчен кайгырма, ул — утта янмый, суда батмый торган гадел һәм тугры кеше. Башымны кисәргә бирәм, ул дошман түгел. Бәештә аның яхшылыгын күпсенгән кешеләр чактылар аны. Әмма Сабир абый, мин әйтте диярсең, менә озакламас, акланып чыгар, эйебит. Китмәскә иде сезгә пока Бәештән, «күтәргә иде аның кайтканын. Утыныгыз өчен Мәликә апага акча бирәсе идем, алмады. Тик мин бер агачын да югалтмам утыныгызның. Үзегез кайту белән кайда урнашсагыз, шунда соңгы пүләненә кадәр ташырмын, эйебит»,— диде миңа утынны алырга килгәч Кәшиф абый.

Бу сүзләр авылда сөйләнгәндә әти инде еракта, Казанда иде. Аның язмышын хәл иткәндә халык фикере белән кызыксынучы, белмим, табылыр микән?!



## Унбишенче бүлек

### 1

Бәештә безне инде берни дә тоткарламый. Шулай да дәррәү кубынып һаман чыгып китә алмыйбыз әле. Юл төшкәнне — Кама катканны көтәбез. Хәлемнән килсә, әнине иртәгә бүген очар идем әти янына Казанга. Булмый. Кемнең кендегеннән югары сикерә алганы бар?.. Юк. Башымны уйлар өермәсе тинтерәтә, берсеннән-берсе авыррак сораулар җәфалый, кайчан тынычлыкта калырмын, белмим. Туйдым, чын-чынлап туйдым бу билгесезлектән. Онытыласым, тынычлап йоклыйсым килә. Тизрәк китәргә иде инде Бәештән. Китсәк, бөтен күңелсезлекләр безгә иярмәс, монда төпләнеп калыр кебек. Иртәгебез бүгенебездән дә яман булмас, шәт. Болын кебек иркен өйдән соң Миләүшәләрнең аналы-кызлы икесенә генә дә кысрык куышларында яшәү дә читен. Әни ничектер, белмим, фатир төшкәннән бирле нишләсәм дә мин үземне Зада апа белән Миләүшәгә комачаулыйм төсле сизәм. Кеше өсте — ут өсте, дип безнең шикелле кая барырга аптырап фатир кергән адәмнәр әйткәндер. Әнинең дә Бәештән китәргә ашыгуы, бәлки, күбрәк шулай кысан фатирда газапланган-гадыр. Ул үзен кая куярга белми, хәзер бөтенләй элекке әни кебек түгел, үзгәрде, танырлыгы калмады.

Зада апа, без аларга күчкәч, мәктәпне җыештырырга бүтән бармады.

Хезмәт укытучыбыз Кәшиф абый да мәктәптән китеп колхозда эшли башлады.

— Тинтәк белән тапма да, бүлешмә дә, тапсаң бөтенесен аңа гына бир, үзеңә тамчы да алма, эйебит. Һаҗәре дә, Габбасы да балаларны җәберлиләр, шуңа җаным әрни, гаделсезлекне сөймим, укытудан чыгуымның сәбәбе шул,— диде ул Камали бабайга, ферма сыерларына Олачыктан печән алып кайтырга ат җигәргә төшкәч.

Әти кулга алынганнан бирле, Сөләй белән Кәримнең минем белән очрашканнары юк. Алар әтинең халык дошманы икәненә тәмам ышандылар, күрәсең. Гайфинең Басарыннан кайтканы юк. Ул әле, бәлки, әтинең кулга алынуын ишетмәгәндер дә. Ишетсә, тасыраеп килеп җитәр иде. Ул дуслыкка турылыклы. Сөләй белән Кәрим күк, җил ары иссә — ары, бире иссә — бире каерылып, өч нарат арасында да адашып йөрми.

Классташларымнан бар аралашкан кешем хәзер Миләүшә генә.

Без аның белән, ул мәктәптән кайткач, дәресләр карыйбыз, сөйләшәбез. Миңа киләчәктә укуымны барыбер дәвам итәсе бит, мәктәптән кудылар дип, дәреслекләрдән йөз чөерергә ярамый, үзлегемнән укыйм.

Кичә Ярулла абзый керде. Өйдә әни белән икәү генә идек. Ул:

— Буш башлы ахмак, күке мие эчкән этрәк әләмнәрнең кыерсытуларына төкерегез, Мәликә күрше. Сабирның сәвиткә дошманлыгына мин бөртек тә ышанмыйм. Бу сүземне теләсә кемнең күзенә карап әйтә алам. Ежуф белән Сталинның үзләренә дә. Сабирның кулга алынуы аңлашылмаучылык ул. Мин аның саф намуслы кеше икәненә дә, чын камунис булуына да, сәвит хөкүмәтенә, шулай ук халыкка турылыклыгына да, ипи белән ант итеп әйтәм, әз генә дә шикләнмим. Көнләштеләр аңардан, шуңа башын ашарга булдылар. Бу тик безнең Бәеш кешеләренең генә эше. Мәчет үчен алдылар, дим мин Сабирдан. Тик кырын эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Сабирның эше кырык елга сузылмас, тиз ачыкланыр, мин әйтте диярсез, иң күбе бер ай-ай ярымнан акланып кайтып, эшенә керешер. Моңа һич шикләнмим мин. Сезгә бу өйдә кысрык, Мәликә сеңлем, әйдәгез, безгә күчегез торырга. Хәбибәнең дә, минем дә күңелләребез киң, өебез дә иркен. Ирекне Бәдри малае Гайфетдин янына, Басарга укырга җибәрербез, урысча өйрәнер. Курыкмагыз миннән, ялгыз хуҗалык дигәч тә, Ярулла кешелеген югалтып, битенә ыштыр каплаган залим бәндә түгел. Сезне үзебезгә ихлас күңелдән чакырам. Сабирга булган ышанычым, аңа хөрмәтем хакына,— диде.

Әни аңа безнең Бәештән шушы көннәрдә китәсебезне белдерде һәм этинең гаепсезлегенә ышанганы, хәлебезгә кергәне өчен чын күңелдән рәхмәт әйтте.

— Ай-ай ярым көтегез, кубынмагыз Бәештән, барып йөрмәгез Казанга. Сабирны монда гына көтегез,— дип үгетләде Ярулла абзый.

Әмма әнинең үз бише биш булды.

— Казанга бармый ярамый. Бәештә мин инде иремнән башка бер көн дә кала алмыйм, Ярулла абый.

— Казанга үзең генә барып кайт. Ирекне бездә калдырып тор.

— Аны үземнән калдыра алмыйм, ул миңа юлда иптәш булыр.

Ниһаять, Кама катты. Без юлга кузгалыр көн килде.

Бәештә соңгы кичемне мин Миләүшә белән үткәрдем. Башта без Түбән очны әйләндек, аннары ашыкмый гына Югары очка мендек. Һава тын, салкын, күк аяз иде. Югары очтан тау буена үтеп, Хәйрүш абзый чишмәсенең җырын тыңладык, аның янындагы шәрә тирәкләрнең, йокымсыраган төсле, тын гына оеп утыруларына сокландык. Аннан соң авыл башына кайтып Чүлмәк тауга күтәрелдек. Анда инде чана, чаңгы шуып мәш килгән бала-чагалар юк, өйләренә таралганнар иде.

Бөтен кич буена берни турында да сөйләшмәдек. Минем онытылып елыйсым килә иде, хәлемне аңлапмыдыр, беренче сүз каткан кеше оттыра дип җәдәч аергандагы кебек, Миләүшә тел ачмады. Уйларым ул кичне дә гел әти тирәсендә буталдылар. Нинди гаеп яктылар икән аңа, хәзер нишли икән, мәктәп турында, әни белән минем турымда уйлый микән? Һәм башкалар, һәм башкалар...

Чүлмәк таудан без төнге авылны күзәттек. Кызылъярга, Каршы тауга озак карап тордык. Күк йөзен исәпсез-хисапсыз йолдызлар чуарлаган иде, мин Җидегәнгә карадым. Әнә минем йолдызым. Аның янәшәсендә үк Кәрим, Сөләй һәм Гайфи йолдызлары. Кайларга гына барсам да, кайларда гына йөрсәм дә, Җидегән миңа гомерем буена балачак дусларымны, ат саклаган җәйге сихри төннәрне, Камали бабайны, Бәешне искә төшерәчәк. Дусларым да, еллар үткәч, мине искә алырлар микән? Бәлки, алар Җидегәннең безгә уртак икәнен онытканнардыр да инде?

Миләүшәнең җиңемнән тартуы уйларымны бүлде.

— Ирек, әйдә без күктә үз йолдызларыбызны билгелик. Аерылгач, шуларга карап, бер-беребезне искә төшерербез, ә?

Мин Җидегән чүмеченнән күзләремне аермыйча:

— Күктә минем йолдызым бар инде, Миләүшә. Әнә ул, күрәсеңме Җидегән чүмеченең сабы белән тоташкан почмагын? Шул почмак йолдыз минеке,— дидем.

— Синең йолдызың астындагысы минеке алайса, яме, Ирек. Онытмассың бит?

— Юк, Миләүшә, Кәрим йолдызы ул, синеке була алмый.

— Кәрим йолдызы? Кайсының иясе юк соң аларның?

— Җидегән чүмечендәгеләр барысы да ияле.

— Ә сабындагылары ияләмe?

— Алары иясез.

— Синең йолдызың өстендә Җидегән чүмече сабындагы беренче йолдыз минеке булыр алайса, яме? Сине искә төшергәндә мин шул йолдызга карармын. Син дә Җидегәнне күргәндә дусларың белән бергә мине дә күз алдыңа китерерсең. Бәештән киткәч, айга бер тапкыр гына булса да хат яз миңа. Язарсың бит, Ирек?

Их, берәүдә әнкәй кайгысы, берәүдә җәнкәй кайгысы, дип юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең, дигән уй узды башымнан.

— Күз күрер,— дидем, теләр-теләмәс кенә.

Бу минутта миндә хатлар алышу кайгысы юк иде. Иртәдән башлап тормышымда яңа сәхифә, шомлы карурман сыман, билгесез сәхифә ачылачак иде бит, башымны алда нәрсәләр көтүе, киләчәктә юлдашларым шатлыклармы, борчылулармы булачагы турындагы уйлар биләгән иде. Әңгәмәбез ачның ничек тә хет бәләкәй генә булса да ипи сыныгы юнәтүне кайгыртканда, тукның ваемсыз төстә тузганак шарына өреп кечкенә парашютлар очыру турында хыяллануына охшады безнең. Аны Миләүшә сиздеме, сизмәдеме — белмим.

## 2

Иртәгесен, таңнан торып, атлар дворына төштем.

— Бүген иртәләгәнсең, улым. Очкының җокыда бит әле,— дип каршылады мине Камали бабай.— Әтиең кайттымы әллә?

— Кайтмады. Мин синең белән саубуллашырга төштем, Камали бабай. Без бүген әни белән Бәештән китәбез.

Картның сыңар күзе киң ачылды.

— Китәсез? Кая китәсез?

— Әтине эзләп Казанга барабыз.

Карт тирән көрсенде.

— Бала җангыз җөрми, үз артыннан ишләрен дә ияртә. Шулай... Тормыш, бакый, адәмгә бер алдын, биш артын күрсәтә, һич аңламассың аны. Сүз уңаенда әйтәм боларны, авырга алма, улым. Синең җәштән четерекле тормышның буталчык табышмакларына җавап эзләргә тотыну иртәрәк, әмма башка чара җук, күрәсең. Күрәсене күрми гүргә кереп булмый, дигән борынгылар. Киңәшем, улым, сиңа шул: баш бирмә хәсрәт-сагышларга, тез чүкмә алар алдында, үзеңә хыянәт итмә тормышта, җегет бул. Нинди генә кара болыт та күк җөзен озак каплап тора алмый, кояш нурлары нинди генә калын болытны да тишәләр. Әйе. Хәзер элекке Микулай заманы түгел, җугалмассың, аллаһы теләсә. Күңелем сизә, менә күрерсең, әтиең, һичшиксез, акланыр.

Картның сүзләре күңелемне йомшартканнан-йомшарта бардылар. Мин, күзләремнән яшь ага башлаудан куркып, тизрәк китәргә булдым.

— Әни югалтыр, кайтыйм мин, Камали бабай, сау бул.
— Очкының белән дә саубуллашмыйсыңмыни?
— Уятмыйк, йокласын ул.
— Алай җарамый, улым, саубуллаш. Җоклатмыйбыз, уятабыз ул җокы чүлмәген.— Камали бабай бер кулына фонарь тотты, икенче кулын минем иңемә салды.— Әйдә.
Без Шонкар ябылган аранга юнәлдек.
Ат безне җиңелчә кешнәп каршылады. Колыны да, ул да инде аяк өстендә иде.
— Әнә, Ирек абый килер дип, җокысыннан уянып көткән ул сине. Мә, шушы ипи катысын каптыр анасына.— Карт кесәсеннән бер-ике кабарлык кына ипи сыныгы чыгарып миңа бирде.— Кер җанварына.
Мин, аранга кереп, Шонкарга кулымдагы ипи катысын бирдем дә Очкынның башыннан сыйпадым.
— Хуш, Очкын, тизрәк үс, Камали бабайны тыңла, борчыма.
Колын, әйткәнемне аңлап, баш каккандай итте.
— Булды, улым, бар, изге җул сезгә. Бәхетле бул. Очкын белән без синең тизрәк әйләнеп кайтканыңны көтәрбез.
— Рәхмәт, Камали бабай, рәхмәт яусын сиңа.
— Мине җакын итеп саубуллашырга төшкәнең өчен үзеңә рәхмәт, улым.
Двордан кайтканда Зиннәт абый очрады.
— Нихәл, Ирек, Камали бабай янында кундыңмы әллә?
— Бер килеш, Зиннәт абый. Кунмадым, иртәләтеп Камали бабай белән саубуллашырга төштем. Без әти янына китәбез бит.
— Кайчан, бүген кузгаласызмы әллә?
— Менә кайтып ашыйм да юлга чыгабыз.
— Бик ашыкмагыз, мин районга барам, Каранга кадәр утыртa китәрмен, көтегез. Берәр сәгатьтән сезгә үзем кагылырмын.
Зиннәт абыйдан аерылгач туры әни янына кайтмадым, Ярулла абзыйларга кердем. Алар ирле-хатынлы кап сугалар иде.
— Әйдә, Ирек, түргә уз, бик шапшак чагыбыз, гаепләмә,— дип каршы алды мине Хәбибә түти.
— Зарар юк, Ирек үз кеше, аның безгә беренче керүе генә түгел бит,— диде Ярулла абзый.— Әйдә өстеңне чишен, үзеңә ошаган җиргә утыр, нинди яңалыклар алып кердең, сөйлә.
— Чишенеп тә, утырып та тормыйм, рәхмәт. Мин сезгә бер генә минутка, саубуллашырга гына кердем.
— Саубуллашырга? — Хуҗалар эшләреннән туктадылар.— Кая барасың?
— Хәзер әтине эзләргә Казанга китәбез.
Хәбибә түти орыша башлады.
— Алданрак керергә ярамадымыни сиңа бу хәбәрең белән, Ирек үскәнем, юлыгызга нәрсә дә булса әзерләр идем. Без сезгә чит кешеләр түгел, орынып торган күршеләр. Ызгышмадык, талашмадык, бертуганнар кук яшәдек, ничек була инде ул сезне буш кул белән озату? Әзрәк тоткарлана алмыйсызмы соң хет?
— Юк, Хәбибә түти, ашап-эчәбез дә юлга чыгабыз.
— Һәй, аллам, кеше көлкесенә калдым бит, калдым.
— Калмадың, Хәбибә түти, безгә берни дә кирәкми.
— Һәй, нәрсә кирәген, нәрсә кирәкмәсен беләсеңмени әле син?!
— Ярар, тынычлан, карчык, берәр нәрсә уйлап чыгарырбыз,— диде моңарчы сүзгә катнашмаган Ярулла абзый.
Мин алардан чыккач туктап калдым. Тагын кая барырга? Мирсәет абыйларга керергә уңайсыз, ул олы кешене тынычсызлау булыр, бәлки Сөләй белән Кәрим алдында түбәнсенергәдер? Кирәкми, потлары бер тиен ул куян йөрәкләрнең, бармыйм яннарына.

Инде көн яктырган иде, як-ягыма күз аттым. Бөтен әйләнә-тирә ничектер бәйрәмчә төсле, авыл, юылгандай, ап-ак. Кайбер өйләрнең морҗаларыннан күксел багана булып төтен күтәрелә. Җил юк, тын. Бәлки хәзер барып, мәктәп белән саубуллашыргадыр? Юк, бармыйм, анда Бичураның очравы бар, аны мәктәп тирәсендә каңгырап йөрүем белән шатландырмыйм. Анда мин үзем генә түгел, тиздән эти белән бергә барырмын.

— Әйдә, утырып аша да юлга чыгарбыз, улым,— дип каршылады әни.

Ул, ни гаҗәптер, мин өйдә юкка борчылмаган, тыныч иде. Юлга кузгалыр алдыннан әллә кайларда биләмдә йөрисең, сине көтә-көтә көтек булдым инде, түзәрлегем калмады, дип гадәтенчә орыша башламавына гаҗәпләндем.

— Ашыкмыйк, әни, Зиннәт абый Каранга бара: «Сезне утыртып барырмын, берәр сәгатьтән кагылырмын»,— диде.

— Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына шушы инде ул. Болай булгач, юлыгыз уңа да уңа сезнең,— дип куанды сүзләремә Зада апа.

Әни бер сүз дә дәшмәде.

Мин ашап өстәл артыннан торырга өлгермәдем, култык астына ниндидер төргәк кыстырып, Ярулла абзый килеп керде. Исәнләшкәч:

— Өлгердем,— диде ул, елмаеп.— Менә сезгә кечкенә генә юл аягы. Мәликә күрше, тот әле, мә.

Әни аптырап калды.

— Нинди юл аягы, нәрсә ул? Безгә берни дә кирәкми, Ярулла абый.

Сунарчы агай җитдиләнде.

— Курыкма, күрше, урланган нәрсә бирмим, ал. Үзегез ашамасагыз, Сабир күршене сыйларсыз. Алмасагыз, мин дә, Хәбибә дә разый булмабыз. Рәнҗетмә безне...

— Нәрсә соң бу?

— Какланган каз, күрше.

— Рәхмәт, Ярулла абзый, ала алмыйм мин бүләгегезне. Без юлга чыгабыз бит, җәяүлегә янчык та авыр, дигәннәр, керегез хәлебезгә, зинһар, йөгебез болай да шактый. Тимер юлга чаклы үтәсе юлыбыз гына да йөз чакрымга якын. Үз итүегез өчен чын күңелдән рәхмәт сезгә...

Ярулла абзый:

— Аптырама, күрше, йөгегезне аркагызда биштәрдә күтәреп бармассыз, мин сезгә үземнең җиңел чанамны бирәм, аның бер авырлыгы да юк, шуңа салып тартып барырсыз. Юл түбән төшкәндә Ирек аңа утырып шуар да, бер дә аптырамагыз,— диде үҗәтләнеп.

— Уңайсыз миңа, нәрсә әйтергә дә белмим...— Әни кулына тоткан казны кая куярга белми аптырады.

— Юкка баш ватма, күрше, мин сезгә казны Сабир энекәшне канатларына утыртып алып кайтсын дип керттем. Хикмәтле каз ул, һич икеләнми алыгыз.— Сунарчы агай миңа күз кысты.— Йә, син ничек, каршы килмисеңме, Ирек?

— Рәхмәт сезгә, Ярулла абзый, Хәбибә түти белән икегезгә дә рәхмәт яусын.

— Уңган юлга чыгыгыз, моннан икәүләп барып, Казаннан өчәүләп әйләнеп кайтыгыз. Кая, мин сезгә тиз генә чанамны алып керим...

Ярулла абзый чыгып киткәч күп тә үтмәде, капка төбенә Зиннәт абый килеп туктады. Мин кабаланып аның янына чыктым.

— Әйдә, энем, әйберләрегезне алып чык,— дип каршылады ул мине.— Ничек, Мәликә апа әзерме анда?

— Әзер, хәзер чакырам.

Без — әни, мин, Зада апа һәм Миләүшә, әйберләрне күтәреп капка төбенә чыккач, Ярулла абзый да килеп җитте.

Зиннәт абый, әни белән мине җәй исе аңкып торган карасу-яшел төстәге йомшак печән белән түбәләмә тутырылган кашовкасының түренә утырткач, үзе кучер урынына кунаклады. Ярулла абзый чанасын, бавын кыска гына калдырып, кашовка артына такты.

— Изге юл сезгә, исән йөреп сау кайтыгыз!

— Яхшы теләгегез өчен мең рәхмәт, сау булыгыз! — Әни бияләйле кулы белән яшьле күзләрен сөртте. Ул безнең яңадан Бәешкә әйләнеп кайтмаячагыбызны, бәлки, шул чакта ук сизгән булгандыр, мөгаен...

Ат урыныннан ук юртып кузгалып китте. Зада апа, Миләүшә, Ярулла абзый, урам уртасына чыгып, кул болгап озатып калдылар.

Бәештән китү, аның безне туганнарча үз иткән эчкерсез кешеләре белән аерылышу минем күңелемдә бернинди сызлану да, сыкрану да уятмады. Мөгаен, бу минем күпмедер вакыттан соң анда кабат әйләнеп кайтасыбызга ышануымнан килгән булгандыр.

Казанга без, әни белән икебез дә, матур тәңкәләрен көн яктысында елкылдатып, канатларын уйнаклата-уйнаклата, алдын-артын уйламый сөкәгә барып кергән гамьсез балык кебек, башларыбызга бәла эзләп барганбыз. Анда әни республикадагы иң югары оешмаларның ишекләрен күпме генә кагып караса да, этине күрү бәхетенә ирешә алмадык. Ул гына да түгел, Казанга килеп ике атна үткәч, әни дә кулга алынды. Бу минем өчен аяз көн кинәт кенә кара төнгә әверелеп, бөтен нәрсәне караңгылык чорнаган шикелле, котмагәндә булды. Чит шәһәрдә, ят һәм бөтенләй таныш түгел кешеләр арасында, ялгызым бер тиен акчасыз нишләргә, кая барырга аптырап калгач мине, Черек күл буендагы Татарстан эчке эшләр халык комиссариатының пропусклар бүлеге алдындагы коридорда әнинең кереп киткән ишегеннән әйләнеп чыгуын көтеп өч төн кунгач, халык дошманнарының балалары өчен оештырылган махсус колониягә озаттылар. Төш идеме бу, өнме — берни дә аңламадым. Акылдан шашканмын, башкача тормышымны болай асты өскә килгән итеп күрмәс идем, дип еш кына үз-үземне тынычландырырга тырыштым. Ләкин моның чынбарлык, хакыйкать икәненә миңа озакламый ышанырга туры килде. Тормышның Камали бабай әйткән буталчык табышмаклары белән йөзгә-йөз очраштым... Кыскасы, үзе дә гомеренең ике дистәгә якын иң гүзәл елларын нахакка кимсетелеп чәнечкеле тимерчыбык киртәләре артында тоткынлыкта үткәргән шагыйрь сүзләрен әзрәк үзгәртеп, үземә яраштырып әйтсәм: бирде тормыш кирәкне, авыр чакта тез чүкмәскә, сыкрамаска өйрәтте.

*Беренче кисәк тәмам.*

1967 ел.

Усть-Качка — Казан.

## Сәйдә Зыятдинова

# ХӨКЕМ

хикәя



Хәтирәне алып керүгә, залдагы халык берьюлы гөжләп куйды. Ачулы, усал гөжләү иде бу.

— Җир бит! Үз баласын ерткыч та үтерми!

— Азгын! Башта өстерәләләр дә, аннары...

Кыз, башын аска игән хәлдә, гаепләнүчеләр эскәмиясенә барып утырды. Бөтен гәүдәсе калтырана, болай да уттай янган битләре тагын да ныграк кызыша иде.

— Басыгыз, суд килә!— дигән тавышка Хәтирәнең башы чак кына күтәрелеп куйды. Шул мәлне алгы рәттә утыручылар аның озын керфекләрен, кап-кара күзләрен күреп калдылар.

Суд эшкә кереште.

— Гаепләнүче, судка үзегезнең исемегезне, фамилиягезне, туган елыгызны әйтегез.

Хәтирәнең пышылдап кына чыккан гаепле тавышы залга таралды.

Судья дәвам итте:

— Гражданка Шәймәрданова, сез үз балагызны үтерүдә гаепләнәсез. Гаебегезне таныйсызмы?

Хәтирә эндәшмәде...

— Алайса мин судны медицина экспертизасы нәтиҗәсе белән таныштырам: шушы елның 29 мартында гражданка Шәймәрданова «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән больницага китерелә. Ул әле яңа гына баладан котылган була...

Хәтирәнең башы тагын да аскарак иелде. Монда яңгыраган һәр сүз аның тормышына, хисләренә барып кагыла, әмма ул аларның мәгънәсенә төшенеп җитә алмый, төшенеп җитү турында уйламый да. Аның хәләте, язмышы — кинокадрда күрсәтелә торган вакыйгалар сыман...

Авылдан чыгып киткән чагы. Сигезенчене тәмамлагач, әнисе белән ике арада мәнә мондый сөйләшү булган иде:

— Укуың бетте. Инде нишләргә уйлыйсың?

— Унны бетерәм,— диде Хәтирә, әнисе кебек үк кыска гына итеп. Аннары, сезгә борчуым тимәс дигәндәй, кабаланып өстәде: — Интернатта торырмын.

— Һе,— диде әнисе. Әлеге «һе» дигәне әллә ризалык, әллә каршылык билгесе иде.

---

Сәйдә ЗЫЯТДИНОВА (1941)— *«Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкта чыккан «Җыелмаган җиләк» дигән шигырьләр циклы авторы. Шигырьләр һәм чәчмә әсәрләр яза. Казанда яши.*

— Аннары нишлисең?

«Кызык та инде бу әни,— дип уйлап алды кыз.— Аннары нәрсә буласын каян беләсең?!» Уендагысын телдән кабатлады:

— Белмим.

— Алайса мин беләм!— диде әнисе, бу хакта озак сөйләшеп торырга исәбе юклыгына ишарәләп.— Апаң янына Чаллыга барырсың. Анда буяучы булырга өйрәтә торган урын бар икән.

— Техник училищегамы?

— Тихниктырмы, михниктырмы — анысы миңа билгеле түгел. Ул мәктәпне бетергәч, буяучы булып чыгалар икән. Буяучы кеше акчаны әйбәт төшерә. Апаң шулай ди.

Күңеле тартмаса да, Хәтирә шунда китте. Тулай торакка урнашты. Укыды. Аннары төзелештә эшли башлады. Бәйрәмнәрдә авылга кайтты.

Хәтирәнең колагын ярып, тагын судьяның сүзләре яңгырады.

— Егет судка килмәде,— дип белдерде ул.— Гаепләнүче Хәтирә Шәймәрданова турында белгәннәрен язмача тапшырды.

Бу хәбәр халыкның кызыксынуын тагын да көчәйтеп җибәрде, залдагылар янә бер гөжләп алдылар да авызларына су капкандай булдылар. Әле үзе дә балалыктан чыгып җитмәгән шушы япь-яшь кыз кемнән алданган? Нинди кеше икән ул? Һәркемнең шушы хакта тизрәк беләсе килде. Хәтирә өчен исә егет ... язмышының иң текә борылмасы иде...

...Ул көнне Хәтирә иптәш кызы Илүсәне автовокзалга озата төшкән иде. Аның бәйрәмгә кайтуына бераз кызыгып та калды. Илүсәләрнең җайлы шул: автобуска бер утыргач, өйләренә хәтле рәхәтләнеп кайтып җитә. Хәтирәгә андый бәхет тәтеми — автобустан төшкәч тә аның әле тәпи-тәпи янә ун чакрым атлыйсы бар. Машина очраса ярый ла... Хәер, авылга кайткач та кеше шикелле ял итеп булмый. Кайткан саен өйдә — тавыш, гауга. Әтисе белән әнисе, нидер бүлешә алмый. Сыңар кулын сугышта калдырып кайткан әтисе, кызып киткән чакта, исән кулына ни эләксә, шуның белән әнисенә тондыра. Андый вакытта бала-чага кайсы кая чыгып шыла. Балалар белән чыгып киткән әнисе йә көмешкә, йә аракы табып кайта. Төн аларның икесен килештерә. Бу хәл инде ничә тапкыр, ничә еллар — Хәтирә үз-үзен белә башлаганнан бирле шулай кабатлана...

Ул чакта Хәтирә бәйрәмгә кайтмаска булды. Кайтасы килмәде аның. Йөрәге урыныннан кузгалды, каядыр җилкенде: әллә нәрсә булды аңа. Автовокзал бакчасындагы чәчәк һәм куакларны, беренче тапкыр күргәндәй, озаклап карап торды. Үзе дә аңлап җиткерми торган шул гаҗәп бер халәткә чумып торганда, аңа кемдер дәште:

— Сез кая җыендыгыз, чибәркәй?

Ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй сискәнеп, кинәт борылды Хәтирә. Каршысында озын буйлы, какча яңаклы, зәңгәр күзле бер егет басып тора иде. Өстендә куе коңгырт төстәге пальто, яшькелт чалбар. Егетнең тавышы аңа кемнедер хәтерләтә иде. Әйе-әйе, ялгышмый, күңеленә бик якын кешенең тавышына — Габделхак абыйсы тавышына охшаган! Хәрби хезмәте тулгач та авылга кайтмады бит ул — кайдадыр еракта калды бугай. Элек... Хәтирә аның тавышын койма артына кача-кача тыңлый торган иде. Койма аша карап озатып кала иде. Ә бервакыт Габделхак абыйсы белән машинада янәшә утырып, район үзәгеннән бергә кайттылар. «Кич белән клубка чык»,— дип күз кысты аңа Габделхак. Хәтирә исә комачтай кызарган иде ул чакта...

Таныш түгел егет җавап көтә иде.

— Беркая да җыенмыйм, дус кызымны озаттым,— дип сүзне кыска тотты.

— Дус кызың ерак киттеме?— дип кызыксынды егет.

— Авылларына, кунакка.

— Сине алып кайтмадымыни?

— Мин үзем кайтмадым.— Инде соравың беттеме, дигәндәй, егеткә карап алды да кайту ягына борылды. Егет аннан каласы итмәде.

— Мин менә абыйны озаттым,— диде ул, Хәтирә белән янәшә атлап.— Авылда бераз җилләнеп килсен әле. Ә мине өй сакларга калдырды.

— Өегезне күтәреп китәрләр дип курыктымыни?

— Юк ла. Безнең үз йортыбыз. Мин армиягә киткәнче салган идек. Армиядән кайтканда, әнә, шәһәр безнең янга килеп җиткән. Үз йортлы кешене беләсез инде, каз-үрдәк дигәндәй...

— Алай икән,— дип җөпләде Хәтирә.— Йә, сау булыгыз. Минем трамвай килде...

— Безнең трамвай...— диде егет, «безнең» сүзенә басым ясап.

Хатип Хәтирәне беренче тапкыр әнә шулай озата кайткан иде.

Хәзер менә аларның уртак төне, уртак сере — халык хөкемендә. Судья өчен — документ, залдагы халык өчен... «Танышканнан соң без еш очраша башладык. Кинога йөрдек. Яңа елны каршыларга аны үзебезгә чакырдым... Мин аны көчләмәдем. Өйләнәм дип тә вәгъдә бирмәдем...»

— Йа раббем!— Хәтирәнең йөрәк әчесе белән чыккан тавышы тып-тын утырган халыкны сискәндереп җибәрде. Бу тавышта аны пычраклыкка батырган дөньяга рәнҗеш бар иде. Әйе, яратты. Ярату һәм яратылу гаеп эшмени?! Татлы, җылы сүзләрен яратты, игътибарлы булуын яратты! Габделхак абыйсын хәтерләтеп торган тавышын яратты, иркәләвеннән исерде...

— Әти усал иде безнең,— дип сөйләде Хатип.— Әни вафат булгач та ике тапкыр өйләнде.

— Әниең күптән үлдеме соң?

— Күптән,— дип авыр сулады егет.— Әни үлгәч, үз көнебезне үзебез күрә башладык...

Кызганган иде, яратып һәм ачынып кызганган иде Хатипны Хәтирә, аңа берьюлы хатын да, әни дә була алыр кебек хис иткән иде үзен.

Судья Хатипның язуын укып та бетермәгән иде әле, залдагылар арасыннан бер ир түзмәде, кычкырып җибәрде:

— Кабахәт! Җиләк кебек кызны шулай итеп калдыр да... Майть якасын! Үзен хөкемгә тартырга аның!..

Судья аны катгый бүлдерде:

— Бүген без гражданка Шәймәрданованың җинаятен карыйбыз, иптәшләр...

Аның бу сүзләре халыкның ачуын кабартты. Хатын-кызлар төрле яктан кычкыра башладылар:

— Ул бит үзе ир кеше! Шуңа күрә ирләрне яклый!

— Ул әтрәк-әләм дә бүген монда булырга тиеш!

Залдагылар тынычлана төшкәч, судья дәвам итте:

— Гаепләнүче Хәтирә Шәймәрданова адвокат яллаудан баш тартты. Судка гаепләнүченең әтисе белән әнисе дә килмәде. Шаһит булып монда аның бертуган апасы катнаша.

Залга тулы гына гәүдәле, тәбәнәк буйлы, урта яшьләрдәге хатынны керттеләр. Суд тәртибендә барлык формаль сорауларга җавап алынгач, судья җинаятькә кагылышлы сораулар бирә башлады:

— Гаепләнүче Хәтирә Шәймәрданова турында сез ниләр беләсез?

Үз гомерендә беренче тапкыр суд ишеген ачып кергән бу хатын

башта каушап калды, тотлыгып җавап кайтарды:
— Әй... барсын да беләм. Ул минем сеңлем бит.
— Сеңлегезнең бала көткәнен сез кайчан белдегез?
Хатын, бер мәл Хәтирәгә карап торгач, башын аска иеп кенә әйтте:
— Сизелә башлагач белдем инде...
— Әлегрәк сеңлегез сезгә берни әйтмәдеме?
— Юк.
— Әйтегез әле,— дип сүз башлады судья яңадан.— Бу хәлгә әтиәниегез ничек карады. Гаиләгездә сөйләшү булдымы?
Ничегрәк итеп аңлатырга, дигәндәй, шаһит тагын сеңлесенә карап алды.
— Әни моннан бер ай элек кенә белде,— диде ул, җавабын өстәл артында утыручылар гына ишетелерлек итеп.— Курыктык. Гәүдәсе тулылана башлагач, Хәтирә авылга кайтмады. Аннары, табар вакыты җиткәндәрәк, әни килде... Күрде...
— Бәлки, әниегез берәр киңәш биргәндер?
Хатын аптырап калды:
— Нинди киңәш?
— Баладан котылу юллары турында.
— Юк. Нишләп андый киңәш бирсен әни? Ул аңа мондый хурлыктан соң өйгә кайтып күзенә күренмәскә, туган йорт бусагасыннан аяк атлап кермәскә генә кушты.
— Ә әтиегез?
— Әти? Ул әни сүзеннән узмый... Айнык чакта...
— Бала туганда сез кайда идегез?
— Хәтирә кичтән безгә килеп кунды. Ирем иртүк эшкә китте. Мин төнге сменага барасы идем. Иртә белән Хәтирәнең борчылып йөрүен тоеп уянып киттем. Сораштым. Аннары, киендем дә, скорый чакырырга чыгып киттем.
— Гаепләнүче Хәтирә Шаймәрданованың утын сараена кергәнен сез күрмәдегезме?
— Юк.

...Үзенең йөкле булуын белгәч, кинәт куркып калды Хәтирә. Врачка барыргамы? Аның беркайчан да моңарчы гинеколог янына барганы юк. Кияүгә чыкмаган килеш анда ничек барырга? Сүгәрләр, мыскыл итәрләр... «Тукта әле,— дип уйлап алды ул шул чакта.— Хатип белән киңәшим, аның янына барыйм. Өйләнешербез... Ул Хатипны ярата, Хатип — аны. Кайчан да булса барыбер гаилә корып бергә яшәячәкләр ич инде!..»
Хәтирәнең күңеле күтәрелеп китте, баш очына җыелган кара болытлар кинәт таралгандай булды. Әнә шулай уйлап, чәй кайнатып йөргән Хәтирә янына ул чакта Хатип үзе килеп керде.
— Вәт бит, ә! Минем ашыйсы килгәнне каян белеп тордың?— дип шаяра-шаяра, Хәтирәне кочагына алды.— Мин сине алмага килдем. Абый бүген төнге сменада! Җиңги дә авылларына китте. Әнисе янына. Алар үпкәләшеп йөри әле.
«Үпкәләшеп...» Әлеге сүз Хәтирәне сискәндерде. Бу арада ул үзе дә әллә нишләде әле: юктан гына хәтере кала, юкка гына үпкәли. Җанына урын таба алмый гаҗизләнә. «Ничек кенә аңлатырга, ничек кенә белдерергә соң?» Уйларын әйтә башлаганчы, күзләрен тутырып, егеткә карады.
— Хатип,— диде ул, күзләрен читкә төбәп.— Әгәр балабыз булса, син нәрсә әйтер идең?
Кинәт куелган бу сорау егетне сагайтып җибәрде.
— Нигә алай дисең? Әллә уздың?..
Хәтирә баш какты.

Егет бермәл тын алалмый торды. Изүләрен чишеп җибәрде. Аннан соң көчәнеп кенә елмайгандай итте. Бу ясалмалылыкны Хәтирә сизде. Алай да күңел түрендәге өмете моның белән килешергә теләмәде. Өмет һаман үзенчә пышылдады: «Ул бит мине ярата. Бәлки аның сөенүе шулай чагыладыр?..»

Берничә көннән Хатип үзе сүз башлады:

— Хәтирә, минем бераз акчам бар,— диде ул.

«Туйга»,— дигән уй йөгереп үтте кызның башыннан.

— Акча? Нинди акча?— дип сораган булды Хәтирә.

— Акча инде. Эшләп тапкан акча. Берәр гинеколог белән сөйләшсәң, дим.

Көтмәгән иде Хәтирә мондый сүзне. Көтмәгән иде. Хәзер менә өстенә кинәт бозлы су койдылармыни... Бер мәл телсез калды. Сүзләре тамак төбенә утырды. Башына килгән беренче уе тышка ук бәреп чыкты:

— Мин тудырам аны!

Аннары бар көчен җыеп, басынкы, әмма таләпчән тавыш белән сорау бирде:

— Гаилә корырга исәбең булмагач, нишләп миңа кагылдың соң? Нишләп мине бу хәлгә җиткердең?

Туры сорауга туры җавап бирү кирәк иде. Хатип та турысын әйтте:

— Менә сиңа вәт! Мине генә гаепләргә ашыкма инде син! Миңа, мәсәлән, хатын-кыз кирәк иде. Бу — табигый күренеш. Бары шул...

Тормышның бар матурлыгы, ямьсез бетте Хәтирә өчен. Берүзе шәһәр урамнары буйлап йөри-йөри дә, тулай торакка кайтып, мендәренә капланып елый.

Бу сөйләшүдән соң алар тагын берничә тапкыр очраштылар. Тулай торакка Хатип үзе килде. Тагын врачка бару турында сүз кузгатты.

Үз-үзен кая куярга белмичә, хыянәтнең ачы газабыннан интегеп йөргән көннәрнең берсендә, Хәтирә яши торган бүлмәнең ишеген шакыдылар. Хәтирә: «Тагын Хатип микән?»— дип уйларга өлгермәде, ишектән Габделхак килеп керде.

— Безнең Хәтирә монда торамы?— Көтелмәгән очрашудан Хәтирә бөтенләй югалып калды.— Сине эзләп, Чаллыны аркылыга-буйга иңләдем, малай. Барыбер таптым,— диде Габделхак көр тавышы белән бүлмәне тутырып.

— Габделхак абый?! Утырыгыз, Габделхак абый...

Габделхак утырырга ашыкмады, бермәл Хәтирәгә карап торды да, үзенең уңайсыз хәлгә калганын тоеп сорады:

— Син кияүдәмени?..

Хәтирә, ни дип җавап бирергә дә белмичә, әйтте:

— Аерылыштык.

— Шушы хәлеңдәме?

— Әйе...

— Тормышта була торган хәл, килешерсез,— диде Габделхак, Хәтирәне юаткандай итеп.

Саубуллашкан чакта Габделхак Хәтирәнең иңнәрен ике куллап тотты да:

— Ә мин сине һаман оныта алмыйм...— дип әйтеп чыгып китте.

Судьяның соравы, кайтаваз шикелле, Хәтирәнең колакларына килеп бәрелде:

— «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җиткәндә гаепләнүче кайда иде?

Апасы инде бераз тынычлана төшкән, сөйләшүе салмакланган, фикерен төгәлрәк әйтергә тырыша.

— «Скорый»ны мин урамга чыгып көтеп тордым. Мин чыгып киткәндә ул өйдә калган иде. Өйгә врачлардан соң кердем. Керсәм, врачлар аптырашып тора. Авыру кая, диләр. Йөгереп барып ванна ишеген ачып карыйм. Хәтирә анда да юк. Кухняга керәм, анда да юк. Йөгереп ишегалдына чыктык. Кычкырабыз, эзлибез...

«Эзлибез...». Әйе, баласын утын сараенда утынлыкта тапты Хәтирә. Аның кычкырган, әллә нинди ят тавыш белән өзлексез иңрәгән авазы Хәтирәнең котын алды, һушсыз аңына курку салды. Ишегалдында үзен эзләп йөгерешкән кешеләрнең тавышын ишеткәч, нишләргә белмәде, үз-үзен белештермичә, баланың илерү авазын тыярга теләп, аның өстенә иске бишмәт каплады...

Врачлар соңыннан әйттеләр: бала тыны томаланудан үлгән, диделәр.

Хәтирәне залдан алып чыгып киттеләр. Суд хезмәткәрләре таралышты. Тып-тын калган халык шул мәлдә телгә килде:

— Кыз баланың башын ирләр ашый инде...

— Кыз баланы әнисе тәрбияләргә тиеш. Ә ул!.. Тулай торакка озаткан да тынычланган. Акча кирәк булган!

— И-и, эчкән ир белән гомер итүләре... Әтисе бик эчә икән бит.

— Әтисе генәме соң! Хатын-кыз үзе аракы капкач, булмый инде ул!..

Халык урамга чыккач та таралышырга ашыкмады, төркем-төркем булып, һаман шушы хакта сөйләште, үзенчә хөкем йөртте. Әмма унсигез яшьлек Хәтирәнең үз-үзен ничек хөкем итәсен, иртәгесен ялгыз камерадан аның үле гәүдәсен алып чыгачакларын бүген әле беркем дә белми, хәтта күзалдына да китерә алмый иде...

# ХИСЛӘРГӘ ТИРӘНЛЕК БИР, КАЛӘМ!

Борчулы, гаугалы заманда яшибез. Тормышыбызның кай ягына күз салма, тотрыксызлык хөкем сөрә. Яшәвебезнең мәгънәсе, яме кимеп бара. Үсмерләребез урам тутырып сугышалар, эчкечелек, җинаятьчелек кимеми, гаиләләр таркала. Егет-кызларыбыз, алдын-артын уйламыйча, яше җитмәс, никахлашмас борын җенси мөнәсәбәткә керәләр, ятимнәр, гарип-горабалар ишәя. Борчылабыз, төннәр йокламыйча уйланабыз, моның сәбәпләрен эзлибез. Эзләнә торгач, төп сәбәпләрнең берсен, ниһаять, таптык бугай. Ата-бабадан калган гореф-гадәтләрне, гасырлар буена чарлана килгән һәм адәм баласын мәгълүм бер кысада тоткан әхлак кагыйдәләрен инде бик күптәннән бирле санга сукмый башлаганбыз икән ләбаса.

Әйе, бездән элгәреге буыннарның канына сеңгән, тормыш законы дип кабул ителгән күркәм гадәтләрдән тайпылу зур күңелсезлекләргә, хәтта үз кулың белән үз гомереңне чикләү кебек гайре табигый булган җинаятьләргә кадәр алып бара. Безнең халыкта моны мордар китү (имансыз үлеп китү) дигәннәр һәм ул иң зур гөнаһлардан саналган. Сәйдә Зыятдинованың «Хөкем» исемле хикәясе әнә шундый фаҗигага бер мисал рәвешендә язылган.

Унсигез яше тулар-тулмас Хәтирә очраклы бер егеттән балага уза. Егет исә аңа өйләнүдән баш тарта. Шуның аркасында кыз, оятын күтәрә алмыйча, яңа туган баласын белер-белмәс хәлдә томалап үтерә. Моның өчен аны хөкем итәләр. Хөкем чыгарылганнан соң Хәтирә төрмә камерасында үз-үзен дә һәлак итә.

Гыйбрәтле хәл, уйландыра, әлбәттә. Димәк, әсәр куелган бурычын күпмедер дәрәҗәдә үтәгән һәм ул үзенең укучысын да табар дип уйларга кирәк. Тик бер нәрсә сагайта. Әхлак киртәләрен сикерүне, җилдән бала табуны чүпкә дә санамый

башлаган замана яшьләре: «Тапкан икән фаҗига, шуның өчен үз-үзеңне үтереп торырга соң!»— дип борын җыерып кына карамаслармы? Ә бит хикәядә моңа урын бар.

Никахсыз бала табуны үзе өчен түзә алмастай хурлык, оят дип саный икән, Хәтирәне без табигате белән гадәттән тыш хисле, нечкә күңелле бала итеп, шул нигездә аның мәхәббәт турындагы хыяллары да үтә саф, самими дип фараз кылырга тиеш булабыздыр. Ләкин безнең бу фаразлар хикәядә фараз килеш кенә кала. Әсәрдәге вакыйгалардан кызның чын тойгыларын, без фараз кылган табигатенә ярашлы кичерешләрен күрмибез. Алар сүлпән һәм сүрән. Сурәтләнгән дәрәҗәдәге генә кичерешләр кызны әсәрнең финалындагы хәлгә китереп җиткерер идеме икән?

Фаҗигагә сәбәпче булган икенче кеше — Хатип. Кем ул, аның чын йөзе нинди? Мәхәббәткә карата фәлсәфәсе ничегрәк? Әсәр өчен монысы да вак нәрсә түгел. Хәер, хикәядә бу беркадәр чагылыш таба. «Менә сиңа вәт! Миңе генә гаепләргә ашыкма инде син! Миңа, мәсәлән, хатын-кыз кирәк иде. Бу — табигый күренеш. Бары шул...»— ди Хатип кызга. Әнә бит нинди ваемсыз, куркыныч фәлсәфә. Иләһи хыяллар белән ана булырга җыенган кыз баланың якты өметләрен егет челпәрәмә китерә һәм моның өчен әллә ни үкенү, сызлану галәмәтләрен дә күрсәтми. Югыйсә, әле кайчан гына өлкәннәрнең: «Кыз баланың яше төшмәсен!»— дигән кисәтүләре, үгет-нәсихәтләре яшьләребез күңеленә барып ирешә, аларны саксыз адымнардан коткарып килә иде. Хатип исә бу төшенчәләрдән бөтенләй азат.

Кеше язмышы белән уйнауны бернигә куймый торган каты бәгырьле бу егеттә хатын-кызга карата әлегедәй мыскыллы мөнәсәбәт ничек туган? Боларны Хатип тормышындагы гыйбрәтле вакыйгалар аша күрсәтергә булыр иде. Әмма хикәяче моңа игътибар итеп җиткермәгән, Хатип турында сөйләгәннәре, китергән дәлилләре егет характерының үсеш динамикасын шәйләргә ирек бирми.

Егет судка да килми, «Мин аны көчләмәдем. Өйләнәм дип вәгъдә бирмәдем...»— дигән эчтәлекле хат кына җибәрә. Ул рәсми суд хөкеменә тартылмый. Ләкин язучы иркендә вөҗдан, намус хөкеме, сәнгать хөкеме бар бит. Хатип анысыннан да читтә кала, аны гаепләп залдан ташланган бер-ике реплика гына гөнаһысына тәңгәл җәза була алмыйдыр.

Хикәянең суд залыннан репортаж рәвешендә язылуын да уңышлы алым дип әйтеп булмый. Репортаж хәрәкәтне ярата, анда вакыйгалар тиз алышынучан. Ул сүлпәнлекне күтәрми. Судьяга да, гаепләнүчегә дә, шаһитларга да сүз бирәсе бар. Шуның өстенә тагын зал да битараф түгел, анда-санда репликалар ташлана. Автор һәркайсына игътибар бирергә мәҗбүр. Шуңа күрә чикләнгән бер вакытта гына чигенешләр ясап, бишкә бүленгән хәлдә, төп геройларының эчке, рухи дөньяларына үтеп керү мөмкинлеге тарайган.

Сәйдә Зыятдинованың хисләргә, тойгыларга баерак, тәэсирлерәк әсәрләрен дә беләм мин. Бу хикәясендә исә журналистика алымнары өстенлек итә. Бер жанр алымнары белән икенче жанрда тулы канлы образлар, чын мәгънәсендә җитлеккән әсәрләр иҗат итү мөмкин түгелдер. Элек язылган әсәрләрендә сәләтен, талантын күрсәтеп караган автор әлеге киңәшләргә колак салыр дип уйлыйм.

**Габдулла ШӘРӘФИ.**

# ПУБЛИЦИСТИКА

# БЕЗ БИК ОЗАК КӨТТЕК

**Көттек. Дистәләрчә еллар көттек. Кылган гамәлләребезнең барысы да Ленин сызган олы юлдан бара, алда безне фәкать җиңүләр, иң гадел җәмгыятьтә генә була торган хөр, мул тормыш көтә, дип ихластан ышанып яшәдек. Шулай түгел икән, ил ихтыяҗын иңгә алып, утлы сугышларга керер идекме?! Таңнан алып төнгәчә басу-кырларда тузан эчәр идекме?! Атналар-айлар буе завод капкасыннан чыкмыйча тимер чүкер идекме?! Күкләргә күтәрелү кирәкме, җир астына яки суларга төшүме — санашып тормадык, хакы азлыкка да, эшләү әмәлләренең камил түгеллегенә дә түздек һәм тырыштык. Илдә муллык артсын, гадел, рәхәт тормышлы җәмгыятькә тизрәк ирешик! Теләк-ниятләр зурдан иде. Олы максатка барып җитүнең җиңел булмавы күпләргә мәгълүм. Шуңа да сабыр иттек, сабыр гына көттек. Әнә шулай Татарстан автономияле социалистик республика рәвешендә яши башлавыбызга тиздән 70 ел тула.**

**Инде җиңәбез, инде коммунизмга аяк басабыз, дигәндә генә... ялгышларны сизеп алдык. Дөресрәге, КПСС Үзәк Комитеты үзе ап-ачык итеп белдерде: без, социалистик революция ясаганбыз да, беренче адымнарыбыздан соң ук шактый кыек юлдан кереп киткәнбез ләбаса! Кичекмәстән барын да үзгәртергә, ил күләмендә кыю борылыш ясарга кирәк! Шул рәвешчә партия яңа революцион үзгәртеп корулар игълан итте.**

**Бу яңа көрәш дәверенә керүебезгә дә инде биш елдан артык вакыт үтте. Азмы бу, күпме? Тарихи үзгәрешләр өчен биш ел — азрак шул, дияр идең, безнең гомерләр моңарчы да күп акты бит инде. Болгария, ГДР, Чехословакия, Румыния кебек күрше илләрдә хәтта атна-ун көн эчендә тамырдан үзгәреш ясалды. Биш ел — бик күп вакыт арасы ул, дип раслар идең, үзгәртеп коруларыбызның нәтиҗәсе әле һаман да ярлы...**

**Үзгәртеп кору һәм демократия чагылышы буларак, илебездә төрледән-төрле рәсми булмаган («формаль булмаган» дип тә йөртәләр) оешмалар төзелде. Татарстанда да бар алар. Без шундый оешма вәкилләренең берсен — Татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Марат МӨЛЕКОВНЫ әңгәмәгә чакырдык.**

С о р а у. Марат әфәнде, бездә хәзер рәсми булмаган берничә оешма эшли: «Туган як», «Болгар-әл-җәдид», Ш. Мәрҗани исемендәге җәмгыять һәм башкалар. Татар иҗтимагый үзәге исә бөтен ил буенча таралган татарларны канат астына алуы, үзенең киң колачлылыгы, максатлары һәм җәмәгатьчелектә тиз арада абруй казануы ягыннан аерылып тора. Әйтсәгез иде: «Үзәк» ни сәбәптән һәм нинди шартларда барлыкка килде?

Җ а в а п. Татар иҗтимагый үзәгенең беренче оештыру утырышы 1988 елның октябрендә Казанда узды. Илдә үзгәртеп корулар игълан ителгәннән соң инде дүрт ел вакыт үткән иде. Партия әйткән революцион борылыш бездә әллә ни сизелмәде, күп хәрәкәтләр, башланып җитмәс борын, сүлпәнләнә барды. Өлгергән мәсьәләләрне хәл итү хәтта элеккегә караганда да кыенлаша башлады. Бу нәрсә дигән сүз? Бу — үзгәртеп коруга аяк чалучылар барлыкка килде дигән сүз иде. Андыйлар аеруча рәсми урыннарда, җитәкчеләр арасында, хәтта — ни гаҗәп! — партия оешмаларының кайбер җитәкчеләре арасында да калкып-калкып чыкты. Сәер бит: партия үзе башлаган эшкә аның үзенең үк кайбер хезмәткәрләре каршы төшә. Мондый гайре табигый хәлгә ничек инде тыныч кына карыйсың? Халыкның тәмам өметсезлеккә бирелүе ихтимал иде. Инде бу мөмкинлектән дә вакытында файдаланып калмасак, илнең гаять катлаулы, төзәтеп булмастай фаҗига алдында торып калуы бар. Мин моны тарихчы күзлегеннән карап та раслый алам. Шул хакыйкатьне аңламаган җитәкчеләр бик нык оттыралар. Моңа Азәрбайҗан, Грузия, Үзбәкстан, Балтик буенда булган, берсеннән-берсе катлаулырак вакыйгалар да шаһит.

Рәсми булмаган оешмалар исә, КПССка ярдәм итү йөзеннән, нәкъ менә партия

башлаган революцион үзгәртеп коруларны тизләтү һәм ныгыту максатыннан барлыкка килде. Күп кенә республикаларда «Халык фронтлары» оешты. Литвада — «Саюдис», Үзбәкстанда — «Берлек», Украинада — «Рух» һ. б. Бу — язын бөдрә таллар төбеннән тибеп чыккан саф сулы чишмәләр кебек, бик табигый хәл иде.

Сорау. Шулай да ул берләшмәләрнең төрлесе төрле юнәлешләрдә эшли. Сез оештырган Татар иҗтимагый үзәгенең нииндирәк шартларда барлыкка килүе турында күбрәк сөйләсәгез иде! Кемнәргә таянасыз? Максатларыгыз нинди?

Җавап. Бүгенге көн күзлегеннән бер генә сорауга җавап эзләп карыйк: Ленин җитәкчелегендә җиңеп чыккан социалистик революция татар халкына ни бирергә тиеш иде? Ниебез бар иде безнең, нәрсәгә мохтаҗ идек? Без, әллә ни тирәнгә төшеп тормастан, еллар буе бу сорауларга яңгыравыклы сүзләр белән җавап кайтара килдек: «Кеше болай иркен сулый торган башка илләр әле җирдә юк», «Син яшәсәң, безгә рәхәт. Мәңге яшә, Сталин!»— дидек.

Чынлабрак карасаң, «җир йөзендәге иң бәхетле халык», «алга киткән социалистик ил» тәмам мөшкел хәлгә төшкән икән бит. Экономиканы әйткән дә юк. Ифрат нык оттырганбыз. Индустрия гигантлары да, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү дә безне рәхәт, мул тормыш белән тәэмин итә алмады. Әйтергә дә оят кебек: бүген безне Япония кебек кечкенә генә капиталистик илнең экономистлары ничек яшәргә кирәклеген өйрәтә. «Сез бит бөек держава,— диләр,— Сез бик бай яши аласыз, тик...» Әйе, әйе, өйрәтәләр, гафу үтенә-үтенә өйрәтәләр, әле бер хатабызны, әле икенчесен күрсәтәләр. Расдыйлар. Каршы сүз әйтерлек урын калдырмыйлар. Фәнни фикер йөрткәндә, бездән дә, аерым алганда, Татарстаннан да бай яшәүче җөмһүрият дөньясында булмаска тиеш кебек. Ни генә җитештермибез?! Уңдырышлы җирләр, су, урман, нефть, газ, электр энергиясе, киң колачлы машина төзелеше... 1988 елгы милли керем — 9 млрд. тан артык иде, шуның 7 млрды республикада файдаланылган. 2 млрд.— саф табыш. Литва, мәсәлән, елга 7 млрд. ны үзе ала, 6 млрд. ны чыгара. Чагыштырып карагыз!

Фән, әдәбият-сәнгать, культура яки спорт өлкәсендә дә сер бирмибез. Исемнәре бөтен дөньяга мәгълүм академикларыбыз (Р. Сәгъдиев, К. Вәлиев һ. б.) биючеләребез (И. Мөхәммәдов, Р. Нуриев) бар. 161 татар — Советлар Союзы Герое. Әле бүгенге шартларда да 17 яшьлек студентка Алисә Галләмовабыз, дөньяны шаккатырып, шахматта халыкара гроссмейстер дәрәҗәсенә ирешкән, Гата исемле малаебыз 13 яшендә үк шахматчылар җәмәгатьчелеген хәйран калдырган икән, бу — безнең халык сирәк очрый торган талантлар бирүен дәвам итә диген сүз.

Шул халык, шул республика үзе исә вак кына мәсьәләләрне дә мөстәкыйль төстә чишә алмый, Мәскәүгә барырга, үзенә кирәкне бил бөгеп, үтенеп сорарга мәҗбүр. Ихтыярсыздан Тукай сүзләре искә төшә: «...Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?!» Милли культура, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге югалтулар чик-чамадан ашты. Октябрь революциясенә кадәр илдә татарча 59 газета, 37 журнал чыккан. Хәзер Татарстан күләмендә нибары 4 газета, 7 журнал чыга. Халык үз тарихыннан аерылды. Тарихын оныткан халыкның исә киләчәге дә юк.

1913 елгы белешмәләргә караганда, патша Россиясендәге бары биш халык кына — рус, латыш, татар, эстон, әрмәннәр генә китап басуга әһәмият биргән. Басмаларның саны буенча татарлар өченче урында торса, һәр басмага тираж туплауда ул беренчелекне тоткан. Бүген исә без мондый җиңү белән һич тә мактана алмыйбыз. Миллионлаган татарлар яши торган төбәкләрдә дә (әйтик, Башкортстанда) бер генә татар китабы да басылмый. Йөз меңнәрчә татар яшәгән шәһәрләрдә дә халык үз телендә эшләүче театрлардан мәхрүм ителгән. Алфавитыбызның ике тапкыр үзгәртелүе дә халыкның үз культура байлыгыннан бик нык читләшүенә китерде.

Тарихыннан, теленнән, культурасыннан аерылган кешеләребезнең кайберләре хәтта үзенең татар милләтеннән икәнлеген яшерә башлады. Югыйсә, татар теле — йөзгә кызыллык китерә торган телләрдән түгел. «Юнеско» мәгълүматларына караганда, татар теле дөньяда иң күп таралган 14 телнең берсеннән санала. Тормыштагы кулланылышы тарайтылганлыктан гына аның абруе төште кебек. Талантлы егет-кызлар, максатларына ирешер өчен, русча гына сөйләшергә, фәнни хезмәтләрне русча язарга, чыгыш-докладларын русча ясар-а мәҗбүрләр. Хәтта ата-баба биргән исемнәрен үзгәртүчеләр, милләтен алмаштыручылар очрый башлады. Әле дә илнең һәр тарафында бик тә җаваплы бурычларын намус белән башкаручы татарлар арасында исем-фамилиясен русчага әйләндергәннәр җитәрлек. Соңгы мәгълүматларга караганда, СССРдагы 6 млн. 654 мең татарның 1 млн 130 меңгә якыны ана телен үз теле дип танымый. Кыскасы, күркәм гадәтләребез онытылып, ата — улны, ана кызны белмәс хәлләргә җиттек. Балаларыбыз, өер-өер булып, берсе өстенә икенчесе ташлана, нәтиҗәсе — сугышу, кырылышу, тормаләргә ябылу...

Гайре табигый хәлме бу? Әлбәттә. Чыдап торырлыкмы? Һич юк. Татар иҗтимагый үзәге урындагы җитәкчеләрнең нә шушы гайре табигый хәлләргә күз йомарга

маташуын тоюдан, киләчәгебезне кайгыртырга теләүдән дә туды шикелле.

Безнең хәрәкәт, чыннан да, гаҗәеп тиз таралды. Оештыру комитетына унбер кеше кергән иде. Атна-ун көн эчендә йөзләрчә, меңнәрчә милләттәшләрнең хуплавын сиздек. Татарстан районнарында гына түгел, Себер, Урта Азия, Пермь, Пенза, Чиләбе, Куйбышев, Саратов, Свердловск, Якутия — кыскасы, татар яши торган һәр төбәктә теләктәшлек төркемнәре оешты. Рига, Мәскәү, Таллинн кебек шәһәрләрдә аларны рәсмиләштереп, теркәп тә өлгерделәр. Өч-дүрт ай дигәндә, без Оештыру съезды үткәрерлек, һәрьяклап җитлеккән, үзенең ныклы максаты, киләчәккә сызып куйган ап-ачык юлы булган берләшмә идек инде. Бәхеткә, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, СССР фәннәр академиясенең Казан филиалы җитәкчеләре безгә теләктәшлек күрсәттеләр. Һәр атнаның дүшәмбесендә әле университетның берәр аудиториясенә, әле филиал бүлмәләренең берсенә җыела торган булып киттек. Җыелабыз, хәл ителәсе мәсьәләләрне билгелибез. Андыйлар исә арта гына тора. Аерым бүлекләр, секцияләр төзергә булдык. Алар хәзер унсигезәү: тел, әдәбият, фән дөньясы, автономиябез хәле, мәгариф, милли демографиянең бозылуын тикшерү, күрше өлкәдәге татарлар хәле, чит илләрдәге милләттәшләр белән элемтә булдыру...

Сорау. Мәсьәләләр бик җитди, этрафлы сөйләшүне сорый. Шунлыктан Татар иҗтимагый үзәген борчыган кайбер сорауларга тулырак аңлатма бирү кирәк кебек. Әйтик, демография мәсьәләсе...

Җавап. Әйе, бу очракта милли демография мәсьәләсенә тукталу бик урынлы. Бу — безнең халыкның иң авырткан җире. Билгеле булганча, Ленин фәрманы белән төзелгән Татарстан автономиясендә татар халкының, чама белән әйтсәк, чиреге генә яши. Төрле сәбәпләр аркасында таралган да таралган ул... Борыннан ук киң мәйданнарга таралып утырган. Ачлык елларында, афәттән качып котылырга теләп, Иделеннән еракракка китәргә мәҗбүр булган (1921 ел), Сталин репрессияләренә буйсынып та, сугыш юллары белән дә, мәҗбүри «вербовкалар» буенча да туган җирен калдырырга дучар ителгән. Халык бу хактагы уйларын җырга салып әйткән әнә: «...телеграм баганасын чакрым саен кем куйган, китәсем килеп китмим лә, туган җирдән кем туйган?!»...

Сорау. Аңлашыла. Мәҗбүри аерылулар хәтта бармак белән генә санарлык әдипләребез язмышына да кагылган. Гаяз Исхакый кебек бөтенләй чит илгә үк китеп баручыларны әйтмим әле мин. Чагыштырмача яшь буынга да кагылган ул. Шагыйрәбез Флера Гыйззәтуллина үзенең «Шахтер атлар» шигырен ничек язуы турында сөйләргә ярата.

— Безне эшелоннарга төяделәр,— дип башлап алып китә ул.— Бер вагонда — атлар, икенчесендә — без, уналты-унҗиде яшьлек татар кызлары. Кайберәүләребез — торф чыгарырга, башкаларыбыз күмер шахталарына бара. Атлар да шахтага икән. Минем кебек. Аларны җир астына мәңгелеккә төшерәләр. Анда алар сукырая икән. Без сукыраймыйбыз, чыдыйбыз, без бит — кызлар, татар кызлары. Чыдамый чараң юк:

*...Ил кырында канлы сугыш бара, ир-егетләр яуда егылып кала.*
*Җиде катлы кара җир астында, бинихая караңгыга карап,*
*Вагон тартып шахтер атлар бара.*
*Кем йөгәнли, җигә ул атларны? Алларына печәнен кем сала?*
*Күмерләрен төйи, атын куа — ил хакына, туган җир хакына —*
*Татарстан кызы, и бала!..*
*Мин дә сабыр идем, сабыр иттем. Йөзләремә кунган күмер оны,*
*Кулларымда — маңгаемның дымы, икмәк төйнәп йөрткән киҗеле киндер.*
*Малкаемның күзе — мөлдер-мөлдер...*

Флераның бу шигыре хәтерегездәдер әле?

Җавап. Шигырьнең соңгы юллары гыйбрәтле. Монда татар халкына аеруча хас сыйфат — сабырлык оста бирелгән. Тарихның буеннан-буена безнең милләт сабырлыгы һәм фидакярлеге белән аерылып тора. Хәтта нәкъ менә шул сыйфатлар аны халык һәм милләт буларак саклап та калгандыр әле. Моңа кадәр шулкадәр мул җирдә яшәп тә, хезмәттә шулкадәр зур күрсәткечләргә ирешеп тә үзе өчен әллә ни ялый алмаган икән, инде, шул ирешкәннәребезгә таянып, матди һәм рухи яктан кискен борылыш ясарга тиешбез.

Республикабыз зур төзелешләр мәйданына әйләндерелде, нефть манаралары белән чуарланды. Нефть химиясе заводлары, КамАЗ, Түбән Кама... Аларга әллә кайлардан, бригада-бригада оешып та, аерым-аерым да эшчеләр китерелде. Күбесе башка милләт халыклары иде: руслар, украиннар, әрмәннәр, белоруслар. Татарстанда аның үз хуҗаларына урын тарайганнан-тарая барды. Хәзер ТАССРдагы бөтен халыкның нибары 47,6%-ын гына татарлар тәшкил итә. Без шушы демографик чатаклыкны төзәтергә телибез. Әле дә безгә эшче көчләр кирәк. Капкаларыбызны каерып ачып, баш-

ка яклардан эшкә килүләрен көтәбез. Алар арасында кайчандыр Татарстаннан китәргә мәҗбүр ителгәннәр булса, милләтебез ныгый төшәчәк. Татар иҗтимагый үзәге Татарстан хөкүмәтеннән, мондыйлар өчен, аерым җиңелләкләр сорый. Безгә: «Туган җиргә кайтыр идек, чәч белән җир себереп, хезмәт итәр идек, кайтып баш төртер урын гына булсын иде!» — дип, мөрәҗәгать итүчеләр бар. Үзбәкстан, Казахстан, Азәрбайҗан, Әрмәнстандагы күңелсез хәлләрдән соң андый үтенечләр бигрәк тә ешайды. Күңелендә туган җиргә мәхәббәт чаткысы сакланганнарга нигә ярдәм итмәскә?! Алар бит — ил ихтыяҗын үргә алып, әллә кайларга китәргә мәҗбүр ителгән җаннар. Мондый үтенечләрне санга сукмаска берәүнең дә хакы юк.

Икенчедән, республиканың демографиясен бераз төзәткәләүдә безнең башка мөмкинлегебез юк һәм булмаячак та. Милләт яшәү белән үлем арасында басып тора, чөнки балалар ата-баба телен аңламый башлады.

Сорау. Татар теленең киләчәге һәм автономияле республиканың статусын союздаш республика статусына тигезләштерү — Татар иҗтимагый үзәгенең максатлары арасында төп урынны алып тора. Язма документларыгызга караганда, мәсьәлә шулай куела. Тик ул документлар төрлесе төрле вакытта, төрле газета-журналларда («Агитатор сүзе», 1989 ел, № 3; «Социалистик Татарстан», сентябрь, 1989 ел.) басылды. Укучыларның кайбере аңлап та өлгермәде шикелле.

Җавап. Әйе. Без беренче көннәребездән үк Татарстанга союздаш республика хокуклары таләп итеп чыктык. Татар теленә исә үз республикабызда дәүләт теле статусы бирелергә тиеш дип саныйбыз: бу хәл башка телләрне рәнҗетмәячәк, ә бәлки милли культурабызны сакларга хезмәт итәчәк. Татар иҗтимагый үзәгенең иң беренчел максатларыннан саналган бу таләпләр, безнең карашыбызча, бик кирәкле, нигезле һәм халыклар мәнфәгатенә хезмәт итәргә алынган ленинчыл партия максатларына тамчы да каршы килми.

Шуңа игътибар итик: кайбер союздаш республикалар ил казнасына, Татарстан белән чагыштырганда, байлыкны азрак кертә, ә мөмкинлекләрдән киңрәк файдалана. Безнең бер нефтебез генә дә, житештерелә башлавыннан санаганда, илгә ике йөз илле миллиард доллар табыш бирде. Вакытында Татарстан нефте илдәге валюта байлыгының уннан сигез өлешен тәэмин итә иде. Шуның урынына ни алдык? Ул районнарда чишмәләр корыды, басулар мазутка батты, һава бетте. Кибет киштәләре саекты.

Хикмәт нәрсәдә соң? Сәбәбе ачык. Бер нефть промышленносте генә дә түгел, гомумән, безнең иң зур байлык чыганагы булырдай предприятиеләребез Татарстанга бөтенләй буйсынмый. Андыйларның 98%лабы турыдан-туры РСФСР яки СССРга карый. Алар тудырган байлыктан кергән өлеш Татарстан бюджетының нибары 3 %ын тәшкил итә. Союздаш республикаларда исә эш башкача тора. Моннан да зур гаделсезлекнең булуы мөмкинме?! Безнең халык тир түксен, башкалар ул житештергән байлыктан рәхәт чиксен, ә?! Татарстанга союздашлык статусы сорау әнә шуңа да нигезләнгән.

Бәхеткә, иң беренче без авыз ачып сөрән салган шушы таләпкә хәзер СССР Верховный Советы депутатлары да кушылды. Алардан автономияләр белән махсус шөгыльләнүче төркем оешты. Житәкчесе — шагыйрь Д. Кугелтдинов. Бу хәл Татар иҗтимагый үзәге тоткан юлның дөреслеген раслый. Фикерләрнең шундый ук таңгаллеге татар телен Татарстан өчен дәүләт теле итеп танырга кирәклеген сораганда да, ТатАЭС төзүне туктатуны даулаганда да килеп чыкты. Милләтара мәсьәләләргә кагылышлы эшчәнлегебез дә КПСС ҮКның милли мөнәсәбәтләргә карата уздырган пленумы Платформасында күтәрелгәнчә алып барыла. Тик без бу мәсьәләләрне күпкә алдарак күтәргән идек.

Сорау. Теләкләрнең болай уртак юлга килеп чыгуы бик әйбәт. Сез, бу хакта кат-кат тәкърарлап, ни әйтергә телисез? Партиягә алмаш булырга яки аның белән рәттән көрәшүче икенче төр партия булдыру турында хыялланмыйсыздыр бит? Гомумән, күппартиялелек кирәк, дигән фикерләргә ничек карыйсыз?

Җавап. Минемчә, Татарстанда оешкан, рәсми булмаган берләшмәләрнең берсе дә үз алларына КПСС эшчәнлегенә хилафлык китерүне алга куймый. Без бары **революцион** үзгәртеп коруларны, милләтебезгә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүне тизләтергә тырышабыз. Татар иҗтимагый үзәгенең эшчәнлеген партиягә каршы куеп сөйләшү, гомумән, мантыйкка сыймый. Идарәбездәге 21 кешенең 18е — КПСС членнары, съездыбызга килгән 600 делегатның 258е коммунистлар иде. Идарәдәге иң актив кешеләрнең берсе саналган Рафаэль Хәкимов хәзер КПССның өлкә комитетында эшли. Шундый шартларда без ничек итеп КПСС максатларыннан үзгә юлны алга сөрик?! Михаил Сергеевич Горбачев тоткан юлга ышанып карыйбыз без. Аның һәр чыгышын ныклап өйрәнәбез. Әмма безнең үзгәртеп кору адымнарын тизләтәсебез килә. Халык та шуны тели. Шуңа күрә безнең кайбер чыгышларыбыз кискенрәк яңгырый.

Шуны аңламыйча, гомумән, эшчәнлегебезнең ниятен анык белмичә, безгә төрле яманат тагарга маташучылар табылып кына тора. Каты-каты тәнкыйть сүзләре матбу-

гатка да үтеп керә. Съездыбызның бик матур, бердәм хуплау белән узуын да авыр кабул итүчеләр булды. Журналистка Сидорованың «Советская Татария» газетасында чыккан мәкаләләре, мәсәлән, Татар иҗтимагый үзәге омтылышларын нык кына бозып күрсәтә.

КПСС райкомнарының кайбер хезмәткәрләре, съездыбыздан соң, безнең эшкә турыдан-туры аяк чала башлады. Аларга хәтта шундый күрсәтмә бирүчеләр дә булган. Безне милләтчелектә, экстремизмда гаепләргә маташтылар. Кайбер авыл районнарына теләктәшлек төркемнәре оештырырга барган иптәшләрне куып-куып кайтардылар: «Бездә һичнинди милли мәсьәлә юк! Китегез, вәсвәсә таратып йөрмәгез!»— дигәннәр. Чаллыда чыга торган русча бер газета хәтта: «Татар иҗтимагый үзәге элеккечә яшәргә, күпхатынлы гаиләләр булдырырга өнди» — дигән ялган хәбәр дә басып чыгарды. Татар теленең киелышы белән кызыксынган иптәшләребезне мәктәпләргә кертмәделәр.

Мондый мөнәсәбәт безнең эшне нык кына тоткарлады, сүлпәнләнеп калдык. Оешманың озак кына рәсми рәвештә теркәлә алмый торуы да күңелләрне боектырды. Безне узган елның июнь аенда гына теркәделәр. Съезд материалларын, Платформа, Устав һәм Мөрәҗәгать кебек документларыбызны бастырып тарату коточкыч каршылыкка очрады. Ахыр чиктә Балтыйк буе республикаларының ярдәменә мохтаҗ булып калдык. Рәхмәт, алар булыштылар.

Хәзер акрын-акрын бары да үз эзенә төшеп бара. Хатын-кызлар белән эшләү комиссиясе ай саен «Иман» мәҗмугасе чыгара башлады. «Ташкын» исемле газетабыз да әзлекле рәвештә басыла. Дөрес, кыенлыкларның беткәне юк. Газетабызның тиражы кечкенә. Күрше өлкәләргә җибәрергә җитми. Арттырыр идең, матди мөмкинлекләребез чамалы, бастыру җайланмалары юк, кәгазь табуы читен, акча да җитенкерәми. Без бит бары милләттәшләрнең ихтыярый рәвештә, дәүләт банкындагы 700629 нчы безнең счетка күчерә торган акчасы белән генә эшләрне җәелдерә алабыз. Аннары, кайбер артистлар безнең файдага концертлар бирә, мәчетләр ярдәм итә. Мөмкинлек арткан саен, чыгымнар да ишәя бара. Газетаны русча, чувашча, марича да чыгарырга иде. Кушымта төсендә генә булса да.

Татар иҗтимагый үзәге — күпмилләтле оешма. Сан ягыннан да ишәя барабыз. Хәзер безнең сафларда, кара исәп белән генә дә, миллионлап кеше санала. Төрле милли секцияләребез бар. Руслар белән кулга-кул тотынышып эшлибез. Чуваш, яһүд, кырым татары секцияләре дә активлашып бара.

Сорау. Эшләрегез шактый җайга салынган икән инде. Бүгенге көндә нинди мәсьәләләрне хәл итәсез?

Җавап. Бу авыр юлда барын да җайга салып бетерү мөмкин түгел. Чөнки кайсы гына мәсьәләгә кагылма, үзенә ияртеп ул, мең дә бер яңа проблема китереп чыгара. Хәзер күрше өлкәләрдәге милләттәшләрдән үтенечләр килә: татар теленә өйрәтүче кадрлар, методик кулланмалар сорыйлар. Бу — матди чыгымнарга бәйле эш. Татарстан республикасы бөтен ил буенча таралган татарлар ихтыяҗын үз бюджетыннан гына канәгатьләндерә алмый. Бик аяныч: без хәтта Татарстанда яңа ачылган татар класслары өчен дә кирәкле укытучылар һәм кулланмаларны бирә алмас хәлгә җиткәнбез. Казан булып Казанның үзендә нибары бер татар интернат-мәктәбе калган иде бит. Иң борынгы татар авылларындагы мәктәпләрдә дә укытуны русчага күчерә башлаганнар иде инде. Шуңа күрә татарча дәреслекләр бастырып чыгару да һаман саен киметелә барды.

Инде менә шул аянычлы хәлләрне кичекмәстән төзәтергә кирәк. Татар иҗтимагый үзәгенең яшьләр белән эшләү секциясе, күрше өлкәләргә җибәрү өчен, татарча дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары җыя. Татарстандагы укыту эшләренә ярдәм йөзеннән, Казанның 13 мәктәбенә үрнәк кабинет ясап бирдек. Тик болар гына һич тә канәгатьләнерлек адымнар түгел. Татарча укыту өчен мәктәпләр, урта һәм югары уку йортларында тулы мөмкинлек булырга тиеш. Шуңа да мәсьәлә зурдан куелырга, Татарстанга союздаш республика статусы бирелергә тиеш, дибез без. Имзалар җыябыз. Теләкләребез язма рәвештә СССР Верховный Советына, М. С. Горбачевның үзенә дә җиткерелде.

Әмма монда бик хикмәтле бер нәрсә бар: бу мәсьәлә иң әүвәл Татарстан дәүләтенең үзендә хәл ителергә, Татарстан Верховный Советы тарафыннан расланырга тиеш. Татарстан — социалистик суверен республика итеп игълан ителгәннән соң, аңа союздаш республика статусы сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Раслау-расламау Мәскәү карамагында. Безнең исә хәзергә бу адымны ясарга җыенган җитәкчеләребез күренми. Көтик: ТАССР Верховный Советы, на әле яңа гына сайланган депутатларның бу мәсьәләдә тәвәккәллеге нинди булыр?! Без исә имза җыюны дәвам иттерәбез. 300 000ләп имза тупланды инде. Без депутатлардан кыюлык көтәбез.

Сорау. Рәсми булмаган оешмаларның кайберләрендә акылга сыймастайрак хәлләр дә булгалый. Әйтик, бер милләт кешесен икенчесенә каршы кую, берәүләр өчен генә аерым җиңеллекләр таләп итү...

Җ а в а п. Мин сезнең тел төбен аңладым. Җитди мәсьәлә бу. Тик әлегә кадәр без күтәреп чыккан бер генә мәсьәләдә дә кемгәдер зыян сала торган юнәлеш булмады. Чөнки без мәсьәләне һәрьяктан өйрәнеп, фәнни яктан нигезләгәч кенә яктыга чыгарабыз. Татар иҗтимагый үзәгендә башкарылган эшләребез җиз иләк аша үткәрелә. Идарәдән яки секцияләрдән берәү анда-монда командировкага барса, ниләр эшләячәге күмәк хәл ителә, кайту белән чираттагы утырыш аның исәп-хисабын тыңлый. Сәфәрдә ниләр башкарылуы энәсеннән-җебенә кадәр бәян ителә. Утырышларыбызга исә теләге булган һәркем керә ала.

Секцияләр эшендә дә шундый ук тәртип. Идарә җитәкчелегенә дә ялгышларга, абыну-сөртенүләргә юл куймаслык итеп оештырылды. Барына да бер генә рәис җавап бирсә, аның барын да күреп бетерә алмавы бик ихтимал бит. Шуңа күрә безнең идарәдә җиде кеше рәис итеп билгеләнде. Без алмаш-тилмәш, ике ай буена җитәкчелек итәбез. Шул вакыт арасында ул кеше Иҗтимагый үзәк эшенең төп җаваплылыгын үз өстенә ала. Мондый ысул эштәге берьяклылыкка урын калдырмый.

Аннары, мин сезнең бу сорауның төбендә яман бер шикләнү дә тоеп торам. Телгә алырга атамасыннан чиркандыгыз, бугай. Кайберәүләр, рәсми булмаган оешмаларның эшчәнлеген тизрәк томалап кую өчен, аларга ленинчыл партия идеяләренә чит булган милләтчелек тамгасы ябыштыралар. Моңа сәбәп итеп алар оешма вәкилләренең туган җир, туган халык, тел, тарих өчен кайгыртучанлык күрсәтүләрен алалар. Узган ел азагында яңа ачылган «Идел» журналында эшләүче, татарча белми торган берничә хезмәткәр редакция җитәкчелегенә шундый тамга ябыштырырга омтылып карады. Ни өчен? Бары тик журналның төп нөсхәсе татарча чыгарылган өчен генә бит!

Татар халкында: «Олы сүз сөйләгәнче, олы телем ипи аша!» — дигән мәкаль бар. Кемнедер милләтчелектә гаепләгәнче, иң элек ул ярлыкның ни аңлатканын өйрәнсеннәр иде! Милләтчелек, гади генә иттереп әйткәндә, бары бер генә милләт вәкилен өстен кую, аны башкаларга каршы котырту, милләтләр арасында дошманлык тудырырга омтылу ул. Татар иҗтимагый үзәгенең ишекләре теләсә кайсы милләт кешесенә ачык. Һәр милли секция эшенә безнең тарафтан тигез кайгыртучанлык күрсәтелә. Әле менә әлек Казанда чыгып та, алтмышынчы елларда ябылган чувашча газетаны кабаттан бастыра башлау артыннан йөрибез. Кырым татарлары секциясе исә нахакка җәберләнгән бу халык язмышына җиңеллек китерү чараларын кайгырта. Казандагы христиан диненә ышанучыларның үтенече буенча, Петропавел чиркәвен элекке үз ияләренә кайтарып бирүгә ирештек. Күрәсез, мисаллар башка төрле сөйли.

Совет законнарына, Конституциябезгә туры килмәстәй бер генә акция дә үткәрмибез без. Митингларыбызның һәммәсе, алдан килешенеп, закон нигезендә оештырыла. Анда һәркем үзе белгән телдә чыгыш ясый. Хәтта кызык хәлләргә калгалаганыбыз да бар. Кайберәүләр, безгә бәйләнер өчен, әллә нинди сәбәпләр уйлап таба. Әүвәл кисәтәләр, өркетәләр, яныйлар, зурдан кубып, язмаларыбызны, эшләребезне тикшерергә тотыналар. Ахырдан үзләренә оялырга туры килә — юк икән бит хаталар, һичнинди яманлык та кылмыйбыз, илгә дә, партиягә дә ярдәм генә итәбез икән ләбаса!

Безнең оештыру съездының гомумхалык бәйрәменә әйләнүе һәр яңага шикләнеп-куркып караучы функционерларны аеруча куркытып калдырган иде. Аңа күрше өлкәләрдән дә күп делегатлар килде. Барысы да укымышлы, тәрбияле. Трибунага чыга да, ике-өч минут эчендә, халыкның үзәгенә үткән мәсьәләне яра да сала. Укытучылар, галимнәр, юристлар, инженерлар... Һәммәсенең әйтере, зары бүгеннән хәл ителергә тиешле мәсьәләгә килеп тоташкан. Тыңлаучылар да һәр чыгышны күтәреп кенә алдылар. Кул чабалар, «Афәрин!» — дип, хуплыйлар. Кайчан, кайсы җыелышта шундый аңлашу, җыелганнар күңеленең шундый уртаклыгы күзәтелгәне бар иде?! Юк, булганы юк иде андый җыелышларның. Шуңа күрә дә безгә кырын карый башладылар, әллә нинди тамгалар ябыштырмакчы булдылар.

С о р а у. Дөрес, делегатлар арасында да, Идарәгездә дә, секцияләрдә дә укымышлылар күп сезнең. Съездда академик Мирза Мәхмүтовның катнашуы, Мәскәү академигы Камил Вәлиевтән телеграмма килүе, президиумда күпсанлы профессорлар арасында Мәскәү профессоры Ә. Борһановның утыруы һәм чыгыш ясавы — болар барысы да Татар иҗтимагый үзәгенең дәрәҗәсе хакында ачык сөйли. Әмма бу хакыйкатьнең икенче ягы да бар. Милләтнең эшчеләре, крестьяннары, кыскасы, гадиләре бу хәрәкәткә ничек карый икән соң? Әлегә кадәр башкарылган эшегездә аларның өлеше нинди? Сез, халык өчен, дип күтәргән мәсьәләләрне алар кирәксенәме, хуплыймы?

Җ а в а п. Милли горурлык дигән бик тә үзенчәлекле хис адәм балаларының һәммәсенә дә хас. Дөрес, «киләчәктә бөтен милләтләр бер генә милләт тирәсендә эреп юкка чыгачак» дигән, фәнни яктан тирәнтен ялгыш фикер алга сөрелгән елларда, сталинчылык һәм брежневчылык дәверендә, кешеләрдәге милли аң, милли горурлык хисе, табигый ки, бик тирәнгә яшеренде. Бигрәк тә материаль байлыкны үз күкрәк көче белән тудыручы эшче-крестьян халкы бу хакта уйламаска тырышты. Шулай ди милли аңны, милли горурлык хисен сыйныфларга бүлеп карау дөрес түгел. Инде Татар иҗ-

тимагый үзәге эшенә җиң сызганып катнашмаганнар икән, моның сәбәпләрен аңлатырга мөмкин. Әлеге дә баягы, халкыбызның сабырлыгы гадиләргә бигрәк тә нык сеңгән. Бусы — бер. Икенчедән, тормыш итү, көн күрү ысулы аңа, беренче чиратта, физик эштән аерылмау ягын кайгыртырга куша. Милли культураның, тел-әдәбиятның бүгенге хәлгә калуын аңлаган хәлдә дә, гадиләрне социаль тигезсезлекләр, ил байлыгын бүлешүдәге гаделсезлекләр аеруча нык кыерсыта. Союздаш республика булырга тырышу бу очракта да аклана. Остазым профессор Әкъдәс Борһанов аңлатуынча («Вечерняя Казань» газетасы, 3 ноябрь, 1989 ел), күпмилләтле генә түгел, милләтләре тәмам үзара буталып-аралашып беткән безнең илдә, һәр милләтне тигез хокуклы итмәгәндә, күңелсез ыгы-зыгылардан котылып булмый. Һәр милли территория исә азатлык статусы алырга һәм тигез хокуклы халыклар федерациясен тәшкил итәргә тиеш.

Әле күп мәсьәләләр хәл ителмәгән бүгенге шартларда да Татар иҗтимагый үзәгенең теләктәшләре арасында эшче һәм крестьян вәкилләре артканнан-арта бара. Иң активлардан Казанның оптик механика заводы, бигрәк тә, Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск шәһәрләре кешеләрен санарга була. Казан эшчеләрен дәррәү кузгату авыррак. Башта аларны матбугатның безне тәнкыйтьләве шөбһәләндерде. Аннары, әлбәттә, милли аңның халык күңелендә шактый тирәнгә кереп бикләнүен дә кабатламый булмый. Бу хис бик тирәндә һәм йокымсыраган. Безгә шул аңны уяту кирәк. Сабыйлардан башлап. «Әнием, минем янда син татарча сөйләшмә, дус кызларым көлә»,— дип, үзенең татар баласы булуыннан гарьләнеп йөрүче сабыйлардан башлап, өлкән яшьтәге милләттәшләребезгә кадәр безнең аңлатуларга мохтаҗ. Бакчаларда, мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында ана теле өйрәтелергә тиеш. Безгә инде күп кенә ата-аналар мөрәҗәгать итә. Без барысына да игътибарлы булырга тырышабыз.

Сорау. Алайса, матди кыенлыкларны санамаганда, соңгы вакытта эшләрегез җайлы бара? Совет һәм партия органнары белән уртак тел тапкансыз, халык хуплый, идарәгез дә, секцияләрегез дә яхшы эшли. Шулаймы?

Җавап. Өздереп үк әйтергә иртәрәк. Рәсми оешмаларда безгә аяк чалырга торучы эреле-ваклы түрәләр җитәрлек әле. Бер генә мисал китерим. Узган елның 15 октябрендә Иван Грозныйның Казанга басып керү көнен кайгы митингысы белән билгеләргә ниятләгән идек. Без теләгән шартларда уздырырга рөхсәт бирелмәде. Мәгълүм ки, тыелган нәрсә кешеләрне аеруча ымсындыра. Рөхсәтнең булу-булмавын сорап тормастан, барыбер Сөембикә манарасы янына җыелды халык. Андый-мондый күңелсезлек чыкмасын, сүзе безгә булыр, дип, без дә баруны кирәк таптык. Арада еректан, Баку шәһәреннән килгән кунаклар да бар иде. Дингә ышана торган берәү, Казаныбызның азатлыгы өчен, җаннары шәһит киткән борынгы кан кардәшләр рухына багышлыйм, дип, ясин чыкты. Бер әдибә шул тарихның канлы вакыйгасына багышлаган бәетен укыды, җырчы «Туган тел»не башкарды. Күпләрнең кулында чәчәкләр иде. Үз туфрагын ятка бирмәс өчен сугышып һәлак булганнарның якты истәлеген олылап, Сөембикә манарасы итәгенә кызыл канәферләр түшәделәр.

Рәсми рөхсәт булмаганлыктан, тавыш көчәйткеч бернинди аппаратлар да көйләнмәгән иде. Баштарак һәммәсе бик тыныч, дус-туганнарның үзара сөйләшеп утыруы кебек кенә барды.

Инде кайту ягына борылырбыз, дигәндә генә иңенә чиләк кадәр мегафон аскан берәү, бик каты кычкырып:

— Митинг не санкционирован, разойдитесь!— диде.— Предупреждаю!...

Бары шуннан соң гына бераз ыгы-зыгы куба язды: яшь егетләр аппаратуралы кешене урап алдылар:

— Кем син? Ник исемеңне әйтмисең? Нигә татарча сөйләшмисең?— диләр.

Мин ул кешене — халык депутатлары Советының Бауман районы Башкарма комитеты председателе Ногмановны танып алган идем инде. Кызу канлы егетләрне «суытырга» ашыктым. Тиз тынычландылар. Таралышырга булдык. Казанның борынгы Кремле мәйданын иңләп, халык капкага юнәлде. Сөйләшә-сөйләшә барабыз. Киләчәк елларда бу көнне, алдан әзерләгән күреп, зурлап билгеләргә килешендек. Митингка килгәннәр бары беравыздан 1552 елда миһербансыз патша тарафыннан һәлак ителгән сугышчыларга һәйкәл салырга кирәклеген телгә алды. Татар иҗтимагый үзәге счетына акча салучылар, ярдәмнәренең шушы һәйкәлне салуда тотылуын теләсә, ул хакта квитанциягә үк язарга тиеш булачак.

Мин киләчәктә Иван Грозныйның явыз патша икәнлеген фаш итүчән мондый митингка рөхсәт бирелүенә ышанам. Ник дигәндә, тәҗрибә шуны күрсәтә: баштарак Татарстанга союздаш республика статусы таләп итә торган митингка да рөхсәт бирелми иде. Бу юлы исә рөхсәт мәсьәләсен хәл итүче җитәкчеләр үзләре үк:

— Йәгез инде, Татарстанга союздашлык сорагыз да шуның белән чикләнегез!— диделәр.— Әллә кайчангы сугышларны искә төшереп тормагыз! Татар белән руслар бәрелешен китереп чыгарасыгыз киләмени?

Тыюлары әнә шундый сәбәп аркасында булды. Сорау туа: ни өчен әле, Иван

Грозныйның вәхшилеген фаш иткәннән соң, рус белән татар арасында низаг чыксын икән?! Грозный бер татарны гына җәберләгәнме?! Бу бит — тарихны белмәү, наданлык. Әлеге патшаның башка сыймас ерткычлыгы, иң беренче чиратта, руслар башына төшкән ләбаса! Шуңа күрә мин, рөхсәт ителсә, әлбәттә, 1552 елгы вәхшәткә багышланган митингта киләчәктә татарлар гына түгел, шәһәребездә яшәүче һәр милләт вәкилләрен дә катнашыр, тарихны бәяләр дигән карашта торам.

Сорау. Инде Татарстан иҗтимагый үзәгенең әдәби хәрәкәткә, язучыларга булган мөнәсәбәте, Татарстан Язучылар союзы белән ике арадагы элемтәләр турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

Җавап. Язучылар белән мөнәсәбәтләр яхшырып, тыгызланып бара. Дөрес, баштa алар безгә тартылырга ашыкмадылар. Югыйсә, башка милли республикаларда мондый хәрәкәтләр башында язучылар атлый. Бездә алай булмады. Бик актив бер-ике язучыны санамаганда, күпчелек читтә торды, айлар буена шактый читтән күзәттеләр. Безнең эш исә, алда әйтүемчә, бик тиз таралды, төрледән-төрле һөнәр кешеләренең хуплавына ирешге. Бу да, съезд хәлләре дә язучыларны уятып җибәргәндәй итте. Татарстан язучыларының XI съездында ясалган чыгышларда без алга сөргән максатлар телгә алынды. Мине «Казан утлары» журналына редколлегия члены итеп, идарә әгъзасы Римзил Вәлиевне — «Идел» журналының баш редакторы, ә тарих секциябезнең председателе Сәлам Алишевны яшьләр журналына редколлегия члены итеп сайладылар. Рафаэль Хәкимовны КПСС өлкә комитетына эшкә алырга кирәклеген дә, үз съездларында, иң әүвәл, язучылар күтәреп чыкты.

Иҗат көчләребездән, ягъни рәссамнар, композиторлар, артистлар һәм язучылардан башка Татар иҗтимагый үзәгенең эшен күз алдына да китереп булмый. Чәчәксез болын, сандугачсыз яз кебек булыр иде бу хәл. Мондый берьяклылык килеп чыкмасын дип, без якын арада республикабызның иҗат союзлары белән берлектә Пленум уздырырга уйлыйбыз. Татарстан, халык, телебез һәм мәдәниятебез алдында торган бурычларны тиз һәм нәтиҗәле үтәү өчен безгә барлык көчләрне бергә туплау кирәк. Партия дә шуңа чакыра бит: бердәмлеккә һәм тырыш хезмәт итүгә өнди.

Сорау. Киләчәк турында сүз чыккач, әңгәмәбезне түгәрәкләү йөзеннән, алдагы елларда башкарачак эшләрегезгә дә кагылып үтик. Килер көнгә уй-ниятләрегез ничек?

Җавап. Без күп мәсьәләләрне күтәреп кенә чыктык бит әле. Шуңа күрә, беренче чиратта, авыз ачып әйтелгән сүзләрне тормышка ашыра бару күздә тотыла. Шулай ук яңа бурычлар да билгеләнгән инде. Татарлар ил буйлап кына түгел, дөнья буйлап та таралган, дидек. Әлегрәк безгә чит илләрдәге милләттәшләр белән элемтәгә керүләр, хәтта кызыксынулар да катгый тыелган иде. Ул гынамы?! Хәтта, әйтик Оренбургтагы бер татарның мактаулы эше турында Казанда чыга торган газета-журналларга язарга ярамады. Сәяхәттән кайткан бер журналистыбыз исә, газетага тәкъдим иткән язмасында, Төркиядәге татар профессорын телгә алганы өчен генә эштән куылды.

Бүген хәл башкача тора. Элемтәләр ныгый. Күрше өлкәләрдәге татарлар үз җәмгыятьләрен булдыралар. Күбесе рәсмиләштерелде. Анда татар телен, мәдәниятен өйрәнүләр башланды. Хәзер безгә ил күләмендә уртак татарча газета кирәк.

Чит илләрдәге милләттәшләр белән аралашу да башланды, дияргә мөмкин. Хәтерегездәдер: былтыр Идел буе Болгариясенең ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулу тантанасына күп кенә чит илләрдән кунаклар килде. Араларында татарлар да бар иде. Мин монда аңлатып үтү кирәктер дип уйлыйм: Татар иҗтимагый үзәгенең дин әһелләре, төрле мәхәлләләр белән мөнәсәбәте бик яхшы. Дөреслекне әйтми ярамый: дингә ышанучылар, әллә нинди болгавыр елларда да, үзләре нык кыерсытылган хәлдә дә халкыбызның күркәм гадәтләрен, якты киләчәккә ышанычын саклап калуда бәхәссез уңай роль уйнады. Алыштыргысыз бу форсаттан бүген дә файдаланырга кирәк.

Ислам диненең бәйрәменә дә без шулай карадык. Кунаклар белән бергә шәһри Болгарга сәяхәткә баргач, киңәшмә уздырдык. Сүз үзара ныграк аралашу, татарларның бөтендөнья берлеген булдыру турында барды. Инде Татар иҗтимагый үзәгендә бу дөньякүләм берлекнең оештыру комитеты төзелде. Аңа Бөтендөнья татар лигасының Устав проектын булдыру, һәр илдәге татар җәмгыятьләре белән элемтә тоту һәм Оештыру съездын әзерләү бурычлары йөкләнде. Шәһри Болгардагы киңәшмәдә катнашкан кунаклар һәрберсе үз илендә татарларны барларга, безнең теләкне аларга җиткерергә ризалык бирде. Мәскәүдә инде эшләп килүче «Родина» берләшмәсе дә, Казанда «Ватан» бүлекчәсен булдырып, чит илләге татарлар белән элемтәне ныгытырга ниятли. Бергә-бергә эшләсәк, уңышларга тизрәк ирешербез, дип ышанырга кирәк.

Әгәр бу бурычны өчлап чыга алсак, минемчә, без дөнья халыкларының үзара тыныч, дус яшәвенә ирешүдә лаеклы өлеш керткән булырбыз. Максатыбыз — халык һәм демократия файдасына эшләү. Элеккечә бар нәрсәне югарыдан китереп бирүләрен көтеп кенә утырсак, без тагын буш кул белән калачакбыз. Күп көттек бит инде.

Әңгәмәне язучы **Кояш ТИМБИКОВА** алып барды.

## Әмир Мәхмүдов

# ҮЗГӘРЕШ БУЛЫРМЫ?

Безнең бүгенге көннәребез зур үзгәрешләр, халыкның тормышын яхшырту өчен барган көрәш, тизләнеш чоры булып тарихта калачак. Хәзер сәясәт, экономика, мәдәният өлкәсендә революцион үзгәртеп корулар бара.

Ил күләмендә барган бу хәл безнең Татарстанда да өмет, киләчәккә карата ышаныч уятты. Газета-журналларда мәдәни тормышыбызны үзгәртеп коруга багышланган, кичекмәстән хәл итәргә кирәкле мәсьәләләр ешрак яктыртыла башлады. Язучыларыбызның XI съездында да Татарстанга союздаш республика статусы бирү, татар телен республикабызның дәүләт теле итеп кабул итү, милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачу, югары уку йортларында татар һәм рус телләрендә параллель укытуның кирәклеге турында гадел фикерләр әйтелде. Җәмәгатьчелек тарафыннан да кичекмәстән тормышка ашырырга кирәк булган байтак мәсьәләләр күтәрелә.

Әмирхан Еники, Туфан Миңнуллин, Әбрар Кәримуллин, Мансур Вәлиев, Рафаэль Мостафин кебек язучылар, шулай ук галимнәр, укытучылар, журналистлар, күпсанлы укучылар туган тел өйрәнүне яхшырту, татар әдәбиятының киләчәге турында уйланып, конкрет тәкъдимнәр белән чыктылар. Татарча укытырга теләп тә, татар классы булмау сәбәпле, баласын үз телендә укудан мәхрүм иткән гаиләләр бар. Алар, ярдәм сорап, газета һәм журналларга мөрәҗәгать итә. Мондый хатларның күбесе басылып та чыкты. Бу чыгышларның, мәкаләләрнең нәтиҗәсе нинди? Тормышыбызда үзгәреш булдымы, юкмы? Кызганыч, киң җәмәгатьчелекнең фикерләре әле һаман да һавада эленеп кала бирә, сорауларга җавап күренми, тәкъдимнәр кабул ителми. Газеталарга гомуми җаваплар килсә дә, мәсьәләләр конкрет хәл ителүдән ерак тора. Культура һәм мәгариф министрлыгы җаваплары торгынлык чорында язылган хатлардан әллә ни аерылмый.

Хөрмәтле газетабыз «Социалистик Татарстан» да һаман әле кыюланып җитә алмый. Туган тел турында сөйләшү дә ярты юлда туктатылды.Мәсьәләләр хәл ителмәгән килеш әлеге сөйләшүне туктату һич тә дөрес түгел иде.

Кайбер мәсьәләләрне кабат искә төшереп үтик. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Алабуга, Зеленодольск, Әгерже, Буа кебек зур шәһәрләрдә район үзәкләрендәге барлык балалар бакчаларында татар балаларын туган телдә сөйләшергә өйрәтергә, кечкенәдән үк халкыбызның бай культурасына мәхәббәт уятырга, балаларыбызны үз телебездә фикерләргә өйрәтергә кирәк, дигән тәкъдимнәр ясалган иде. Шулай ук республикабызда яшәүче башка халыкларны да, интернациональ тәрбия бирү максатында, татар культурасы белән таныштыру, аларга да татар телен өйрәтү кирәк, дигән фикерләр әйтелде. Бу тәкъдимнәр телевидение һәм радиотапшырулар аша да халыкка җиткерелде.

КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш Лигачевның КПСС Үзек Комитеты февраль (1988) Пленумында ясаган докладында бу мәсьәлә ассызыклап билгеләп үтелде, ачыклык кертелде: «Үз чиратында башка милләт вәкилләренең җирле милли телне өйрәнүен һәрьяклап хупларга кирәк».

Хәзерге көндә җәмәгатьчелек тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрнең күбесе тормышка ашырылмый, республикабыз шәһәрләренең балалар бакчаларында татар телен һәм әдәбиятын, татар культурасын өйрәтү мәсьәләсе хәл ителми кала бирә. Мәсьәләне конкрет хәл итү өчен Халык мәгарифе министрлыгы да, шәһәрләрнең һәм районнарның мәгариф бүлекләре дә, бу мәсьәләне контрольдә тотарга тиеш булган партия һәм дәүләт органнары да тиешле чаралар күрми. Ни өчен соң бу мәсьәләләр хәл ителми?

Үзгәреш чорында матбугатта әйтелгән һәр файдалы тәкъдимне, фикерне игътибар белән өйрәнергә, алар буенча конкрет эшлекле чаралар күрелергә тиеш иде. Мин ул чараларга кагылышлы төстә чыгарылган карарны түбәндәгечә күз алдына китергән идем:

«1. Республиканың барлык балалар бакчаларында туган тел дәресләре үткәрүне җаваплы эш дип санарга, татар телендә шигырь сөйләүгә, җырлар, әкиятләр, халык биюләрен өйрәнүгә игътибарны арттырырга.

2. КПСС Үзәк Комитетының февраль Пленумында (1988) әйтелгәнчә, «рус һәм туган телләрдә бер үк мәктәпләрдә укыту практикасы интернационализм һәм халыклар дуслыгына хезмәт итә, Ленинның бу мәсьәлә хакындагы васыятен ешрак искә төшерергә кирәк. Бу эшнең тормышка ашуында мәктәпкәчә яшьтәге төрле милләт вәкилләренең бер үк балалар учреждениеләрендә тәрбияләнүе яхшы нигез булып тора».

Пленум материаллары яктылыгында балалар бакчаларында татар телен һәм әдәбиятын, рус телен һәм әдәбиятын тигез дәрәҗәдә өйрәнүгә игътибар итәргә. Һәр ике халыкның культурасын мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә тигез өйрәтү мәсьәләсе өчен җаваплы итеп балалар бакчалары мөдирләрен билгеләргә.

3. КПСС Үзәк Комитетының февраль (1988) Пленумы карарлары яктылыгында интернациональ тәрбия бирү максатында, балалар бакчаларында рус һәм башка халыкларның культура мирасын өйрәнү белән беррәттән, татар мәдәниятен, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә игътибарны арттырырга, бу эшкә контрольлек итүне шәһәр һәм район мәгариф бүлеге җитәкчеләренә тапшырырга.

4. Педагогия училищеларында шәһәр балалар бакчалары өчен татар тәрбиячеләрен хәзерләүне тизләтергә, яңа группалар ачарга. Бу мәсьәләгә контрольлек итүне педагогия училищесы директорларына һәм Халык мәгарифе министрлыгының җаваплы хезмәткәрләренә йөкләргә.

5. Бу эш өчен җаваплы кешеләрнең отчетын даими рәвештә тыңларга, бурычын үтәмәүчеләргә карата тиешле чаралар күрергә...»

Әлбәттә, мәсьәләне тирәннән үзгәртү өчен, иң әүвәл татар теленә Татарстанда дәүләт теле статусы бирелергә тиеш. Заман таләбе булган бу мәсьәләләр конкрет төс алса, аларны хәл итү өчен җаваплы кешеләр билгеләнсә, бу иптәшләр халык алдында җавап тотса, бу күренешләр кискен рәвештә уңай якка үзгәрәчәк. Бакчада ук татар телен өйрәнгән бала мәктәптә укыганда беренче класста ук туган телне һәм әдәбиятны җиңел үзләштерәчәк.

Туган тел һәм әдәбиятны балалар бакчаларында өйрәнүне республикабызның югары уку йортларында нинди телдә укыту мәсьәләсеннән аерып карасак, бу — бер генә яклы уйлау булыр иде.

Югары уку йортларында барлык фән нигезләрен дә ике телдә укытуга күчүнең кирәклеген, мөһимлеген тормыш үзе раслый. Университетта, ветеринария, авыл хуҗалыгы, медицина, культура институтлары, консерватория һәм башка уку йортларында барлык фән нигезләрен, рус теле белән беррәттән, татар телендә дә укыту мөмкинлеге булмагач, белгечләребез үз белгәннәрен туган телдә аңлата белми. Артистларга килсәк, «кюзляр», «эзлядем», «мәхәэббәт», «быйлбыйл», «шяркъ кызый» дип сөйлиләр һәм җырлыйлар. Татар милли опера театрында татар телендә җырлыйсы урынга, классик операларны русча башкаралар. Рус һәм башка халыкларның опера театрларында да барлык әсәрләр шул халыкның үз телендә башкарыла югыйсә.

Югары уку йортларыбызда фән нигезләрен нинди телдә укыту мәсьәләсен Мәскәү министрлары түгел, халык үзе хәл итәргә тиеш. Үзгәреш барган көннәрдә бу мәсьәләдә дә кискен борылыш булырга тиеш; югары уку йортында фән нигезләрен үз телендә укыйсы килгән татар балаларына ясалма кыенлыклар тудырмаска, барлык имтиханнарны да туган телендә тапшыру мөмкинлеге бирергә кирәк.

Бүгенге көндә бу мәсьәләдә халыкның теләген матбугат аша, авыл һәм шәһәрләрдә исә анкета тутырту ярдәмендә белергә булыр иде. Бу анкетаны халыкның фикерен өйрәнү буенча партия һәм совет органнары үткәрә алыр иде. Мондый социологик тикшеренүләр үткәрү кайбер милли республикаларда килеп чыккан хаталардан арыну юлында зур роль уйнаячак.

1922 елның 31 декабрендә язылган «К вопросу о национальностях или об «автономизации» исемле язмасында В. И. Ленин, төрле сәбәпләр табып, милли телләрне чикләргә тырышучыларга бүгечге көндә дә гаять актуаль яңгырый торган җавап биргән иде. Бөек Ленин фикерләрен төгәл чагылдыру максатында өзекне рус телендә үк китерик: *«...надо ввести строжайшие правила относительно употребления национального языка в инонациональных республиках, входящих в наш союз, и проверить эти правила особенно тщательно... У нас, при современном нашем аппарате, будет проникать масса злоупотреблений истинно русского свойства. Для борьбы с этими злоупотреблениями необходима особая изобретательность, не говоря уже об особой искренности тех, которые за такую борьбу возьмутся. Тут потребуется детальный кодекс, который могут составить сколько-нибудь успешно только националы; живущие в данной республике»* (Ленин В. И. Полн. собр. соч., т. 45, с. 356-362).

Мәсьәләне дөрес аңламаган бюрократларга 1922 елның декабрендә үк язылган В. И. Ленин җавабы безнең өчен методологик нигез, җирлек булып тора. Бу юлдагы ялгышулар исә Казахстан, Үзбәкстан, Таулы Карабах һәм башка регионнарда булган күңелсез күренешләрнең кабатлануына китерү ихтималын онытмаска кирәк.

В. И. Ленинның бу гаять кыйммәтле фикеренә таянып, безнең республикада үткәрелгән тантаналы җыелышларны ике телдә — татар һәм рус телләрендә үткәрү практикасына күчәргә вакыт. Шулай ук вокзалларда; автобусларда, трамвай-троллейбусларда, кино-театрларда, кибетләрдә, дәүләт учреждениеләрендә практик рәвештә ике телдә аңлашу мөмкинлеге тудырырга, моңа каршы килүче шовинизм һәм милләт-

челек белән авыручы иптәшләргә тиешле җәзасын бирергә кирәк.

Ике телне дә тигез дәрәҗәдә файдаланмау — Татарстан республикасының бәхете өчен кан койган, якты киләчәк өчен һәлак булган Мулланур Вахитов кебек революционерларның изге рухына тап төшерү ул. В. И. Ленинның көрәштәше, татар революционеры Мулланур Вахитовка һәйкәл ачылганда исә бер генә оратор да татар телендә чыгыш ясамады. В. И. Ульянов катнашындагы студентлар сходкасына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелышта да бер генә татар сүзе яңгырамады, Кукмара районыннан килгән вәкилнең рус телен вата-җимерә чыгыш ясавы өчен кызарып утырырга туры килде.

Интернационализмның тантанасы, милли телләрнең чәчәк атуы турында бөтен ил күләмендә сүз барганда Совет власте елларында үсеш чоры кичергән татар теленең әһәмиятен аңлап бетермәү — политик сукырлык ул. Торгынлык елларында Мәгариф министрлыгы күп кенә татар мәктәпләрен япты. Бу акция халыкка хыянәт итү, җинаять белән бер иде. Алны-артны карамыйча гына мәктәпләрне ябу конституцион таләпләрне бозуның ачык бер мисалы булды. Татар мәктәпләренең ябылуына сәбәпче иптәшләр хәзерге көндә дә исән-саулар, кайберләре җаваплы урыннарда эшлиләр. Алар үзләренең башбаштаклыгы, җавапсызлыгы, битарафлыгы өчен халык алдында җавап тотарга тиешләр. Халык хөкеме — намус хөкеме ул. Торгынлык елларында җылы постларын саклап калырга тырышкан, мәктәпләр язмышы белән уйнаган бу иптәшләрне хәзер идеология өлкәсендәге эшләргә якын да җибәрергә ярамый, минемчә.

Бу уңайдан, махсус рәвештә, кадрлар мәсьәләсенә тукталып үтәсе килә. Милли республикаларда идеология өлкәсендә эшләүче кешеләрне әзерләүгә бөек Ленинча караш булырга тиеш. Татарстан шартларында ике телне дә, татар һәм рус культурасының тарихын, үзенчәлекле сыйфатларын тигез дәрәҗәдә белмәгән кеше бу өлкәдәге җаваплы урыннарга куелмаска тиеш, дисәк, ялгышмабыз кебек. Татар һәм рус телләрендә басыла торган журналга русча гына белүче редактор кую күңелсез нәтиҗәләргә китерә, журналның татарчасы җитәкчесез кала, бик начар дәрәҗәдә тәрҗемәләнгән мәкаләләр басылып чыга.

Хәзерге көндә татар китаплары, газета һәм журналлары Советлар Союзының төрле республикаларында, өлкәләрендә яшәгән татарларга барып җитми. Шулай ук татар язучыларының әсәрләре илебез халыклары телләренә, демократик илләрдә яшәүче халыклар телләренә тиешле дәрәҗәдә тәрҗемә ителми.

Ике культураны да тирән үзләштермәгән кеше культура мәсьәләләрен хәл иткәндә объектив була алмый, татар телен һәм әдәбиятын белмәгән, иҗат ителгән әсәрләрне, бүгенге көннең катлаулы мәсьәләләрен аңламаган, татар мәдәниятенең тарихын белмәгән кешеләр нейтраль позициягә, кайчакта хәтта мәсьәләне хәл итәргә теләмәү позициясенә басалар.

М. С. Горбачевның КПСС Үзәк Комитеты февраль (1988 ел) Пленумында ясаган чыгышында әйтелгәнчә, «Тарихыбызга мөрәҗәгать итү — үткәннәр белән кызыксыну гына түгел. Ул безгә бүгенге эшебез өчен, үзгәртеп кору бурычларын хәл итү өчен дә бик кирәк»

XX йөз башында, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр, әдәбиятыбыз тормышында 500ләп әдипнең актив катнашуы, иҗат итүе мәгълүм. Киң җәмәгатьчелеккә исә барлыгы 10-15 язучының гына исеме билгеле. Ул чорда зур шәһәрләрдә татар телендә басылучы газета һәм журналларның саны йөздән артып китүе дә бәхәссез. Бай әдәбиятыбызга бүгенге көндә — үзгәреш чорында марксистик-ленинчыл эстетика биеклегеннән торып, В. И. Ленин методологиясе нигезендә, дөрес бәя бирергә тиешбез, ягъни гасыр башында иҗат ителгән әдәбиятның уңышларын һәм кимчелекле якларын күрсәтеп, ул чорның үзенчәлекле сыйфатлары белән бәйләп аңлатырга кирәк. Үзләре яшәгән чорда халык тарафыннан укылган, халык арасында популяр булган язучыларның исемнәрен кайтаруга теш-тырнак белән каршы булган, татар телен белмәүче җаваплы кешеләр үзгәртеп кору турында сөйләргә яратсалар да, культура мирасыбызны халыкка кайтару мәсьәләсенә килгәндә, үзгәрергә теләмиләр.

Иҗатлары бәхәс уяткан язучылар мирасы буенча авторитетлы комиссияләр төзелеп, язучы файдасына уңай фикерләр әйтелсә дә, ике культураны да яхшы белмәгәнлектән һәм белергә дә теләмәгәнлектән, җаваплы иптәшләр мәсьәләне уңай хәл итмиләр, җәмәгатьчелекнең үтенечен кире кагу юлына басалар. Нәтиҗәдә, әдәбиятыбыз тарихы берьяклы гына яктыртыла, «ак таплар» барлыкка килә, эзлеклелек югала.

Тегe яки бу татар язучысының әсәрләрен дөньяга чыгаруны, җәмәгатьчелек теләген аяк астына салып таптамыйча гына хәл итү дөрес булыр иде.

Граф булганы өчен генә Л. Н. Толстойны өйрәнмәсәк, гомеренең күп елларын чит илләрдә үткәргән Ф. И. Шаляпинның талантын хөрмәт итмәсәк, бер яклы гына карашта торсак, «туганлыкны оныткан иваннарны» хәтерләтер идек. Рус халкының бу күренекле вәкилләрен һәм башка шундый әдипләрен хөрмәт итәбез икән, татар халкының күренекле улларын да, уңай һәм кимчелекле якларын дөрес бәяләп, барлап чыгарга тиешбез.

Әлбәттә, киләчәктә тарих үзе халкыбызның культура мирасын дөрес бәяләүгә каршы булган, битарафлык позициясенә баскан кешеләргә тегәл бәясен бирер, кайбер кешеләрнең чын йөзе ачылыр, хакыйкать тантана итәр. Хәзерге көндә исә бу эш демократия, үзгәреш заманы таләпләренә җавап бирми, ачыктан-ачык әйткәндә, бу өлкәдә үзгәреш аз.

Үзәк матбугат, союздаш республикаларның газета һәм журналларына махсус тукталмыйча, үзебезнең республикабызда рус телендә басылган кайбер матбугат органнарына мөрәҗәгать итик. «Советская Татария», «Комсомолец Татарии», «Вечерняя Казань» кебек газеталар культурабызны рус телендә пропагандалауга бик зур урын бирергә тиеш булсалар да, алар халкыбыз мәдәниятен очраклы рәвештә генә яктырталар, хәтта «татар телен өйрәнү кирәкми», дип язган бәндәләрнең фикерләрен бастырып чыгаралар. Мондый хәлне ни белән аңлатырга?

Бу газеталар, нигездә, кинофильмнарга рецензияләр бастыру, Казанга килгән төрле артистлар белән интервьюлар бирү, рус театрларының әсәрләрен анализлау бик билгеле шәхесләрнең эшчәнлеген яктырту белән шөгыльләнәләр.

Әйтик, «Вечерняя Казань» газетасы Шаляпин турында бик күп материаллар бастырды. Шаляпинны хөрмәт итәргә кирәкме, юкмы, аңа һәйкәл куярга кирәкме, юкмы дигән мәсьәлә тирәсендә буш фәлсәфә куертылды.

Халыкка Шаляпин кирәкми дип кем әйтсен инде?! Шаляпин — бөек җырчы, ул — хөрмәткә лаеклы кеше. Шаляпин кирәкми дип әйтү — кешегә һава, ипи, тоз, су кирәкми дип раслау булыр иде. Газета битләрендә аерым бер шәхес белән мавыгып, шул ук дәрәҗәдә игътибарга лаеклы булган татар халкының бөек уллары турында бөтенләй онытып җибәрү дөрес булмас, дип әйтүем.

Дөнья культурасы өчен шул ук дәрәҗәдә әһәмиятле булган Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Салих Сәйдәшев, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд һәм дистәләрчә башка культура әһелләре турында ни өчен бу газеталарда бер сүз дә әйтелми?!

Мәсәлән, 1988 елның 21 март санында «Белешмәләр бюросы» бүлегендә «Вечерняя Казань» газетасы «Галимҗан Ибраһимов исталеге ни дәрәҗәдә мәңгеләштерелгән?» дигән сорауга дүрт җөмләдән торган җавап язу белән генә чикләнә.

Чагыштырыйк: берәүгә тулы битләр багышланган хисапсыз мәкаләләр һәм Галимҗан Ибраһимов турындагы дүрт җөмләдән торган җавап. Сәер түгелме? Сүз Татарстан башкаласында басылган газета турында бара бит! Бу чагыштыру күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә. Татар культурасының иң күренекле вәкилләренә бу газетада игътибарның беренче урында булмавын, бөтенләй җитмәвен ачык күрәбез.

Халыкның тормышын, илдә яңа тормыш төзүнең тирән тамырларын ачып биргән Галимҗан Ибраһимов исталеген мәңгеләштерү, аңа багышланган әдәби музей ачу, Казанда һәйкәл кую мөһим түгелме? Бу белешмәдә хәтта язучы күмелгән зират та ялгыш күрсәтелгән, «могила писателя на Арском кладбище» дип язылган. Язучының Архангель зиратына күмелгәнен хәзерге көндә мәктәп баласы да белә. Газетада зур язучы турында хаталар җибәрү, аның мирасына битараф карау, әдипнең якты исеменә тап төшерү, ачыграк әйткәндә, аны мыскыл итүгә тиң.

Газета редакциясендә ике культураны да белгән журналистлар эшләсә, мондый хаталарны булдырмаслар иде.

Бик мөһим тагын бер мәсьәләне читләтеп үтсәк, мәкаләбез тулы булмас. Минем шуны ачыклыйсым килә: ни өчен халык тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр совет һәм партия органнары тарафыннан өйрәнелми, аларны тормышка ашыру буенча чаралар күрелми?! Газеталарда, журналларда, радио һәм телевидение аша әйтелгән фикерләрне өйрәнү, аларны тормышка ашыру билгеле бер системага салынмаган. Әйтик, беренче класска — татар классына баласын бирергә теләгән, үзе яшәгән районда мондый мәктәпнең һәм классның булмавы турында язган, ярдәм сорап газетага мөрәҗәгать иткән иптәшкә дә җавап бирелмәгән.

30—40 ел сөйләнә торгач, ниһаять, яшьләребезгә «Идел» журналы чыга башлады. Яхшы. Тик моның белән генә туктап калмаска иде. Татар телендә яшьләр театры да юк, кинематографистлар союзы булса да, нәфис фильмнар чыгару буенча киностудия эшләми. Муса Җәлил, Язучылар Союзы председателе булганда Бөек Ватан сугышына кадәр үк күтәргән мәсьәлә — әдәби газета чыгару мәсьәләсе дә хәзергәчә хәл ителмәгән.

Татар-болгар әдәбиятының мәшһүр вәкиле шагыйрь Кол Галигә һәйкәл куярга вакыт җитмәдеме?! Җәмәгатьчелек, газета һәм журнал укучылары Галимҗан Ибраһимовка, Салих Сәйдәшевкә, Фатих Әмирханга, Галиәсгар Камалга һәйкәл ачу кирәклеген күтәреп чыксалар да, бу мәсьәләләр хәл итүдән ерак тора.

Дөрес, беренче адымнарны төрле тармакларда күрергә була. Мәсәлән, телевидениедән татар теле дәресләре алып бару тамашачыда җанлану уятты. Тик ярты юлда тукталырга ярамый. Ни өчен безнең Татарстан телевидениесе каршында махсус хор

капелласы, музыкаль ансамбль юк? Балалар өчен татар телендә мультфильмнар күрсәтүнең кирәклеге дә ап-ачык. Бу фикерләр гел әйтелә, әмма суга сәнәк белән язылган теләк булып кына кала бирә.

Бу мәсьәләләрне хәл итү өчен Казанда тиз арада Татар культурасы үзәге ачу урынлы булыр иде. Бу Үзәкнең татарлар яшәгән төрле өлкәләрдә филиалларын булдыру тиешле нәтиҗәләр бирер иде. Культура Үзәге булса, татар китапларын башка республикаларда сату һәм тарату, СССР халыкларының китапларын пропагандалау, халкыбызның культура өлкәсендәге ихтыяҗын өйрәнү, бу мәсьәләләрне тиз арада хәл итү өчен зур мөмкинлек ачылыр иде. Татар язучыларының китапларын демократик илләрдә, шулай ук СССР халыклары телләренә тәрҗемә итеп бастыруны оештыруда Татар культура үзәгенең роле әйтеп бетергесез зур булыр иде. Язучыларыбызның юбилейларын, әдәби бәйрәмнәр үткәргәндә Культура үзәге, информацион агентлыклар белән бәйләнешкә кереп, алар турындагы мәкаләләрне илебез һәм чит ил матбугатында бастырып чыгаруга ирешер иде.

Татар халкының күпчелек өлеше СССРның төрле тарафларына таралган. В. И. Ленинның, Татарстан республикасы читтә яшәүче татарларга культура ярдәме күрсәтергә тиеш, дигән фикере бүгенге көндә бик актуаль. Нинди генә республикада, өлкәдә яшәүләренә карамастан, барлык татар балалары да законлаштырылган системалы бер программа нигезендә туган телләрендә белем алса, алар бай культурабызга да, тарихны өйрәнүгә дә якынаерлар иде.

Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә... Үзгәрергә теләмәгәндә исә юкны бар дип, акны кара дип яшисе генә кала.

# ТАЛАНТ — МИЛЛӘТНЕ КҮТӘРӘ!

Эшкә барышлый миңа көн саен гаҗәп бер күренешнең шаһиты булырга туры килә. Күз алдына китерегез: иске таш корылма. Түбәсен кыңгырау манарасы очлый. Манара төбеннән як-янга шүрлек сыман нәрсә чыгып тора. Менә шул тар гына таш яссылыкта, бер дә исе китмәгәндәй, каен агачы үсеп утыра! Әйе, җир — юк, туфрак — юк, ә каен үсә! Могҗизамы? Һәрхәлдә, бу — табигатькә хас яшәү көчен, аның зурлыгын, бетмәслеген раслаучы күренеш. Димәк, тормыш яралгысы булганда, тишелеп чыгу өчен уңайсыз шартлар да аңарга киртә була алмый.

Иҗат кешеләренә хас талант яралгысы белән дә эш шулайрак тора, диләр. Чын талант басылып ятмый, иртәме-соңмы — үзен барыбер раслап күрсәтә. Ләкин мәсьәләнең икенче ягын да онытмыйк: әлеге каен тишелеп чыккан чыгуын, тик менә ул — бик ябык, бик чандыр. Яфраклары да аз, ботаклары да санаулы гына, буе да үз яшеннән артта калган. Димәк, шартлар җитәрлек булмаган.

Шуның кебек үк, талантларның ачылуы, үсүе, камилләшүе өчен дә шартлар кирәк. Уңай шартлар. Әйе, бу — бәхәссез. Ләкин иҗат өчен уңай шартлар тудыру — ул комплекслы проблема, әдәби хуҗалыкның барлык тармакларын актив рәвештә эшләтү дигән сүз. Биредә иң әһәмиятлесе — талант иясе турында кайгыртучанлык. Мәгълүм ки, зур тәэсир итү көченә ия булган әсәрләр иҗат итү өчен язучыдан кимендә ике нәрсә таләп ителә: талант һәм зур шәхес. Талант — табигать бүләге, шәхес исә җәмгыятьтә формалаша. К. Маркс болай ди: «Адәм баласының эчтәлеге аерым бер кеше өчен генә хас булган абстракт нәрсә түгел. Чынбарлыкта ул эчтәлек — барлык иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең чагылышы булып тора».

Димәк, шәхеснең зурлыгы, олылыгы, бөеклеге аның җәмгыятьтәге бәйләнешләрына нык бәйле икән. Бу җәһәттән рус әдәбияты вәкилләре безгә үрнәк булып тора. Алар ил эчендәге партия, дәүләт, хуҗалык эшләрен башкаручылар белән аралашып, тәҗрибә һәм фикер алышып кына калмыйлар, бәлки чит илләргә дә даими чыгып торалар. Анда төрле очрашу, бәхәс, киңәшмә, симпозиумнарда катнашып үзләренә тәҗрибә туплыйлар, чарланалар. Кызганыч ки, әлеге практика, газета хәбәрләренә караганда, Татарстан язучылары тормышында әлегә бик аз урын алып тора. Чит илгә чыксалар да турист сыйфатында гына чыгалар.

Иҗатка уңай шартлар тудыруның тагын бер ягы бар. Ул шуннан гыйбарәт: язучы хезмәте — гаять тә үзенчәлекле хезмәт, ул физик көч, рухи киеренкелек сорый торган эш, дөньяда иң катлаулы хезмәтләрнең берсе. Язучы көн саен 6—8 сәгать вакытын иҗат эшенә багышларга тиеш. Шунсыз талант тутыга, сафтан чыга, кечерәя. Ләкин мондый режимда иҗат итү өчен бер шарт бар: язучы хәләл хезмәте китергән гонорар хисабына яши алсын. Әйе, аның гонорары тормыш ихтыяҗларын — ашау-эчү, кием-салым, гаилә, торак... өчен кирәкле чыгымнарны капларлык булсын. Юкса иҗат эшчәнлеген өзлексез алып бару мөмкин түгел. Бу — закон. Тормыш законы. Бу турыда Ф. Энгельс әйткән сүз бар: «Маркс кешелек җәмгыяте тарихының үсеш законын ачты: ул закон бик гади — кешеләр политика, фән, сәнгать, дин һ. б. белән шөгыльләнә алсын өчен, иң элек алар ашау-эчү, торак урыны һәм кием-салым белән тәэмин ителгән булырга тиеш».

Шушы хакыйкатьне истә тотып, чынбарлыкка күз салыйк. Мәгълүм булганча, бүгенге көндә татар язучыларыннан нибары 22 кеше генә гонорар хисабына яши, калган 173 е — СССР Язучылар союзы члены була торып та, үзенә иҗат белән шөгыльләнү мөмкинлеген тудыру өчен, башка төр эшчәнлектән керем эзләргә мәҗбүр. Чөнки гонорар хисабына яшәр өчен ел саен кимендә 10-15 табаклык китап бастырып чыгарырга кирәк. Нәшрият исә авторның андый күләмле китабын бары тик ике елга бер мәртәбә генә чыгара ала. Анда да әле эш бик уңышлы барса гына. Хәлбуки, китапның тиз чыгуы — ул матди якка гына кагылмый, бәлки язучының иҗат эшчәнлеген активлаштыручы фактор ролен дә үйный. Мәсәлән, Тукайга еш кына бер үк вакытта берничә редакциядән шигырь сорап мөрәҗәгать итмәгән һәм ул шигырьләрне икенче көнне үк басып чыгармаган булсалар, бүгенге көндә без белгән Тукай булыр иде микән?

Яки В. Маяковскийны алыйк. Ул үзенең иҗат эшчәнлеге дәверендә 99 китап бастырып чыгара. Әгәр дә моңа ирешә алмаган булса, бүгенге көндә аны трибун-шагыйрь итеп кабул

итә алыр идекмени? Ниһаять, Жюль Верн романнарының һәркайсын Этцель үз нәшриятында бер ай эчендә укучылар кулына ирештерә. Нәширдән шундый яклау тапмаса, Жюль Верн үзеннән соң 100 томнан артык әдәби мирас калдыра алыр иде микән? Безнең татар язучыларына исә андый тизлек белән әзер хезмәтне бастыру хәзергә әле хыял булып кына кала. Һәм бу хәл иҗат эшен бермә-бер катлауландыра. Авырлыкларны җиңә алмаучылар барлыкка килә. Алар беренче әсәрләре белән укучыны ымсындырып куялар да, аннары «шып итеп» туктап калалар, йә бөтенләйгә әдәбият белән араны өзәләр. Бүгенге көндә андыйларның исемлеге шактый озын... Иҗат эшен башка хезмәт белән бәйләп алып баручылар да укучыларны куандырырлык әсәрләр иҗат итүгә сирәк ирешәләр. Һәм бу аңлашыла да. Иҗат бит ул шундый эш: аңа син бөтен вакытыңны бир, тырышлыгыңны бир! Күңелеңне, илһамыңны бир! Көн саен, даими рәвештә! Әнә бит Жюль Верн гомере буена иртәнге сәгать биштән кичке сигезгә кадәр эшли. Дус-ишләре белән очрашуга да китапханәдән өйгә кайту вакытын гына багышлый. Иҗатны башка хезмәт белән алып баручыларга исә әсәр өстендә җиң сызганып эшләргә вакыт әз кала. Тоташ бар көчкә эшләмәгәч, әсәр дә сыек чыга. Укучыны канәгатьләндерми. Бу — талантның абруен төшерә торган хәл. Бу — борчылырлык хәл. Ләкин чара бар. Беренчедән, язучыларга шәхес буларак үсәргә шартлар тудыру; икенчедән, СССР Язучылар союзы члены булган талантлы язучыларга, нәшрияттан килгән гонорардан тыш, тормыш алып баруга кирәкле чыгымнарны капларлык өстәмә гонорар билгеләү. Әйе, язучы тормыш итү чыгымнары турындагы уйлардан азат булсын. Гел иҗат эше белән шөгыльләнсен, язсын, язсын... Мондый практика яңалык түгел. Ул борын-борыннан килә. Хәтерлибез: Александриядә тулысынча дәүләт тәэминатында яшәп иҗат иткән фән һәм культура эшлеклеләре булган. Хәтерлибез: герцог сарайларында ашау-эчү турында кайгы белми иҗат иткән урта гасыр культура әһелләре булган. Хәтерлибез: Франция республикасының ярдәмен алып, үзенең үлмәс әсәрләрен язган Виктор Гюго булган. Дәүләт хисабына утыздан артык бүлмәле йорт тотып яшәгән бөек Гете да истә. Ниһаять, зур талант иясе мәшһүр П. Чайковский да бары тик гонорар хисабына гына яшәмәгән. Читтән ярдәм алган. Хәлбуки, талант — ул халык байлыгы, халык даны, халык шөһрәте, халык үлемсезлеге! Кемнәр халыкка шөһрәт һәм дан китерә? Талант ияләре — бөек язучылар, рәссамнар, архитекторлар, скульпторлар, галимнәр. Кемнәр халыкны үлемсез итә? Шулар. Кемнәр иҗтимагый аңда тирән үзгәрешләр тудыра? Шулар.

Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язган шигырьләрен беренче мәртәбә немец теленә тәрҗемә иткән Франц Лешницер үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Иске бозык гадәт татарлар турында пычрак фикер тарата: янәсе, татарлар — җимерүчеләр, кан эчүчеләр, вәхшиләр. Татар шагыйре Муса Җәлилнең каһарманлык тулы тормышы, тиңсез иҗат батырлыгы әлеге шовинистик уйдырманың көлен күккә очырды» («Зоннтаг», № 34, 1964 ел).

Күрәсез, бердәнбер шагыйрь күрсәткән гражданлык каһарманлыгы, нибары бер шагыйрьнең иҗат батырлыгы. Ә менә аның кешеләр аңына тәэсире нинди зур, нинди көчле! Шагыйрь берүзе гасырлар буе килгән «шовинистик уйдырманың көлен күккә очыра». Әдәбиятның шушы көчен истә тотып, Татарстан хөкүмәте үз язучыларының иҗат шартларын тагын да яхшыртуга кирәкле финанс чыгымнарын юлларга әмәлен табар, дип уйларга кирәк.

Ләкин иҗат шартларын уңай якка үзгәртү — материал чыгымнарны арттыруга гына кайтып калмый. Биредә башка чаралар да юк түгел.

Мәгълүм ки, бүгенге көндә авторлар кульязмасының язмышы нәшриятта берничә эчке рецензия белән, ә вакытлы матбугат редакцияләрендә фәкать бер кеше тарафыннан хәл ителә. Бу юл бүгенге көн рухына — демократиялек, хәбәрдарлык рухына туры килми. Ул кода-кодагыйлык, туган-тумачалык, белдеклелек дәгъвасе белән исерү, борын чөерү, тәкәбберлек, масаю, тәлинкә тотучанлык, бюрократлык кебек яман чирләр таралуга юл ача. Моңа каршы чара — нәшриятка килүче кульязмаларны язучылар союзы секцияләрендә демократик юл белән тикшерү һәм шунда басу-басмау мәсьәләсен хәл итү! Әйе, секция карары белән кульязмага фатиха бирелсен! Нәшриятның эчке рецензентлары тарафыннан түгел. Вакытлы матбугатта исә бу вазифаны һәр редакция каршында эшләп килүче иҗат түгәрәкләре үтәсә, бик тә заманча булыр иде. Ул түгәрәкләр утырышын яшьләр катнашында үткәргәндә файда икеләтә артачак.

Әйтергә кирәк, югарыда кузгатылган мәсьәләләр — өлгереп җиткән мәсьәләләр. Аларны хәл итүнең уңай нәтиҗәсен алдан ук әйтергә мөмкин. Беренчедән, урта кул әсәрләр басылып чыгуга җирлек калмаячак. Икенчедән, иҗаттан китү бетәчәк. Өченчедән, нәшрият редакторлары алдында ялагайлану, кода-кодагыйлык... кебек яман чирләргә урын калмаячак. Ниһаять, иң әһәмиятлесе — язучыларыбызга ашыкмыйча, кабаланмыйча югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итү өчен кирәкле шартлар туачак. Мондый нәтиҗәләр хакына чыгымнарны да, тырышлыкны да кызганмаска мөмкин.


**Шәрәф ӘХМӘДУЛЛИН,**
КДПИ доценты.

# ТУКАЙЛАР РУХЫ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

*Сине кызыксындырган әдипләр белән әңгәмә алып бару өчен журналыбызда махсус сәхифә ачабыз. Әңгәмә үткәрү өчен кемне чакыру да, аңа нинди сораулар бирү дә үзебездән тора. Шуңа күрә теләгән һәркем үзенең фикерен язса тәкъдимен редакциянең әдәби тәнкыйть бүлегенә хәбәр итә ала.*

*Безнең беренче әңгәмәбез — күренекле шагыйрь* ***Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ*** *белән.*



— Мөдәррис әфәнде, бу очрашу-әңгәмәләрнең төп юлын, төп рухын без шундый сүзләр белән билгеләргә булдык: Тукайлар рухы. Әйдәгез, үгезне шунда ук мөгезеннән алырга тырышыйк әле. «Тукайлар рухы» дигән сүз Сезгә олуг шагыйрь шәхесенең нинди сыйфатларын искә төшерә?

— Тукай исемен әйткәндә минем күз алдына иң элек шагыйрьнең фидакарьлеге килеп баса. Тукайлык — ул барыннан да бигрәк фидакарьлек дигән сүз. Үзеңнең татарыңа, милләтеңә фидакарьләрчә бирелгәнлек, фидакарьләрчә тугрылык дигән сүз! Тукайның үзенең зур шагыйрь, бөек шагыйрь булып китүенең дә бөтен сере, бөтен хикмәте әнә шунда! Әгәр дә ул, бүгенге хәйләкәр язса артык акыллы кайбер шагыйрьләр сыман, һәрчак алдын-артын уйлап кына, теге якка да, бу якка да карап кына барган булса — гап-гади бер рифмачы булып калыр иде. Власть башындагылар ни әйтер икән, теге кешенең кәефе кырылмас микән, бусы ачуланмас микән дип яшәсә — бүген без сокланып күтәрә торган олуг шәхес булмас иде!

— Бүгенге әдәбиятта Тукайлар нигә аз? дигән сорауның да төп җавабы әнә шул тирәдә шикелле...

— Кызык... Бу сорауны туры мәгънәсендә аңларга кирәкмәгәнлеген укучы, әлбәттә, төшенә торгандыр. Без бүгенге тормышта, әдәбиятта Тукайның үзен күрү турында сүз алып бармыйбыз. Без Тукайга иң хас булган сыйфатларны яшәтү хакында уйланабыз... Чыннан да, нишләп аз соң бүген Тукай сыман кыю, фидакарь шагыйрьләр? Ә бит иҗатчыларыбыз сан ягыннан аз түгел! Хәтта шушы ук бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемен йөрткән дәүләт бүләгенә лаек дип табылган шагыйрьләребез дә бик күп...

— Без бирелә тагын, әлеге дә баягы торгынлык чорын гаеплибезме инде?! Шагыйрьләребез кыю булмауны торгынлык чорыннан күрәбезме инде?!

— Әйе, ил күләмендәге хәлләр шагыйрьләргә дә тәэсир итми калмыйдыр анысы. Татар халкын рәсми рәвештә бетерергә тырышу, татар мәктәпләре санын бик нык киметү, ә шәһәр җирләрендә аларны бөтенләй диярлек бетерү, халыкларны «илдә бары тик бер генә милләт калырга тиеш» дип ышандыру — һәммәсе дә чын иҗат өчен начар климат тудырды. Байтак кына язучыларның һәм шагыйрьләрнең кыйбласын да үзгәртте...

Ләкин шагыйрьләргә булган таләпне аз гына күтәрә төшсәк — күрербез. Шәхесләрнең зурлыгы, ныклыгы нәкъ менә шундый чакларда ачыла да инде ул! Хәзерге демократия шартларында, ирек килгәч, теләсәң ни әйтеп була — бусы кыен эш түгел. Ә

теге чакта, безнең газета һәм журналларыбыз гел дә «югарыдагы»лар сүзен генә сөйләп яшәгәндә, шагыйрьләребезнең цензура аша үтми калган әсәрләре күп булдымы?! Үз иманына тугрылык саклап язган әдипләребез байтакмы безнең? Әллә күпләребез әкрен-әкрен җайлаша башлаган идекме инде?! «Шулай тиештер күрәсең» дип уйларга күнегеп килә идекме?

Мин, мәсәлән, Нурихан ага Фәттахны алай уйлады дип әйтә алмыйм. Аның күкрәгеп гәрчә Г. Тукай премиясе бизәмәсә дә, ул авыр елларда Н. Фәттах милләткә Тукайча тугрылык күрсәтте. Чын иман ныклыгы күрсәтте. Әмирхан ага Еники шулай булды... Тагын берничә исем атап була.

— Биредә милләтебезнең рух ныклыгын гәүдәләндерүче әдипләр исемен телгә алганнан соң, халкыбызга карата Тукай әйткән мәгълүм сорауны китерәсе килә. Сез ничек уйлыйсыз, Яңарыш чоры өчен безнең татар милләте үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?

— Халык ул үлми дә, йокламый да! Аны үтереп кенә, йоклатып кына була! Әнә шундый: йоклый торган, үлә торган шартларга куйсак — ул, әлбәттә, үләчәк! Әлбәттә, йоклаячак! Менә Сез уйлап карагыз: без Ленин үлгәннән соңгы 60 ел дәвамында «милләтләр бетәчәк» дип кычкыра килдек, ил эчендә шундый политика үткәрдек. Алда әйтеп узганыбызча, милли мәктәпләрне ябып бетерә яздык! Ә матбугатны карагыз. 1905 елгы революциядән соң шаулап үсә башлаган татар матбагасы ни хәлгә төште! Җан башына периодик басмалар чыгару буенча без илдә иң арттагы урыннарның берсен билибез! Хәтта безне революциягә кадәр укый-яза белмәгән милләтләр дә узып китте. Ә соң ни өчен безнең эшебез кирегә таба борылды. Халык үзе теләп яптымы ул матбагаларны? Юк, бу начар эш югарыдан торып эшләнде! Власть иляре тарафыннан башкарылды ул. Бик тә нечкә формаларда һәм үтә оешкан төстә!

— Шул уңайдан бер мөһим нәрсәгә басым ясап китәсе килә. Милли мәктәпләрне һәм милли матбаганы ябу, әнә шулай, сез әйткәнчә, дәүләт органнары тарафыннан башкарылды. Бетерү политикасы системалы рәвештә 60 ел буена алып барылды. Ә хәзер күп кенә чиновниклар, милли мәктәпләр мәсьәләсе кузгалгач, «ата-аналар теләге» дип акланалар. «Алар теләми» дип милли мәктәпләрне ачарга ашыкмыйлар. Шул уңайдан К. Маркснең һәм В. И. Ленинның күп кенә хезмәтләрендә кабат-кабат әйтелгән фикерне китерәсе килә. Алар «белем бирү һәм культура-агарту эшләре дәүләт тарафыннан оештырылырга тиеш», диләр. Биредә гражданнарның хәзерге аң дәрәҗәсе хәлиткеч роль уйный алмый, диләр бөек фикер иляре... Чөнки халыкның аң-белем дәрәҗәсе кайвакытларда, аерым мәсьәләләрдә, тиешле дәрәҗәдән түбән дә булырга мөмкин. Гадел хәл итүгә булыша алмаска мөмкин.

— Без нәкъ әнә шундый чорны кичерәбез дә инде. Халыкны 60 ел буена, «милләтләр бетәчәк» дигән рухта тәрбияләп килдек тә, хәзер аннан кинәт кенә милли уяну, аякка басу көтәбез. Ул без теләгәнчә эшләмәсә — чынлап ачуыбыз килә. Алай булмый ул, егетләр! Халык белән бик нык эшлисебез бар әле безнең! Фидакарьләрчә эшлисебез бар! Әсәрләребез аша да, очрашып сөйләшүләр юлы белән дә һәм башка формаларда да...

— Мөдәррис әфәнде, газета-журнал битләрендә дә, китапларыгызда да Сезнең Тукай рухына бик якын булган әсәрләрегез еш кына дөнья күреп тора. Соңгы елларда алар арасыннан иң көчлесе — «Тукайдан хатлар» булгандыр, мөгаен. Чын мәгънәсендә революцион, чын-чыннан Тукайча поэма иде ул... Тукай чоры һәм бер үк вакытта безнең чор турында иде ул әсәр! Сез һәр ике чор хакында, һәр ике чордагы безнең милләтебез турында, аның уллары алдында торган иң-иң изге бурычлар хакында бик мөһим әчтәлек бирдегез... Үткән ел «Социалистик Татарстан» битләрендә басылган «Исәннәр турында балладалар»ыгыз да шуңа якын. Халкыбызның олы шәхесләре, каһарман уллары һәм кызлары үзәккә куела анда... Ә менә күптән түгел генә вакытлы матбугат битләрендә Сезнең «Революция дәвам итә» дигән шигырегез дә дөнья күрде. Шәп шигырь ул! Анда менә мондый юллар бар:

*Ревосын, Люциясен тапкан*
*Ана*
*Беркөн*
*революциясен тапмады...*

Билгеле, биредә шагыйрьдән үз әсәренең эчтәлеген сөйләттерү дөрес эш түгел. Ул инде бик тә образлы итеп әйткән. Һәм без аның ни әйткәнен тирән, киң мәгънәдә аңлыйбыз да... Ләкин шулай да бу юллар турында барыбер үзегездән берничә сүз ишетәсе килә бит.

— Нәрсә әйтим инде? Шигырь менә мондый бер очракка нигезләнеп язылды... Революция белән рухланып, дәртләнеп күпме татар хатыннарының үз балаларына әнә шундый исемнәр кушканын сез барыгыз да яхшы беләсез инде. Бу факт үзе генә дә без-

нең халыкның революциягә ничек ышануы турында сөйли... Мин белгән әлеге апа да әнә шундый булган: үз балаларына Рево һәм Люция дип исемнәр куштырган. Аларны тәрбияләп үстергән, кеше иткән... Әмма, ни гаҗәп, теге апа бүгенге көндә — бер ялгызы! Ревога да, Люциягә дә инде аналары кирәкми... Менә шундый хәл күрдем мин... Уйланган кешегә уйларлык нәрсәләр бар бит монда!

— Әйе, Сезнең шигырьдә бер дә юкка гына «Ана» сүзе дә, «Беркөн» сүзе дә аерым юлларга һәм баш хәрефләр белән язылмаган шул! Шигырь укучы анда Ана образы аша — бөтен татар халкын, ә Беркөн дигәндә бүгенге чорны, безнең халыкның бүгенге хәлен аңлый бит! Димәк, 1917 дә башланган революциянең татар өчен изге булган максатларын чынлап тормышка ашырырга кирәк! Аналар — революциянең яхшылыгын, изгелеген күрсеннәр! Ул революция бөтен халыкларга тигез, матур яшәү китерсен! Аналарның да, халыкларның да өметләре чынлап аклансын!..

— Мин үзебезнең укучыга ышанам. Ул шигырьнең ни икәнен, образлы фикернең нәрсә икәнен бик яхшы төшенәдер дип уйлыйм.

— Шулаен шулай... Ләкин без кайчакларда һәм кайбер кешеләр өчен, аңлатудан, бераз гына шәрехләүдән дә баш тартырга тиеш түгелбездер. Бигрәк тә хәзерге вакытта: илне берсеннән-берсе гыйбрәтлерәк вакыйгалар шаулатканда, әнә шул вакыйгалар күпләрнең игътибарын яулаган вакытта...

Тик менә бүген шигырь турында уйланган чагында, кайчак күңелгә шик төшерә торган сүзләр дә ишетелеп ала. Андый сүзләр үзәк матбугатта да, безнең үзебездә дә күренгәли. Хәтта чит илләрдә дә. Әш нәрсәдә икән? Мондый шөбһәле сүзләр тууның объектив җирлеге нидә?

— Һәрбер кимчелекнең, фаҗигәнең җирлеген үзең басып торган ноктадан эзләргә кирәк. Син кайда басып торасың? «Бу — минеке» дигән хис бармы? Трибунага чыккан кеше әлбәттә «бар!» дип кычкырачак. Чыннан да, анда менгән кешеләр өчен бар. Алар үз туклыклары белән канәгать. Ә халык өчен? Аның өчен дә бар: киселеп беткән урманнар бар, авылдан чыгам дисә — юлсызлык бар, кешечә яшим дисә — тыючы кануннар бар. Уйлап карасаң, элек тә шулайрак булган кебек. Әмма элек халыкның трибунасы — тапкыр сүз, иҗат, моң, сабантуй иде. Кыскасы, әнә шул зур иҗатның Әнкәсе булган — шигърият бар иде. Халык аллага ышанган кебек шигъри дулкынга иярә иде. Юкка гына безнең берничә йөз еллык шигъриятебезне көйгә салып, мөнәҗәт итеп көйләмәгәннәр. Ул аның трибунасы булган. Хәзер, ничә еллар инде, без аның трибунасыннан «туклык» турында сөйлибез. «Шаулый урман, гөрли болын, яфрак яра тал тирәк» дип, үлеп барган табигатькә мәдхия җырлыйбыз. «Алда көтә безне якты юллар», дип җыр сузабыз.

Уйлап карасаң, халык шул ук кара урман ул. Урманга нәрсә дип кычкырсаң, ул шул рәвешле җавап кайтара. Җавабы бераз тоныклана, әлбәттә. Әмма үз тавышың барыбер кире әйләнеп кайта. Безнең белән дә шундыйрак хәл булды. Шигырьдәге лаф орулар, табигать җимерелүгә битарафлык, йөрәк яраларына кимсетеп карау — халыкның, әнә шул кара урманның безгә җавап бирүе түгелме?!

Инде әлеге «объектив җирлек»кә килсәк, ул җирлек — син басып торган нигез ул. Мәшһүр Дәрдмәндне тыңлап карыйк әле:

*Ни газизрәк: бу Ватанмы?*
*Ах, туган кавемем газиз —*
*Ул изге кан белән сеңгән.*
*Изге сөткә ни җитәр,*
*Сөт калыр, Ватан китәр ул.*
*Сөт калыр, Ватан китәр!*

Мәсәлән, минем үзем өчен объектив җирлек булып шул сөт калды. Һәм тагын Тукай әйткән, хыялымда булган «Хөр мәмләкәт» бар. Һәм мин ул хыялның чынбарлыкка әйләнәсенә ышанып яшим. Шуңа ышанмасам, минем яшәвем, шигырь язуым бер тиенгә дә кирәкми!

— Таш һәм тимердән торган бүгенге тормышта үтә нәфис зат булган шигърияткә яшәү кыенлашмадымы икән? Сез ничек уйлыйсыз?

— Ташның һәм тимернең монда берниндә дә катнашы юк. Шигъриятне «нәфис зат» дип атау да сезнең кебек тәнкыйтьчеләрдән һәм кайбер язучылардан чыккан термин. Тукай, Җәлил, Туфан шигърияте «нәфис зат»мы? Бик тә ялгышасыз. Ә Твардовский? Әти-әнисе, бөтен нәселе сөргендә. Үзе тере классик. Аның әсәрләре белән яңа буынны коммунизмга алып баралар. Ә ул сөргеннән качып кайткан әнисенә бер чынаяк чәй дә әчертә алмый.

Кол Галинең язмышын без белмибез. Мин аңа җиңел булгандыр дип уйламыйм. Ә Тукай? Гасырлар катламын актарганда, Тукайҗан кичә генә арабыздан китте бит әле.

Ә бит Хәсән Туфанга ул чакта унөч яшь иде инде. Мин Тукайның туксан еллыгына поэма язып, шуны Сибгат Хәким һәм Хәсән Туфанга укыганда Тукайҗан рәнҗеп тыңлап утырды сыман:

*Җирдә апрель, гомум тантана.*
*Россия — йорт. Түбә кыегында*
*Боз сөңгеләр — аннан кан тама.*

Мин аңлыйм. Тукайҗанның рәнҗүен аңлыйм. Һаман шул хәлмени әле дип, рәнҗеп утыра иде Тукайҗан.

Әнә шул «гомум тантана» эчендә дә безнең шигърият Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановлар, Рөстәм Мингалим, Кадыйр Сибгатуллин, Зөлфәт, Эдуард Мостафин, Ләис Зөлкарнәев кебек шагыйрьләрне вакыты-вакыты белән бирә килде. Ә әгәр ул «нәфис зат» кына булса, тиз сыгылыр иде. Татар шигърияте руда кебек, янган саен чыныга гына барды! Совет чорында гына ул утыз җидене кичте. Кырык бер — кырык бишне кичте. Халык шагыйре Наҗар Нәҗми әйткәнчә: «Төрмәләрне ярып чыктың, Ялкынланып чыктың кире — хәтта фашист тегермәне тарта алмады сине». Бу туган телебез турында, шигъриятебез турында, Җәлил, Кәрим, Туфан турында әйтелгән сүз!

— Без, бүгенге кешеләр, барыбыз бергәләп һәм бик нык теләгән очракта, шигърият файдасына нинди әйбәт үзгәреш ясый алыр идек икән? Әз генә хыялланып алмыйбызмы?

— Күп хыялландык — җитәр! Әгәр дә бүген, максат итеп, партия «үзгәртеп кору» һәм «хәбәрдарлык»ны алган икән, мин бу чакыруны хыялдан әшкә күчү дип аңлыйм. Мин аңлау гына бер хәл әле, минем каләмдәшләрем дә моны аңларга тиештер ләбаса. Ә кем аңлатырга тиеш?! Мин кара акылым һәм шагыйрьлегем белән язучылар алдында шундый сораулар куям.

Инде «үзгәрешләр» ясауга килсәк, чишмә башын эзләргә кирәк. Дөрес, бу юнәлештә беренче адымнар ясалды. Кол Гали иҗаты халыкка барып җитте... Утыз Имәни, Акмулла, Кандалый барып иреште... Әле безнең Тукайга кадәрле яшәгән йөзләгән шагыйребез мөлдерәп күзгә карап тора. Әлегә без аларның исемен генә беләбез... Чишмәбезнең башы әнә шунда.

Икенче чишмәбезнең башы — аның бүгенге чыганагы. Ул чыганак — балалар бакчалары. Бармы ул бакчалар?! Авылларда булган татар балалар бакчалары өчен дә шигырьләребез, җырларыбыз юк икән бит! Әгәр дә әлеге «үзгәрешләр»не ясарга телибез икән, эшнең башы шунда! Бүгенге көндә нәниләр өчен генә язучы бер генә шагыйрьнең булмавы нинди аяныч?! Кая нәниләргә китапчыклар? Кая нәшрият?! Кая ул бүгенге нәниләрне тәрбияләрлек кадрлар? Нәниләргә Такташның «Ләйлә»сен чыгарыйк әле:

*Урамнар бүген сөенгән.*
*Ап-ак карга киенгән —*
*Ләйлә чанасын өстерәп*
*Чыгып китте өеннән.*

Бари Рәхмәтнең «Ялкау, Кире, Иренчәг»ен... Гамил Афзалның табигатебезгә дан җырлаган «Кар сулары» китабындагы шигырьләрен дә кәтә балалар. Юк, дип җыларга уйласаң, классикабыз коткара. Балалар әдәбиятының үз классикасы бар. Исәнбәт әле исән! Зәкия Туфайлова, Әминә Бикчәнтәевалар да бар. Ә бүгенге Рәшит Бәширне кая куясың? Безнең арабыздан яшьләй генә киткән Афзал Нигъмәтуллинны без күрми дә калдык бугай...

Хыялланып алырга, дисең. Безгә хәзер хыяллардан ваз кичеп, балаларга дип кирпеч-кирпеч калынлыгы (бәлки татар телен белмәгән үз балаларына дип?) чыгарылган китаплардан ваз кичеп, нәниләргә кайтып төшәргә кирәк. Безнең киләчәгебез аларда. Шигърият дип авыз чайкаганчы, без алар хакында уйларга тиеш.

Әгәр хәтерләсәң, Ринат Мөхәммәдиевнең хикәяте чыкты. Анда кәҗәне тартырга өйрәтү турында сүз бара иде. Бездә дә шул ук хәл килеп чыкты. Татар балалары белән. Дәрәҗәләр, лауреатлар, һ. б., һ. б. лар исеме аша кайбер шагыйрьләр балаларны ялган шигырьгә, үз-үзеннән көләргә өйрәттеләр. Алар «өйрәткән» балаларны төзәтер өчен ничә буын кирәк булыр икән?!

Күп хыялландык — җитәр! Шундый бер кызыклы шигырь китерергә телим:

*Мал барда — сәүдәгәр татар,*
*Үзе мал була мал юкта.*

*Язмыш аны ваклап сатты...*
*Ә заманы*
*Уптым сата талчукта.*

*(Ләис Зөлкарнәев)*

— Кайбер шагыйрьләр белән әңгәмә вакытында алар бүгенге поэзия өчен, аның абруен күтәрү өчен һичбер төрле өстәмә чаралар үткәрүне кирәксенмиләр. Моның өчен үзләрен җаваплы да санамыйлар... Әлбәттә, яхшы шигырь язу — поэзия абруен күтәрүнең иң төп юлы. Ләкин, бусын максималь дәрәҗәдә файдаланырга тырышкан хәлдә, безнең файдаланыласы башка юлларыбыз да бардыр бит әле...

— Әлбәттә, яхшы шигырь язу — поэзиянең абруен күтәрүнең иң төп юлы. Әмма күзәткәнең булса, чучканың борыны ялгашка тисә, аны кубарып ала алмыйсың. Безнең шигырьчеләребез, такмакчыларыбыз белән дә шулай килеп чыкты. Бу — аларның табигый халәте. Һәм мин аларны гаепләргә дә җыенмыйм. Бары тик чама чиген генә онытмасыннар иде. Шәехзадә Бабич әйтмешли:

*Ата-бабам сөйләшмәгән,— ди чучка,—*
*Ничек килсен синең сүзең дөрескә?*
*Үзем дә күрмәдем кояш дигәнне*
*Көне-төне кызынсам да тирестә.*

Мин Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Ренат Харис кебек шагыйрьләр бәреп чыккач, хәлләр үзгәрер — халыкның мең еллык классикасы белән алар бер бөтенгә әверелеп, ташкын барлыкка килер дигән өмет һәм сөенеч белән яшәдем. Тик ни гаҗәп: шигърнятебез киңәйде, тирәнәймәде. Шигърнятебездә зур шагыйрьләр күбәйде, укучыларыбыз азайды. Абруен такмакчылар да, шигырьчеләр дә төшермәде. Алар һәр чорда булган, бар, булачак. Абруен бөтен әдәбият белән бергә төшердек. Мисал өчен: зур-зур романнарга, повестьларга дивана кебек тиле-миле шагыйрь образлары килеп керде. Туфан Миңнуллин кебек шигъри драматург иҗатына да илһам котеп, җирдә ни барын да күрмичә, әллә кая айга, йолдызларга гына табынган шагыйрь килеп керде. Без бөтен зал белән аңардан көлдек. «Тукай, Туфан, Җәлилдән башка җитди шагыйрь була алмый, андыйлар хәзерге заман өчен түгел» дигән фикер укучының башына дыңгычлап тутырылды. Бүгенгедә андый фидакарьләр өчен җирлек юк, бүгенге халык андыйларны тудырырга сәләтле түгел дигән фикер үсте. Бу фикер әкренләп укучыларга да йокты. Чирү җәелде. Язучылар арасында шагыйрь икенче сортлы иҗат берәмлегенә әверелде. Бу фикернең җәелә баруын тоеп, иң авыр кичерүче Сибгат ага Хәким булды. Түзә алмагач:

*Яңа буын шагыйрьләрен көтә*
*Җәлилләрдән бушап тормәләр.*

— дип кычкырырга мәҗбүр булды. Буыны-буыны белән шагыйрьләрне Тукай-Такташ традицияләренә тугры булмауларында гаепләделәр. «Традицияләрне яклап» исеме астында дилбегә-дилбегә буе мәкаләләр чыкты. Кемнән яклап? Нәрсәдән яклап? Халыктанмы?! Мөстәкыйль фикер йөртә алырга кыюлык иткән шагыйрьдәнме?! Андый шагыйрьләрне гражданлык җитмәүдә гаепләделәр.

«Җәлилләр, Фатих Кәримнәр бәхетле булган икән... Алар ышанып китте, шигърнятебезнең могҗизалы теленә ышанып киттеләр». Сибгат ага Хәкимнең әнә шул сүзләре искә килеп төшә дә, аркалар чемердәп китә.

Шул кадәр дәрәҗәгә килеп җиттек, Рөстәм Мингалимнәре, Зөлфәтләре, Ренат Харислары, Кадыйр Сибгатуллиннәры булган шигърияттә ничә ел инде Тукай бүләгенә тәкъдим ителгән шагыйрь юк! Ләис Зөлкарнәев, Ркаил Зәйдуллин, Газинур Моратов булган шигърияттә Җәлил бүләгенә тәкъдим ителгән шагыйрь юк! Лаекмы-түгелме, биреләме-юкмы — бары тик татар шагыйре генә булмасын. Тәнкыйтьчеләр, язучылар, драматурглар «Сезгә рәхәт, сез юләр» дип күзгә карап көлеп йөри бирәләр. Шигърнятнең абруен без әнә шулай, бергәләп тырыша-тырыша, төшердек һәм бу афәт хәзер тауның яртысына җитте.

Тагын бер зур афәт — шигырь укымый торган язучылар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр барлыкка килде. Әниләреннән ваз кичкән балалар кебек, алар Шигъри Әнкәдән баш тарттылар. Прозада шигъри тел әкренләп юкка чыкты. Каткан агач тел барлыкка килде. Югыйсә бит Шигъри Әнкәбез һәрберсен дә әдәбият мәйданына изге теләкләр, зур өметләр белән озаткан иде.

Һәммәсе дә үзебездән, гаеп үзебездә! Безгә моны танырга кирәк. Үзебезнең кальбебезне турайтмыйча, үзебез чистармыйча — шигърнятнең абруен күтәреп булмаячак.

— Хәзер яшь буынны шигъри яктан тәрбияләү мәсьәләсе күпләрне борчый. Хәлне яхшырту өчен Сез нинди мөмкинлекләр күрәсез?

— Сиксән еллык бәйрәмен каршылаганда, 1979 елны «Яшь ленинчы» газетасында Нәкый ага Исәнбәт белән очрашу булган иде. Шул очрашуда сөйләүләрен язып барганмын. «Бүгенге яшь буынны шигъри яктан тәрбияләү» дигәч тә, кылт итеп хәтергә шул язмалар төште.

«Мәдрәсәләрдә дәрес һәр көн Г. Тукай, М. Гафури шигырьләрен көйләп әйтү белән башлана иде. Көйләп шигырь әйтү ул ритмга, тәртипкә өйрәтә, дисциплинага тарта, укучыларны тынычландыра, аларга көне буена җитәрлек кәеф бирә.

Шигъри тәрбия хакында янә шуны әйтәсем килә: үзең яраткан шигырьләрдән альбом төзүне мәктәпләрдә кагыйдә итеп кертәсе иде. Укучылар шигырь сайларга өйрәнәчәк. Яхшы шигырь сайлый белгән бала яхшыдан яманны аера белә. Яхшыдан яманны аера белү инде ул алга бик зур сикереш. Аның зәвыгы үсәчәк. Балаларның зәвыгын кайгыртыгыз, зәвыгын. Зәвыксыз бала илен дә, телен дә, ата-анасын да сата ала.

Без укып йөргән чакларда һәркемнең бәләкәй генә сандыгы һәм ул сандыктагы китап-дәфтәрләр янында бер шигырь альбомы була иде. Бармы ул хәзерге балаларда?

Латвиядә безне Ригадан ерак түгел бер авыл мәктәбенә алып киттеләр. Мәктәп музеен карап йөрибез. Музей өстәлендә — шигырь альбомнары. Һәр бала үзенең яраткан шагыйрьләренең шигырьләрен матур итеп күчереп алып, рәсемнәр белән бизәп, әнә шундый альбом төзи икән. Нинди күркәм гадәт, нинди күркәм эш! Шуңа күрә дә Риганың китап кибетләренә керсәгез, шигырь китапларын бик аз очратырсыз. Ул көнендә үк сатылып бетә. Без бәләкәй чакта да шулай иде. Авылга китап сатучы килсә, иң беренче итеп көйле китаплар сорый идек...»

Мин Нәкый агага өстәп шуны гына әйтә алам, укучыларыбыз яки укытучыларыбыз гына түгел, бер генә строфа шигырь дә яттан белмәгән шагыйрьләребез дә күп хәзер. Аллага шөкер!

Менә бит эшне нәрсәләрдән башларга кирәк!

— Ә шигырь китапларын халыкка җиткерүдә Сез бүген нинди ысуллар кулланыр идегез? Мондый сорау белән бергә үк күңелгә, билгеле, «Акмулла арбасы» да килә... Сезнең атаклы поэмагыздан...

— Китап тарату мәсьәләсе торгынлык чорыннан калган иң авыр мирас безгә. Сталин чоры безнең татар китабын халыктан аерып алып «карточка»га күчергән булса, торгынлык чоры безнең татар китабын чын мәгънәсендә талонга күчерде. Башкортстандагы миллион ярым кешебез китапсыз калды. Анда башта дәреслекләр бетерелде, укытучылар әзерләнмәү аркасында мәктәпләр ябылды. Мәктәпләр ябылгач, мәдәни үзәк булган Казан белән бәйләнешләр өзелде. Сез, шигырь китабын халыкка җиткерү хакында сорыйсыз. Мин мәсьәләне күп гасырлы татар китабы дәрәҗәсендә, 7 миллионлы татар халкы дәрәҗәсендә күз алдына китерәм. Әйтик, Мәскәү, Ташкент, Оренбург, Төмән, Әстерхан, Горький кебек, татарлар иң күп яши торган шәһәрләрдә «Татар китабы» дигән кибет ачып җибәрсәң, без аларга китап җиткерә алмас идек! Ә бәлки түрәләрнең бөтен курыкканнары да шуннандыр?! Мәсәлән, Кол Галинең «Кыйсса»сын 200—300 мең тираж белән чыгарсаң да, кулга тимәгән булыр иде. Җ. Зәйнуллинның «Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба»сын 300 000 данә бастырып әнә Татарстан китап нәшрияты бик яхшы эшләде бит!

Озакламый Хәсән Туфанның 90 еллыгы. Минем ишетүемчә, бу зур бәйрәмгә дә шагыйрьнең олы мирасы укучыларга тулы килеш җиткерелмәячәк әле. Инде йөзләгән хатлары, прозасы, язмалары хакында әйткән дә юк! Аның шигъри мирасының да бик азы басылган бит әле. Әлбәттә, бу очракта торгынлык чоры тарафдарларын аңлап була. Алар Туфанның исеме онытылуын көтәләр. Әмма:

*Халык барыбер үз ярасын таба,*
*Әрнесә дә таба актарып.*

Акмулла белән шулай булды. Дәрдмәнд, Сәгыйт Рәмиев иҗаты белән... Шагыйрьне вакытында халыкка җиткермәү бөҗралар тезмәсендә өзеклек барлыкка китерә. Хәсән Туфан мирасын халыкка җиткерү мәсьәләсендә бәлки безгә Уфадагы дусларыбызга да мөрәҗәгать итәргә кирәктер? Шикләнмим, алар моңа ике куллап алыначаклар. Һәм өч-дүрт ел эчендә ерып та чыгачаклар. Без бу очракта тагын бер яктан отар идек: Башкортстанда яшәүче күпме татар укучысы Туфанлы булыр иде!

Уфа дигәннән, күңелдә тагы бер әрнү яши. Ул да булса, Шәехзадә Бабич әтисенә: «Нигә мине эшсез үстердең?» — дип, үзеннән канәгать булмыйча, унбиш яшьлек Шәехзадә халыкка белем тарату өчен казакъ далаларына чыгып китә. Балалар укыта, шигырьләр яза. Уфага кайткач, иптәшләренең «җырларыңа ия бетәсе булмас әле, үзебез шикелле татарча сукалый торган малайлар беткән дисеңмени» дигән киңәшләрен тотып, «Шура» һәм «Акмулла» кебек зур мәртәбәле журналларда басыла башлый. Берничә ел эчендә Бабич Тукайдан соң иң зур фигурага әйләнә. Пушкиннан

соң Лермонтов булса, бездә Тукайдан соң — Бабич. 1919 елда 24 яшендә аны атып үтерәләр.

*Саф көмеш тик җырларымны*
*Җырламыйм алтын өчен.*
*Җырлыем тик саф көмеш тик*
*Саф йөрәк халкым өчен.*

«Халкым өчен».

*Утырдым мин таунның күкрәгенә,*
*Җырлар язам, җилкәй, исми тор!*
*Чишмәкәй! Тын! Әкрен!.. Чү! Шаулама!*
*Үткән гомрем, искә төшми тор!*

«Я» «»

Шагыйрьнең үлеменә җитмеш ел вакыт үткән, халык һаман җырлый. Бу җырларны инде төрле автор исеме белән дә, халык җыры дип тә ничә буын көйләп үсте.

Быел Чаллы районына кайткач, туганнарымда кунакта чагымда, Сарман районының Таулык авылында туып үскән агай борынгы көйгә сузып җырлап җибәрде:

*И кая ул көн, ки бездә шәп торулар бар иде.*
*Ду китереп дөньясын тик әйттерүләр бар иде.*
*Җыелышып бар дус вә ишләр, ресторанларга тулып,*
*Бер-бер артлы шешәләр бушаттырулар бар иде.*

Күзләр маңгайга менде: Бу бит — Бабич! 1915 елда язылган «Бер эчүченең зары» («аракы сату тыелгач») шигыре. Агайның беләгенә асылындым: син моны кемнән ишеттең?

— Бабай җырлый иде.

— Ә әтиең?..

— Бәлки ул да җырлагандыр, сугыштан кайтмаган.

Менә шундый хәлләр... Ни өчен Уфа дигәч, Бабич искә төште? Бабич анда укыганнан гына түгел. Башкортлар Бабичка карата егетлек күрсәттеләр. Бабичны халыкка тапшырдылар. Дөрес, безгә китаплары килеп җитмәде, шулай да егетлек егетлек дип атала инде ул. Бездә бер утыз ел элек шагыйрьнең иҗатын астын-өскә китереп бер җыентык чыккан иде. Инде аңа да утыз ел...

Менә без кайларга кереп киттек... Монда «Акмулла арбасы»н хәтергә төшерүең гаепле, әлбәттә. Бабич, Акмулла язмышлары — шулай ук татар китабы язмышы ул.

— Сүзебезнең башында «Тукай рухы» дигәндә Сез иң элек фидакарьлекне искә төшерәм дигән идегез. Ә бүгенге китапларда, шигърияттә әлеге фидакарьлек шактый кимегән түгелме?

— Кимегән генә булса, без мондый хәлгә калыр идекмени?! Бу нәрсә, китап һәм поэзия тирәсендә генә булса, без болай «аһ!» орып та тормас идек. Бу хәл бит безнең бөтен сфераларга кагыла. Бүгенге катлаулы дөньяда, гомумән, китап чыгару, агач җитештерү, металл кою, иген үстерү дигән төшенчәләр аерым гына яши алмыйлар. Алар бер-берсе белән меңләгән, йөз меңләгән, күзгә күренгән һәм күренмәгән җепләр белән бәйләнеп беткәннәр. Әйтик, басуда күкрәп иген уңды, ди. Аның урыласы бар, сугыласы бар, келәткә керәсе бар һ. б. һ. б. лар. Табынга килеп җиткән өлеше ничә генә процент икән аның? Кайсы гына тармакка карама, шул ук хәл. Партия шуңа да чаң кага. Җитәкчеләр шуңа җан ачысы белән халыкка мөрәҗәгать итә. Нидән килеп чыкты бу? Сәбәп нәрсәдә? Нәкъ менә син телгә алган фидакарьлекнең кимсетелүеннән, мыскыл ителүеннән. Фидакарьлек — фәкыйрьлеккә илтә торган юл булып әверелде. Фидакарьләрчә иген иккәннең — башта район, аннан өлкә планын үтәү өчен икмәген алып бетерделәр. Фидакарьләрчә фикерен әйткән шагыйрьнең шигырен бастырмыйча «ахмак!», «дивана!» дип кенә атыйлар иде. Кыскасы, фидакарьлек юлы — фәкыйрьлектә үтүче тереклеккә бара торган юлга әверелде.

Ә күпме асыл затлар сынды... Аларны да аңлап була. Аның да эти-әнисе, туган өе, туган авылы бар, сөйгән яры бар. Аның да «минем улым, кызым, балам, сөйгән ярым әнә кем булды» дип әйтерлек итеп яшисе килә. Аның да якыннарын сөендерәсе килә. Әнә шулай «Җинаятьме ул, яхшылыкмы — кушканны эшләсәң, тук яшисең» дип ышанган буын барлыкка килде. Әгәр хәтерләсәң, «Тукайдан хатлар» поэмасында мин аларны кызганып, болай билгеләп киткән идем: «...бер-икедән кала, калганнары Ишми түгел микән».

Ишми дигәннән, гафу итәрсең, тагын Хәсән Туфанга кайтам. Туфан — совет чоры

Тукае иде. Фидакарьлекнең үрнәген ул Сталин челтәрләре эчендә генә түгел, торгынлык чорында да күрсәтте. Торгынлык чорының иң зур тантанасы барганда, түрәләребезнең берсенә язган шигырен генә китерик:

*Безнең башта, энем, зур исәпләр,*
*Синең башта, энем, ни исәп?—*
*Кусәк икәнеңне күптән беләм,*
*Кем кулында соң син, и Кусәк!?*

Торгынлык чорын камчылаганда аның үзенең сатирик геройлары бар иде. Иптәш Хөлли, иптәш Пәси, Хөлли Мәймунович, Сатамшин һ. б. лар. Әмирхан Еникинең «Рәшә» повесте басылып чыккач, әнә шул Хөллиләр, Пәсиләр, Сатамшиннар мыжгып кузгалдылар. «Кояшлы көнебезне рәшә капламасын» дип сөрән салдылар. Туфан шул типларны гомумиләштереп үтергеч җавап бирде.

*Инде дә милләт тәрәккый итмәсә, иптәш Пәси*
*Доносны искә төшергән чыгышлар ясый-ясый*
*Ишми ишаннар эшенең дәвамы булып яши.*

Ишми ишанның кара реакция елларында нинди роль уйнаганы һәммәбезгә мәгълүм инде. Әнә шундый шигырьләрнең осталары булган Пушкин илә Тукай — Туфанның кулын рәхәтләнеп кысарлар иде!

Безнең шигъриятебез «фидакарьлек» дигән мөһим һәм асыл сыйфатны иң кыен вакытта да югалтмады. Торгынлык чоры эчендә кайнап, вакытсыз арабыздан киткән Зиннур Насыйбуллин: «Без котылдык күптән коллыктан, Котыласы калды безгә бары шул коллыктан калган холыктан», дип кисәтте. Егетләрнең башларына суга башлагач та, «Кыюлар барында тыюлар булачак, тыюлар барында кыюлар туачак» дип, юталлиюталли безне юатты ул!

Зөлфәтнең халыкка мөрәҗәгать иткән шигырь юлларын искә төшерик:

*Коммунизмга барган хәлеңдә*
*Тукаеңны уйлап нервыларың*
*Тартышачак әле тәнеңдә.*

Ә бит шигырь кулсыз гармунчының кулын эзләп тартышкан нервлары хакында гына бара иде сыман!

Зиннурның да, Зөлфәтнең дә әнә шундый дистәләгән әсәрләре мең авырлык белән булса да (нигездә Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан ярдәмендә), торгынлык чорында дөнья күрә алдылар. Фидакарьлеккә тәнкыйтьчеләр дә фидакарьлек белән җавап бирергә тиешләр иде. Әмма берсенең дә таң әтәче кычкырганга уянасы килмәде. Сәгыйть Рәмиевтәгечә: «Таң вакыты... Татар йоклый, ә мин куркып уянам».

— Әйе, дөрес сүзгә җавап юк! Тукайлар рухы яшәсен дисәк — без уяныргa тиеш! Ләкин шунысы бар: тәнкыйтьчеләр генә түгел, әле бик күп каләм ияләре уянырга тиеш! Аларны бәлки намуслары борчып уятыр дип, шушы урында нокта куйыйк!

Әңгәмәне тәнкыйть бүлеге редакторы
**Мансур ВӘЛИЕВ** үткәрде.

## Тәлгат Галиуллин

# «ЙОЛДЫЗЛАР ҖИТӘҺӘРКЕМГӘ...»

### ӘХСӘН БАЯНОВ ШИГЪРИЯТЕ ТУРЫНДА

Поэзиягә Әхсән Баянов илленче елларда Г. Афзал, Х. Камалов, Ш. Галиев, С. Сөләйманова, И. Юзеевлар белән бер чорда килә һәм, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин язганча, «әдәби җәмәгатьчелек арасында... яңачалык эзләүче язучы» буларак таныла. Лирик әсәрләре, «Диңгез шавы», «Сез аңларсыз мине», «Сәяхәтнамә», «Кышкы чәчәкләр» поэмалары, «Төнге бәхәс», «Тыйнак кеше турында» балладалары, «Һәйкәл» шигъри драмасы аны тормыш киңлекләрен, күңел тирәнлекләрен ачу рәвешен туктаусыз төрләндерергә омтылучы шагыйрьләр белән бер рәткә куйды. Проза һәм драма әсәрләрендә дә Ә. Баянов дөньяны һәм кешене күбрәк шагыйрь буларак, хисси кабул итә. Бу юнәлештә тәнкыйть фикере бердәм.

Ә. Баяновлар буыны иҗатка шактый катлаулы чорда килде: әдәбиятта дусларча сөйләшүгә, үзара макташуга корылган, битараф рухлы, салкын әсәрләр өстенлек итә иде... Рифмалы прозага якын, салмак, хиссез, әмма дилбегә буйлы озын, күләмле тезмәләр ачык метафораны, лиризмны кысрыклый иде... XX съездан соң илдә урнаша килгән яңа иҗтимагый рух тормышның үзәгендә туган тирән фикерле һәм бай кичерешле поэзия таләп итте. Яңа буыннан яңача фикерләү соралды.

Г. Афзал белән Ш. Галиев үткен, кыю эчтәлекле, афористик яңгырашлы, җор телле сатира һәм юмор әсәрләре, халык лирикасы байлыгыннан үсеп чыккан җырлары, самими шигырьләре белән халык рухында үз урыннарын таптылар. Х. Камалов үтеп киткән сугыш фаҗигасен реалистик тасвирлау юлына чыкты. С. Сөләйманова татар поэзиясенә хатын-кызның мөлаем образын, якты нур сирпеп торган бай рухи дөньясын, кичерешләрен алып керде. Ә. Баянов исә иҗат юлын шәхси, интим лириканы үстерү, йөрәк хисләрен шигырьдә тулырак яңгырату нияте белән башлап җибәрә:

*Бер генә сүз белә минем йөрәк,*
*Бу сүзне кем аңа өйрәткән?*
*Һәр тибеше белән кабатлана,*
*Китми бер сүз, китми йөрәктән:*
*— Яратам, яратам...*

— ди ул 1951 елда ук язылган «Бер генә сүз белә минем йөрәк...» шигырендә.

Алдагы елларда да шагыйрь үз замандашларының рухи һәм интеллектуаль-фәлсәфи эзләнүләрен психологик төгәллек, төрледән-төрле төсмерләре белән ачу юнәлешендә хәрәкәт итә. Заманында тәнкыйтьтә «Ә. Баянов тар, субъектив хисләре, иҗтимагый тормыштан ерак эчке кичерешләре белән артык мавыга» дигәнрәк фикерләр дә ишетелгәләде. Чыннан да, шагыйрьнең беришә әсәрләрендә әрну, сыктау, сызлану мотивлары урын ала. Бу — табигый. Чөнки тормышта кайгы-хәсрәте дә, авырлыгы да булып тора, барысы да кеше башыннан йөри. Иҗтимагый тормышыбыздагы бозыклыклар, халык язмышы да борчымый калмый шагыйрьне. Әйтик, «Сез аңларсыз мине» поэмасында сүз яшьлек һәм үсмер еллары сугыш һәм аннан соң аяныч дәверләргә туры килгән буынның катлаулы әхлакый эзләнүләре, хисле йөрәкнең шул чор вакыйгаларын яңадан кичерүе турында бара. Вакыты белән кемгәдер (фашизм тудырган заманга, бозык шәхесләргә һ. б.) үпкә сизелеп үтсә дә, алар үзәк тенденциягә әверелми, шагыйрь күбрәк тормышның матур яклары, күңелдә якты-җылы эз калдырган сәхифәләре турында уйлана, шулар уяткан өмет белән яши.

Ә. Баяновның шатлык һәм авырлык, табигать күрке һәм тормыш низагълары турында уйланулар рәвешендә язылган уңышлы әсәрләренә замана нурлары сирпелә, тормышчан рух төшә. «Кимә, бәгърем, кара күлмәк», «Син ки һаман Кояш нурларыннан тукылган кызыл-сары күлмәк»,— ди ул «Кимә кара күлмәк» (1968) шигырендә. Әлегик уйлану рухы, психологик халәтне үзәккә алу индивидуалистик лирика ярларына алып чыкмый. Икенче яктан, хәзер без индивидуалистик лирика белән өркетү дәверен узып, плюрализм турында сүз алып барабыз түгелме?

Ә. Баянов — халык җырлары рухына, халык хыялы тудырган образларга якын юлдан атлаучы шагыйрь түгел. Һ. Һейне, М. Лермонтов, Г. Лорка әсәрләрен өлге итеп алып шигырьләр язса да, ул әдәби остазлары турында җәелеп сөйләргә (дөрес, тәнкыйтендә ул Пушкин, Блок, Есенин, Маяковский, Твардовский, Такташ, С. Хәкимнәргә ихтирамы турында еш искә төшерә), аларга багышлап шигырь язарга яратмый. «Әгәр уянсалар» әсәре Сибгат Хәкимгә атап язылса да, анда сүз Җәлил һәм, гомумән, шагыйрьләр каһарманлыгы, хәзерге буынның элгәрләре каршындагы әхлакый бурычы турында бара.

Төрле жанрларда көч сынавы, шигъри ритмикасының иркенлеге, фикер белән хиснең бердәмлегенә омтылуы, иҗади тынгысызлыгы белән ул татар язучыларыннан Ә. Фәйзи белән Ә. Давыдовка якын юлдан атлый. Тематик һәм шигъри диапазонның киңлеге дә шуңа бер дәлил. «Йолдызларга карап юлда барам», «Дәрья эчендә янып», «Безнең күгебез», «Мин — диңгез», «Йолдызлар җитә һәркемгә» h. б. шигырьләрендә олы дөнья, йолдыз, диңгез, дәрья сурәтләре шәхес омтылышларының олылыгын, ниятләренең изгелеген ачуга буйсына. Мәхәббәт, олы дөнья кешене алга, яктыга, рухи һәм физик батырлыкка әйди, рухландыра.

*Батырлыгың дәрья эчендә янып*
*Хәбәр сала: «Кара, аңлагыз,*
*Җирдә тынмас өермәләр булмас,*
*Тынсын, э сез туктап калмагыз!»*
*(«Дәрья эчендә янып», 1954).*

Табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтнең катлаулана барган бер дәверен киеренке кискенлек, фәнни-техник революциянең файдалы һәм зарарлы якларын кискен калкытып куюы белән «Сәяхәтнамә» поэмасы җәмәгатьчелекнең игътибарына лаеклы әсәрләрнең берсе булды.

Туган җир, аны фидакарь хезмәте белән бизәүче кешеләр турында уйланулар «Икмәк» (1969) шигырендә гомумиләштерү төсмерен ала. Шагыйрь икмәкне югары аһәң белән олылый, аны йөрәккә тиңли, җир белән чагыштыра, «Бөтен тормыш килә икмәктән» дигән нәтиҗәсен ясый. Бу очракта күтәренке интонация, тантаналы хөкем үзен аклый:

*Синең кулда — сөю, хезмәт, дан.*
*Синең кулда — Тормыш!*
*Нык тот аны —*
*Дөнья яралган көчтән,*
*Икмәктән.*

Туып-үскән җире, иҗатына илһам биргән төшенчәләр, шәхесләр турында язганда Ә. Баяновның вакыты белән кытыршы, катлаулы, прозаизмнар белән тукылган стиле җыйнаклана, ягымлы, табигый агышлы төсмер ала:

*Туган җирләр ерак миннән,*
*Арада еллар ята.*
*Уйлар, еллар әйләнә дә,*
*Шул якка борылып кайта.*
*(«Туган җирләр ерак миннән...», 1960-67).*

«Кыр казлары белән канат җилпеп...» шигыренә халык җырларыннан килгән кешелекле моң, илаһи рух үтеп керә. Фольклорда аерылу, сагыш, юксыну символы буларак яшәгән кыр казлары образы кичереш, вакыйга үсешенә бәйле рәвештә психологик төсмергә баеп, үсеп китә:

*Бу дөньяда кем дә йөри шаулап,*
*Бәхет, өмет алда кеткәндә.*
*Кала тып-тын, кыр казлары кебек,*
*Мәңгелеккә таба киткәндә.*

Бәхетнең иҗтимагый һәм әхлакый эчтәлеген ачу, аның һәр чорда, һәр шәхес язмышында үзенчә булуын күрсәтүгә омтылу — Ә. Баянов поэзиясенең үзәк мотивларыннан берсе. Кеше әүвәл бәхет артыннан җәяү чапкан, аннан атка, машинага күчеп, аны тәмам куып җитә язган. Ә хәзер ул бәхетне самолетка, ракетага утырып эзәрлекли, әмма куып җитә алмый, тегә, бәхет дигәне дә тизлеген арттыра бара.

*«Шаяртасың, беләм, тотармын!» — дип,*
*Айкыйм мин җир өозен.*
*Йолдызлар кицлеген.*
*«Түз, иптәш, түз» — димен.*
*Эзлимен.*

*(«Бәхет артыннан», 1964).*

Һәр аерым шәхеснең бәхете олы дөнья хәлләренә, якын кешесенең аны аңлавына, йөрәк хисләрен сиземләвенә бәйле икән. Кешене яшәтә һәм яшәртә торган олы мәхәббәт хисе турында да Ә. Баянов, берәүне дә кабатламыйча, үзенчә яза белә. «Тик гадәттә калды сөю, дидем...», «Су кызымы чыккан яр буена»...», «Тәрәзә юа кызлар», «Шагыйрьләр һәм сандугачлар җырлый...», «Сөйгәнемә гомер теләдем...», кебек шигырьләрендә ул табигый матурлыкка, кешене рухи үстерә, күтәрә торган мәхәббәткә мадхия җырлый.

Кайчакларда мәхәббәт сагышы, аерылу газабы, юксыну хисе ничаклы авыр, кыен булмасын, үткән шатлыклы мизгелләрне лирик герой урамнардан, җилдән, яфраклар шавыннан эзләмәсен, аның нечкә күңелен тоташ моң каплап китми. Яшәү һәм тормыш рухы, бәхетле көннәр истәлеге авыр тойгыны җиңәргә ярдәм итә:

*Яфракларның кичке шавын тыңлап,*
*Шундый рәхәт үйга мин батам.*
*Сине уйлап, ахры, табигатьне,*
*Бар дөньяны сөям, яратам.*

*(«Бәлки, мине күптән оныткансың...», 1958).*

Ә. Баяновның мәхәббәт лирикасы кеше күңеленең иң нечкә борылышларын, хисси, мәгънәви төсмерләрен, сизелер-сизелмәс нюансларын тулырак ачу юнәлешендә үсә килә. Эчке анализга омтылыш, психологик медитативлык көчәя. «Күк самолет алып китте сине...» (1965), «Бер сәбәпсез тилереп күлүләрең...» (1968), «Син кичермә» (1968), «Хыянәтче төсле минем күзләр...» (1968) шигырьләрендә ул мәхәббәт рухын, аның күпьяклы чагылышларын тулырак сынландыру юнәлешендә Дәрдмәнд белән Туфан, рус поэзиясеннән А. Ахматова белән Б. Пастернак эзләнүләренә якыная бара.

*Сөюеңне әйткәнең юк, дисең,*
*Әллә чынлап яшереп йөртәммә?*
*Әйт, күзләрем берни сөйләмиме,*
*Караганда сиңа текәлеп?*

Алдагы юлларда лирик герой мәхәббәтен үз-үзен тотышының, тән хәрәкәтенең башка күренеш-чагылышлары (куллар, гәүдә, йөз) аша сөйгәненә җиткерү турында хыяллана һәм, кискен күчеш ясап, хисләрен тавышка күчерә. Ләкин сөйгәне инде еракта яши, ул аны ишетә алмый икән. Шигырь юлларына чишмә суы кебек саф, моңсу, нечкә, назлы хис йөгерә: «Хәзер беләм — артык ерак шул без, Ишетмәссең берни беркайчан».

Шул рәвешле, Ә. Баянов лирикасының үзәк мотивлары — туган җир һәм мәхәббәт, «Баш иярга мөмкин» (1974) шигырендә ул һәвәслеген ике юлга сыйдыра алган: «Тезләнергә мөмкин бары туган җиргә, баш иярга — бары мәхәббәткә!»

Ә. Баяновның кешелекле лирикасы бүгенге киеренке тормышны тасвирлау белән генә чикләнми, ул киләчәк белән яши, уйлана. Тынычлык һәм дуслык темасы, яңа үзгәрешләр чорына кергән иле белән горурлану, аның иртәгәсенә тирәнтен ышану хисе гражданлык лирикасының үзәгендә ята.

«Мират» поэмасы кешене күтәрә, үстерә торган конкрет хезмәтне сурәтләве белән отышлы. Аның герое хис-кичереш дөньясында гына бикләнеп калмыйча, иҗтимагый-әхлакый проблемалар уртасына килеп чыга, шунда кайный. Хезмәтнең конкрет чагылышын, эш кешесенең холкын-характерын сурәтләүдән бигрәк, шагыйрь аның нәтиҗәсен, гомуми пафосын, дәртен ачуга игътибарын юнәлтә. «Шигырьдән түгел, поэмалардан башланып китте Әхсән Баянов,— дип язды С. Хәким.— Ул миңа «Мират» поэмасы белән ачылды. «Мират» кешеләрне үзенә җәлеп итте, бәхәс кузгатты».

Чыннан да, Ә. Баяновның шагыйрьлек мөмкинлекләре поэмаларында иркенрәк ачылып китте. Аның һәр яңа поэмасы сюжеты, рухи халәтне ачу рәвеше, фикер сөреше, ритмик, интонацион һәм җөмләви рәсемнәре буенча бер-берсеннән нык аерылып торса да, аларны төп уртак сыйфат бер дисбегә тезә. Бу — шәхси башлангыч, лиризм. Дөньяны шигъри иңләү — «Сез аңларсыз мине» автобиографик поэмасын, эпик ва-

кыйгалы «Яшел мәйдан» һәм драматик, трагик «Һәйкәл», «Алтын Кашбау» әсәрләрен якынлаштыручы үзәк сыйфат. Шул ук вакытта шагыйрь, нигездә, реалистик фикерләүгә таянса да, символика, шартлылык, романтик гомумиләштерү алымнарыннан да баш тартмый. Бу сыйфат бигрәк тә «Һәйкәл» әсәре өчен характерлы.

«Яшел мәйдан» (1957) поэмасында тормышны идиллик кабул итү, ал төсләр һәм табигать үзе биргән бизәкләр белән тасвирлау алгы планга чыккан иде. Олы жанрда эшләү тәҗрибәсенең җитешмәве үзен сиздерә иде. Бөек Ватан сугышына чаклы һәм аннан соңгы авыл тормышы, сабан туена кагылышлы җырлы-уенлы күренешләр, җиңел яуланган уңышлар, фашизмга каршы көрәштә бер кулын калдырган элеккеге мәйдан батыры Җамалиның бәхетле халәтен («Җилдә шат җилпенә инде кесәдән чыккан җиңе...» кебек мажор юллар) язуга 80 нче еллардагы Ә. Баяновның «кыюлыгы» җитмәс иде. Чынбарлыкны берьяклырак күзаллауга алып килә бу адым.

Әмма поэма шаян, йөгерек интонациясе, халык җырлары рухына якын стиле белән күңелдә кала.

*Алай иткән юк безнең лә,*
*Болай иткән юк безнең;*
*Яшьникләргә сыерлыкмы —*
*Йөрәкләрдә ут безнең.*

Алтмышынчы еллар башында иҗат ителгән «Сез аңларсыз мине» әсәрендә сюжет кору осталыгы, сурәтлелек алымнары байый, драматизм көчәя. Соңгы сугыш һәм аның артыннан килгән авыр, фаҗигале елларны кеше язмышы, үзара мөнәсәбәтләрдә туган катлаулы бәйләнешләрдә тасвирлау тәҗрибәсе арту күз алдында... Поэманың герое — үсмер егетне чынбарлык төрле яклап сыный. Бозык, эчкерле, мәкерле кешеләр, сөйгән кызын заводтан чыкканда капшаулар аның күңелен рәнҗетә. Әмма киләчәк матурлыкка һәм хакыйкать тантанасына ышаныч аның характерын чыныктыра:

*Вакыт килер, җиребездә булган*
*Барлык капкаларны ачарбыз.*
*Шул яклардан килеп күңелләргә*
*Үрмәләгән барлык бациллаены*
*Себереп ташларбыз.*

Поэмада тәнкыйди рух көчле агым булып яши. «Махсус машиналар, больницалар, бикле ашханәләр, дачалар һәм башкалар» турында гына кайгыртып, җылы урын өчен намусын сатуга да әзер бәндәләрне тәнкыйть итүе белән поэма безнең көннәрнең яңарыш рухына һәм демократизмына якын.

Ә. Баянов — әзер капитал исәбенә яшәп, бер яулаган үрдә торып калмый. Туктаусыз эзләнү, уйлану нәтиҗәсендә аның дөньяга карашы байый, фикерләү культурасы үсә, язу стиле төрләнә, катлаулана. Үзгәреп-яңарып торган замана, аны тирәнрәк чагылдыруга омтылу үзгәртә шагыйрьне. «Кышкы чәчәкләр» (1972-1974) поэмасы — шул эволюциянең бер мисалы.

Такташ шигъри мәктәбен үзенчә кабул иткән Ә. Баянов бу поэмасында «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә расланган әхлакый сафлык, мәхәббәткә, дуслыкка тугрылык кебек проблемаларны яңа җирлектә үстерә. Такташ иҗатына хас романтик рух, иркен ритмика, шаян, уйнак образлар «Кышкы чәчәкләр» поэмасының буеннан-буена үтеп, әсәргә яңа нур, яктылык, җылылык сирпиләр.

*Шагыйрь,*
*Җил,*
*Мин — өч дус —*
*Кочаклашып*
*Карлы көннәр аша узганда,*
*Җил — сыбызгы, тышта ялгыз калса,*
*Морҗаларны кага буранда:*
*— У — у — у — у — у!*
*Җәйге тын кичләрдә*
*Тәрәзәдән якты бөркелә.*

Шул кереш аккорд поэма үзәгенә алынган вакыйга агышын, стилен билгели, геройның мәхәббәтендә алдануын, дусларында ялгышуын, әмма оптимизмын, ахыр чиктә акыллы башлангычның тантанасына ышанычын югалтмавын ачык буяуларда тасвирларга мөмкинлек бирә. Дөрес, романтик күпертүнең куелыгы («Тау-ташларны

эретердәй шәфкать балкый кызның төпсез күзендә»), тискәре образларның күбрәк булуы, сентименталь патетика («Кулын сузган Матур бер кыз, кәфенле һәм чәче тузган», «Хәсрәт атлы диңгез кичәбез») «Кышкы чәчәкләр»не Такташтан ераклаштыра. Бу төр мавыгулар исәбенә тәфсилле озынлык барлыкка килә. Шул ук вакытта әлгәрләр традицияләрен яңарту — Ә. Баянов иҗатының диапазонын бермә-бер киңәйтеп җибәрә.

Шигырь белән язылган «Һәйкәл» драмасы — батырлык, илеңә һәм антыңа, мәхәббәтеңә тугрылык идеяләрен нигез итеп алган олы хисле, күләмле, фикерле әсәр.

*Батырларга һәйкәл — шушы дөнья,*
*Рәссамнар күк, бизәп, төзеп аны үзебезчә,*
*Саклап аны бөтен көенчә,*
*Тапшырырбыз яңа чорга!*

Гражданнар сугышы батырлары белән бүгенге тормыш арасында якынлык табып, кешене үстерүче, тарих белән бәйләүче изге хатерне олылап, шагыйрь, гуманизм байрагын күтәреп, явызлыкка, мәкергә, сатлык җаннарга каршы көрәш юлына чыга.

«Һәйкәл»гә С. Хәким югары бәя бирә. «Әхсән Баяновка туктаусыз әзләнү хас. Шул күзлектән караганда, «Һәйкәл» драматик поэмасы — язучының иҗатында ирешкән иң зур уңышларның берсе. Автор киң колачлы бу әсәрендә художник буларак та ныклап ачылып җитә».

Алтмыш яшьлек юбилеен Ә. Баянов «Алтын кашбау» исемле шигъри трагедиясе белән каршылады. 1987 елда «Казан утлары» журналында басылган бу әсәрдә шагыйрь тарихилык рухы белән заманча фикерләүне кушу, үткәннең олы сәхифәләрен бүгенге югарылыктан килеп бәяләү юнәлешендә «Һәйкәл»дә башлаган киеренке эзләнүләрен дәвам иттереп, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт ачышларына таянып, сәнгатьчә кыю һәм үзенчәлекле ачышлар ясый алган. Бу әсәрдә Ә. Баянов иҗатының күп сыйфатлары яңача ачылып китә.

Хыял канатында ерак үткәнгә юл алып, шагыйрь чәчәк атып үсеп утырган Болгар иленең Бату урдалары тарафыннан җимерелү, хәрабә хәленә китерелү вакыйгасын тасвирлый. Авыр сынау минутларында кешеләр икегә бүленә. Берәүләр дәррәү дошманга каршы күтәрелә, йә җиңә, йә үлә... Үз мәнфәгатьләре белән генә яшәгән, илен, халкын, намусын, мәхәббәтен сату исәбенә булса да гомерен озынайту турында гына кайгырткан Балтамар, Изух кебек бәндәләр дошман ягына авыша, үз халкын кыса, әзәрлекли, рәхимсез изә, җәзалый башлый (Балтамарны агу эчереп үтергәннән соң, чибәр кыз Алсылу бу социаль күренешкә төп-төгәл бәя бирә: «Җыен хәшәрәтне өскә алып чыккан Дәүләт үзе чыгачактыр юкка»). Аларның мәкерле, сатлык җәтмәсенә җайдак кыздай беркатлы, самими ышанучан яшьләр генә түгел, дөньяның ачысын-төчесен татыган, тышкы кыяфәтләре белән хөрмәткә лаеклы авыл картлары да килеп эләгә. Искелек хорафатлары һәр чорда дошман тегерменәнә су агыза. Үләтне, суешны, кырылышны туктату өчен алар, бик борынгы йола буенча, иң укымышлы, иң акыллы бер затны күккә корбан итәргә карар кылалар. Шул кыргый ышаныч буенча илнең «соңгы күзе», галим һәм фикер иясе, халык бәхете өчен көрәш җитәкчесе Баян үләргә тиеш була.

*Сынап бактык без күп эмәлләрне,*
*Тик берсе дә китермәде файда.*
*Кан эчендә ята ил һаман да.*
*Сынамакка калды соңгы чара:*
*Тәңгә дучар итеп үзебезне,*
*Күккә биреп карыйк соңгы күзебезне,—*

ди надан картларның берсе. Баян аларның күзләрен ачарга тырышып карый:

*Кычкырыгыз күккә һәм сорагыз,*
*Кирәкме аңа кыргый бу йолагыз?*
*Адәм үзе уйлап тапкан моны,*
*Адәм үзе — йолаларның колы.*

Халыкны кораллы көрәшкә күтәргән Җикү, Баяннар ирлек һәм туган җиргә бирелгәнлек үрнәге күрсәтеп, һәлак булалар.

Трагедиядә ул хакта турыдан-туры әйтелмәсә дә, ай-кояшны, йолдызларны, халкын сөеп яшәгән Баян образында «Кыйссаи Иосыф» дастанының авторы, атаклы Кол

Гали чалымнарын сиземләве кыен түгел. Тормыш юллары, язмышлары арасындагы якынлык Баянга биргән олы бәядә дә күренә:

*Җирне көндез ни яктырта? Шул — бер кояш.*
*Кемнән сорап бакма, җавап ике булмас.*
*Үзе галим, үзе катиб, зур зиһенле.*
*Атап булмый аннан башка бер исемне*
*Ул — Баян бәк.*
*(«Беренче карт»).*

Шул ук вакытта рухи өлгергәнлек белән физик матурлык үрнәге булган Баян образының потенциаль мөмкинлеге, Болгар илендә тоткан роле, үз чорының фәлсәфи, әхлакый проблемаларын үстерүе ахыргача ачылып җитмәгән дигән тәэсир дә кала. Әйтик, шул ук Балтамар әсәр тукымасында, сюжет үсешендә, Баян белән чагыштырганда, зуррак урын били.

Җыеп әйткәндә, «Алтын кашбау» трагедиясе халык фаҗигасенә игътибарлы булуы, вәхшәтне, явызлыкны, сатлыкны инкарь итүе белән безнең чорга якын һәм бүгенге кешенең киеренке эзләнүләренә аһәңдәш.

Ә. Баянов — психологик контрастлар, сурәтле янәшәлекләр шагыйре. «Сез аңларсыз мине» поэмасында, мәсәлән, геройның эчке халәте, яшәү белән үлем арасында яткан тормыш күренешләрен янәшә кую алымы белән ачыла:

*Тукта! Бу ни? Өскә агач ава.*
*Ә тегендә гармун тарталар.*
*Агач ава, өскә үлем төшә.*
*Ай-яй,— акрын төшә икән ул!*

Ә. Баяновның уңышлы әсәрләренә лаконизм, фикер төгәллеге, идеяне тар мәйданга сыйдыруга омтылу хас («Борынгыдан килгән кара хиска...», «Су буенда», «Элегия», «Чәчләребез безнең чәчкә тигән...», «Күз карашың...», «Бу җырларда минем яшьлек гомерем...»).

Сурәтле фикерләү чараларын үстерү юлында яңачалык эзләү — афоризмга тартым лирик гомумиләштерүләр тудыра: «Тик шатлыклар гына каңгылдаша, ә сагышлар була тавышсыз». Кыскалыкка, кискенлеккә һәм контрастлыкка омтылыш поэзиясен «Син ышанма минутларга — ышан елларга!» кебек көчле, тәэсирле юллар белән баета. («Ышан — елларга!», 1968).

Ә. Баянов «шигъри ритмика бай һәм төрле булырга тиеш» дигән фикеренә турылыклы. Ул проза элементларын шигырьгә алып керү, сүзләрне юлдан юлга күчерү алымнарыннан, авазлар яңгырашыннан, катлаулы рифмадан иркен файдалана:

*Башын иеп, җанлы факелга борылып карамый*
*Узды егет. Ут белән шул*
*Шаярырга ярамый.*
*(«Су буенда»).*

*Чишмәләр юк, болытлар узды,*
*явып өлгермичә.*
*(«Элегия»).*

«Хыял төсле матур кара чәчләр» сынландыруы «Диңгез шавы» поэмасының романтик рухына килеп тора. «Җәйге баллада»га хас трагизм табигатьтән катлаулы образлар эзләү юлына алып чыга: «Күктә болыт — йөкле ана, Тудырыр ул яшен». «Аерылышу — җәйге күкрәү түгел, Ул — корылык, булмый сагышсыз» («Кыр казлары белән канат җилпеп...», 1966) кебек сыйдырышлы, тирән мәгънәле җөмләләр күңел түрендә урын алуга лаеклы.

Ә. Баянов иҗаты, поэзия төрле һәм кҿтелмәгән юнәлешләрдә үсәргә тиеш, дигән хакыйкатькә инандыра. Шагыйрь тасвирчылыктан, тышкы күренешләрне хикәяләүдән эчке халәткә атлый, поэзиядә психологик анализ ысулларын үстерүгә зур көч куя. «Уйладым да кабат...», «Сөйгән җирем...», «Агып бара...», «Тыйнак кеше турында баллада» кебек әсәрләрендә Ә. Баянов рухи дөньяны сурәтләү юлларын катлауландыра бара, шатлык һәм кайгы, мәхәббәт һәм нәфрәт, ышану һәм алдану шикелле төшенчәләрне җисемләштереп, тормышчан ситуацияләрдә тасвирлый. Озак еллар дәвамында эзләнүләрен бер юнәлештә алып баруы аның омтылышлы, максатлы һәм үзенчәлекле шагыйрь булуы турында сөйли.

**Рәфыйк Нәфыйков**

# ТУКАЙ ҺӘМ ХАТЫН-КЫЗЛАР

Халкыбызның күренекле улы, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тормышы һәм кабатланмас иҗаты турында күп яздык, күп укыдык. Шулай да биографиясендәге ачыкланып җитмәгән кайбер фактлар һаман да кала килә әле.

Белгечләребез арасында бүгенге көнгә кадәр «Тукай хатын-кызлар белән аралашырга яратмаган» дигән фикер яши. Бу чыннан да шулай микән соң? Әлеге язмамда мин «гүзәл яртыбыз»ның шагыйрь тормышында күпмедер дәрәҗәдә роль уйнаганлыгын күрсәтүне максат итеп куйдым.

Г. Тукай Уральск басмаларында дөнья күргән әсәрләрендә хатын-кыз азатлыгы проблемасына шактый зур урын бирә. Хатын-кызның хөрлеген, ирләр белән тигезлеген кайнар яклый; аларның, ана буларак, балаларын Ватанга лаеклы ул-кызлар итеп үстерүдә төп көч булуларын ассызыклап күрсәтә. Ул заманда мондый юнәлештә эш алып баруны буржуаз кануннарга, дини догмаларга каршы көрәш чарасы итеп карарга кирәктер. Һәрхәлдә, мондый эчтәлекле язмалар мөселман руханиларының артта калган катлауларында кискен каршылыклар китереп чыгара.

Безгә Г. Тукайның матбугат чыгышлары тәэсирендә янсә аның турыдан-туры катнашы белән язылып, «Фикер» газетасында басылган кайбер язмалары билгеле. Укытучы Ә. Биктимеров, мәсәлән, кайбер татарларның хатын-кызга карата начаррак мөнәсәбәтен кискен тәнкыйть итә, кызларны белем алырга, кияүгә яраткан кешеләренә чыгарга өнди. Тукайның шәриге, «Фикер»нең Гурьев шәһәрендәге махсус хәбәрчесе Я. Моради да хатын-кызның аяныч язмышы турында ачынып яза. («Фикер», 39 сан, 1906 ел, 22 октябрь). Газизә Шәрипова исә казакъ хатын-кызлары исеменнән чыгыш ясый. Ул якты киләчәкләре хакына мөмкин булганның бөтенесен дә эшләргә әзер икәнлекләрен хәбәр итә. Дала тормышының арттлыгыннан зарлана, мәктәпләр юклыгы, хатын-кызларның ирләре тарафыннан кыерсытылуы, алар йортында хезмәтче ролендә яшәүләре турында яза. Шул ук вакытта казакъ хатын-кызларын тигез хокуклылык һәм белем алу өчен көрәшкә өнди. Газизә Шәрипова үз телендә шигырьләр дә яза.

«Фикер»нең 1907 ел 22 февраль санында «Бер татар кызы» имзасы белән (ул Оренбургта яшәүче Зөләйха исемле туташ



*Уңда — Гарифә Гаделшина. Тукайның танышы. Уральск. 1912—1913 еллар.*

тан булып чыга) думага депутат булып сайланган мулла Х. Госмановка «Йә хатыннар файдасына сөйлә, йә тавышыңны

чыгарма» дип исемләнгән ачык хат басыла («Фикер», 1907, 22 февраль). Шул ук елның 13 маенда исә Себердә яшәүче хатын-кызлар да газета аша үз сүзләрен әйтәләр. Ә Уралда яшәүче казакъ хатыннарының ирләрен «кешеләрне кыйнап йөрмәсеннәр өчен» хезмәттән кайтаруларын сорап дума члены Бородинга телеграмма җибәрүләре турында хәбәр газетада Тукай һәм аның дуслары тарафыннан игълан ителә.

Тукайның күп кенә мәкаләләре, очерклары, шигырьләре нәкъ менә алдынгы карашлы татар хатын-кызларының шул рәвешчә яктылыкка, азатлыкка омтылуын чагылдыра да инде. Аның хатын-кызларга, аналарга дан җырлаган, күңел кылларын тибрәтә, кешеләрнең акылларын һәм хисләрен әсир итә алган әсәрләре кемгә генә мәгълүм түгел икән? Кем белә, мондый югарылыкка ирешүдә, бәлки, ул таныш булган хатын-кызларның да ярдәме тигәндер?

Тукай аралашкан, аның тормышында билгеле эз калдырган иң беренче хатын-кызлар, мөгаен, ике Газизә булгандыр. Берсе — әтисенең сеңлесе, икенчесе — әтисенең беренче хатыныннан туган кызы. Шагыйрьнең истәлекләреннән билгеле булганча, икесе дә аңа гаять җылы мөнәсәбәттә яшәгән, Габдулла да аларны бик яраткан.

Мин үзем Уральск чоры буенча шагыйрьгә таныш булган дүрт Фатыйманы беләм. Аларның берсе — Тукайның туганнан туган апасының кызы. Дөрес, бу сөйкемле кыз үзе аның тормышында әллә ни зур эз калдырмаган. Мин аны Ватан сугышы алдыннан Уральскига баргач күрдем. Борынгы татар стилендә киенгән зифа буйлы чибәр хатын иде ул. Фатыйма Белоусова Алма-Атадагы хәлле генә кешегә кияүгә чыккан булган; бу шәһәргә икенче Фатыйманың — Уразованың хәлен белергә үтеп барышлый тукталган иде. Аларның ни турыда сөйләшкәннәрен хәтерләмим инде. Тукай исемен телгә алуларын гына беләм. Шагыйрь үзе Ф. Уразованың үги малае, мәдрәсә шәкерте Насретдин белән дус булган.

Ә өченче Фатыйма — Тукайның шактый яхшы танышы. Аның язмышы шагыйрьнең иҗатында да чагылыш тапкан. Ул бәхетсез татар кызы турындагы күләмле шигырен шушы Фатыймага багышлаган.

Революционер язучы Г. Колахметовның ерак туганы Бибифатыйма Колахметова исә башка Фатыймалардан алдынгы карашлы булуы белән аерылып торган. Ул татар хатын-кызлары арасыннан чыккан беренче мөгаллимәләрдән исәпләнгән. 1906 елның 10 июнендә «Фикер» газетасы, Тукай инициативасы белән, бу сәләтле кыз турында мәкалә бастыра. Октябрь революциясеннән соң Ф. Колахметова Совет властен ныгыту юлында актив эш алып бара. Бик күп яшь белгечләр тәрбияли. Аның



*Бибиәсма Билюкова. Уральск, 1907—1908 еллар.*

бер укытучысы З. Утюшева Уральскида актив комсомол работнигы була, аннан соң, 1940 елда, Казан университетын тәмамлый. Ярты гасырга якын гомерен заводта инженер-химик булып эшләүгә багышлый. Бүген ул лаеклы ялда. З. Утюшева кайчандыр Тукайның дусты, аның белән бергә укыган Шакир абый Утюшевның кызы Мөнәвәрә Утюшева белән дә дус була. З. Утюшева да, М. Утюшева да шагыйрьнең дусты С. Билюковның улы Шурикны яхшы белгәннәр. Малайның әти-әниләре гражданнар сугышы чорында үлгән булырга тиеш. Ул мәктәптә техник хезмәткәр булып эшләүче Хәлимә апа Билюкова гаиләсендә тәрбияләнгән.

Дүрт Фатыймага бәйле мин белгән мәгълүматлар менә шулар гына. Шулай да, эзләнгәндә, алар аша бүгенгене үткәннәр белән бәйләргә мөмкиндер дип уйлыйм.

Шагыйрьнең Уральск буенча тагын бер танышы — Гайшә Җомагулова барлыгын да беләм. Бервакыт аның каты авырып киткән улы Хәсәнне Тукай мәдрәсәдән өйләренә алып кайта. Шуннан бирле аңа бу квартирага еш килеп йөрергә туры килгән. Гайшә ханым ачыккан шагыйрьне «хәзинәдә бары» белән сыйлап җибәрә торган булган.

Тукай тормышыннан менә тагын бер

эпизод. Элеккеге казак Усман Сәгыйтов Бохара тирәсендә бакчачылык белән шөгыльләнгән. 1905 елның җәендә, полиция типография эшчеләренең забастовкасын оештыручыларны эзәрлекләгәндә, Тукай һәм аның иптәшләре С. Насыйбуллин, Г. Кәлтиев ай буе бу тарлауда яшеренеп ятканнар. Биредә Тукайны яхшы белгән ниндидер хатын-кыз да яшәгән, ул аларга кичәннән килгәнчә ярдәм иткән.

Без Тукайның дусты Мортаза исемле кешенең хатыны Нәгыймә апа Шәрипова турында да бик аз беләбез. Нәгыймә апа, беренче ире үлгәннән соң, атаклы «сәгатьче Камали»га кияүгә чыга.

Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең беренче коммунистларыннан Гарифә Гаделшинаның исеме дә хаксыз онытылды. Революциягә кадәр аны төрмәгә дә утырталар, этләрдән дә талаталар. Октябрь революциясеннән соң Гарифә апа үзен сәләтле педагог, тәрбияче итеп танытты. Тукайны белүчеләрнең Г. Гаделшинаны белмәүләре мөмкин түгел. Бу хакта хәбәр итүче булса, шагыйрьнең тормышын һәм әдәбият тарихын өйрәнүдә янә бер адым ясалыр иде.

Тукай әтисе ягыннан туган тиешле С. Әмировның кызы Әсманы белгәнме, юкмы, дип тә бәхәсләшергә була. Әсма апа миңа таныш Г. Төхфәтуллинның хатыны иде. Моны вакытында белмәвем бик кызганыч. Ә артык тыйнак холыклы Гариф абый бу хакта үзе сөйләмәде.

Утызынчы еллар башына кадәр Уральскида узган гасыр азакларында туган Рәхилә апа Даутова яшәде. Ул шәһәрнең А. С. Пушкин музеена, андагы Габдулла Тукайга багышланган бүлеккә еш килеп йөрде. Рәхилә апа, үзенең бала вакытында, өйләренә шагыйрьнең килеп йөрүен сөйләргә ярата иде (Даутованың әнисе Тәминә ханым үз заманы өчен һич тә хупланмый торган профессия кешесе — биюче булган). Рәхилә ханым Уральскидан китәр алдыннан Тукай утырырга яраткан кәнәфине, борынгы стена сәгатен һәм шагыйрьнең, артына гарәп хәрефләре белән «Рәхилә туташка» дип язылган фоторәсемен бүләк итте.

Ятим кыз Бибиәсма Билюкованың язмышы исә бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган. Сөйләүләренә караганда, ул Тукайның беренче мәхәббәте булган.

Мөәзин кызы Я. Гафиятуллина белән аның дусты Г. Яруллина да шагыйрь белән яхшы таныш булган. Аның түбәндәге шигъри юллары шушы кызларга багышланган (бу хакта 1900—1903 елларда Уральскида Тукай белән бергә укыган Г. Хикмәтуллин истәлекләреннән белдек):

*Укыгыз, кызлар, укыгыз,*
*Куп хәлләрне белегез!*
*Остабикәләрне ташлап,*
*Мәктәпләргә керегез!*

Я. Гафиятуллина гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казанда яшәгән. Кызганыч ки, бу хакта беребез дә белмәде. Бәлки аның туганнары Тукай турындагы истәлекләрне тулыландырырга ярдәм итәр?

Мин кайчандыр Тукай белән таныш булган Мәрьям Галиева һәм Зиннәт Баткаеваны күрү бәхетенә ирештем. Алар шагыйрьнең төннәр буе типографиядә куль-язмалар өстендә утыруын искә алдылар. Кызлар аңа кайчакларда ашарга алып кереп торган булганнар.

Уралдагы социал-демократик оешманың иң актив эшлекләреннән Надежда Шилова турында да әйтеп үтәргә кирәк дип уйлыйм. Тукай Н. Шилованы яхшы белгән, аның белән демонстрацияләрдә һәм митингларда булган, революцион йомышларын үтәгән. Шилова 1981 елга кадәр Мәскәүдә яшәде. Тукайның аның дусларыннан А. Бокаушинаны, О. Донскованы белмәве дә мөмкин түгел. Ул аларның якшәмбе мәктәпләренә йөреп, лекцияләрен тыңлаган.

Мин бу язмамда Г. Тукайга Уральскида яшәү чорында таныш булган кайбер хатын-кызлар турындагы мәгълүматларга тукталырга тырыштым. Аларның шагыйрьнең шатлыгы һәм сыкрануы да, илһамчысы һәм сызлануы да булуларында шигем юк. Чордашларының тормышлары белән якынрак танышу шагыйрьнең эчке дөньясын, хиссият чыганагын тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итәр.

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР

***

«Казан утлары» журналының чираттагы санын кулыма алганда һәрвакыт тирән бер дулкынлану кичерәм. Чөнки күз алдымда татар әдәбияты күгендә якты йолдыз булып кабынып калган язучылар гәүдәләнә. Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим һ. б. күренекле әдипләр белән очрашкандай булам. Минем бу сүзләремне бүгенге әдәбиятыбыздагы күренекле язучыларыбызның әсәрләрен бәяләмәү дип карарга кирәкми. Хәзер дә бар талантлы язучылар, шагыйрьләр. Аларның әсәрләрен яратып, аерыла алмыйча укыйм мин.

Соңгы елларда «Казан утлары» бик күп яхшы әсәрләр бүләк итте безгә. Шул әсәрләрнең берсе турында үземнең фикерләремне язмакчы булам. Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү»ен укып чыккач, ничә көннәр, төннәр тынычлык таба алмадым үземә. Әллә ул чорны күреп, күп нәрсәне ишетеп үскәнгәме?

Халкыбыз кичергән авыр, фаҗигале хәлләрне чын дөреслектә сурәтләп биргән бу кешегә — Ибраһим Салаховка мең рәхмәт. Бу әсәрдә мин утлы чоңгылларның берсеннән икенчесенә ташланган Ибраһим Салахов һәм аның кебек кешеләрнең көчле ихтыярлы булуларына сокландым. Язучы бөтен явызлыклардан өстен, фаҗигале язмышыннан никадәр көчле! Менә шуңа күрә дә ул бөтен авырлыкларны җиңә алган. Ахырда әле, сөргеннән кайткач, язмыш сынауларын да чын ирләрчә үткәрә белгән.

Әдәбиятта мондый әсәрне күптән көтә идем. Хәсән Туфан язармы әллә дип өметләнеп яшәдем. Шәйхи Маннур, әтигә язган бер хатында, шәхес культы елларында әдәбиятыбыздан вакытсыз киткән күренекле язучылар турында язарга ниятләнүен сиздергән иде. Шәйхи Маннур да юк инде.

Шәхес культы җилләре кемнәргә генә тимәде ул чорда! Минем әти — мәктәп директоры, татар әдәбияты укытучысы — көтмәгәндә эштән чыгарылды. 1938 елда Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш һ. б. «гаепле» язучыларның әсәрләрен яшереп саклаганы өчен аны «халык дошманы» сыйфатында эштән кудылар. «Халык дошманына безнең арада урын юк»,— дип кычкырды кайбер бушбугаз укытучылар. Ә икенче көнне, мәктәп коридорында линейка ясап, безне — өч кызны пионердан чыгардылар.

«Халык дошманы балалары пионер галстугы тагарга лаек түгел»,— дигән сүзләре белән безнең йөрәкләргә мәңге җуелмас яра салды мәктәп директоры (әти урынына Туктабаев сайланган иде). Шул арада берничә яшь укытучы безнең галстукларыбызны чишә башлады. Миннән бер яшькә олы апам, галстугын чиштермәс өчен, елап яшь укытучының кулларына ябышты. Ләкин алар «халык дошманы» балаларына аяусыз иделәр. Туктабаев үзе апамның галстугына килеп ябышты, ерткалап булса да аны чишеп алды. Апаның кулында галстукның бер почмагы калган иде, аны учына кысып тоткан килеш өйгә йөгерде ул һәм: «Мин галстугымны бирмәдем»,— дип елап җибәрде. Мәктәп директорының кансызлыгын күреп, укучылар тораташтай катканнар иде. Икенче көнне берничә укучы безгә пионер галстугы китерделәр. Без исә Туктабаев күрмәгәндә генә галстукны тагабыз, ә ул класска килеп керә башласа сумкага яшереп куябыз. Минем апам галстук таккан килеш мәктәп директоры каршына килеп чыга, аны шулай җәфалый, галстук тагып йөрүе белән үч ала иде.

Ул тентүләр һаман күз алдымда. Әти, китапларны яшикларга тутырып, базга яшергән иде. Идән астыннан калын, кара тышлы Г. Ибраһимовның томнарын, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш әсәрләрен чыгара башладылар. Шулар арасында Һади Такташ, Хәсән Туфанның шигырьләре бар иде. Әле дә хәтеремдә: Хәсән Туфанның шигырьләр җыентыгы юка гына, кечкенә генә китапчык иде. Баздан чыккан китапларны мичкә ыргыта торалар, китаплар яна, дөрләп яна! Мин китапларның әле берсенә, әле икенчесенә ябышам. «Бу бит Һади Такташ китабы, ул үлгән бит инде, нигә халык дошманы булсын ул»,— дип китапларга сарылам. Мине этеп җибәрәләр. Ул кешеләр — кансыз, җансыз, ерткычлар булып әле дә күз алдымда гәүдәләнәләр. Утта янган китапларга карап елап торганым бүгенгедәй хәтеремдә. Утта янган китаплар көле... Әллә шуның өчен микән — «Казан утлары»н

кулыма алганда шул фаҗигале минутлар күз алдыма килә. Утта янган китаплар белән минем әдәбиятка булган изге хисләрем дә янгандай булды ул чакта. Бу турыда уйласам, җаным хәзер дә өши.

Сугыштан соңгы беренче еллар. Мин Казан педагогия институтына укырга килдем. Әдәбиятны яратуым аерата көчле иде. Мәнә монда мин әдәбият дөньясында кайнадым дияргә була. Балачакта ук әти миңа: «Сине, кызым, Такташлы Казанга алып барырмын»,— дип әйтә иде. Тик миңа Такташсыз Казанны күрергә насыйп икән. Тукай клубында уза торган бер генә әдәби җомганы калдырмыйм. Өлкән язучылар белән беррәттән, әдәби җомгада яшь язучылар, шагыйрьләр чыгыш ясый. Күңелле. Кызык. Тик ни аяныч: Муса Җәлил дә, Гадел Кутуй да, Фатих Кәрим дә, Хәсән Туфан да юк. Бу турыда мин әдәбияттан дәрес бирүче өлкән укытучыларга мөрәҗәгать итәм:

— Ни өчен Галимҗан Ибраһимовны өйрәнмибез?

— Нигә Муса Җәлил әдәбият программасыннан төшерелгән?

— Әкиятче Абдулла Алишны өйрәнмибезмени? Нигә? Ник? — дигән сорауларны өсте-өстенә бирәм.

Бервакыт мине деканатка чакырып алдылар. Ул вакытта ук профессор исеме белән йөргән бер укытучы миңа:

— Сиңа, Себер кызына, нигә Муса Җәлил кирәк булды әле? Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин дип сөйләнеп йөрсәң, әдәбият факультеты ишеге артыңнан ачылмаслык ябылыр. Моны акылыңа сыйдырып куй,— дип, миннән аңлатма язуы яздырып алды. «Г. Ибраһимовтан, М. Җәлилдән башка татар әдәбиятын күз алдыма китерә алмыйм,— дип язганым өчен, мине югары стипендия бирү исемлегеннән төшерделәр.

Урынсызга гаепләнгән күренекле шәхесләрнең төрмәләрдә, сөргеннәрдә җәфалануларын, авыр язмышларын уйлап, әдәбият белгече, доцент Җамал апа Вәзиева чын йөрәктән кайгыра иде.

— Харап иттеләр бит Галимҗан Ибраһимовны. Хәзер аның кайда күмелүе дә билгеле түгел. Ә никадәр талантлы язучылар сугыш кырында ятып калды. Муса Җәлилне, Гадел Кутуйны, Фатих Кәримне саклап кала алмадык. Болар бит әдәбиятыбызның җәүһәрләре, иң көчле затлары. Никадәр талантлы кешеләрне югалттык. Кайсы милләт үзенең күренекле уллары белән шулай эш итте? — дип әрнеп сөйли дә тына иде Җамал апа Вәзиева. (Әле без ул вакытта Бөек Ватан сугышында 30 татар язучысының үлеп калуын белми идек). Җамал апа белгәндер бу санны. Гадел иде ул, кычкырып әйтмәсә дә, йөрәге сыкраганын ике сүзеннән үк аңлый идек.

1931 елда Шәйхи Маннур (әтинең дусты, гомеренең соңгы көннәренә кадәр әти белән хат язышып яшәде) әтигә Һади Такташның ничек үлүе турында язды. Кайбер истәлекләрдә әле хәзер дә, Такташның ничек үлүен ачыклыйсы бар, дип язалар. Бу — Себердә яшәгән әтигә, аның гаиләсенә күптән билгеле, ачыкланган мәсьәлә. Хәзер хәбәрдарлык заманы, шулай булгач, нигә инде Һади Такташның ничек үлүен, аның сәбәпләрен ачыклап бирмәскә? Г. Кутуй һәм Һ. Такташка да бит ул елларда нахак бәлаләр ягучылар күп булды. Андый кешеләрнең исемнәрен әйтергә вакыт җитте шикелле.

Рашат Низамиевның «Язмыштан көчлерәк» әсәре — «Тайгак кичү»гә күпмедер аваздаш. Илебезнең иң уңган, талантлы кешеләрен күрсәтергә теләмәү, алардан көнләшү, карьера өчен көрәш елларын Рашат Низамиев композиторның иҗади үсеш чорына бәйләп күрсәтә.

Татарстан Композиторлар союзы рәисе Н. Җиһанов һәм театр директоры И. Әүхәдиев нәрсә уйладылар икән Фәрит Яруллинны күрәләтә сугышка җибәргәндә? Бер карасаң — көлке бит. «Шүрәле» балетына репетицияләр үтә, артистлар барысы да үз урынында, тик композитор Фәрит Яруллин гына сугыш кырында утлы чакрымнарны ерып бара. Аның исемен телгә алучы да юк. Бу очракта автор курыкмыйча дөресен әйтә: «Теләк булганда Фәрит Яруллинны алып калу мөмкин иде»,— ди.

Билгеле, Фәрит Яруллин барысын да сизгән. Үзенә кыерсытып караулар, җитәкчеләрнең мөнәсәбәтен күрми-сизми калмаган ул. Моны хатлардан кайбер өзекләр ачыклап бирә: «Казан, гомумән, иҗат итә башлаганнан бирле минем тәгәрмәчкә таяк тыгудан башканы белми әле..., намусларына көч килмәсә, хат язсыннар»,— дип хәбәр итә ул хатынына.

Рашат Низамиевның бу әсәрен яратып укыдым. Бер якта — йомшак күңелле, мәхәббәткә турылыклы, олы җанлы ата, үзенең «Шүрәле»се өчен янып-көеп яшәүче Фәрит Яруллин һәм аның кешелекле остазы Генрих Литинский, икенче якта — үзенең карьерасын гына өстен күрүчеләр... Мәхәббәт белән нәфрәт күңелне айкый бу әсәрдән соң.

Моңлы Тукай, тормыш һәм матурлык җырчысы Һади Такташ, илнең батыр улы Муса Җәлил, нечкә лирик язучылар Әмирхан Еники һәм Сибгат Хәким, олы җанлы Гомәр Бәширов һәм Хәсән Туфаннар — минем гомерлек юлдашларым. Алар һәрвакыт хезмәткә дәрт, матурлыкка илһам биреп торалар. Алар аша мин әдәбият, тел дәресләрендә укучыларда әхлак сыйфатларын, эстетик зәвык, югары патриотик хисләр тәрбиялүгә

ирештем. Минем мәктәбемдә — әдәбият кабинетында кемнәр генә булмады. Зәки Нури, Әхмәт Исхак, Атилла Расих, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Мәрзия Фәйзуллина, Хәсән Сарьян, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов, тел һәм әдәбият дәреслекләре авторлары Бәйрәм Мифтахов, Гөлчәчәк Әдһәмова һ. б. белән аралашып, Казаннан аерылмыйча яшәдем. Барлык фәннәр рус телендә укытыла торган бу мәктәптә, җирле диалектта көчен югалтмаган шартларда, укучыларда бөек Тукай теленә, әдәби телгә мәхәббәт уяту өчен күп көч куйдым. Бу өлкәдә минем дә юлымда күп киртәләр булды. Ана телен һәм әдәбиятын укытуның изге бурычы — халыклар арасындагы дуслык һәм бердәмлек хисләрен тәрбияләү, ана теленә, туган халкыңа мәхәббәт тәрбияләү. Бу бурычны үтәүдә күп тырышлык куярга туры килде миңа.

Әдәбият-сәнгать кешеләренең тормышы, иҗаты турында язылган әсәрләрне тыныч кына укый алмыйм хәзер. Фаҗигале язмышлы сәнгать кешеләре турында чын йөрәктән кайгырам, кешегә карата гаделсезлек эшләгән кешеләргә карата күңелем өши, җаным әрни.

**Люция ХӘБИБУЛЛИНА,**
РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. Төмән өлкәсе,
Төмән районы, Акъяр авылы.

***

Шул «Туган тел» булды тел ачкычым,
Бәхет ачкычым да шул булды.
Туннель азагында ак нур булды,
Миңа язмыш сузган кул булды.

Тургеневка терәк булган кебек
Ерак Парижларда үз теле,—
Туган телем, бары синнән алам
Илһам җырын, куәт-көчемне!

***

Онытмагыз: тарих — кысла түгел,
Алга әйләнә аның көпчәге.
Юл куймаслар коллык камытына
Яңарыш һәм иҗат көчләре!

**Фоат МОРТАЗИН.**
Ялта шәһәре.

## Заман зары

*(Тукайга ияреп)*

И туган тел, и матур тел,
Әби-бабамның теле!
Аңлый алмаганга еглыйм
Әткәм-әнкәмнең телен.

Сөйләшәләр күп вакытта
Мин белмәгән телләрдә.
Өйрәтмиләр туган телне,
— Кирәксез тел! — диләр дә.

Иң элек бу тел белән
Әткәм сөйләшми башлаган.

— Бу заманда яраксыз,— дип,
Аннары әнкәм ташлаган.

— Йом-йом күзең, йолдызым! — дип,
Юк мине көйләүчеләр.
Айлы төндә әкиятләр дә
Юк инде сөйләүчеләр.

И туган тел, и матур тел,
Әби-бабамның теле!
Имчәктән аерган сыман
Аералар синнән мине.

**Хәмид ВӘЛИДИ.**
Казан шәһәре.

***

Кайбер әдәби әсәрләрне укыгач, мин беравык исем китеп, хәйран калып утырам. Язучының теленә, акыл-фикеренә, әсәрдәге вакыйгаларга бирелеп яши башлыйм. Шул вакыт язучыга рәхмәтләремне әйтеп хат язасым килә. Тик минем әлегә хәтле язганым юк иде. Барлык укучылар да шулай хат яза башласа, язучының аларны укырга да вакыты калмастыр, шикелле.

М. Мәһдиевнең «Казан утлары» журналында (1989 ел, 1—2 саннар) басылган «Бәхилләшү» повестен укыгач, түзеп тора алмадым, хат язарга булдым.

Күршеләрнең өй китапханәсеннән язучының «Мәңгелек яз», «Торналар төшкән җирдә» дигән китапларын да алып укыдым. Бу әсәрләрдәге телнең байлыгы, моңлылыгы мине хәйраннар калдырды. Рәхәтләнеп тел дәрьясында йөздем, андагы җөмләләр белән сөйләшергә тырышып йөри башладым.

Былтыр Бразилия язучысы Габриэль Маркесның «Ялгызлык» романын укып чыккан идем. Кыям Миңлебаев аны татар язучысы язгандай итеп тәрҗемә иткән. Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләрен дә бөтен моңы белән башка телгә тәрҗемә итсәләр икән?

Рауза ВӘЛИЕВА.<br>Чистай шәһәре.

***

«Казан утлары» журналын 50 ел буена бер генә санын да калдырмыйча укып баручы бер укучыгыз булам мин. Журнал, ялгыш килми калган очраклар булганда да, эзләп табып укымыйча калганым юк. Гади генә итеп әйткәндә, журнал — гаҗәп әйбәт, киң эчтәлекле, бар нәрсәсе күңелгә якын булган бер китап ул. Рәхмәт сезгә, кадерле редакция хезмәткәрләре!

Тагын да зуррак рәхмәтләремне язучыларга әйтәсем килә. М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» дигән моңсу повестен укыгач, менә шундый хат язарга батырчылык иттем. Башка язучылардан аермалы буларак, М. Мәһдиев үз күңелендә сакланган хәлләрне гаҗәеп осталык белән сурәтләп бирә белә. Ул кадәр дә хәтер, искә төшерә алу сәләте ничек була икән кешедә! Без дә олы кешеләр. Ә хәтеребез бик начар икән безнең. Бүгенге кешеләрнең хәтерләре бик күп нәрсәләрне оныткан. Хәтерсез кешеләр күбәя бара.

Рәхмәт Сезгә, кадерле язучы! Гаҗәп, Сез яшәгән төбәктә яшәмәсәк тә, сүзләр шул ук, җырлар шул ук булганнар икән бит. Ул Җәмил дигән баланың җырлаган җырларын мин дә бәләкәй чакларда җырлап кешеләрне елата торган идем.

Кешеләргә карата Сездә тамчы да ачу юк. Сез ачулана да белми торгансыздыр. Әдөресен әйтү ул, минемчә, ачулы булу түгелдер. Сез дөресен язасыз. Ә кайберәүләр ачуланган була, ләкин әсәрләре күңелгә җыр булып урнашып кала алмый. Сезгә күптән инде Тукай премиясе бирелергә тиештер.

РӘЙСӘ.<br>Казан шәһәре.

## ХӨРМӘТЛЕ ЯЗУЧЫБЫЗ!

«Бәхилләшү» әсәрегезне озак кына укырга куркып йөрдем. Әмирхан Еникинең «Соңгы китабы» кебек авыр тәэсир итәр дип. Ә укый башлагач, чапкан атны туктатуы ничек авыр булса, мин дә шул хәлдә идем.

Сезнең кебек зур иҗатчыларга хат язуы да авыр. Әйтергә теләгән сүзләрне, фикерләрне ничек итеп җиткерергә соң? Мактауга лаеклы бу әсәр. Бик моңсу, бик авыр, бик күңелле һәм бик акыллы да. Сезнең повесть белән бергә, безнең өебезгә мәрхүм булган әбибабай, әти-әни, күршеләр, белешләр, кардәшләр, авылыбызның гореф-гадәтләре — барсы да терелеп, терелеп, яныбызга кайттылар.

Бала чакның татлы хыялларын, авыр кайгы-хәсрәтләрен, авылыбызның матурлыгын табигатьнең сафлыгын, авыл хатын-кызларының нечкә хисләрен, халкының эшчәнлеген, зурлыгын терелтүегез өчен шулар белән бергә яшәү бәхетен бүләк иткән кыйммәтле мизгел өчен — чын күңелдән зурлыйм үзегезне!

«Бәхилләшү» — минем өчен дә туган авылым белән җылап-сыктап бәхилләшү бул-

ды. Без дә үз иркебез белән авыдан киткән кешеләр түгел. 1937—1938 еллардагы ачы язмыш безне дә аямады. Әсәрегездә мин үземне дә таптым.

**Сөембикә ИХСАНОВА.**
Менделеевск шәһәре.

Хөрмәтле Ринат!

Кулыма каләм алып, Сезгә хат язарга әле генә мин укып чыккан «Кенәри — читлек кошы» дигән романыгыз мәҗбүр итте. Әсәрегез миндә тирән уйлар кузгатты. Романыгыздан соң «Истәлек өчен — Гыйлемханга» дигән повестегызны кабат укып чыктым. Шуннан ныклы карарга килдем: автор үзенең әсәрләре турында минем фикерләремне белергә тиеш! Сезнең турыда библиографик белешмәдән кыска гына булса да мәгълүмат алдым. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшлисез икән. Җамал Вәлиди, Габдрахман Кәрамнарнең әдәби һәм фәнни мирасларын тикшерү өстендә эшләп, уңышлы нәтиҗәләргә ирешкәнсез. Җамал Вәлидиләрне белгән яшьләр күбрәк булса, халкыбызның киләчәге ышанычлы булыр. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләвегез — тормышка, әдәбиятка күз карашыгызны киңәйтергә ярдәм иткәндер, мөгаен. Язган әдәби әсәрләрегездә бу бик нык сизелә.

Минем уйлавымча, Сез безнең әдәбиятта яңа «дулкын» барлыкка китерәсез. Ул юкка чыкмасын, һаман да көчәеп, әдәбият дәрьясының зур агымына әйләнсен иде.

Ринат! Сезгә бер тәкъдимем дә бар. Нәфис фильмнар өчен игълан ителгән конкурста «Кенәри — читлек кошы» белән катнашырга кирәктер Сезгә. Романыгызның сюжеты, диалог һәм монологлары — үзе менә дигән сценарий. Бу әсәрдә бүгенге тормыш, үткәннәр белән үрелеп, оста нечкәлек белән, психологик яссылыкта тулы ачылган. Һәр геройны тасвирлавыгыз бик үткен һәм ышанычлы. Авыл егете Фидаилнең үз авылын, җир-тамырын, хис-тойгыларын һәм, ниһаять, телен-мәдәниятен, кешеләргә, халыкка ышанычын югалту фаҗигасе гаилә югалту белән тоташа. Әсәрнең үсүе, чишелеше бик мавыктыргыч һәм көтелмәгәнчә. Милли җирлек турында Фидаилнең уйланулары, профессорның, аның малае һәм оныгының утызынчы елларда башланган канлы тормыш баскычларын үтүләре — безнең тормыш түгелмени?! Канлы дилбегәне тоткан Сталин һаман исәндер кебек тоела миңа. Җантимер һәм аның атасы — эт атучының язмышы гына да бер фильм төшерерлек.

Язасы килгән сүзләрем шуның белән тәмам. Сау-сәламәт булыгыз.

**Шәүкәт МӘҖИТОВ.**
Төмән өлкәсе, Ноябрьск шәһәре.

***

Мин шагыйрь Зиннур Мансуровның «Юлын белгән арымас» дигән китабын кат-кат укып чыктым. Энҗе сүзләр һәм тирән эчтәлек шагыйрьнең уй-фикерләрен түкми-чәчми күңелемә салдылар... Бик тә гыйбрәтле мисаллар, күренешләр аша күңелгә күпме хәзинә сала язучы. Киләчәккә өмет уята, рухыңны хәрәкәткә өнди. Мин авторның сүзләре, әйткән фикерләре белән килешәм һәм хуплыйм. Ул халкыбыз язмышын кайгыртып яза. Аның миңа бигрәк тә Габдулла Тукай һәм бүгенге көн шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатлары турында тирән анализ белән, бар кешегә аңлаешлы итеп язган зур-зур мәкаләләре ошады. Сара Садыйкова, Марс Макаровлар турында әйткән фикерләре дә халык әйткән фикерләр сыман яңгырый. Мин З. Мансуровның үзен күреп белмәсәм дә, язган китабы буенча хөрмәтем артты аңа. Халыкка кирәк сүзне шулай турыдан ярып әйтүчеләр әлегә хәтле сирәк булды. Иҗади уңышлар, яңа кыюлыклар телим егеткә!

**Н. АЛМАЗ.**
Казан шәһәре.

## Шагыйрь Тукай бәете

Бисмиллаһи вә биллаһи, укыдык корбан гаетен,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз Тукай шагыйрь бәетен.
Тугыз йөз дә унөч елда, апрель икесендә,
Тукай мескен вафат булган Клячкин больнисында.

Ак келәтнең келәсен элә белми эләсең,
«Әҗәл» агай, син нишлисең, килә белми киләсең.

Ак келәтнең алдында калды минем җиләнем,
Егерме алтыда үлеп китте Тукай шагыйрь, сөйгәнем.

Тавык йөри кырлашып, кызлар йөри җырлашып,
Безнең өчен җыр язды тырышып та тырмашып.

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз боты озынга күрә,
Без Тукайны сөябез җыры матурга күрә.

Ызба артында алмагач, кисеп җиргә салмагач,
Җырла, моңай, саргай, үл, матур Тукай калмагач.

Мәсҗет башы манир-манир, манир саен бер талир,
Безне ятим калдырып, китте безнең шәп шагыйрь.

Тукай абзый, яшь чагыңнан белә идек без сине,
Онытырлар дип уйлама, онытмабыз без сине.

Алма бирдем — алмадың, тәңкә бирдем — сайладың,
Безнең матур дөньябызда ник ике-өч ел калмадың?

Тауга менсәм — тау биек, түбән төшсәм — тамырлык,
Тукаен җуйган яшьләргә ходай бирсен сабырлык.

Актыр җиләнем минем, күктер җиләнем минем,
Каберендә тыныч йокла, җаным, шагыйрем минем.

Татар халык иҗаты. Бәетләр.— Казан, 1983, 37 б.

## شاعر توقای بەیتی

بِسْمِ اللّٰهِ وَبِاللّٰهِ، اوقودق قربان عەیتن،
بز ئەیتەبز، سز تڭلاغز توقای شاعر بەیتن.

توغز یوز دە اون اوچ یلدا، آپریل ایکیسندە،
توقای مسکن وفات بولغان کلاچکین بولنیسندا.

آق کلەتنڭ کلەسن آلە بلمی آلەسڭ،
«ئەجەل» آغای، سین نیشلیسڭ، کیلە بلمی کیلەسڭ.

آق کله‌تنك آلدندا قالدی مینم جیله‌نم .
یگرمی آلتیدا اولوپ کیتتی توقای شاعر، سویگه‌نم.

تاوق یوری قرلاشوپ. قزلار یوری جرلاشوپ ،
بزنك اوچون جر یازدی ترشوپ تا ترماشوپ.

یوگوره اورده‌ك. یوگوره قاز بوتی اوزونغا کوره ،
بز توقاینی سویه بز جری ماتورغا کوره .

ئز با آرتندا آلماغاچ . کیسوپ جیرگه سالماغاچ ،
جرلا ، موگای ، سارغای ، اول . ماتور توقای قالماغاچ .

مسجد باشی مانیر- مانیر ، مانیر ساین بر تالیر .
بزنی یه‌تیم قالدروپ. کیتتی بزنك شه‌پ شاعر.

توقای آبزی. یه‌ش چاغکنان بله ایدك بز سینی ،
اونوتورلار دیپ اویلاما . اونوتما بز بز سینی .

آلما بیردم - آلمادك . ته‌گکه بیردم - سایلادك ،
بزنك ماتور دنیا بزدانیك ایکی-اوچ یل قالمادك ؟

تاوغا منسه‌م - تاو بییك . توبه‌ن توشسه‌م - تامرلق ،
توقاین جویغان یه‌شله‌رگه خدای بیرسن سابرلق .

آقتر جیله‌نم مینم . کوکتر جیله‌نم مینم ،
قبرکده تینچ یوقلا ، جانم ، شاعریم مینم .

*Текстны журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

## Таһир Нурмөхәммәтовка — 60 яшь



Таһир Мирзагаллә м улы Нурмөхәммәтов 1930 елның 14 апрелендә Казахстанның Семипалатинск шәһәрендә тегүче гаиләсендә туган. Соңрак аның әти-әнисе туган ягына, Казанга кайта. Таһир урта мәктәптә белем ала. 1949—1953 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, Татарстан китап нәшриятында эшли башлый.

Т. Нурмөхәммәтов — әдәби тәрҗемә жанрында эшләүче автор. Аның беренче тәрҗемә китабы 1955 елда дөнья күрә. Хәзер ул — ике дистәгә якын әсәрне татарча яңгыраткан тәҗрибәле тәрҗемә остасы. А. Рыбаковның «Хәнҗәр» һәм «Бакыр кош», С. Җамалның «Кара чәчкәләр», Н. Гюнтекнең «Чалы кошы», Р. Фраерманның «Кыргый эт яки беренче мәхәббәт турында хикәят», Г. Троепольскиның «Акбай коракола к» һ. б. әсәрләр аның тәрҗемәсендә татарча дөнья күрделәр. Шулай ук ул бүгенге рус язучыларының да күп санлы повестьларын тәрҗемә итте.

Т. Нурмөхәммәтов — 1973 елдан бирле СССР Язучылар союзы члены.

Татарстан Язучылар союзы һәм «Казан утлары» редакциясе юбилярны кайнар котлый, аңа ныклы сәламәтлек һәм иҗат уңышлары тели!

---

# *Безнең календарь*

Әдәби тәнкыйтьче Илдус Габделгани улы Ахунҗанов 1930 елның 23 апрелендә Ижевск шәһәрендә туган. Илдусның балачагы Бөек Ватан сугышының кырыс елларына туры килә. Шул чордагы һәрбер яшүсмер кебек, ул да хезмәт чыныгуы уза. Ижевскидагы урта мәктәпне тәмамлагач, 1948 елда Казанга килә һәм университетның тарих-филология факультетына укырга керә. Икенче-өченче курсларда укыганда үзе дә каләм тибрәтә башлый. Күренекле әдәби тәнкыйтьче Гази Кашшаф аны «Совет әдәбияты» журналына эшкә тарта. 1953—1958 елларда ул шушы журналның тәнкыйть бүлегендә эшли. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләре турында тирән эчтәлекле, оригиналь фикерле мәкаләләр яза. Бер үк вакытта дөнья әдәбияты һәм рус классик язучыларының иҗатына багышланган мәкаләләр дә бастыра. 1958—1964 елларда И. Ахунҗанов Татарстан радиосында, телевидениедә һәм Казан хроникаль фильмнар студиясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Аннары, каты авыру сәбәпле, аның исеме шактый еллар күренми тора. Җитмешенче елларда ул Татарстан газета-журналларында һәм үзәк матбугатта күп кенә мәкаләләр бастыра. Бу хезмәтләре аның иҗади яктан тагын да үсүе турында сөйли. 1978 елда Татарстан китап нәшриятында И. Ахунҗановның «Художник һәм аның сүзе» дигән китабы дөнья күрә.

Илдус Ахунҗанов — 1979 елдан СССР Язучылар союзы члены иде. 1990 елның 18 мартында вафат булды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

22 февральдә язучыларның ачык партия җыелышында А. Кожевников иҗаты тикшерелде һәм сайлау кампаниясенең барышы турында зур сөйләшү булды. Фикер алышуларда Р. Хәмид, И. Ильялова, А. Бадюгина, Н. Беляев, Р. Кәрами һ.б. катнашты.

Җыелышта язучыларның Татарстан АССР Югары Советына һәм КПССның Татарстан өлкә комитетына татар алфавитына үзгәрешләр кертүгә мөнәсәбәтләрен белдергән хат кабул ителде.

## ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

30 январьдан 1 февральгә кадәр Мәскәүдә тәрҗемәчеләрнең Дүртенче Бөтенсоюз киңәшмәсе булып узды. Анда Татарстаннан әдәби тәрҗемә өлкәсендә эшләүче язучылар Л. Хәмидуллин, С. Шәмси, Н. Вәлитова катнашты. К. Миңлебаев чыгыш ясады.

Киңәшмәдә сүз үзгәртеп кору заманында әдәби тәрҗемәнең әдәбиятлар арасында бәйләнешләр урнаштыру, милли культураны баету, аны бөтендөнья мәдәнияте белән бәйләүдә тоткан урыны турында барды.

## «ВАТАН» ҖӘМГЫЯТЕ

7 февральдә Казанда В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалы конференция залында «Ватан» җәмгыятенең Татарстан бүлеген оештыру җыелышы булды. Җәмгыять чит илләрдәге милләттәшләребез белән мәдәни-экономик һәм башка шундый бәйләнешләр урнаштыру өчен төзелде. Җәмгыятьнең президиумы рәисе — академик Мирза Исмәгыйль улы Мәхмутов, аның урынбасары Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдинов. Ватан җәмгыятенең төп штабы — Казанның Пушкин урамындагы 42 йортта, Мемориал бинасында. Җәмгыять үзенә нигез салучы оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләрнең матди ярдәмендә эшли. Акча күчерү өчен аның счеты: Татарстан коммерческий банк, 161501, ОПЕР ТРУ АПБ, Татарское общество «Ватан», учредительный или спонсорный взнос.

## Н. ИСӘНБӘТНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

2 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле галим, драматург, шагыйрь, Татарстанның халык язучысы Нәкый Исәнбәткә 90 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Аны кереш сүз белән ТАССР культура министры М. М. Таишев ачты.

Юбилярның тормыш юлы һәм иҗаты турында галим һәм язучы Нурмөхәммәт Хисамов сөйләде.

Юбилярны В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты проректоры профессор М. Г. Госманов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, СССРның халык артисты М. Х. Сәлимҗанов, РСФСР культура фондының Татарстан бүлеге рәисе, язучы Г. А. Ахунов, Башкортстан АССРдан килгән кунаклар: РСФСРның атказанган, БАССРның халык артистлары Фәридә Кудашева, Бәхти Гайсин, әдипнең авылдашы, врач Сабит Фәйзуллин, шагыйрь Сафуан Әлибаев, Үзбәкстаннан килгән язучы Ваһап Рузематов, Татар иҗтимагый үзәге рәисе М. А. Мөлеков, Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе Р. С. Мөхәммәдиев котладылар. Әдәбият галиме, профессор И. Нуруллин Татарстан халык язучысы Әмирхан Еникинең юбилярны котлап язган хатын укыды (авыру булганлыктан, Ә. Еники кичәгә үзе килә алмаган).

Аннары нигездә Нәкый Исәнбәт әсәрләреннән торган концерт күрсәтелде.

Әдәби-музыкаль кичәдә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин, ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире Р. М. Харисов катнаштылар.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘКЛӘРЕ ХӘБӘРЛӘРЕ

### Ленинград

Ленинградтагы татар мәдәнияте үзәге «Җомга кичәләре» оештыра башлады. Алар «Восток» культура йортындагы кафеда уза. А. Юзиев җитәкчелегендәге фольклор ансамбле, М. Шәңгәрәев триосы (аккордеон, кубыз һәм скрипка), пианист Н. Арсланов, Р. Хәйруллин, И. Ким һәм Р. Фаниннарның гитаралар, М. Сәйфетдинов (курай) һәм И. Мифтахетдинов (баян) дуэтлары, шулай ук башка һәвәскәрләрнең чыгышлары кичәнең бизәгенә әйләнә.

Кичәләр «Туган тел»не күмәкләп җырлау белән тәмамлана.

### Балхаш

Казахстандагы Җизказган өлкәсенең Балхаш шәһәрендә «Дуслык» дигән татар культура-агарту җәмгыяте оештырылды. Җәмгыять концертлар, халык иҗаты күргәзмәләре һәм башка чаралар оештыруны күздә тота. «Дуслык» членнары туган телне, фольклор һәм гореф-гадәт, йолаларны өйрәнү өчен китаплар җыялар.

### Воркута

Шахтерлар һәм төзүчеләр культура йортында «Яшьлек ялкыны» дигән татар ансамбле эшли иде. Күптән түгел тагын бер

татар үзешчән сәнгате төркеме барлыкка килде — «Заполярная» шахтасы шахтеры В. Сәетов, балалар бакчасы тәрбиячесе Г. Якупова Воргашор поселогы культура йортында «Дуслык» исемле группа оештырдылар.

«Дуслык» үткәргән кичәләрдә татар җырлары яңгырый, биюләр башкарыла, татар китаплары һәм газета-журналлары күргәзмәләре оештырыла.

## Н. ДӘҮЛИ ИСТӘЛЕГЕНӘ

12-15 февральдә Әлки районының мәдәни тормышында истәлекле вакыйга булды. Язучы Нәби Дәүлинең соңгы васыятен үтәп, аның авылдашы язучы С. Маннапов белән шагыйрь Ж. Дәрзаман әдипнең китапханәсен, кайбер шәхси әйберләрен Алпар урта мәктәбенә тапшырдылар.

Район авыллары һәм мәктәпләрендә Нәби Дәүлинең якты истәлегенә багышланган әдәби атналык узды.

## ЯҢА ФАКУЛЬТЕТ

15 февральдә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының гыйльми советы журналистика факультетын оештыру турында карар кабул итте.

Факультет киләсе уку елыннан эшли башлаячак. Әлегә көндезге бүлеккә 50, читтән торып уку бүлегенә егерме биш кеше кабул ителәчәк.

Факультетта өч кафедра, шул исәптән татар журналистикасы кафедрасы төзеләчәк.

## МУЗЕЙ ЗАЛЫ АЧЫЛДЫ

Республика Халык иҗаты йортының оешуына (ул хәзер Халык иҗаты һәм культура-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәге дип атала) 50 ел тулды. Менә ярты гасыр инде әлеге үзәк үзешчән сәнгать көчләрен барлап, халык иҗатының төрле тармакларын үстерүдә сәләтле кешеләргә булышлык итеп, фольклорыбызны пропагандалауга зур өлеш кертеп килә.

Каюм Насыйри йортында (Париж Коммунасы урамы) әлеге юбилейга багышлап ачылган күргәзмәдә халык иҗатының күптөрле үрнәкләрен күрергә мөмкин. Аны ТАССРның һәм РСФСРның атказанган культура хезмәткәре Р. Сабирҗанов оештырды.

Шушы ук йортта композитор К. Хөснуллин җитәкләгән халык иҗаты кабинеты эшли. Беренче катта исә музыка, кино һәм фото бүлекләре бар.

## И. САЛАХОВ — ПОЧЕТЛЫ СТУДЕНТ

«Колыма хикәяләре» китабының авторы Ибраһим Салахов, утызынчы елларда Күкчәтау якларыннан Казанга килеп, башта педагогия техникумында, соңыннан педагогия институтында укый. Өченче курста чагында Ялтада авырып ятучы өлкән язучы Галимҗан Ибраһимовка Татарстан язучыларыннан сәлам һәм котлау хаты илткәне өчен ул кулга алына...

Моңа инде ярты гасырдан артык вакыт узды. Биш дистә елдан соң Ибраһим абый үзенең туган институтында килде, бүгенге студентлар белән очрашты. Үзенең башыннан үткән гаять аянычлы хәлләрне сөйләде, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең үткәне турындагы фикерләре белән уртаклашты, яшьләрнең күпсанлы сорауларына җавап бирде.

Булачак педагоглар И. Салаховны институтның почетлы студенты итеп кабул иттеләр.

## КОМПОЗИТОРГА БАГЫШЛАП

17 февральдә Татарстан Композиторлар союзы бинасында РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, композитор Җәүдәт Фәйзинең тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Истәлек концерт рәвешендә оештырылган әлеге кичәне музыка белгече З. Хәйруллина алып барды. Ул һәм композиторның туганнары, аны якыннан белгән, аралашып яшәгән иптәшләр Ж. Фәйзи турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар. Республикабызның танылган артистлары — У. Әлмиев, З. Хисмәтуллина, Э. Җәләлетдинов, К. Хәйретдинова композитор тарафыннан төрле елларда иҗат ителгән әсәрләрне башкардылар.

## ЯҢА ГАЗЕТА

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында узган ел татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре факультеты ачылган иде. Быел 1 гыйнварьдан биредә татар телендә «Ленинчы» күп тиражлы газетасы чыга башлады.

Газетаның беренче санында «Студент проблема куя» рубрикасы белән тулай торак һәм анда яшәү шартларын яхшырту мәсьәләләре яктыртыла, уку алдынгыларының фоторәсемнәре, университет проректоры, профессор М. Г. Госманов белән югары уку йортының үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында интервью, булачак сайлаулар уңаеннан депутатлыкка кандидатлар белән әңгәмә, бәхәсле темаларны үз эченә алган башка язмалар урнаштырылган.

Газетада шулай ук әдәбият һәм сәнгатькә багышланган «Илһам» сәхифәсе даими урын алачак.

## МАКТАУЛЫ БҮЛӘК

Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1990 ел, 1 февраль Указы нигезендә Совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен язучы Нәкый Сираҗи улы Исәнбәт Татарстан АССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# ИЗГЕ ТАШЛАР СЕРЕ

Кайчандыр Кремль янында бик зур һәм данлыклы сәүдә үзәге булган. Хәтта үз вакытында ике катлы Сәүдә рәте биналары да калкып чыккан (хәзер шуларның бер өлешендә Татарстан дәүләт музее урнашкан). Әмма Пугачевның Казанны алу көннәрендә, бигрәк тә 1797 елгы зур янгыннан соң, сәүдә үзәгеннән бер нәрсә дә калмый диярлек.

1880 елда биредә яңа бинаның нигезен салу башлана. Тышлыкның беренче битендә китерелгән кабер ташы шул вакытта табыла да инде. Кайберәүләр бу ташны 1793 елда табылган дип белдерәләр. Ләкин шуны әйтергә мөмкин: хәзерге Ленин һәм Чернышевский урамнары кисешкән урында кайчандыр борынгы каберлек булган һәм бу таш та шунда куелган тарихи истәлек.

Бәхеткә күрә, ташны табучыларга вәхшилек чире йокмаган була һәм ул Кабан күле буендагы Беренче мәчеткә (Мәрҗани мәчете) озатыла. Ш. Мәрҗанинең язуына караганда, ташны әүвәл сөннәт бүлмәсендә саклыйлар, аннан соң аны мәчет диварына беркетәләр. Нәрсә язылган соң ул ташта?

*1. Олуг вә шөһрәтле Аллаһе тәгалә әйтте:*
*2. Мондагы (җирдәге) һәммә нәрсә фани, калыр тик*
*3. бөеклек вә хөрмәт иясе Тәңренең үзе генә.*
*4. Тарих тугыз йөз утыз*
*5. алтыда Мөһәммәдшаһ бәкнең улы Мөхәммәдгали бәк*
*6. зөлкагыйдә аенда кафер кулыннан шәһид (ягъни үтерелгән).*

Уң кырында: *Пәйгамбәребез, галәйһес-сәләм, әйтте: бу тормыш — бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан.*

Сул кырында: *Пәйгамбәребез, галәйһес-сәләм, әйтте:...* (сүзләр бозылган).

Арткы ягында: *Бу лухны (ташны) улы Тәңреколы бәк бина кылды.*

Күренә ки, Мөхәммәдгали бәк 1530 елның 10 июлендә вафат булган һәм аны үтерүче кеше мөселман түгел. Бу ташъязмада бер гаиләнең өч кешесенең исеме китерелгән һәм аларның барысы да бәкләр, ягъни югары сыйныф вәкилләре. Бераз ераграк тарихка күз салсак, борынгы рун һәм уйгыр язмаларында «бәк» дип хөкемдарларны, дәүләт башлыкларын атаганнар. Соңрак төрки халыкларда гаскәр башлыкларына, дружина җитәкчеләренә, аерым өлкә идарәчеләренә «бәк» титулы бирелә башлаган. Болгар чоры кабер ташларындагы язуларга караганда, Идел буе Болгарстанында өлкәләрнең һәм шәһәрләрнең башлыклары да бәкләр булырга тиеш.

XX гасырда томанарак кешеләр, кабер ташларын дин белән генә бәйләп, «атеистик» теләкләреннән чыгып, ташларны юк итәргә тырышканнар. Аларның тарихы һәм тел документы гына түгел, сәнгать үрнәге икәнлеген дә тоймаганнар. Бу таш та — XVI йөзнең беренче яртысында ташларны бизәү сәнгатенең бер үрнәге. Болгар ташларыннан аермалы буларак, бу истәлекләрдә бизәкләр аерым-аерым гына эшләнмиләр, ә катлаулы схемага нигезләнеп, төрле чәчәкләрдән, үсемлек өлешләреннән үзенчәлекле гөлләмәләр, бакча хасил ителә. Аларда нәфис сәнгатькә күчү, ташка язылган коры һәм күңелсез хәбәрләрне, сагыш тойгыларын тере чәчәкләр итәргә тырышу сизелә.

**Фәрид ХӘКИМҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Гариф Ахунов.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)